Д О К Л А Д

О ДЕЯТЕЛЬНОСТИ УПОЛНОМОЧЕННОГО ПО ПРАВАМ РЕБЕНКА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН И СОБЛЮДЕНИИ ПРАВ И ЗАКОННЫХ ИНТЕРЕСОВ РЕБЕНКА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН В 2017 ГОДУ

КАЗАНЬ – 2018

ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ 5

2017 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛА ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ ҺӘМ АНЫҢ АППАРАТЫНЫҢ ЭШЧӘНЛЕГЕ

1.1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшчәнлеге 8

1.2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге 16

1.3. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар мәнфәгатьләрендә законнарны камилләштерүдә катнашуы 22

1.4. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашуы 29

1.5. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең нотыклары 32

1.6. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эш визитлары 33

1.7. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координацион комитет эшчәнлеге 36

1.8. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында Гаиләдән балаларны алу практикасын анализлау буенча эшче төркем эшчәнлеге 39

1.9. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең проект эшчәнлеге 40

1.10. Балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерү эшчәнлеге 53

1.11. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре институты эшчәнлеге 59

2017 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛАЛАР ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕН ТӘЭМИН ИТҮНЕҢ ГОМУМИ МОНИТОРИНГЫ

2.1. 2017 елда Татарстан Республикасында төп демографик тенденцияләр 68

2.2. 2017 елда Татарстан Республикасында балаларның хокукларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән төп гамәлләр һәм чаралар 73

2.3. 2017 елда халыкара, федераль һәм республика законнарындагы бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре өлкәсенә караган яңалыкларга күзәтү 82

2017 ЕЛДА ТОРМЫШ КӨНКҮРЕШЕНЕҢ ТӨП ӨЛКӘЛӘРЕНДӘ БАЛА ХОКУКЛАРЫНЫҢ САКЛАНУЫ

3.1. 2017 елда гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлауга нигезләнгән Татарстан Республикасында балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше өлкәсендәге проблемалы мәсьәләләрнең гомуми мониторингы 92

3.2. Баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклануга һәм иминлеккә хокукын тәэмин итү 103

3.2.1. Балаларның тышкы сәбәпләр (бәхетсезлек очраклары, суицидлар, җинаятьләр) аркасында үлүен анализлау 103

3.2.2. Обеспечение права на защиту от жестокого обращения и насилия 122

3.2.3. Тискәре мәгълүматтан яклау хокукын тәэмин итү 129

3.3. Баланың сәламәтлеген саклауга һәм сәламәт үсешкә хокукын тәэмин итү 139

3.3.1. Балалар үлеменә гомуми анализ 140

3.3.2.Балалар сәламәтлеге торышына гомуми анализ 142

3.3.3. Балаларның сәламәтлеккә хокукларын тәэмин итүнең проблемалы аерым мәсьәләләре 152

3.3.4. Балаларның ялы һәм аларны савыктыру 168

3.4. Баланың яшәү һәм гаиләдә тәрбияләнү хокукын үтәү 177

3.4.1. Гаиләдә иминлек булмау проблемалары 177

3.4.2. Социаль ятимлек проблемалары 189

3.4.3. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру 193

3.4.4. Баланың гаиләгә хокукын гамәлгә ашыру проблемалары һәм, гаиләдә каршылыклар булганда, гаилә эчендәге бәйләнешләр 201

3.5. Баланың белем алу өлкәсендә хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү 207

3.5.1. Мәктәпкәчә белем 207

3.5.2. Гомуми белем бирү 212

3.5.3. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балаларга белем бирү 230

3.6. Социаль тәэмин ителешкә хокукны гамәлгә ашыру 242

3.7. Баланың торак һәм башка мөлкәти хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү 248

3.7.1. Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын тәэмин итү 248

3.7.2. Күпбалалы гаиләләрнең торак хокукларын тәэмин итү 252

3.7.3. Инвалид балалары булган гаиләләрнең торак хокукларын үтәү 256

3.7.4. Балигъ булмаганнарның башка мөлкәти хокукларын яклау 258

ЙОМГАКЛАУ 261

КЕРЕШ

1989 елның 20 ноябрендә БМОның Генераль Ассамблеясы тарафыннан Бала хокуклары турында конвенция кабул ителүгә һәм аны алга таба ратификацияләүгә бәйле рәвештә, планетаның барлык илләрендә диярлек дөньякүләм җәмәгатьчелек балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен иң югары дәрәҗәдә тәэмин итүне өстен итеп куйды. Конвенция нигезләмәләре балалар хокукын тәэмин итә торган дүрт төп принципка бүленә: яшәргә тырышу, үсеш, яклану һәм иҗтимагый тормышта актив катнашуны тәэмин итү.

Татарстан Республикасында балаларның һәм һәр аерым баланың хокукларын, ирекләрен һәм мәнфәгатьләрен яклау максатында бала хокукларын яклау буенча махсус дәүләт институты – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гамәлгә куелды. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үз гамәлләре белән, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары компетенциясен алыштырмыйча, баланың бозылган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауны һәм торгызуны тәэмин итә.

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – Закон) 3 статьясында каралган Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү буенча эшләрнең торышына анализ ясау кысаларында, Законның 13 статьясы нигезендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (алга таба – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил) ел саен үз эшчәнлеге турында һәм Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше хакында доклад әзерли.

Әлеге доклад Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан әзерләнгән еллык докладларның сигезенчесе, ул 2017 ел йомгакларына багышлана. Докладта узган елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты эшчәнлегенең төп юнәлешләре тасвирлана, шулай ук БМОның Бала хокуклары турында конвенциясендә һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының бала хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре турында гамәлдәге законнарында гарантияләнгән бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү эшләренең торышына бәйсез анализ ясала һәм бәя бирелә.

Доклад, гадәттәгечә, рәсми дәүләт статистикасы белешмәләрен, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнарыннан, республиканың муниципаль районнарыннан һәм шәһәр округларыннан, җирле үзидарә органнарыннан соратып алынган мәгълүмати-аналитика материалларын, гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен, республиканың төрле балалар учреждениеләрендә үткәрелгән тикшерүләр һәм аларга барып кайтулар нәтиҗәләрен, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашында балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча аерым мәсьәләләр каралган төрле координацион һәм киңәшмә органнар эше, киңәшмәләр, очрашулар, конференцияләр, «түгәрәк өстәлләр» барышында Вәкаләтле вәкил алган мәгълүматларны өйрәнүгә, анализлауга һәм гомумиләштерүгә нигезләнде. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты эшчәнлегендә аның үзе катнашында тикшерелгән һәм анализланган мәгълүматлар күрсәтелә.

Доклад структурасы керештән, өч бүлектән һәм йомгаклау өлешеннән тора.

Беренче бүлектә 2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең төп юнәлешләре турында мәгълүмат бирелә.

Икенче бүлектә Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлешенә гомуми мониторинг ясала. Бу бүлектә Татарстан Республикасы территориясендә 2017 елда бала хокукларының үтәлешенә гомуми бәя бирелә, анда балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүне яхшырту максатларында республикада күрелгән чаралар, ясалган адымнар, башлангычлар, төп демографик тенденцияләр күрсәтелә, федераль һәм республика законнарындагы балалар яшәешенә турыдан-туры кагылышлы төрле аспектларга йогынты ясый торган яңалыклар анализлана.

Өченче бүлектә Татарстан Республикасында балалар тормышының төп өлкәләрендә балалар хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлешенә кагылышлы вәзгыятькә анализ ясала. Биредә төп игътибар республикада балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруның Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә үз эшчәнлеге барышында мәгълүм булган проблемалы мәсьәләләрен тасвирлауга бирелә. Мондый тасвирлама Бала хокуклары турында БМО Конвенциясендә беркетелгән төп хокукларның түбәндәге төрләре буенча бирелә:

баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклануга, иминлеккә хокукын тәэмин итү;

баланың сәламәтлеген саклауга һәм сәламәт үсешкә хокукларын тәэмин итү;

баланың гаиләдә яшәүгә һәм тәрбияләнүгә хокукларын тәэмин итү;

баланың белем өлкәсендә хокукларын тәэмин итү;

баланың социаль тәэминатка хокукларын тәэмин итү;

баланың тораккa һәм мөлкәткә хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү.

Әлеге бүлектә хокуклары бозылу ихтималы булган төркемнәргә кергән балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә аерым игътибар бирелде. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дөрес мәгълүмати-аналитик белешмәләр биргән һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең үзенә йөкләнгән бурычларын үтәүдә ярдәм иткән өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, республика муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә үзенең рәхмәтен белдерә.

Доклад Законның 13 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Татарстан Республикасы Прокурорына җибәрелә.

2017 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛА ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ ҺӘМ АНЫҢ АППАРАТЫНЫҢ ЭШЧӘНЛЕГЕ

БҮЛЕК 1

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең һәм аның Аппаратының эшчәнлеге «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (алга таба – Закон) билгеләнгән бурычларны һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга юнәлдерелә.

Аның эшчәнлегенең төп юнәлешләре түбәндәгеләр була:

контроль-күзәтчелек эшчәнлеге (гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау, тиешле органнарның һәм учреждениеләрнең эшчәнлеген тикшерү, суд процессларында катнашу һәм башкалар);


экспертиза-аналитика эшчәнлеге (бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләре буенча гамәлдәге законнарны, бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау механизмнарын камилләштерүгә ярдәм итү, Татарстан Республикасында бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлешенә анализ ясау, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлегенә ярдәм күрсәтү, балалар мәнфәгатьләрендә Россия төбәкләре арасындагы һәм халыкара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру һәм башкалар);

агарту эшчәнлеге, моңа бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча халыкны, шул исәптән балаларны, хокукый агарту, консультация ярдәме күрсәтү керә.

Гомумән алганда, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында документлар әйләнеше Татарстан Республикасының Бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында башкарыла (алга таба – БВЭДӘС). 2017 елда документлар әйләнешенең гомуми күләме 7 258 берәмлек тәшкил итте.

1 нче диаграмма

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында гомуми документлар әйләнеше




1.1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшчәнлеге

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен дәүләт яклавы гарантияләрен һәм тәэмин итү һәм балигъ булмаганнарның бозылган хокукларын торгызу эшчәнлегендә иң мөһим бурычларның берсе.

2017 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә 1 938 мөрәҗәгать керде, шулар буенча 200ләп проблема ачыкланды. Мөрәҗәгатьләр 2016 елга караганда 209га (11%ка) күбрәк.

2 нче диаграмма

2011-2016 елларда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрнең динамикасы




Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләренә гражданнардан 218 мөрәҗәгать керде, алар 15 район һәм Казан шәһәре округларында 150 кабул итү барышында каралды. Шулай итеп, республикада бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институты адресына гражданнардан 2 156 мөрәҗәгать керде.

2017 ел дәвамында гражданнарның **мөрәҗәгать итү динамикасы** мониторин– гыннан күренгәнчә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каравына гражданнардан ай саен уртача 160 мөрәҗәгать керде (2016 елда – 144). Шул ук вакытта шикаятьләр белән эшләгәндә Аппаратның бер хезмәткәренә һәр айда уртача 50 мөрәҗәгать туры килә.

3 нче диаграмма

2017 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнар мөрәҗәгатьләре динамикасы



Гражданнарның Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә квалификацияле ярдәм, яклау, консультация алу өчен мөрәҗәгать итү мөмкинлеген арттыру максатында Аппаратта **граждан мөрәҗәгатьләре белән эш итүнең төрле рәвешләре һәм ысуллары** оештырылды.

2017 елда даими рәвештә Хокукый ярдәм көннәре һәм кайнар линияләр оештырыла башлады, җәмәгать ярдәмчеләре институты эшли башлады.

4 нче диаграмма

Гражданнарның Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итү тәртибе




Гражданнарның мөрәҗәгать итү рәвешен **анализлаудан** күренгәнчә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә һәм аның Аппаратына телдән мөрәҗәгать итүчеләр артта бар: алар күбрәк шәхсән очрашуга киләләр йә телефон аша мөрәҗәгать итәләр. 2017 елдагы гомуми мөрәҗәгатьләрдән 978 (50,5%) язмача кекрде, 960 (49,5%) – телдән. Язма мөрәҗәгатьләр 2017 елда 2016 ел белән чагыштырганда 11%ка кимеде (2016 елда язма мөрәҗәгатьләр 61,4 % иде), ә телдән мөрәҗәгать итүче гражданнар саны артты.

Язма мөрәҗәгатьләрнең кимүе Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хезмәткәрләре тарафыннан телефон аша йә шәхсән очрашу барышында консультатив яки аңлату эшләре алып баруның артуы белән аңлатыла, республикада яшәүчеләрнең күбесе үз проблемаларын Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә язмача мөрәҗәгать итмичә дә хәл итә алды.

5 нче диаграмма

2013-2017 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр динамикасы *(мөрәҗәгать итү рәвеше буенча)*




Язма мөрәҗәгатьләрнең керү ысулына килгәндә, 2017 елда да 2016 елдагы кебек үк хатларны электрон элемтә чаралары аша алуга өстенлек бирелде. Мәсәлән, узган чорда 978 язма мөрәҗәгатьтән бары тик 303 (31%) мөрәҗәгать (2016 елда – 277 (26,1%) кәгазьдә алынды, калган 675 мөрәҗәгать (69 %) (2016 елда – 73,9 %) – электрон элемтә чаралары аркылы.

Кәгазьдә алынган 303 мөрәҗәгатьтән 64 (21%) – Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты аша керде, 17 (5,6%) – Россия Федерациясе башка төбәкләренең Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләре аша.

Телдән мөрәҗәгатьләрнең керү ысулына килгәндә, монда күпчелек мөрәҗәгать (59,4% яки 570 мөрәҗәгать), гадәттәгечә, шәхси кабул итүләр барышында керде, калган 390 мөрәҗәгать (40,6 %) телефон аша алынды.


6 нчы диаграмма

2013-2017 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр динамикасы *(керү ысулы буенча)*



7 нче диаграмма

2013-2017 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә телдән кергән мөрәҗәгатьләр динамикасы *(керү ысулы буенча)*




2017 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хезмәте тарафыннан 110 граждан кабул ителде, шуннан 59ы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан шәхсән кабул ителде, 51 – Аппарат хезмәткәрләре тарафыннан.

Шәхсән кабул итү кысаларында барысы 570 граждан кабул ителде: 374 кеше (65,6%) Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итте, тагын 196 кеше Аппарат белгечләреннән ярдәм һәм консультация алды.

8 нче диаграмма

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Аппарат хезмәткәрләре тарафыннан шәхсән кабул ителгән гражданнар саны



Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан турыдан-туры 59 кеше кабул ителде, шуннан:

26 гражданны ул Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында үзе генә кабул итте;

31 граждан федераль һәм республика дәүләт хакимияте органнары, иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре һәм вәкилләре тарафыннан бергә кабул ителде;


23 – республиканың муниципаль районнарына, шәһәр округларпына чыкканда кабул ителде;

5 – учреждениеләрдә кабул ителде.

1 кабул итү Россия Федерациясе президентының Иҗтимагый кабул итү урынында булды.

9 нчы диаграмма

2013 – 2017 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан шәхсән кабул итү




Гражданнарның максималь дәрәҗәдә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән юридик консультация алуын һәм аның тарафыннан яклану булдыруын тәэмин итү максатларында 2017 елда республиканың муниципаль районнарына һәм шәһәр округларын **чыгып кабул итүләр** оештырылды. Мондый күчмә кабул итүләр ел саен раслана торган график буенча планлы тәртиптә башкарылды.

2017 елда Республиканың 22 муниципаль районында (шәһәр округларында) 24 күчмә кабул итүләр булды, болар: Зеленодольск, Минзәлә, Бөгелмә, Чистай, Азнакай, Әлмәт, Лениногорск, Нурлат, Мөслим, Баулы, Сарман, Кама Тамагы, Лаеш, Буа, Түбән Кама, Әлки, Балтач, Тәтеш, Биектау муниципаль районнарында, Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе, Совет, Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнарында һәм Чаллы шәһәрендә оештырылды.

Карта

2011 – 2017 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең муниципаль районнарда (шәһәр округларында) күчмә кабул итүләре



Шулай итеп, 2017 ел дәвамында гражданнарны күчмә кабул итүләр республика муниципаль районарының яртысында (45тән 23ендә) һәм шәһәр округларында оештырылды, шундый очрашуларда 211 граждан кабул ителде.

2017 ел гражданнар проблемаларын **уртак кабул итүләрдә** хәл итүгә ихтыяҗ булулын раслады. 2017 елда 31 уртак кабул итү очрагы булды (2016 елда – 26):



Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле С.Х.Сабурская белән Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында (07.02.2017);




Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе җитәкчесе Т.П.Ларионова белән Зеленодольск муниципаль районында (02.03.2017);



Татарстан Республикасы Дәүләт Советы ның Социаль сәясәт комитеты рәисе урынбасары, «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе әгъзасы Т.В.Воропаева белән Әлки (14.11.2017), Балтач (28.11.2017) һәм Тәтеш (05.12.2017) муниципаль районнарында;



Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе әгъзасы А.Х.Мезикова белән Түбән Кама муниципаль районында (07.11.2017);



Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасары О.А.Дәминов белән Лениногорск (27.06.2017), Мөслим (10.07.2017) һәм Лаеш (10.10.2017) муниципаль районнарында;




Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасары Ю.И.Наумова белән Сарман муниципаль районында (07.09.2017);



Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы Тикшерү идарәсе җитәкчесе урынбасары В.Н.Циома белән Мөслим (10.07.2017), Лаеш (10.10.2017) муниципаль районнарында һәм Чаллы шәһәрендә (19.09.2017);



Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе җитәкчесе Р.М.Ильясов белән Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында (31.10.2017);



«Татарстан Республикасы буенча Баш медико-социаль экспертиза» Федераль казна учреждениесе җитәкчесе Р.Х.Низамов белән Чаллы шәһәрендә (19.09.2017), Лаеш (10.10.2017) һәм Биектау (19.12.2017) муниципаль районнарында ;



Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Белем бирү өлкәсендә күзәтчелек һәм департаменты җитәкчесе Г.З. Габдрахманова белән Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында (27.11.2017);



Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминләштерү фондының Татарстан Республикасы идарәсе төбәк бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары К.Ш.Фатыйхов белән Чаллы шәһәрендә (19.09.2017);



Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре И.Х.Гарифуллина белән Татарстан Республикасының 21 муниципаль районында һәм шәһәр округында;



Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды директоры А.М.Мифтахова белән Кама Тамагы (26.09.2017) һәм Түбән Кама (07.11.2017) муниципаль районнарында;



Казан шәһәр Думасы депутатлары белән Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе (12.09.2017), Совет (24.10.2017), Авиатөзелеш һәм Яңа Савин (21.10.2017) районнарында.

Шул ук вакытта гражданнарны уртак кабул итүләрнең күпчелеге (31 дән 21 республиканың муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында оештырылды. 2017 елда халыкны уртак кабул итүләрдә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә барысы 237 кеше мөрәҗәгать итте.

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан «Балалар мәсьәләсе» хокукый ярдәм көннәрен үткәрү гамәлгә кертелде, ул чарага балалар хокукларын тәэмин итү өлкәсендә аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы тармак министрлыклары һәм ведомстволары, хокук саклау органнары, прокуратура вәкилләре җәлеп ителде. Хокукый ярдәм көннәре 2017 елның 1 июненнән 25 октябрнә кадәр үткәрелде. Бу чаралар кысаларында гражданнардан 110 мәсьәлә буенча 66 мөрәҗәгать керде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләренең күпчелеге түбәндәге проблемаларга кагылышлы иде: торак, опека һәм попечительлек, ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү, мәктәптә укыту-тәрбияләү эшен оештыру, ой шартларында укыту, белем бирүдә катнашучылар арасындагы конфликтлы вәзгыятьләрне хәл итү, аерым фәннәрне укыту, медицина хезмәте күрсәтү, инвалид баланы дарулар белән тәэмин итү, инвалаид баланы карау чаралары белән тәэмин итү, балигъ булмаганнар файдасына мөлкәт бүлешү һәм алимент түләтү, күп балалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү, уңайлы мохит булдыру мәсьәләләре.





2017 елда шулай ук ике **кайнар телефон линиясе** эшли башлады, алар аша гражданнардан 123 мөрәҗәгать алынды.

2017 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнардан кергән барлык язма һәм телдән мөрәҗәгатьләр законнарда билгеләнгән тәртиптә каралды һәм алар буенча балаларның бозылган хокуклрын торгызу максатларында тиешле чаралар күрелде.

1.2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге түбәндәгеләр буенча тикшерү чаралары уздыруга юнәлдерелә:

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә ***гражданнардан кергән шикаятьләр*** буенча;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан теләсә кайсы оешманың, аларның оештырылу-хокукый рәвешләре һәм милек рәвешләре нинди булуга карамастан, һәм аларның вазыйфаи затларының эшчәнлеген алар тарафыннан бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тану һәм үтәү күзлегеннән чыгып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең **үз *инициативасы буенча;***

ведомствоара экспертлар төркемнәре составында;

бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу фактлары турында ***мәгълүмат керү буенча.***

Тикшерүләр, гадәттәгечә, урыннарга чыгып, экспертиза нигезендә һәм тиешле документларны өйрәнеп (докумнтар тикшерү) башкарыла. 2017 елда, урыннарга чыгып, барысы 125 тикшерү оештырылды һәм уздырылды.

Тикшерү эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча бала хокукларыһәм мәнфәгатьләрее бозылу турында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан барысы 89 бәяләмә чыгарылды һәм аларны бетерү һәм тагын булдырмас өчен чаралар күрелде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча тикшерүләр дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының, оешмаларының һәм вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата гражданнарның шикаятъләрен карау кысаларында үткәрелде. 2017 елда гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча 547 шикаять тикшерелде. 478 шикаять буенча тикшерүләр Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан башка компетентлы дәүләт органнары белән берлектә оештырылды:

123 тикшерү – федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнары белән берлектә (Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе белән, Суд приставлары Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе белән, Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы белән, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән, Россия Федерациясе Тикшерү идарәсенең Татарстан Республикасы буенча Тикшерү комитеты белән берлектә);

54 тикшерү – Татарстан Республикасы прокуратурасы органнары белән берлектә;

148 тикшерү – ведомство контроле тәртибендә республика дәүләт хакимияте органнары белән берлектә (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юллар хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясебелән берлектә);

173 – җирле үзидарә органнары белән берлектә (опеки һәм попечительлек органнары, мәгариф бүлекләре (идарәләре), балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре, торак сәясәте һәм коммуналь хуҗалык бүлекләре белән).

Гражданнар шикаятьләрен карау нәтиҗәләре буенча 49% очракта (265 шикаять буенча) мәсьәләләр уңай хәл ителде, балаларның бозылган хокуклары һәм мәнфәгатьләре торгызылды.

Мөрәҗәгатьләрдә күрсәтелгән фактларны күпьяклы һәм объектив өйрәнү максатларында шикаятьләрне тикшерү 324 очракта учреждениеләргә йә гражданнар гаиләләренә чыгып тикшерелде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен тикшерүләр нәтиҗәләре буенча тиешле органнаргаһәм вазыйфаи затларга бала хокуклары бозылу турында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 51 бәяләмә җибәрелде, шулардан:

6 – Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына;

8 – Дәүләт учреждениеләренә – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсенә;

1 – балалар йорты директоры адресына;

7 – гомуми белем бирү оешмалары директорлары адресына;

29 – республиканың муниципаль районнары һәм шәһәр округлары адресларына:

Актаныш муниципаль районы (1 бәяләмә),

Әтнә муниципаль районы (1 бәяләмә),
Баулы муниципаль районы (1 бәяләмә),
Буа муниципаль районы (1 бәяләмә),
Алабуга муниципаль районы (2 бәяләмә),
Зәй муниципаль районы (2 бәяләмә),
Зеленодольск муниципаль районы (2 бәяләмә),
Кукмара муниципаль районы (1 бәяләмә),
Түбән Кама муниципаль районы (2 бәяләмә),
Минзәлә муниципаль районы (1 бәяләмә),
Спас муниципаль районы (1 бәяләмә),
Чаллы шәһәр округы (4 бәяләмә),
Казан шәһәр округы (10 бәяләмә).

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ***үз инициативасы белән*** республиканың балигъ булмаганнар өчен төрле төрдәге 90 учреждениесенә һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә күчмә тикшерүләр уздырылды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе авыр тормыш шартларында калган балаларның, ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау булуны исәпкә алып, әлеге төркемгә керә торган ***балалар өчен махсуслаштырылган учреждениеләр эшчәнлеге*** хезмәтнең махсус контролендә тора. Болар – ятимнәр өчен учреждениеләр (балалар йортлары, сабыйлар йорты, ятимнәр өчен интернат мәктәпләр) һәм социаль приютлар. 2017 елда, иң беренче чиратта, түбәндәге оешмаларда тәрбияләнүче балаларны тоту, тукландыру, тәрбияләү, дәвалау, реабилитацияләү, укыту, ял итү шартлары, аларның хокуклары тәэмин ителеше тикшерелде:

балалар һәм яшүчмерләр өчен биш социаль приютта (Әлки, Бөгелмә, Баулы, Минзәлә муниципаль районнарында, Чаллы шәһәрендә);

өч «ятимнәр» учреждениесендә (Лаеш муниципаль районында һәм Казан шәһәренең Идел буе районында балалар йортлары, «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Минзәлә интернат-мәктәбе» ДББУ).

Әлеге оешмаларны тикшерү нәтиҗәләре буенча балигъ булмаганнарның хокуклары бозылуга карата чаралар күрелде һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына, Казанның Идел буе балалар йорты директорына мөрәҗәгатьләр җибәрелде.

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дәүләт *кадет интернат-мәктәпләренә аерым игътибар бирде.* 2017 ел дәвамында 6 кадет интернат-мәктәбе тикшерелде (Казан, Чаллы шәһәрләрендә, Тәтеш, Кама Тамагы, Зеленодольск муниципаль районнарында).

Тикшерү йомгаклары буенча балигъ булмаганнарның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында 4 бәяләмә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына җибәрелде.

Җәйге чорда җәйге савыктыру кампанияләрен әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аерым контрольгә ала. 2017 елда балалар өчен савыктыру лагерьларында (алга таба – БСЛ) балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре тәэмин ителешен һәм үтәлешен тикшерү максатында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 18 муниципаль берәмлектә 51 БСЛда, шул исәптән 18 шәһәр чите стационар лагеренда, 31 мәктәп лагеренда, 2 палата лагеренда тикшерү уздырылды.

Тикшерүләр ачыкланган ачыкланган хокук бозулар, аларга карата искәрмәләр, аларны төзәтү буенча күрсәтмәләр лагерьлар җитәкчеләренә, аларны гамәлгә куючыларга җиткерелде, аларның күпчелеге тикшерү барышында яисә кыска вакытларда төзәтелде.

Шул ук вакытта 7 лагерьда җитди хокук бозулар ачыкланды, шуңа бәйле рәвештә сменаларны гамәлгә куючылар һәм аларны оештыручылар адресына, хокук бозуларны бетерү буенча чаралар күрүне таләп итеп, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 6 бәяләмә җибәрелде. Һәр факт буенча Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча республика ведомствоара комиссиясенә хәбәр ителде.

2017 елда хокук бозулар ачылган лагерьлар исемлеге:

«Заречный» БСЛ ДОЛ) – Нурлат муниципаль районы;

Муса Җәлил ис. БСЛ – «Исток» яшьләр клубы берләшмәсе» МБУ – Зеленодольск муниципаль районы;

«Радужная страна» мәктәп лагере – «10 нчы гимназия» – Зеленодольск муниципаль районы;

«Ласточка» көндезге мәктәп-савыктыру лагере – «Иске Чыкалы төп гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ – Чүпрәле муниципаль районы;

«Берсут» ААҖенең «Берсут» БСЛ – Мамадыш муниципаль районы;

«Санаторий-профилакторий «Азнакай» шифаханә-профилакторий» ҖЧҖенең «Солнышко» БСЛ – Азнакай муниципаль районы;

«Татнефть» ГАҖенең «Баулынефть» нефть-газ чыгару идарәсе»нең «ИВОЛГА» БСЛ – Баулы муниципаль районы.

Күзәтчелек итүнең төп предметы булып, балалар өчен ябык типтагы махсус учреждениеләрдә торучы, закон белән конфликтка кергән балигъ булмаган балаларны тоту шартлары, укыту процессын оештыру, медицина ярдәме күрсәтү санала. 2017 ел дәвамында түбәндәгеләр тикшерелде:

«Республика махсус гомуми белем бирү Н.А.Галлямов мәктәбе» ябык типтагы дәүләт казна махсус укыту-тәрбияләү учреждениесе;

«Җәзалар үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсенең (УФСИН по РТ) 1 нче тикшерү изоляторы» федераль казна учреждениесе;

«Җәзалар үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсенең (УФСИН по РТ) 3 нче тикшерү изоляторы» федераль казна учреждениесе;

«Җәзалар үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсенең (УФСИН по РТ) нче тикшерү изоляторы» федераль казна учреждениесе.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны укыту һәм тәрбияләү шартларын анализлау максатында ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен махсуслаштырылган гомуми белем бирү учреждениеләре эшчәнлеген дә игътибар үзәгенә алды (Казан, Чаллы шәһәрләрендә, Түбән Кама, Бөгелмә Лаеш муниципаль районнарында). Тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында ике бәяләмә җибәрелде.

Моннан тыш, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан түбәндәге сәламәтлек саклау оешмалары да тикшерелде:

«Чистай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең (ГАУЗ) реабилитация һәм чыныктырып дәвалау бүлекчәсе;

Үзәк район хастаханәсенең балалар бүлекчәсе (Сарман муниципаль районы);

Психоневрологик диспансерның балалар психиатрия бүлекчәсе (Казан шәһәре);

«Черки-Килдураз авылында республика балалар шифаханәсе» (Буа муниципаль районы) дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе.

Тикшерү барышында реабилитация һәм чыныктырып дәвалау бүлекчәсендә җитди кимчелекләр ачыкланды, шуңа бәйле рәвештә, гамәлгә куючы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы адресына тиешеле бәяләмә җибәрелде.

Ел дәвамында тагын түбәндәгеләргә тикшерү уздырылды:

балалар өчен реабилитация үзәкләрендә:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Баулы муниципаль районындагы Мөмкинлекләре чикле булган балалар һәм яшүсмерләр өчен «Радость» («Шатлык») реабилитация үзәге» ДАСХУ (ГАУСО);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Лаеш муниципаль районындагы Мөмкинлекләре чикле булган балалар һәм яшүсмерләр өчен реабилитация үзәге» ДАСХУ (ГАУСО);

шулай ук республиканың башка районнары һәм шәһәрләренең (Балтач, Буа, Биектау, Әлки районнары, Казан шәһәре) *гомуми белем бирү оешмалары, өстәмә белем бирү оешмалары, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тикшерелде.*

Тикшереү чаралары барышында ике гомуми белем бирү оешмасында һәм бер балалар иҗаты йортында хокук бозулар ачыкланды, аларга балигъ булмаганнарның хокуклары бозылу һәм аларны төзәтергә кирәклеге турында 3 бәяләмә җибәрелде.






Югарыда билгеләп үтелгәнчә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиленең күзәтчелек эшчәнлеге балалар учреждениеләрен тикшерү белән генә чикләнми, ә ул тиешле хакимият органнары эшчәнлеге белән дә кызыксына.



Республика районнарына һәм шәһәрләренә эшлекле визитлар кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәтләр (опека һәм попечительлек органнары, мәгариф идарәсе органнары, сәламәтлек саклау, социаль яклау идарәләре, балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча муниципаль комиссияләр) эшчәнлеге дә анализланды.

Шулай итеп, 2017 елда югарыда күрсәтелгән хезмәтләрнең имин булмаган гаиләләр белән эшләү, ятим балаларны гаиләгә урнаштыру, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны укытуны оештыру, мәктәптә балаларны тукландыруны оештыру, балаларга өстәмә белем бирү, девинат холыклы гаиләләр һәм балалар белән эшләү эшчәнлеге 21 муниципаль районда, Чаллы шәһәр округында, Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе, Совет, Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнарында анализланды. Балаларны гаиләдән алуны анализлауга Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан аерым игътибар бирелде.

Бу эшчәнлекне өйрәнү нәтиҗәләре буенча ачыкланган хокук бозулар турында һәм эшләрнеэ җитәрлек башкарылмавы турында түбәндәге 12 муниципаль район (шәһәр округы) башлыгы адресына 14 бәяләмә җибәрелде:

Азнакай (1 бәяләмә);

Әтнә (1 бәяләмә);

Зеленодольск (1 бәяләмә);
Баулы (1 бәяләмә);
Бөгелмә (1 бәяләмә);
Буа (1 бәяләмә);
Нурлат (2 бәяләмә);
Түбән Кама (2 бәяләмә);
Балтач (1 бәяләмә);
Тәтеш (1 бәяләмә);
Биектау (1 бәяләмә);
Чаллы (1 бәяләмә).

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ведомствоара эксперт төркемнәре составында контроль-күзәтчелек эшчәнлеге дәвам итте.

2016 елдан башлап Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты белгечләре ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеенән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларның эшчәнлеге һәм аларда ата-ана тәрбиясеенән мәхрүм калган балаларны урнаштыру турында» 2014 елның 24 маендагы 481 номерлы карары таләпләренә туры килүен бәяләү буенча *эксперт төркеме эшендә* катнашалар.

Әлеге эксперт төркеме эше кысаларында 2017 елда 13 ятим балалар оешмасы тикшерелде.

Аерым алганда, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеенән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларның эшчәнлеге һәм аларда ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру турында» 2014 елның 24 маендагы 481 номерлы карары таләпләренә туры килүен тикшерү буенча Татарстан Республикасы Премьер-министры буенча В.Г.Шәйхразиев тарафыннан 2016 ел йомгаклары буенча расланган Чаралар планының («Юл картасының») үтәлеше тикшерелде.

Моннан тыш, «Акылга зәгыйфь балалар өчен Дәрвишләр балалар интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учрежденисендә биш баланың хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу очраклары ачыкланды – опека һәм попечительлек органнары инициативасы белән аларны хокуктан файдалануга сәләтсез дип тану өлешендә. Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, учреждение администрациясе белән берлектә, балаларның бозылган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызу буенча суд тәртибендә чаралар күрелде.

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның 2017 елның 4 августындагы 43654 номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән 2017 елның августында *коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча республика эксперт төркеме эшчәнлеге кысаларында* Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты белгечләре тиешле комиссия составында Татарстан Республикасының коррекцияле белем бирү оешмалары эшчәнлеген ведомствоара тикшерүдә катнаштылар.

Бу юнәлештә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен җиде дәүләт гомуми белем бирү оешмасы тикшерелде:

«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен Казан интернат-мәктәбе №1» ДБМУ, Казан шәһәре;

«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен Лаеш интернат-мәктәбе» ДБМУ;

«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен Әлмәт интернат-мәктәбе №19» ДБМУ;

«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен Актүбә интернат-мәктәбе» ДБМУ;
«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен Азнакай интернат-мәктәбе» ДБМУ;
«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен Рус Акташы интернат-мәктәбе» ДБМУ;
«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен Әлмәт интернат-мәктәбе» ДБМУ.
Тикшерү чаралары барышында түбәндәге мәсьәләләргә аерым игътибар бирелде:
белем алучыларның комплексы иминлеге;
мәктәпкә алу өчен нигезләр;
кадрлар белән тәэмин ителеш;
матди-техник тәэмин ителеш;
укыту-тәрбияләү процессын оештыру;
укучыларны тукландыруны оештыру;
медицина хезмәте күрсәтүне оештыру;
балаларның яшәү шартлары (интернат-мәктәпләрдә).
Тикшерү нәтиҗәләре буенча системалы рәвештә хокук бозулар барплык 7 белем бирү оешмасында ачыкланды, шуңа бәйле гамәлгә куючы – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан балигъ булмаганнарның хокуклары бозылу турында 7 бәяләмә җибәрелде.





Бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу фактлары, шул исәптән аерым җәмәгатьчелек резонансын алган фактлар турындагы ***хәбәрләр һәм мәгълүмат буенча*** да Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан берничә тикшерү уздырылды.
2017 елда шундый 22 вәзгыять өйрәнелде.
Вакыйгалар торышын һәрьяклап һәм оператив өйрәнү, алар буенча фикер алышу өчен, җайга салу гамәлләрен эшләү һәм балалар мәнфәгатьләрендә нәтиҗәле карарлар кабул итү өчен күп вәзгыятьләр Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координация комитеты утырышында каралды. Әлеге тәжрибә оператив чаралар күрүне таләп итә торган аеруча кискен һәм четерекле вәзгыятьләрне хәл итүдә нәтиҗәле механизм булды.
Күрсәтелгән фактлар буенча уздырылган тикшерү чаралары йомгаклары буенча балигъ булмаганнарның хокуклары бозылу турында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 10 бәяләмә җибәрелде, шул исәптән: Саба, Нурлат, Спас муниципаль районнары башлыкларына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына (2 бәяләмә), белем бирү оешмалары җитәкчеләренә (4 бәяләмә), балалар йорты җитәкчелеге адресына.

1.3. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар мәнфәгатьләрендә законнарны камилләштерүдә катнашуы

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты эшчәнлегенең иң мөһим юнәлешләреннән берсе – балалар мәнфәгатьләрен кайгыртып, законнарны камилләштерүдә катнашу.

2017 елда норма чыгару эшчәнлеге норматив хокукый актлар проектларының законнар белән гарантияләнгән бала хокукларына, шулай ук аның мәнфәгатьләренә туры килүен алдан ук тикшерүдә катнашу рәвешендә барды.

Федераль законнар проектлары буенча үз фикереңне белдерү бала хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы федераль закон проектларын «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 26.4 статьясында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы тарафыннан Татарстан Республикасы Президентына килештерүгә җибәрү процедурасы кысаларында тәэмин ителә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан *республика норматив хокукый актлары проектларын* (Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре проектларын) рәсми килештерү, Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты нигезендә 2013 елда балалар хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив хокукый актларны килештерергә тиешле вазыйфаи затлар исемлегенә кертелгәннән башлап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертү чорында катгый рәвештә башкарыла.


Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең республика законнары проектлары буенча фикер алышуларда катнашуның мөмкин булган тагын бер ысулы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларында закон проектлары алдан каралган вакытта закон чыгару процессында катнашудан гыйбарәт. Ул үз исеменә алынган рәсми гарызнамәләргә бәяләмәләр бирү юлы белән һәм закон проектларын эшләү өчен төзелә торган эшче төркем утырышларында комитетлар инициативасы белән катнаша.

Карауга кертелә торган барлык норматив хокукый актлар проектлары буенча аларның халыкара хокук, федераль һәм республика законнары нормалары белән гарантияләнгән бала хокукларына һәм мәнфәгатьләренә туры килү-килмәвенә бәйсез экспертиза ясала һәм тиешле бәяләмәләр бирелә.

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә килештерү өчен балигъ булмаганнарның хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы 36 федераль һәм республика норматив хокукый акты проекты керде.

10 нчы диаграмма

2013-2017 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан каралган бала хокукларына кагылышлы федераль һәм республика норматив хокукый актлары саны



2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан бала хокуклары һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы ***20 федераль закон проекты*** буенча бәяләмә әзерләнде. Болар – түбәндәге закон проектлары:

1. «О внесении изменений в статью 48 Россия Федерациясе Гаилә кодексының 48 статьясына һәм «Граждан хәле актлары турында» Федераль законның 17 статьясына үзгәрешләр (баланың атасын билгеләү өлешендә, әгәр бала анасының элеккеге ире балага ата булмаса);

2. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» (балигъ булмаганнар турында мәгълүмат җыю һәм тарату тәртибен билгеләү өлешендә);

3. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.15 статьясына үзгәрешләр кертү турында» (статьяның балигъ булмаганнарга һәм исерек хәлдәге затларга пиротехник әйберләр сатуны тыю турындагы 2 өлешенә өстәмә кертү өлешендә);

4. «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында» Федераль законның 8 статьясына үзгәрешләр кертү турында» (ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга бирелә торган махсус торак бинасын яллау шартанамәсенең гамәлдә булу срогын кыскарту өлешендә);

5. «Опека һәм попечительлек турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү турында» (ата-анасыннан мәхрүм калган балигъ баланың мәнфәгатьләрен яклау өлешендә);

6. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына балаларны суицидка китерүгә юнәлдерелгән эшчәнлеккә каршы торуның өстәмә механизмнарын билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында»;

7. «Россия Федерациясе гражданлыгы турында» 2002 елның 31 маендагы 62-ФЗ номерлы Федераль законга ата-аналарының яки уллыкка алучыларының берсе Россия Федерациясе гражданы булган баланың Россия Федерациясе гражданлыгын алуына карата үзгәрешләр кертү турында» (Россия Федерациясеннән читтә яшәүче балигъ булмаган шундый чит ил гражданнары өчен Россия гражданлыгын алуның максималь гадиләштерелгән тәртибен билгеләү максатларында);

8. «Сугыш балалары турында»;

9. «Россия Федерациясе Салык кодексының 407 статьясына үзгәрешләр кертү турында» (күпбалалы гаиләләрдә ата-аналарны физик затлар салымыннан азат итү өлешендә);

10. «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» (баланы аноним калдыру өчен урыннар булдыру өлешендә);

11. «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында» Федераль законның 8 статьясына үзгәрешләр кертү турында» (җирле үзидарә органнарына ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга торак биргәндә торак биналарның төзеклеген һәм санитар-техник торышын тәэмин итү бурычларын йөкләү өлешендә);

12. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына суррогат ана булуны тыю өлешендә үзгәрешләр кертү турында»;

13. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» (эзләү игълан ителгән бала табылган очракта, аны суд карары буенча кичекмәстән тапшырылырга тиешле затка кайтару яисә (һәм) аннан алу мөмкин булмаган очракта, приставлар-үтәүчеләр тарафыннан баланы опека һәм попечительлек органнарына тапшыру өлешендә);

14. «Бөек Ватан сугышы балалары статусы турында»;

15. «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында» Федераль законның 8 статьясына үзгәрешләр кертү турында» (ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга бирелә торган махсус торак бинасын яллау шартанамәсенең гамәлдә булу срогын кыскарту өлешендә);

16. «Россия Федерациясе Гаилә кодексына тәрбиячеләргә үзләрендә тәрбияләнүчеләрнең барысы белән дә аралашу хокукын бирү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» һәм «Россия Федерациясе Гаилә кодексына тәрбиячеләргә үзләрендә тәрбияләнүчеләрнең барысы белән дә аралашу хокукын бирү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»;

17. «Биш һәм аннан күбрәк балалы гаиләләргә торак субсидияләре бирү турында»;

18. «Россия Федерациясе Гаилә колексының 115 статьясына үзгәрешләр кертү турында» (алиментлар түләргә тиешле затның матди һәм гаилә хәлен исәпкә алып, вакытында түләнмәгән алиментлар өчен неустойка түләве күләмен киметү өлешендә);

19. «Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында» Федераль законга матди (гаилә) капиталы акчалары белән эш итү юнәлешләрен тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында»;

20. «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законга балалар иминлеге дәрәҗәсен арттыру, шулай ук оешмалар тарафыннан балалар ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту өлешендә үзгәрешләр кертү хакында».

Закон проектларына ясалган экспертизалар нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан тиешле бәяләмәләр әзерләнде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде, шуларның алтысы тискәре бәяләмә булып, карала торган закон проектын республика исеменнән хупламаска тәкъдим ителде.

2017 елда да, 2016 елдагы кебек, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә карау һәм килештереү өчен бер – «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе ***Хөкүмәте карары проекты керде.*** Әлеге проект белән уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр, тәрбиягә алучы ата-аналар яисә гаиләгә вакытлыча бала алучылар тарафыннан мөстәкыйль рәвештә опека һәм попечительлек органнарына тапшырыла торган гаризалар һәм документлар бирү исемлеге кыскартылды. Исемлектән төшереп калдырылган документлар тиешле вәкаләтле органнардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә соратып алына.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән алдан килештерү өчен 2017 елда кергән ***төбәк норматив хокукый актлар проектларының*** гомуми саны 2016 ел белән чагыштырганда беркадәр артты һәм нәтиҗәдә 15 акт булды (2016 елда – 10 проект).

Узган елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балалар хокукларына һәм мәнфәгатьләренә, балалар һәм гаиләгә кагылышлы биш Татарстан Республикасы законы проектын карауда катнашты, аерым алганда:

«Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законынеың 11.1 статьясына үзнәерш кертү хакында»;

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында;

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында»;


«Яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында»;

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына, адреслылык принципларын һәм мохтаҗлык критерийларын исәпкә алып, социаль ярдәм чараларын күрсәтүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон кажул итлүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының аерым хкон актларына үзгәрешләр кертү турында».

Республикада 2017 елда балалар һәм балалы гаиләләр мәнфәгатьләренә кагылышлы җиде закон кабул ителде.

11 нче диаграмма

2014-2017 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы законнары проектларын алдан килештерүдә катнашуын тәэмин итү



Шулай итеп, 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасында кабул ителгән алты законның дүресенә карата (66,7%) рәсми килештерү кысаларында үз фикерен белдерә алган булса, 2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына бәяләмә бирү һәм килештерү өчен 7 законнан 5 закон (71,4%) керде. Димәк, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне балалар һәм балалы гаиләләр мәнфәгатьләренә кагылышлы закон чыгару процессына җәлеп итү динамикасы үсештә булуын күрәбез.

Төбәк законнан чыгып эшләнгән норматив хокукый актлар өлешендә 2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан *Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 10 карар проекты каралды:*

1. «Мәктәпкәчә гаилә төркемнәрен оештыру турында»;

2. «2020 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә яшьтән ярдәм күрсәтүне үстерү концепциясен 2017-2018 елларда Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру чаралары планын раслау турында»;

4. «2017– 2019 елларга Татарстан Республикасында медиакиңлектә балаларның мәгълүмат иминлеген тәэмин итү буенча чаралар планын («юл картасын») раслау турында»;

5. «Татарстан Республикасы балигъ булмаган затларына карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибен турында» 2008 елның 1 декабрендәге 843 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»;

6. «2017-2020 елларга балигъ булмаганнар арасында суицидлык халәтне профилактикалау буенча комплексы ведомствоара планын раслау турында»;

7. «Созвездие-Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада фестивале турында»;

8. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 25 апрелендәге 749-р күрсәтмәсе белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә демография һәм гаилә сәясәте өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем составын актуальләштерү турында»;

9. «Закон территориясе» еллык конкурсын үткәрү турында» 2012 елның 20 февралендәге 135 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»;

10. «Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка алуга бәйле рәвештә гражданнарга бер мәртәбә өстәмә акчалата түләү турында».

2017 елда теге яки бу рәвешле балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы 20 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм күрсәтмәсе кабул ителде.

Аерым алганда, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил фикере исәпкә алынмыйча, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 21 мартындагы 169 номерлы «Махсус торак фондында яшәүче ятим балалар һәм ата-аналарыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны йөртү турында» карары; 2017 елның 28 декабрендәге 1068 номерлы «Татарстан Республикасында белем алучыларның контингенты» дәүләт мәгълүмат системасы турында» карары кабул ителде.

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән килештермичә Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән түбәндәге 10 карарда Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентында билгеләнгән килештерү тәртибе бозылган:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының өч карарына карата (21.03.2017 № 169, 20.11.2017 № 922, 28.12.2017 № 1068);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының өч карарына карата (18.09.2017 № 681, 18.09.2017 № 690, 18.09.2017 № 692);


Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ике карарына карата (06.12.2017 № 940, 25.12.2017 № 1031);

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының бер карарына карата (20.11.2017 № 892);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының бер күрсәтмәсенә карата (15.12.2017 № 3277-р).

12 диаграмма

2014 – 2017 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары проектларын алдан килештерүдә катнашуын тәэмин итү



Шуны билгеләп үтәргә кирәк: 2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы актлары (карарлары һәм күрсәтмәләре) проектларын алдан килештерүдә катнашуын тәэмин итү эше 2016 елдагыга караганда беркадәр яхшырды: әгәр 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил республикада кабул ителгән карарларның һәм күрсәтмәләрнең 29% (ягъни 17 проекттан 5) буенча рәсми килештерү кысаларында үз фикерен белдерә алса, 2017 елда 50% (20дән 10) Татарстан Республикасының норматив хокукый акты Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән алдан килештерелде.

Шулай да, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына норматив хокукый актлар проектларын кертүнең һәм аларны карауның билгеләнгән тәртибен саклау ягыннан да, бала хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләренә дәүләт яклавы гарантияләрен тәэмин итү буенча да мондый вәзгыятьне канәгатьләнерлек дип санап булмый. Вәкаләтле вәкил 2016 елгы нотыгында да мондый практика булмаска тиешлеген күрсәткән иде. Бала һәм балалы гаилә хокукларына кагылышлы төбәк норматив хокукый актлар проектларын Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән килештерүне тәэмин итү максатларында, алдан килештерү эшен дәвам итәргә кирәк, дип саныйбыз. Шуңа бәйле рәвештә, түбәндәгеләрне башкарырыга икрәк:

Татарстан Республикасы министрлыкларына һәм ведомстволарына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 2005 елның 5 декабрендәге 563 номерлы карары белән расланган Регламентның 57 пункты таләпләренең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга кертелә торган балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы барлык норматив хокукый актлар проектларының Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән алдан килештерүгә мәҗбүри җибәрелүе өлешендә берсүзсез үтәлүен тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына республика министрлыклары һәм ведомстволары тарафыннан югарыда күрсәтелгән таләпләрнең үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Карала торган өлкәдә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең норма чыгару эшчәнлегенә иң көчле тәэсир итү чыганагы – закон чыгару инициативасы хокукы бул-

мавын истә тотып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм «Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләрне кертү юлы белән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә закон чыгару инициативасы хокукын бирү турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә;

Әлеге тәкъдимне карау йомгаклары буенча республиканың закон чыгару органы тарафыннан Вәкаләтле вәкилгә Татарстан Республикасы Конституциясенә башка үзгәрешләр кертү комплексында закон чыгару инициативасы хокукын бирү мәсьәләсен карарга дигән карар кабул ителде.

1.4. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашуы


Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен суд тәртибендә яклауда федераль граждан-процессуаль һәм җинаять-процессуаль законнар нормалары нигезендә катнашуы омбудсменныңбалаларны судта яклау мөмкинлекләрен чикли. Вәкаләтле вәкилгә әлегә кадәр мөстәкыйль рәвештә процессуаль хокук бирелмәгән һәм шуңа күрә ул хокук суд процессында бәхәснең асылы буенча (эштә катнашучы затлар үтенечнамәсе буенча) мөстәкыйль таләпләр куя алмый торган өченче зат буларак, йә Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Граждан-процессуаль кодексының 47 статьясындагы 2 өлеше нигезендә (суд инициативасы буенча) бала хокукларының һәм мәнфәгатьләренең якламуына дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән дәүләт вазыйфаи заты буларак кына катнаша.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бала хокуклары бозылуның ачыкланган очраклары турындагы бәяләмәләрендә куелган таләпләрне республика дәүләт хакимиятенең тиешле органнары, муниципаль органнар һәм оешмалар тарафыннан үтәмәгәндә яисә тиешенчә үтәмәгәндә бу проблема аеруча кискен төс ала. Мондый очракта Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бала хокукларын яклауны күзәтчелек итү органнарына, беренче чиратта, прокуратура органнарына мөрәҗәгать итү юлы белән генә башкара ала, йогынты ясауның башка чараларын кулланырга аның хакы юк. Шуңа күрә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең хокукый вәкаләтләрен арттыру максатыннан, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары карарлары (гамәл кылмаулары) белән һәм оешмалар тарафыннан балалар (шул исәптән чикләнмәгән даирә затларының) хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу эшләрен караганда бу институтка (федераль һәм төбәк дәрәҗәләрдә) мөстәкыйль процессуаль хокук бирү өлешендә федераль законнарга үзгәрешләр кертергә кирәк.

Бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен законда билгеләнгән тәртиптә суд яклавында катнашу белән бергә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты эшчәнлегендә киңәш бирү, процессуаль документлар төзүдә һәм кирәкле материаллар туплауда ярдәм рәвешендә судта граждан эшен карауга әзерлек кысаларында юридик ярдәм күрсәтү (алга таба – юридик ярдәм) актив башкарыла.

13 нче диаграмма

2013 – 2017 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашкан яисә юридик яктан ярдәм күрсәткән суд процесслары саны



Узган хисап чорында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашкан суд эшләре саны артты (2015 елда – 8 эш, 2016 елда – 25 эш, 2017 елда – 31 эш). Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашында булган суд эшләренең гомуми санынан 28 очракта – эш буенча якларның берсе инициативасы белән, 3 очракта суд инициативасы белән Россия Федерациясе Граждан-процессуаль кодексының 47 статьясындагы 2 өлешендә каралган тәртиптә дәүләт вазыйфаи заты буларак суд эшен карауга җәлеп ителде.

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең суд практикасын, юридик хезмәт күрсәтүне дә кертеп, түбәндәгеләргә бәйле бәхәсләр тәшкил итте:

балаларның яшәү урынын билгеләүгә;

ата-ананың берсе белән генә яисә туганнары белән яшәүче баланың аралашу тәртибен билгеләүгә;

балигъ булмаган балаларны ата-ана тәрбиясенә бирүгә;

балигъ булмаганнарның торак хокукларын яклауга, шул исәптән: балигъ булмаганны торак урында яшәүгә хокуксыз дип тануга;

ата-ана хокукларын чикләүгә (мәхрүм итүгә) бәйле;

алиментлар түләтүгә бәйле;

дарулар белән тәэмин итү өлешендә баланың сәламәтлек саклауга хокукын яклауга;

ивалид бала өчен техник реабилитацияләү чарасын мөстәкыйль сатып алган өчен компенсация түләтүгә бәйле;

сыйфатсыз медицина ярдәме аркасында, шул исәптән үле бала табуга бәйле мораль зыян өчен түләүгә бәйле.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2017 елда суд практикасындагы яңалыгы түбәндәгеләр турында таләпләрне (гаризаларны) карауга бәйле катнашу булды:

гражданны хезмәткә яраклы дип тану турындагы;

атага бала карау буенча отпуск бирүдән баш тарту турындагы карарны юкка чыгару турындагы;

балигъ булмаган баланы опекага алынудан баш тартуны законсыз дип тану;

балигъ булмаганнарның документлардан файдалану тәртибен һәм читкә чыгу кагыйдәләрен билгеләү турындагы.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашкан суд бәхәсләренең асылыннан күренгәнчә, бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өчен дәлилле бәяләмәләр китерелде һәм эшләрне карауга бәйле карарлар аның фикерен исәпкә алып чыгарылды. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне суд эшләрендә катнашуга җәлеп итү практикасының

артуы республика судларының балаларга бәйле эшләрне бала мәнфәгатьләрендә законлы һәм гадел хәл итәргә омтылулары белән аңлатыла.


Шул ук вакытта 2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне конституциячел суд эшләрендә катнашуга җәлеп итү практикасы җәлеп итте. Узган чорда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 51 статьясы тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан түбәндәгеләрнең конституциячеллеге турындагы эшләр буенча бәяләмә бирү өчен җәлеп ителде:

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Уставының (*Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 21.05.2015 № 14/235 карары белән расланган*) 74 статьясындагы 1 цлешенең 3 пункты, 79 статьясындагы 9 өлешенең өченче абзацы; Питрәч муниципаль районының мәгариф оешмаларын төзү, үзгәртеп кору яисә бетерү турындагы нигезләмәсенең (*Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 30.05.2016 № 762 карары белән расланган*) 3.4 пунктының 3.4.1 пунктчасы, 3 бүлегенең 3.4 пункты; Питрәч муниципаль районының мәгариф оешмасын үзгәртеп кору, бетерү, статусын үзгәртү, реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләнешен үзгәртү турында карара кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясе турындагы нигезләмәнең (*Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 08.06.2016 № 881 карары белән расланган*) 8 пунктының 8.1 пунктчасы, 11 пунктының 5 пунктчасы; Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмасын, муниципаль берәмлек оешмасын үзгәртеп кору яисә бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне, мондый бәяләү критерийларын да кертеп (әлеге мәгариф оешмаларының типлары буенча), уздыру тәртибенең, шул исәптән мондый карар нәтитҗләрен бәяләү буенча комиссия төзү тәртибенең (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының *05.02.2014 № 63 карары белән һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары белән расланган)* 1.3, 2.14 һәм 2.19 пунктлары.

Суд органының мондый инициативасы, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил фикеренчә, карарлар чыгарганда, бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү принцибын исәпкә алуда суд тәҗрибәсен законлы нигездә беркетү өчен нигез булып тора.

Балалар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен суд яклавы буенча үз вәкаләтләрен көчәйтү максатларында Вәкаләтле вәкил үзенең 2016 елгы нотыгында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 81 статьясына үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим иткән иде. Әлеге тәкъдимне республиканың закон чыгару органы карады. Югарыда тәкъдим ителгән үзгәреш Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясын (Татарстан Республикасы Конституциясе судына мөрәҗәгать итү хокукы булган субъектлар исемлеген билгели торган статья) үзгәртүгә китерүен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституциясенә башка үзгәрешләрне керткәндә, комплекста карарга дигән карар кабул ителде.

1.5. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең нотыклары



Татарстан Республикасы дәүләт хакимият органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, оешмаларның Татарстан Республикасында балалар мәнфәгатьләрен яклау юнәлешендәге эшчәнлегенә тәэсир итү максатында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасында бала хокуклары һәм аларның законлы мәнфәгатьләрен яклау турында *ел саен нотык әзерләнә,* аны карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасында балаларның хәлен яхшырту буенча чаралар күрелә.

2017 елның 16 мартында «2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү турында» нотык (алга таба – нотык) Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановка тапшырылган иде. Рәсми очрашу кысаларында Татарстан Республикасы Президентына 2017 елда Татарстан Республикасында балалар хокукларын гамәлгә ашыру буенча төп проблемалы мәсьәләләр турында һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты эшчәнлеге нәтиҗәләре хакында хәбәр ителде.



2017 елның 22 мартында Нотык Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында тыңланды.

Законнеың 13 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Нотык шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Прокурорына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына җибәрелде.

Нотыктагы төп тәкъдимнәрне карау нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы министрлыкларына һәм ведомстволарына, муниципаль район башлыкларына Нотыктагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чараларын күрергә, шулай ук балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау чаралары комплексын эшләргә тәкъдим итте.

Нотыкта күрсәтелгәән 2016 ел тәкъдимнәрнең үтәлешенә анализ нотыкның тиешле бүлекләрендә бирелә.

Бала хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре буенча аерым тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Президентына кертү хокукыннан файдаланып, 2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановка түбәндәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итте:

ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруга ярдәм итү эшчәнлеген Татарстан Республикасында «Видеопаспорт» проектын гамәлгә ашыру юлы белән камилләштерү;

балалар һәм яшьләр арасында «Ребенок в мире прав» – «Бала – хокук даирәсендә» дигән видеороликлар буенча өченче республика конкурсын үткәрүгә ярдәм итү;

баланың үз гаиләсен саклап калуга һәм социаль ятимлекне профилактикалауга юнәлдерелгән «Аек акыл» проектын гамәлгә ашыруга ярдәм итү;



Сингапур Республикасына белем алу стажировкасы йомгаклары буенча тармакта Сингапур Республикасы тәҗрибәсен куллану.

Еллык нотыктан тыш, 2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан ике махсус нотык әзерләнде.

2017 елның 17 апрелендә Татарстан Республикасы Иминлек Советы һәм Татарстан Республикасында хокук тәртибен саклау буенча Координация комитетының уртак утырышы узды, ул Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов рәислегендә барды. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ***«Интернет-хәтәрлекләрне һәм балалар-яшүсмерләр гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янауны профилактикалау өлкәсендә өстәмә чаралар күрү турында»*** төп нотык белән чыгыш ясады.



Татарстан Республикасы Иминлек Советы һәм Татарстан Республикасында хокук тәртибен саклау буенча Координация комитеты уртак утырышының 03.05.2017 № Пр-124 Беркетмәсен үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 21.07.2017 № 1739-р күрсәтмәсе кабул ителде, анда 2017-2019 елларда медиакиңлектә балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү буенча системалы чаралар комплексын (чаралар планы («юл картасы» расланды) гамәлгә ашыру күздә тотыла.



Нотыкта бәян ителгән тәкъдимнәрне үтәү йөзеннән, Казан шәһәре территориясендә балалар хокуклары һәм ирекләре үтәлүгә анализ ясау максатында Казан шәһәр Думасы депутатлары чакыруы буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Казан шәһәр Думасының Законлылык, хокук тәртибе мәсьәләләре һәм җирле үзидарә, Мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр, Яшьләр эшләре, физкультура һәм спорт мәсьәләләре даими комиссияләренең уртак утырышында катнашты. Анда ул ***«2016 елда Казан шәһәрендә балаларның хокуклары һәм*** мәнфәгатьләре ***үтәлешенең актуаль мәсьәләләре турында»*** махсус нотык белән чыгыш ясады.

Уртак утырыш карарында Нотыкта Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан билгеләнгән тәкъдимнәрне үтәү буенча йөкләмәләр бирелде.

1.6. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эш визитлары

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең системалы нигездә республиканың муниципаль районнарына һәм шәһәр округларына эш визитларын оештыру һәм уздыру практикасы дәвам итте.

Ел дәвамында 24 эш визиты оештырылды. Мондый эш рәвеше республиканың 20 муниципаль берәмлегендә һәм ике шәһәр округында оештырылды, болар:

Азнакай муниципаль районы,
Арча муниципаль районы,
Алки муниципаль районы,
Әлмәт муниципаль районы,
Баулы муниципаль районы,

Балтач муниципаль районы,
Бөгелмә муниципаль районы,
Буа муниципаль районы,
Биектау муниципаль районы,
Зеленодольск муниципаль районы,
Кама Тамагы муниципаль районы,
Лаеш муниципаль районы,
Лениногорск муниципаль районы,
Минзәлә муниципаль районы,
Мөслим муниципаль районы,
Түбән Кама муниципаль районы,
Нурлат муниципаль районы,
Сарман муниципаль районы,
Тәтеш муниципаль районы,
Чистай муниципаль районы,
Чаллы шәһәре,
Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе, Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары.

Эш визитлары форматы рабочих түбәндәге мәсьәләләргә комплекслы һәм системалы караш тудыра:

һәр муниципаль районда (шәһәр округында) бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлешенә анализ ясау;

ачыкланган хокук бозуларны торгызуга тәэсир итү буенча чаралар күрү;

районның (шәһәрнең) яшьләрен яклау мәнфәгатьләрендә җирле органнарның эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.

Эш визитлары кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан түбәндәге чаралар күрелде.

Һәр визит ***муниципаль район башлыгы белән очрашудан*** башлана, һәм конкрет муниципаль берәмлегендә (шәһәр округында) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итүнең актуаль мәсьәләләре буенча фикер алышына.





Гражданнарынны – район (шәһәр) кешеләрен кабул итүне оештыру да эш визитлары программасының катгый пункты булып санала. Республика районнарында һәм шәһәрләрендә гражданнарны урыннарда кабул итүләр вакытында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә барысы 237 кеше мөрәҗәгать итте.





Районда (шәһәрдә) булганда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балалар учреждениеләрен эшчәнлегенә, шулай ук муниципаль хезмәтләр эшчәнлегенә *тикшерү* уздыра. Тикшерү чаралары уздырганда, проблемалары мәсьәләләр ачыкланып, алар буенча чаралар күрү генә түгел, ә эшнең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча тәкъдимнәр һәм аңлатмалар бирү дә бик мөһим. Бу муниципаль хезмәтләр хезмәткәрләренең профессиональ компетенциясе дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итә. Моннан тыш, тикшерү эшчәнлегенең мондый рәвеше күбрәк уңай нәтиҗә бирә.

Эш тәртибендә тиешле белгечләрне һәм җитәкчеләрне чакыртып, бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәтләр (опека һәм попечительлек органнары, мәгариф идарәсе органнары, сәламәтлек саклау, социаль яклау органнары, балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау буенча муниципаль комиссияләр һәм башкалар) эшчәнлегенә анализ ясала, алар буенча фикер алышулар уздырыла. Урыннарда органнар эшчәнлеген «җанлы» фикер алышу аша, катлаулы һәм җетерекле мәсьәләләр буенча аңлатулар һәм консультацияләр бирү аша тикшерү форматы, беренчедән, шул өлкәдә эшләүче белгечләрнең профессиональ компетенциясен күтәрүгә ярдәм итә һәм шул ук вакытта, региональ йә федераль дәрәҗәдә өстәмә җайга салуны таләп итә торган проблемаларны ачыкларга мөмкинлек бирә.

2017 елда түбәндәгеләр өйрәнелде:


гаилә һәм балаларның имин булуын профилактикалау субъектлары органнарының социаль куркыныч хәлдәге балаларны һәм гаиләләрне реабилитацияләү һәм аларга ярдәм итү эшчәнлеге;

республиканың социаль приютларында торучы балигъ булмаганнар белән индивидуаль профилактик эш оештыру;

ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның тәрбиягә алган гаиләләрдә хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше;

опека һәм попечительлек органнарының алыштыручы гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау эшчәнлеге;

балаларны гаиләдән алу практикасын анализлау.


Районның *аерым балалар учреждениеләрен тикшерүгә* теләсә кайсы мәгариф учреждениесе, ведомство буйсынкына һәм милек рәвешенә бәйсез рәвештә, район (шәһәр) территориясендә урнашкан ял итү, сәламәтлек саклау, спорт оешмалары эләгергә мөмкин. Визитлар кысаларында барысы 40 учреждениедә булынды.





Эш визиты һәр районда балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча *муниципаль комиссиянең киңәйтелгән утырышында башлангыч йомгаклар ясау белән тәмамалана.* Утырышта, кагыйдә буларак, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән тыш, район башлыгы, район прокуроры катнаша, шулай ук аңа муниципаль хакимитнең тиешле органнары җитәкчеләре һәм белгечләре, муниципалитет территориясендә үз эшчәнлеген башкаручы барлык балалар учреждениеләренең җитәкчеләре һәм белгечләре чакырыла. Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең киңәйтелгән утырышлары конкрет районның, шәһәрнең аеруча мөһим мәсьәләләре буенча ачыктан-ачык фикер алышу өчен иң шәп мәйданчык булып санала.





Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эш визиты җирле массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртылып барыла, бу исә районның киң җәмәгатьчелеге игътибарын балалар хокукларын яхшырак тәэмин итү зарурлыгына юнәлтергә мөмкинлек бирә.



Эш визиты йомгаклары буенча бала хокуклары һәм мәнфәгатьләренең системалы рәвештә бозылу очраклары ачыкланганда, район башлыгы адресына тиешле бәяләмәләр җибәрелә. 2017 елда визитлар йомгаклары буенча барысы 21 бәяләмә җибәрелде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең берничә еллар дәвамында шундый форматтагы эшчәнлеге республика территориясендә балаларның хәлен яхшыртуда нәтиҗәле механизм булуын күрсәтте.

2018 елда да әлеге эшчәнлек юнәлеше расланган план кысаларында дәвам итәчәк.

1.7. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координацион комитет эшчәнлеге

Республиканың балалар хокуклары һәм мәнфәгатьләрен үтәлешен тәэмин итү буенча нәтиҗәле эшчәнлекне гамәлгә ашыруны Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белән тыгыз хезмәттәшлек итүдән башка тәэмин итеп булмавын исәпкә алып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 25.03.2016 ел, 13-О номерлы «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында Координацион комитет турында»гы боерыгы белән даими координацияләүче ведомствоара органы – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координацион комитет (алга таба – Координацион комитет) төзелде.

Координацион комитет – консультатив-киңәшләшү органы, ул балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яхшырак үтәү һәм яклау бурычларын хәл иткәндә башкарма хакимиятнең









кызыксынучы органнарының, контроль-күзәтчелек органнарының ведомствоара үзара хезмәттәшлеген һәм килешенгән гамәлләрен тәэмин итә. Координацион комитет утырышларында системалы рәвештә карала торган, шулай ук аерым характердагы, шул исәптән балалар хокукларын бозуның уатлаулы һәм резонанслы очраклары да карала. Координацион комитетның төп бурычлары дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларның балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүдәге эшчәнлеген ведомствоара җайга салудан, балалар мәнфәгатьләрендә ашыгыч, перспектив, системалы килештерелгән каралар эшләүдән һәм кабул итүдән гыйбарәт.

Координацион комитет составына Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы идарәсе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләре керә. Утырышларда барлык мәсьәләләр Татарстан Республикасы прокуратурасы вәкилләре катнашында карала. Координацион комитет утырышына шулай ук конкрет карала торган мәсьәләгә кагылышы булган вазыйфаи затлар һәм гражданнар чакырыла.

2017 ел дәвамында Координацион комитетының 10 утырышы узды, аларда 16 проблемлемалы мәсьәлә каралды.

Каралган барлык мәсьәләләрнең 10сы бала хокукларын бозуның аерым очраклары буенча фикер алышуга һәм карарлар кабул итүгә кагылышлы иде.

Мисал. *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына гражданка Л. балигъ булмаган улын атасыннан алып аңа бирү турында 2017 елның 27 апрелендәге суд карарын үтәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итте. Суд приставы-үтәтүче тарафыннан суд карары буенча мәҗбүри чаралар күрелүгә карамастан, 2017 елның ноябрь азагына кадәр (ягъни 6 ай буе диярлек) суд карары үтәлмәгән. Монда суд приставлары хезмәте аша гына бала файдасына мәсьәләне хәл итеп булмавы ачык күренә.*

Әлеге вәзгыять 2017 елның 30 ноябрендә Координацион комитет утырышында каралды. Бу эшне караганда Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе җитәкчесе урынбасары Е.Ю.Степанова һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр инрның ЮХИДИ идарәсе җитәкчеенең беренче урынбасары А.В.Разумнов чакырылды.

Фикер алышу нәтиҗәләре буенча килештерелгән берничә идарәчел карарлар кабул ителде, шулар нәтиҗәсендә үтәтү эше буенча эзләнә торган кешене – балигъ булмаган баланың атасын – И.ны тоткарлау мөмкинлеге барлыкка килде, ул 6 ай буена суд приставлары белән очрашудан качып йөри. Ведомствоара чаралар нәтиҗәсендә 2017 елның 11 декабрендә бала анасы тәрбиясенә кайтарып бирелде.

Моннан тыш, Координацион комитет утырышларында чикләнмәгән сандагы балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы 6 мәсьәлә каралды:



Татарстан Республикасында мәктәпкәчә гаилә төркемнәре эшчәнлеген оештыру;

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү мәктәпләрендә суицидаль халәтне профилактикалау;

реализация проекта «Аек акыл» («Точка трезвости») проектын гамәлгә ашырпу: проблемалар һәм үсеш перспективалары;

Татарстан Республикасы Иминлек Советының һәм Татарстан Республикасында хокук тәртибен тәэмин итү буенча Координацион киңәшмәнең уртак утырышы беркетмәсен үтәү;

Суицидаль чагылышларга каршы торуның комплексы системасы эшчәнлеге регламенты мәсьәләсе;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017-2019 елларга балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү буенча чаралар планын («юл картасын») раслаган 2017 елның 21 июлендәге 1739-р номерлы карарын үтәү.

Мисал. *Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары В.Г.Шәйхразиев мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы Иминлек Советының һәм Татарстан Республикасында хокук тәртибен тәэмин итү буенча Координацион киңәшмәнең уртак утырышының 2017 елның 4 маендагы Пр-124 номерлы беркетмәсен үтәү кысаларында Координацион комитетта Суицидаль чагылышларга каршы торуның комплексы системасы эшчәнлеге регламенты проектын эшләп бетерү турындагы мәсьәлә каралды.*

Балигъ булмаганнар арасында бәхетсезлек һәм суицид очракларын булдырмау буенча системалы эш алып баруның, яшь буынның «Интернет» челтәреннән имин файдалануы, балаларның һәм яшьләрнең «Интернет»та конструктив эшләве, балигъ булмаганнарның потенциаль куркыныч һәм хокукка каршы интернет-контент белән элемтәгә керүенә бәйле хәтәрлекләрне киметү һәм булдырмау өчен шартлар тәэмин итү эшчәнлеген оештырунының мөһимлеген аңлап, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә түбәндәге документларны, балигъ булмаганнарның интернет иминлегенә бәйле профилактикалау мәсьәләләрен дә кертеп, эшләп бетерергә тәкъдим итте:

балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасына керүче органнар һәм учреждениеләр арасында балигъ булмаганнарда бәхетсезлек һәм суицид очракларын булдырмау буенча хезмәтәшлек итү һәм мәгълүмат алмашу тәртибен (Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең 2015 елның 16 гыйнварындагы № 01-15 карары белән расланган);

балалар суицидына омтылыш булган очракта балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектлары эшчәнлегенең алгоритмын (Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең 2016 елның 13 июнендәге № 18-16 карары белән расланган).

Министрлыкларның һәм ведомстволарның уртак эше йомгаклары буенча әлеге документларга тиешле үзгәрешләр кертелде.

Координацион комитетка фикер алышуга чыгарылган барлык мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча тиешле каралар кабул ителде, алар Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан расланган беркетмә белән рәсмиләштерелде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы әлеге органның эшчәнлеге практикада аның Татарстан Республикасында балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итүдә нәтиҗәле механизм булуын раслый.

1.8. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында Гаиләдән балаларны алу практикасын анализлау буенча эшче төркем эшчәнлеге



2017 елда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның 2017 елның 30 гыйнварындагы 4606-МР номерлы боерыгын үтәү йөзеннән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиленең 2017 елның 3 февралендәге 5 номерлы «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында Эшче төркем төзү турында»гы боерыгы белән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында Гаиләдән балаларны алу практикасын анализлау буенча эшче төркем (алга таба – Эшче төркем) төзелде.

Эшче төркем даими эшләүче ведомствоара орган булып тора, аның

эшчәнлек максаты – тиешеннән артык чаралар кулланып яисә гаилә хокукын бозып, аңа тыкшыну юлы белән гаиләдән балигъ булмаган балаларны алуга һәрьяклы анализ ясаудан гыйбарәт.

Эшче төркем составына кызыксынучы министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре, Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләре керә. Төркем эшендә даими рәвештә Татарстан Республикасы прокуратурасы вәкиле катнаша.

Эшче төркемнең бурычлары:

балаларны гаиләдн законсыз алу очракларын мониторинглау;

гаиләдән балаларны алу чараларын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар эшчәнлеген анализлау;

гаиләдән балаларны законсыз алган очраклар буенча башкарылган чараларны экспертизалау;

гаиләләрдән балаларны алу очракларын булдырмау буенча тәкъдимнәр әзерләү.

2017 ел дәвамында Эшче төркем 5 утырыш уздырды, аларда түбәндге мәсьәләләр каралды:

2016 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында гаиләдән балигъ булмаган балаларны алу мониторингы йомгаклары;

2017 елның 1 кварталы йомгаклары буенча Татарстан Республикасында гаиләдән балигъ булмаган балаларны алу мониторингы йомгаклары;

2017 елның 9 ае йомгаклары буенча Татарстан Республикасында гаиләдән балигъ булмаган балаларны алу мониторингы йомгаклары;

2017 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында гаиләдән балигъ булмаган балаларны алу мониторингы йомгаклары.

Татарстан Республикасында балаларны гаиләләрдән алу вәзгыятен Эшче төркем тарафыннан системалы рәвештә өйрәнүдән, анализлаудан, кирәк булса, тиешле чаралар күрүдән тыш, Эш төркем гражданнардан кергән шикаятьләр буенча аерым очракларн да карады. Ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адесына гражданнардан 14 мөрәҗәгать керде, шул исәптән:

гаиләләрдән балаларны алуның 7 факты буенча 9 хәбәр: Казан шәһәреннән – 2 очрак, калганнары Алабуга, Зәй, Чаллы, Чистай, Зеленодольск шәһәрләреннән;

гаиләләрдән балаларны алуны янауның 3 факты буенча 5 хәбәр: Ютазы муниципаль районыннан, Чаллы шәһәреннән.

Балаларны алу факты буенча һәр хәбәр Эшче төркем тарафыннан урыннарга барып тикшерелде.

Барып тикшерү йомгакларыннан күренгәнчә, гаиләләрдән балаларны алуның 7 факты буенча 5сенең законсыз булуы расланмады (Казанда – 2, Алабуга, Зәй, Чаллы шәһәрләрендә), бу юнәлештә күрелгән чаралар законлы дип һәм алар балаларны яклау мәнфәгатьләрендә башкарылган дип танылды.

Барып тикшерү йомгаклары буенча гаиләләрдән балаларны алуның калган 2 факты буенча (Чистай һәм Зеленодольск шәһәрләре) мөрәҗәгать итүчеләрнең дәлилләре расланды, муниципаль районның хакимият органнары тарафыннан балаларны алу буенча күрелгән чаралар законга нигезләнмичә, гаиләдән балаларны алу аларның хокукларын бозып башкарылган дип танылды. Аның буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан район җитәкчелеге исеменә, балаларны социаль приютлардан алып, кичекмәстән гаиләләренә кире кайтару буенча тиешле таләпләр җибәрелде, нәтиҗәдә, алар канәгатьләндерелде.

Эшче төркем эшчәнлеге йомгаклары буенча Татарстан Республикасында гаиләдән балаларны алу практикасын анализлау әлеге нотыкның өченче бүлегендә китерелә.

1.9. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең проект эшчәнлеге

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегендә балалар мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү механизмын камилләштерү өчен кайбер республика проектларын һәм чараларын гамәлгә ашыру буенча эшләр башкарылды.

Бала хокукларылда әһәмияте буенча төп һәм өстенлекле юнәлешләрнең берсе аның гаиләдә яшәү һәм тәрбияләнү хокукы булу. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы белән республикада гамәлгә ашырыла торган кайбер проетлар әлеге хокукны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән.



Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруга ярдәм итү, шул исәптән Татарстан Республикасында 2011 елда Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов тәкъдиме белән башланып киткән **«Баланың видеопапорты»** проектын гамәлгә ашыру 2017 елда да дәвам итте.

Проект ятим бала турында максималь тулы, дөрес мәгълүматны үз эченә алган һәр бала турындагы 40 минутлы фильм рәвешендә балаларның видеопаспортларын булдырудан гыйбарәт, ул бала алуга кандидат ата-аналарга бала белән якыннанрак танышырга мөмкинлек бирә. Моннан тыш, **«Видеопаспорт»** проекты гаиләгә балаларны урнаштыру эшендә федераль мәгълүмат ресурсыннан файдалануны күз алдында тота, бу ата-анага кандидатларның һәм балаларның бер-берсен табу мөмкинлекләрен киңәйтә: WWW.VIDEOPASPORT.RU Интернет сайтында видеопаспортларны урнаштыру, 2017 елның сентябренә кадәр – «Беренче канал»да һәм 2017 елның сентябреннән «Россия 1» каналында бара торган «Пока все дома» программасының «Сезнең балагыз булачак» рубрикасында ятим балалар турында сюжетлар ясау һәм күрсәтү мөмкинлекләре дә ул.

Гадәттәгечә, проектта Татарстан Республикасыннан гаилә тормышын җайга салуда кыенлыклар булган ятим балалар катнашты. Болар – күпбалалы гаиләләрдән балалар (3 һәм аннан күбрәк), өлкән яшьтәге балалар (9 – 14 яшь), инвалид балалар һәм сәламәтлеге чикле булган балалар.

Җиде ел эчендә барлыгы 430 ятим балага видеопаспорт ясалды (2011 елда – 32 видеопаспорт, 2012 елда – 31 видеопаспорт, 2013 елда – 43 видеопаспорт, 2014 елда – 56, 2015 елда – 94, 2016 елда – 109). Болар 37,9 млн. сумга төште. 2018 елның 1 февраленә 300 бала үз гаиләләрен тапты.



Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил башлап җибәргән һәм Татарстан Республикасы Президенты ярдәме һәм аның кушуы белән 2015 елда гамәлгә кергән «Аек акыл» пилот проекты 2017 елда да дәвам итте, ул социаль ятимлекне профилактикалауга юнәлдерелә.

Гаиләләр таркалу, балалар ятимлеге, балигъ булмаганнар арасында һәм аларга карата җинаятьчелек, балалар сәламәтлегенә физик һәм психик зыян килү – моңа сәбәпче булган, хәтта баланы ата-анадан тартып алуга, баланы тораксыз калдыруга китерә торган халәттән – ата-ананы алкогольгә бәйлелектән котылуга нәтиҗәле ярдәм итү чаралары комплексta каралырга тиеш. Республикада алкогольгә бәйле гражданнарга медицина ярдәме күрсәтү буенча аерым система булдырылды. Бу вәзгыять гаилә һәм балалар бүхетсезлеген профилактикалау буенча өстәмә чарлар күрүне таләп итә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына муниципаль органнардан – гаилә һәм балалар проблемаларын профилактикалау субъектларыннан килгән мөрәҗәгатьләр әлеге эшнең нәтиҗәлелеген арттыру турында уйланырга мәҗбүр итә. Шуңа бәйле рәвештә 2015 елда эшли башлаган «Аек акыл» программасы чараларын гамәлгә ашыру 2017 елда да дәвам итте.

Татарстан Республикасында «Аек акыл» проектын гамәлгә ашыру Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тәкъдиме буенча балалар мәнфәгатьләрендә социаль юнәлеш алды: гражданнарның аерым төркемен – алкогольгә бәйлелектән интегүче, үзләренә карата ата-ана хокукыннан мәхрүм итү мәсьәләсе карала торган хатын-кызларны дәвалау турында карар кабул ителде.

Татарстан Республикасында проектның принципиаль үзенчәлеге аның ведомствоара характерда булуыннан гыйбарәт. Программада алкогольгә бәйлелек белән чирләүчене терапия курсына җәлеп итү, психотерапия сеансы һәм «Налтрексон пролонг инъекцияләре» препараты ярдәмендә инъекция ясау каралган, шулай ук бер үк вакытта дәваланучыны һәм аның гаиләсен башка (медицинага карамаган) проблемаларны җиңеп чыгу өчен актив социаль-реабилитация процессына җәлеп итү дә карала. Соңгы чараны куллану балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләренә йөкләнә. Гаилә бәхетсезлеген профилактикалау субъектлары органнары шулай бергәләп эшләгәндә генә проектны гамәлгә ашырудан уңай нәтиҗәләр көтәргә була.

Шуңа күрә проект Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе тарафыннан расланган проектта катнашучы органнарның һәм учреждениеләрнең хезмәттәшлеге регламенты нигезендә ведомствоара координация киңәшмәләен үткәрү, Вәкаләтле вәкил каршындагы Координация комитеты утырышларында проектны гамәлгә ашыруның барышы хакында фикер алышу күздә тотыла.








Проектның беренче этабы (2015 елның октябре – 2016 елның марты) уңышлы узуын искә алып, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан проектны дәвам итү турында кара кабул ителде. Аны пролонгацияләү өчен 5,8 млн. сум акча бүленде. Икенче этап (2016 елның октябре – 2017 елның марты) 2017 елда тәмамланды. Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2015 – 2017 елларда медико-социаль реабилитация курсын 90 ата-ана узды, гомуми сумма 11,2 млн. сум тәшкил итте. Дәваланууның тулы курсын 78 кеше уңышлы узды (проектта катнашучыларның 87%), нәтиҗәдә 186 бала үз гаиләләрендә калды.

2017 елның ноябреннән проектның өченче этабы башланды. Аны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан 9,1 млн. сум акча бүлеп бирелде. Проектка 70 ата-ана кертелде, аларның гаиләрендә 178 бала исәпләнә.



2017 елда ***«Остазлар: бергә түгел, әмма янәшәдә!»*** *проектына старт бирелде*, ул Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, «УМАЙ» Идел буе гаилә академиясе» АНО ярдәмендә гамәлгә ашырыла. Проект балаларның һәм яшүсмерләрнең деструктив тотышын профилактикалау проблемаларын хәл итүгә, хокук бозган балигъ булмаганнарны реабилитацияләүгә һәм социальләштерүгә юнәлдерелә.

Проектның максаты – Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалауның гамәлдәге дәүләти-иҗтимагый моделен граждан активистлары (җәмәгать тәрбиячеләре) эшчәнлеген хокук бозган балигъ булмаганнар белән эшләүдә остазлык прораммасы белән тулыландыру аша камилләштерү.

Проект чарасында балигъ булмаганнарның кабат хокук бозуларын профилактикалау системасына җирле җәмәгатьчелекне җәлеп итү күздә тотыла. Остазлык программасы җәмгыятьнең сәламәт ресурсларын балигъ булмаганнарның хокукка каршы модельләрен профилактикалау мәсьәләләрен хәл итү өчен берләштерергә юнәлдерелгән.

Шәхеснең хокукый һәм гражданлык компетентлыгы кешенең гомуми культурасының мөһим өлешен тәшкил итә, аның социаль-хокукый, гражданлык активлыгы, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуда катнашырга әзер булы да шуңа бәйле. Хокукый агарту бурычларын гамәлгә ашыруда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан даими һәм системалы рәвештә берничә проект эшли. Бу проектлар, башлыча, балалар аудиториясенә карый.



2015 елдан башлап балаларны һәм яшүсмерләрне хокукый агарту һәм аларда актив гражданлык позициясен булдыру рәвеше – ***«Балалар*** *җәмәгать* ***кабул итүе» республика укыту проекты*** уңышлы эшләп килә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» (алга таба – БОС) Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы региональ иҗтимагый оешмасы белән берлектә гамәлгә ашырыла торган *«Балалар җәмәгать кабул итүе»* республика проекты бала хокукларын яклау механизмнарын камилләштерүгә ярдәм итүдә яңа эшчәнлек рәвеше булды. Проект Татарстан Республикасы балаларын хокукый агартуга, балаларда актив тормыш һәм гражданлык позициясен булдыруга, аларда позитив мораль-этик һәм әхлакый кыйммәтләр тәрбияләүгә, яшь гражданнарны үз тормышларына кагылышлы мәсьәләләргә җәлеп итүгә, шулай ук Татарстан Республикасында яшәүче балаларның

һәм яшьләрнең хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруга һәм яклауга ярдәм итүгә юнәлдерелде.

Республика гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен конкурс оештырылды. Хәзерге вакытта республика буенча «Балалар җәмәгать кабул итүе» оешмасыннан 53 әгъза Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ярдәмчесенә әверелде. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карары буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар арасыннан беренче җәмәгать ярдәмчеләре булды. «Балалар җәмәгать кабул итүе» проекты беренче чиратта анда катнашучы балалар өчен укыту проекты булып тора. Аның төп тәшкилияте – балалар хокукларын яклау тематикасы белән катнашучыларны таныштыруга юнәлдерелгән профильле сменалар кысаларында гамәлгә ашырыла торган укыту программасы, аңа хокукый мастерклассар, тренинглар, эшлекле, интеллектуаль һәм мәдәни-танып белү уеннары, төрле министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре белән очрашулар керә.

2017 елда дүрт профильле смена оештырылды, алар «идел» яшьләр үзәге» ДАУ базасында узды. Сменаларны БОС, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил оештырдылар.

Беренче профильле смена – *2017 елның 26 – 29 мартына кадәр* – 2016 елның декабрендә конкурстан узган җәмәгать ярдәшчеләрен җыйды.







Беренче смена кысаларында балалар Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән очраштылар, аның аппарытының эшчәнелеге белән таныштылар, Татарстан Республикасының Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе җаваплы секретаре И.Х.Гарифуллина белән очраштылар һәм балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләренең урыннардагы эшчәнлеге белән таныштылар. Сменада катнашучылар очрашу вакытында үзләрен кызыкындырган сораулар биреп, аларга җаваплар алдылар. Очрашу азагында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләренә тантаналы рәвештә таныклыклар тапшырылды.

Смена кысаларында мастер-классларны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы В.Н.Демидов, Татарстан Республикасы прокуратурасының балигъ булмаганнар һәм яшьләр турында законнарның үтәлешенә күзәтчелек итүче бүлек башлыгы А.Ф.Хөсәенов, «ImCompany» брендинг һәм коммуникацияләр агнетлыгы җитәкчесе, яшүсмерләр өчен «Фракция» интернет-ММЧын гамәлгә куючы А.А.Аксенова үткәрделәр.



Икенче смена *2017 елның 19 – 22 маена кадәр* барды. Сменада катнашучылар белән түбәндәгеләр очрашты:

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л.Удачина белән – «Балалар һәм яшүсмерләр гомеренә һәм сәламәтлегенә интернет-хәтәрлекләрен һәм куркыныч янавын профилактикалау өлкәсендә өстәмә чаралар күрү турында»гы мәсьәлә







буенча, Татарстан Республикасы прокуратурасының балигъ булмаганнар һәм яшьләр турында законнарның үтәлешенә күзәтчелек итүче бүлек башлыгы А.Ф.Хөсәенов белән – теме «Балигъ булмаганнар арасында хоку бозуларны профилактикалауның актуаль мәсьәләләре турында»гы тема буенча;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе башлыгы Л.Р.Габдрахманов белән – «Балаларның юл-транспорт имгәнүләрен профилактикалау һәм профилактикалау бурычларын хәл итүдә балалар җәмгәгать ярдәмчеләренең ресурслар» темасы буенча, Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре И.Х.Гарифуллина белән – балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләр эшчәнлеге темасы буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең оештыру бүлеге баш киңәшчесе Ю.В.Корнилов белән – «Татарстан Республикасында яшь буынны коррупция каршы тәрбияләү» темасы буенча;

«МТС» гавами АҖенең җәмгәгатьчелек белән элемтәләр буенча менеджеры п Е.Ю.Гаврилова белән – «Балалар Интернетта» проектын презентацияләгәндә.

2017 елның *4 – 7 сентябренә кадәр* өченче укыту сменасы узды. Сменада катнашучылар 6 сентябрьдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советында булдылар, анда парламент музее белән таныштылар һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Мәгариф, фән, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе урынбасары Анастасия Георгиевна Исаева белән очраштылар. Аңа Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаталары белән хезмәттәшлек итү буенча балалар җәмгәгать ярдәмчеләре проектлары күрсәтелде, алар депутат тарафыннан хупланды.







Шул ук көнне җәмгәгать ярдәмчеләре Татарстан Республикасы прокуратурасында булдылар, аның музее белән таныштылар, Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре И.Х.Гарифуллина,



балигъ булмаганнарның һәм яшьләр турындагы законнарның үтәлешенә күзәтчелек бүлеге башлыгы Д.Х.Ибраһимов белән очраштылар.



7 сентябрьдә Татарстан Республикасында Бала хо-

куклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратының бүлек башлыгы Э.Р.Сафина «Балигъ булмаганнарның хокукларын яклау өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу» темасына мастер-класс үткәрде. Проектта катнашучылар бала хокукларын яклау өлкәсендә гамәлдәге законнар нигезләмәләре белән таныштылар.

Проектның дүртенче сменасы 2017 елның *20 – 21 декабренә кадәр* булды. Сменада катнашучыларга Россия Федерациясендә 2018-2027 елларны «Балалыкның унъеллыгы» дип игълан итъү турында Президент указын гамәлгә ашыру буенча төбәк чарпалар планына керерлек *«балалар чаралары»* планы, проектлары өстендә эшләргә тәкъдим ителде. Сменада шулай ук 2017 елда балалар җәмәгать ярдәмчеләре эшенә йомгаклар ясалды.

Өч ел эчендә проект аша республикадан барысы 106 бала узды. балалар җәмәгать ярдәмчеләре тарафыннан балаларны хокукый агарту буенча 195 укыту проекты, 1 000нән артык тематик чаралар үткәрелде, яшьтәшләр белән очрашулар уздырылды.









Балаларны хокукый агарту, аларда гражданлык һәм социаль активлык булдыру, аларның ижади сәләтләрен үстерү бурычларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән тагын бер проект – ***«Ребенок в мире прав» – «Бала хокук даирәсендә» республика мәгълүмати-социаль видеороликлар конкурсы.***

Әлеге конкурс 2014 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәмендә һәм әлеге органнар тарафыннан гамәлгә куелган иде. Конкурсны шулай ук Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе, «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» (алга таба – БОС) региональ иҗтимагый оешмасы оештыра. Конкурсның максатлары түбәндәгеләр: балалар һәм өлкәннәр җәмәгатьчелеген, дәүләт һәм муниципаль органнарны, оешмаларны республикада балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү мәсьәләләренә җәлеп итү, балалар хокукларын популярлаштыру, балаларны һәм яшьләрне мәгълүмати-хокукый агарту, аларның социаль-хокукый активлыгын кызыксындыру, хокукый гыйлемне һәм хокукый культураны үстерү, шулай ук үсеп килүче буында ижади сәләтләрне үстерү.



2017 елның сентябреннән ноябренә кадәр республикада чираттагы, дүртенче республика конкурсы узды.

Дүртенче конкурска старт, гадәттәгечә, 2017 елның 11 сентябрендә «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясендә бирелде.

Балалар һәм яшьләр арасында конкурсның популярлыгы елдан-ел арта:


беренче Конкурска (2014 елда) республиканың 33 район һәм шәһәреннән 160 видеоролик алынды;

икенче Конкурста (2015 ел) жюри карамагына республиканың 38 район һәм шәһәреннән 318 ролик керде;

2016 елда Конкурска Татарстан Республикасының барлык районнарыннан 419 конкурс эше алынды. Бу эшләрне төзүдә 2 меңнән артык кеше катнашты.

14 нче диаграмма


2017 елда «Ребенок в мире прав» – «Бала хокук даирәсендә» республика мәгълүмати-социаль видеороликлар конкурсына муниципаль районнардан (шәһәр округларыннан) кергән эшләр саны



Дүртенче конкурска республиканың 44 муниципаль районыннан (шәһәр округларыннан) 736 конкурс эше керде. Аларны эшләүдә 3 меңнән артык кеше катнашты, аеруча активлык күрсәтүчеләр: Казан шәһәреннән (88 эш), Түбән Кама районыннан (64 эш), Чаллы, Әлмәт, Лениногорск районнарыннан (33әр эш), Нурлат районыннан (25 эш), Менделеевск районыннан (21 эш), Тукай районыннан (19 эш), Лаеш һәм Буа районнарыннан (18 әр эш).

15 нче диаграмма

2014 – 2017 елларда «Ребенок в мире прав» – «Бала хокук даирәсендә» республика мәгълүмати-социаль видеороликлар конкурсында катнашу динамикасы



Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, 2016 елдан башлап авторларның үз роликларын «Интернет» челтәрендә дә урнаштыру мөкинлеге бар. 2016 елда аларны 15,5 меңнән артык тамашачы карады, 2017 – 50 меңнән артык.

Дүртенче Конкурсның жюри составына түбәндәгеләр керде: Г.Л.Удачина – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил – жюри рәисе, Ф.С.Гыймалдинов – ФГУП ВГТРК филиалы «Татарстан» ДТРК директоры, жюри рәисе урынбасары, Ф.Г.Хөснетдинов – Татарстан Республикасы Конституция суды рәисе, С.Х.Сабурская – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Л.Р.Габдрахманов – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе башлыгы, В.Н.Циома – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү комитеты җитәкчесе урынбасары, В.Н. Демидов – Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарә башлыгы, З.Х.Ибраһимов – Татарстан Республикасы прокуратурасының бүлек башлыгы, Д.А.Туманов – «Созвездие-Йолдызлык» фестиваленең генераль продюсеры, А.Ф.Вәлиева – «Ак Барс Созидание» Хәйрия фонды директоры, Т.В.Забегина – Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Р.А.Сәхәбетдинова – «Яңа гасыр» ТРК «Балалар, яшьләр тапшыруы» иҗат берләшмәсе директоры, С.В.Шерстнев – «Эфир» телеканалының яңалыклар хезмәте шеф-мөхәррире, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары вәкилләре.



2017 елның 13 ноябрендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л.Удачина рәсилегендә дүртенче конкурсның жюри утырыш узды, анда конкурсның җиңүчеләре билгеләнде.

Конкурсның җиңүчеләре булып күбрәк балл җыйган 10 конкурс эше авторы танылды:

1. Венаков Даниил – Казан шәһре Идел буе районының «Лицей № 83 – Белем үзәге» МБОУ укучысы, видеоролик: «Рэп:«Конвенция о правах ребенка»;

2. Хорошилов Дмитрий, Невматуллина Ильмира – Чаллы шәһәренең «Балалар һәм яшүсмерләр өчен АСЫЛТАШ» социаль приюты» ДКУ иҗат коллективы, видеоролик: «Хочу домой!»;

3. Поздеева Вероника, Гарифуллин Тимур, Долгов Ринальд, Чуев Михаил, Габсәләмова Латыйфа, Беляева Татьяна – Әлмәт шәһәренең «Белоснежка» балалар бакчасы № 54» МБДОУ иҗат коллективы, видеоролик: «Мы дорожные правила знаем – свое право на жизнь охраняем!»;

4. Мансурова Гүзәл, Павлова Анастасия, Кадаш Вячеслав, Зәһидуллин Рамил – «Казан балалары» («Дети Казани») иҗат студиясе, видеоролик: «Я – твоя семья»;

5. Гомәров Айдар, Геппа Карина – Казан шәһәренең «Лицей № 35 – «Галактика» белем үзәге» МБОУ укучылары, видеоролик: «Мы – есть!»;

6. Антонова Мария – Әлмәт шәһәренең «Золушка» 46 нчы балалар бакчасы – Балаларны өйрәтү үзәге» МБДОУ тәрбияләнүчесе, видеоролик: «Минем туган телем»;

7. Нургалиев Роман – Чаллы шәһәренең «Золушка» 44 нче катнаш балалар бакчасы» МБДОУ вәкиле, видеоролик: «Право на образование»;

8. Григорьева Регина, Югары Ослан районы, видеоролик: «Право на Маму»;

9. Әхмәтҗанов Илдан – Ютазы районының»2 нче Урыссу төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ укучысы, видеоролик: «Право на жизнь»;

10. Мишин Дмитрий, Сюлюкин Вадим, Гордеев Богдан, Сибгәтов Кәрим, Николаева Дарья, Маковская Евсения, Зарипова Сабина, Зарипова Мәликә, Мөхәммәтшин Рүзәл, Золотова Елизавета – Казан шәһәре «Алга» яшүсмерләр клубының «Ерашок» сатира һәм юмор эстрада театрының иҗат коллективы, видеоролик: «Детство одно на всех».

Социаль челтәрләрдә урнаштырылган видеороликларга уңай бәяләүләр саны буенча тамашачылар симпатиясе призына Мәслим районының «Ләйсән» балалар бакчасы һәм Митрәй башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе ижат коллективы ия булды, аларның ролигы «Не лишайте нас права иметь семью».



IV Конкурска йомгаклар ясау, гадәттәгечә, Бөтендөнья балалар көнендә – 2017 елның 20 ноябрендә тантаналы төстә узды. Җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү тантанасы «Корстон» мәдәни-күңел ачу комплексында узды, аңа республикадан 250дән артык бала чакырылган иде.

Конкурста җиңүчеләр липломнар һәм 20 000 сум күләмендә акчалата премияләр белән бүләкләнделәр.



Җиңүчеләрдән тыш, жюри әгъзалары инициативасы белән, җиңүчеләр исемлеген кермәгән 14 эшнең авторлары е членов жюри авторы призлар һәм рәхмәт хатлары белән бүләкләнделәр. Дүртенче конкурста катнашып, икенче этапка үтүчеләрнең барысы да, алар 441 эш авторы, конкурста катнашу турында таныклыклар алдылар.













Конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү тантанасында түбәндәгеләр катнашты:


Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе рәисе В.Г. Шәйхразиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы журналистлар берлеге рәисе Р.А.Ратникова, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе җитәкчесе Т.П.Ларионова, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил С.Х.Сабурская,Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе Л.Р.Фазлыева, Татарстан Республикасы буенча федераль инспектор Р.З.Тимержанов, председатель Татарстан Республикасы Конституция суды рәисе Ф.Г.Хөснетдинов, Татарстан Республикасы Юстиция министры Р.М.Зайдуллин, Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Н.В.Бутаева, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы, конкурсның жюри













әгъзасы Л.Р.Габдрахманов, Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасары, конкурсның жюри әгъзасы О.А.Дәминов, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү комитеты җитәкчесе урынбасары В.Н.Циома, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе Г.З.Габдрахманова, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы җитәкчесе урынбасары И.Ф. Миргалимов, Татарстан Республикасы Яшьләр һәм спорт министрлыгы урынбасары Р.М.Гарифуллин, «Созвездие-Йолдызлык» сәләтле балаларга һәм яшьләргә ярдәм итү республика үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учрежденисе директоры Д.А.Туманов, «АК БАРС ЯҢАРЫШ» хәйрия фонды директоры А.Ф. Вәлиева, «Эфир» телеканалының яңалыклар хезмәте шеф-мөхәррире С.В.Шерстнев.

2016-2017 елда җиңүчеләрнең видеороликлары «Татарстан Республикасында электрон белем бирү» ГИСта (алга таба – Портал) урнаштырылды һәм алар белән «Ученику-Творческаядеятельность-Конкурсы» бүлегендә теркәлгән кулланучыларның барысы да таныша алаларhttps://edu.tatar.ru/scontest/index/31.

Балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү чараларын көчәйтү һәм хокукый агарту бурычларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, «МТС» гавами АҖенең Татарстан Республикасы филиалы белән берлектә 2017 елның октябрендә республиканың барлык мәктәпләрендә ***файдалы һәм имин интернет айлыгы*** (алга таба – Айлык) оештырылды һәм үткәрелде.

Айлык чаралары кысаларында түбәндәгеләр үткәрелде:

республиканың барлык мәктәпләренең башлангыч звено сыйныфларында файдалы һәм имин интернет дәресләре;

башлангыч мәктәп ата-аналары өчен ата-аналар җыелышлары;

педагоглар белән уку семинарлары.

Белем бирү дәресе нигезенә «Мобиль ТелеСистемалар» Гавами АҖ белгечләре һәм Интернетны үстерү фонды экспертлары тарафыннан эшләнгән һәм Мәгарифне үстерүнең федераль институты (ФИРО) тарыфыннан кече сыйныф укучыларына өстәмә белем бирү өчен тәкъдим ителгән методика салынган.

Файдалы һәм имин Интернет дәресенең максаты – кече яшьтәге мәктәп балаларына Глобаль челтәрнең – Интернеттан файдалануның – төрле уңай һәм тискәре якларын мөмкин кадәр киңрәк күзалларга ярдәм итү.

Дәрес нигезендә – иминлекнең җиде кагыйдәсе ята, алар проектның төп геройлары Митясик һәм Интернешка арасында була торган мультипликацион вакыйгалар нигезендә формалаша. Һәр вакыйга интернет-мохитнең берәр куркыныч ягын ача һәм балага шундый хәлдә үзен ничек тотарга кирәклеген өйрәтә. Дәресләр интерактив уен рәвешендә бара, бу уку процессын мавыктыргыч һәм кызыклы итә, балалар тарафыннан материалны тиз үзләштерергә ярдәм итә.




Проектка старт Россиядә Интернет көнендә бирелде, ул 30 сентябрьдә билгеләнеп үтелә. Айлык башлануга багышланган матбугат конференциясе 2017 елның 29 сентябрендә «Татмедиа» матбугат үзәгендә узды.

Матбугат конференциясендә түбәдәгеләр катнашты: Удачина Гүзәл Любисовна – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Мөхәммәтов Илдар Ринат улы – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министр урынбасары, Камалетдинова Татьяна Сергеевна – Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының «Татарстан Республикасы мәгълүмат технологияләре үзәге» ДУП башкарма директоры, Гарифуллина Илсөяр Хәләлетдин кызы – балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларны яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре, Перцев Антон Павлович – директор по продажам на массовом рынке филиала ПАО «МТС» гавами АҖенең Татарстан Республикасы филиалының массакүләм базарында сәүдә директоры.

2017 елның 29 сентябрендә Казан шәһәре Вахитов районының «Инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган 39 нчы урта гомуми белем җирү мәктәбе» МАОУ башлангыч сыйныфларының берсендә файдалы һәм имин Интернет буенча беренче ачык дәрес булды. Дәрескә массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашты, дәрес онлайн-трансляция аша алып барылды.









Проект башланыр алдыннан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм МТС белгечләре белән берлектә сентябрь буе Чаллы, Түбән Кама, Казан, Зеленодольске шәһәрләрендә, шулай ук район мәктәпләре педагоглары өчен видеоконференция форматында уку семинарлары үткәрелде. Бу укуларны 400 укытучы узды. Семинарларда педагогларга балалар һәм ата-аналар җыелышлары өчен дәресләр уздыруга методик материаллар тәкъдим иттеләр.



Барлык методик материаллар «Татарстан Республикасында электрон белем»: https://edu.tatar.ru/internet_deti ДМСында (ГИС), шулай ук safety.mts.ru сайтында урнаштырылды

2017 елның 27 сентябрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында балаларның мәгълүмат иминлеген тәэмин итү мәсьәләсе буенча семинар-киңәшмә уздырылды.











Чарада республиканың профильле министрлыклары һәм ведомстволары белгечләре, мәгълүмат-коммуникация технологияләре буенча методистлар, Татарстан Республикасының гомуми белем бирү учреждениеләренең балалар мәгълүмат иминлеге мәсьәләсендә компетентлы һәм шул өлкәне алып баручы педагоглары (тьюторлар) катнашты.

«Интернет» челтәрендә балаларның мәгълүмат иминлеген яклау буенча өстәмә чаралар күрү турында»гы нотык белән Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратының балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау бүлеге башлыгы Э.Р.Сафина чыгыш ясады.

Чараның практик өлешендә гомуми белем бирү учреждениеләренең балалар мәгълүмат иминлеге мәсьәләсендә компетентлы һәм шул өлкәне алып баручы педагоглары (тьюторлар) өчен уку семинары үткәрелде. Семинар Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында – mon.tatarstan.ru – онлайн – режимда трансляция буенча бирелде.

Айлык йомгаклары буенча 2017 елның октябрь ае буена файдалы һәм имин Интернет дәресләре республиканың 1 317 мәктәбендә бирелде, аларда 202 641 бала катнашты. Тематик гомуми укуда катнашкан ата-аналар саны 146 623 кешегә җитте.























Балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау форматында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан даими нигездә үткәрелә торган чараларның тагын берсе – ***«Балалар соравы» хокукый ярдәм көннәре.***

Бу проект республикада ведомствоара нигезендә барлык кызыксынучы һәм балалар өлкәсен дә эшләүче министрлыклар, ведомстволар, хокук саклау һәм контроль-күзәтчелек органнары катнашында гамәлгә ашырыла.

Гражданнарга Хокукый ярдәм көннәре кысаларында балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча 20ләп ведомство белгечләре консультацияләр бирделәр, аңлатулар алып бардылар, ярдәм күрсәттеләр, болар:

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил,

Татарстан Республикасы прокуратурасы,

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы,

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы,

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы,

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы,

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы,

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы,

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы,

«Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча медико-социаль экспертизаның баш бюросы» ФКУ,

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы Идарәсе,

Кулланучылар хокукларын һәм иминлеген яклау буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсе (Татарстан),

«Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы» НКО,

Россия Федерациясе Социаль иминләштерү фондының – Дәүләт учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе,



Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе,

Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлекчәсе,

Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе һәм башкалар.

2017 елда ике Хокукый ярдәм көне үткәрелде:

1 июньдә – Татарстан халыклары дуслыгы йортында, Балаларны халыкара яклау көненә багышланган;

25 октябрьдә – Габдулла Тукай ис. Татар дәүләт филармониясе бинасында.

Моннан тыш, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты белгечләре 2017 елның 21 ноябрендә үткәрелгән Бөтенроссия балаларга хокукый ярдәм күрсәтү көнендә катнаштылар.

2017 елда гамәлгә ашырылган барлык проектлар буенча эшләрне 2018 елда да дәвам итү планлаштырыла.

1.10. Балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерү эшчәнлеге

Бала хокукларын яклауда нәтиҗәле эшчәнлеккә ирешүдә тиешле механизмнар эшләү максатларында бала хокукларын яклауның Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән хезмәттәшлек итү гамәлгә ашырыла. Республикада Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институты эшли башлаганнан бирле мондый хезмәттәшлек итүнең тотрыклы практикасы барлыкка килде.

Башка ***контроль-күзәтчелек органнары белән конструктив хезмәттәшлек*** бала хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү механизмын камилләштерүгә ярдәм итә. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең федераль күзәтчелек органнары белән хезмәттәшлеге үзара хезмәттәшлек итү турында төзелгән килешүләр нигезендә алып барыла. 2012 елдан бирле мондый хезмәттәшлек Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең (Роспотребнадзор) Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән, 2015 елдан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты, 2016 елдан – Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек (Роскомнадзор) буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсе белән гамәлгә ашырыла.

2012 елдан башлап шундый килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе, Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, җәза үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, «Медик-социаль экспертизаның Татарстан Республикасы буенча баш бюросы» федераль казна учреждениесе белән эшләр алып барыла. Бала

хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында 2016 елда шундый ук килешүләр коммерциячел булмаган оешмалар белән дә төзелде. 2017 елда мондый килешү Россия Федерациясенең Гражданнар оборонасы, гадәтән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү буенча Татарстан Республикасы баш идарәсе белән дә төзелде.

Федераль структураалар белән хезмәттәшлек итү форматы түбәндәгеләр:

гражданнарны уртак кабул итү (тулырак мәгълүмат нотыкның 1.1 бүлегендә бирелә);

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы координацион киңәшләшү органнары (Вәкаләтле вәкил каршындагы Координацион комитет, Вәкаләтле вәкил каршындагы Балаларны гаиләдән алуны анализлау буеенча эшче төркем) эшендә катнашу;

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең кайбер федераль структураларның (Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы идарәсе, «Медик-социаль экспертизаның Татарстан Республикасы буенча баш бюросы» ФКУ, Россия Федерациясе Социаль иминләштерү фондының – дәүләт учреждениесенең – Татарстан Республикасы буенча төбәк идарәсе) иҗтимагый һәм координацион советларында әгъзалыгы;

уртак тикшерүләр;

аермы мәсьәләләр буенча эшче киңәшмәләр практикасы.

2017 елда суд органы – ***Татарстан Республикасы Конституциясе суды*** белән хезмәттәшлек итү тиешле килешү белән документаль беркетелде. Әлеге килешү яклар тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче балалы гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү юлы белән балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау гарантияләрен тәэмин итү максатларында, шулай балаларның бозылган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызуга ярдәм итү һәм дәүләт хакимияте органнарының ачыклыгын булдыру максатларында төзелде.

Татарстан Республикасы ***дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары*** белән хезмәттәшлек итү шулай ук конструктив нигезгә корылган. Контроль органнары белән үзара мөнәсәбәтләрне бары тик хакими күзәтчелек вәкаләтләрен гамәлгә ашыру шартларында гына алып бару тиешле нәтиҗәләр бирмәячәген аңлап, уртак максатларга ирешү өчен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан республика министрлыклары, ведомстволары, муниципаль органнар белән актив партнерлык хезмәттәшлеге форматы практикага кертелде. Мондый хезмәттәшлек итүнең иң нәтиҗәле һәм перспектив вариантларыннан берсе – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең республика районнарына һәм шәһәрләренә эш визитлары.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең даими рәвештә ведомствоара, ***координацион, киңәшләшү органнары, эшче төркемнәр, комиссияләр эшендә*** катнашуы аның эшчәнлегенең төп өлешен тәшкил итә.

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хезмәткәрләре даими эшләүче 14 республика комиссиясе, эшче төркемнәр составында балаларга кагылышлы аерым мәсьәләләрне карадылар, шул исәптән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләр составында да әгъза булып калды:

Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе;

Балаларның һшм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны һәм аларның мәшгульлеген оештыру буенча ведомствоара комиссиясе;

Татарстан Республикасы буенча Федераль инспектор каршындагы Гаилә, аналар һәм балалар мәсьәләләре. социаль ятимлекне профилактикалау, ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрәм калган балаларга ярдәм итү буенча эшче төркем;

Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы инвалидлар эшләре советы;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы «Созвездие – Йолдызлык» республика фестивале хәрәкәтенә ярдәм итү советы;

Татарстан Республикасы территориясендә демография һәм гаилә сәясәте өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Торак комиссиясе;

Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия;

Алыштыручы гаиләләрдән балаларны кире кайтару очракларын анализлау буенча Татарстан Республикасы Экспертной комиссиясе;

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм булган балалар оешмаларының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм булган балалар оешмаларының эшчәнлеге, аларда ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру турында» 2014 елның 24 маендагы 481 номерлы карары таләпләренә туры килүен бәяләү буенча эксперт төркеме;

Инвалидларны һәм сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле затларны һөнәри әзерләү һәм аларны эш белән тәэмин итү проблемалары буенча ведомствоара эшче төркем;

Татарстан Республикасында иртә ярдәм күрсәтү системасын үстерү буенча ведомствоара эшче төркем;

Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыру буенча координацион төркем.

Балаларны яклау өлкәсендә ***гражданлык җәмгыяте институтлары*** белән хезмәттәшлек итү дә бик мөһим.

Иң элек, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән хезмәттәшлек институтына игътибар итәргә кирәк: Иҗтимагый палата әгъзалары Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координацион киңәшләшү органнарында актив катнашучылар. Аерым алганда, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координацион комитет әгъзалары, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары Т.В.Забегина, И.Х.Гарифуллина. Алар ук, тагын Т.И.Леонтьева, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының Социаль сәясәт һәм хәйрия эшчәнлеге комиссиясе рәисе, икенче эшче органның – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Галәләрдән балаларны алу практикасын анализлау буенча эшче төркем әгъзалары да булып торалар.

2017 елда җинаять-үтәтү системасы учреждениеләреннән азат ителгән балигъ булмаганнарны тернәкләндерү һәм яраклаштыру, шул исәптән аларга хокукый, консультатив, социаль һәм психологик ярдәм, һөнәр сайлауда һәм хезмәткә урнаштыруда ярдәм мәсьәләләре буенча «Социаль реабилитация һәм адаптация үзәге» коммерциячел булмаган автоном оешма белән үзара хезмәттәшлек итү һәм мәгариф, тәрбия, балалар хокукларын, балалар һәм ата-аналар мөнәсәбәтләрен яклау өлкәсендә балигъ булмаганнарга һәм аларның ата-аналарына психологик педагогик һәм социаль-педагогик мәсьәләләр

буенча «Параллель» Татарстан Республикасы мәктәп психологлары ассоциациясе» коммерциячел булмаган партнерлыгы белән үзара хезмәттәшлек итү дәвам итте.

Ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ел дәвамында Татарстан Республикасында инвалид балалар ата-аналарының «Кайгырту» («Забота») иҗтимагый оешмасы белән, инвалид балалар ата-аналарының «Могҗиза бүләк ит» («Подари чудо») республика хәйри иҗтимагый оешмасы белән, «Татарстан Республикасының төбәк иҗтимагый оешмасы», Ретта синдромы белән авыручыларга ярдәм ассоциациясе, «АК БАРС ЯҢАРЫШ» хәйрия фонды, Анжела Вавилова фонды, «Дом Роналда Макдоналда» хәйрия фонды, гаиләләрне яклау буенча «Родительское всероссийское сопротивление» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының төбәк бүлекчәсе һәм башкалар белән хезмәттәшлек итте.







Дәүләт хакимияте органнары белән һәм җәмәгатьчелек белән аралашуда мөһим фактор буларак ***Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең һәм аның Аппараты белгечләренең республикада һәм аннан читтә уздырыла торган гавами һәм иҗтимагый мәйданчыкларда*** (семинар-киңәшмәләрдә, форумнарда, «түгәрәк өстәлләрдә», конференцияләрдә) катнашуларын әйтеп китәргә кирәк.

2017 елда балалар мәнфәгатендә Россия эчендәге төбәкара һәм халыкара хезмәттәшлекне үстерү Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегендәге төп юнәлешләренең берсе булып калды. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балалар мәнфәгатьләрендә Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкил белән ***төбәкара хезмәттәшлекне*** дәвам итте. Хезмәттәшлек түбәндәге форматларда барды: Россия Федерациясе субъектларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән бергә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау, бала хокуклары мәсьәләләре буенча икеяклы консультацияләр, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Бөтенроссия һәм төбәкара форумнарда, конференцияләрдә, семинарларда, киңәшмәләрдә катнашуы.

Узган ел Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкил А.Ю.Кузнецова оештырган түбәндәге чараларда катнашты:

«Балигъ булмаганнар арасында суицидларны профилактикалау» темасына бөтенроссия селектор киңәшмәсендә (20 март);

балаларның җәйге ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча бөтенроссия селектор киңәшмәсендә (29 июнь);

Россия Федерациясе субъектларында вщкалщтле вщкиллщрнеж Координацион советы Президиумының бөтенроссия селектор киңәшмәсендә, анда Россия Федерациясе Президентының 2017 елның 01 гыйнварындагы Пр-21 номерлы йөкләмәсен үтәү мәсьәләсе буенча фикер алыштылар (7 февраль);

балаларны халыкара урлауның граждан-хокук аспектлары турында 1980 елның 25 октябрендәге Конвенцияне һәм балаларны яклау буенча аналарның җаваплылыгына карата юрисдикция, хокук куллану, тану, үтәү һәм хезмәттәшлек турында 1996 елның 19

октябрендәге Конвенцияне гамәлгә ашыру буенча бөтенроссия фәнни-методик семинар-киңәшмәдә (22 – 23 июнь);

Россия Федерациясе субъектларында бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең Координацион советының йомгаклау утырышында (11 – 13 декабрь).





Утырыш кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Россия балаларына паллиатив ярдәм. Тәжрибә, проблемалар, перспективалар» семинарында «Татарстан Республикасында балаларга паллиатив ярдәм күрсәтүне оештыру» темасына нотык белән чыгыш ясапды.

Төбәкара хезмәттәшлекнең актив формасы – Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән баланы яклауның аерым мәсьәләләре буенча нотыклар һәм башка материаллар белән ***мәгълүмат алмашудан гыйбарәт.*** 2017 елда Бала хокуклары буенча федераль вәкаләтле вәкил А.Ю.Кузнецова таләбе буенча 10 проблемалы һәм 8 мәгълүмати белешмәгә анализ ясалды.



2017 елның 21 – 22 сентябрендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан авыр тормыш хәлендә калган балалы гаиләләргә һәм балаларга ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы тәжрибәсен Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкил Аппараты вәкилләренә тәкъдим итте. Татарстан Республикасына эш визиты белән Аппаратның әйдәүче киңәшчеләре Новосельцева Елена Александровна һәм Некоркин Дмитрий Александрович килделәр.

Визит кысаларында, республика тәжрибәсен исәпкә алып, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил А.Ю.Кузнецованың социаль навигатора – телефон 117 эшләнде.

Россия Федерациясенең башка субъектларыннан Вәкаләтле вәкил тарафыннан 13 проблемалы мәсьәлә каралды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә башка төбәкләрдән дә конкрет балаларга ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очраклар күп була. 2017 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә түбәндәгеләр мөрәҗәгать итте:

Бурятия Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Е.Вежевич балигъ булмаган А.га торак урынын билгеләү мәсьәләсе буенча;

Свердловск өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил И.Р.Мороков балигъ булмаган балалар өчен алимент алу мәсьәләсе буенча;

Чуаш Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Е.В.Сапаркина балигъ булмаган бала өчен алимент алу мәсьәләсе буенча;

Марий Эл Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Е.П.Бурдо балигъ булмаганн Р.ның тормыш хәлен көйләү мәсьәләсе буенча;

Оренбург өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил О.Г.Ковыльская алимент йөкләмәләрен үтәтү мәсьәләсе буенча;

Төмән өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил А.Э.Степанов Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары бозылу һәм балигъ булмаган К.га карата балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләр хезмәткәрләренең үз вазыйфаларын тиешенчә үтәмәүләре турында;

Мәскәү өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил К.В.Мишонова ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрәм калган балаларны торак урыннар белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча;

Ульяновск өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Л.А.Хижняк балигъ булмаган бала өчен алимент алу мәсьәләсе буенча;

Ханты-Манси автоном округы – Югрaда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Д.Моховикова балигъ булмаган Д.ны апасына опекага бирүнең макчатчанлыгы турында карар кабул итү мөсмкинлеге өчен гаиләнең тормыш шартларын тикшерү мәсьәләсе буенча;

Санкт-Петербургта Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил С.Ю.Агапитова инвалид баланы реабилитацияләү чаралары белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча;

Ульяновск өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Л.А.Хижняк балигъ булмаган балалар өчен алимент алу мәсьәләсе буенча.

Үз чиратында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил да балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча коллегаларына мөрәҗәгать итте:

Ульяновск өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Л.А.Хижняк адресына балигъ булмаган Г.га опека билгәү; ятим бала С.ны ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрәм калган балалар исемлегенә кертү мәсьәләсе буенча;

Санкт-Петербургта Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил С.Ю.Агапитова адресына Санкт-Петербург шәһәрендә «Частная школа ЦОДИВ» хосусый гомуми белем бирү учрежденисе эшчәнлеге мәсьәләсе буенча;

Удмуртия Республикасы башлыгы каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил О.Л.Авдеева адресына Татарстан Республикасы Лениногорск балалар йортында тәрбияләнеп чыккан А.ның гаиләсендәге хәлләрне ачыклау турындагы мәсьәлә буенча;

Марий Эл Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Е.П.Бурдо адресына балигъ булмаган П.га опека билгеләү; балигъ булмаган Ш.ның тормыш хәле мәсьәләсе буенча;

Башкортостан Республикасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил М.М.Скоробогатова адресына Башкортостан Республикасының муниципаль сәламәтлек саклау идарәсе Үзәк район хастаханәсенең Дүртөйле авылындагы акушерлык стационарының патология бүлегендәге балигъ булмаган Г.ның хокукларын яклау мәсьәләсе буенча;

Бурятия Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Е.Вежевич адресына балигъ булмаган И.нең тормыш хәлен ачыклау мәсьәләсе буенча.

Алга таба да Россия Федерациясе президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил А.Ю.Кузнецова һәм Россия Федерациясенең башка субъектларыннан коллегалары белән хезмәттәшлекне дәвам итүне планлаштыра.

Бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре өлкәсендә хокукый белем бирүнең һәм дөньяга карашның дөрес формалашуын тәэмин итүнең иң көчле чыганакларының берсе – ***массакүләм мәгълүмат чаралары***. Хисап чорында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән массакүләм мәгълүмат чараларының үзара эшчәнлеге тагын да активлашты.

Бу шул исәптән ***массакүләм мәгълүмат чараларының*** балалар тематикасына тулаем һәм балалар хокук яклаучысы хезмәте эшчәнлеген өлешчә игътибарын арттыруга бәйле.

Ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре белән 69 очрашу уздырды.

Шулардан 4 очракта тематик брифинглар, матбугат конференцияләре, турыдан-туры линияләр, онлайн-конференцияләр оештырылды.





Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 23 мәртәбә телевизион тапшыруларда һәм интервьюда катнашты, 3 мәртәбә радиоэфирга кунак булып барды. 4 басмада Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау эшчәнлеге мәсьәләләре буенча күләмле интервью басылып чыкты.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил массакүләм мәгълүмат чараларына балалар мәнфәгатьләрендә нәтиҗәле хезмәттәшлек өчен рәхмәт белдерә һәм бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләре буенча хокукый карашны җәмәгатьчелеккә җиткерүдә перспектив мөмкинлекләрнең берсе буларак массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлекне дәвам итүне планлаштыра.

1.11. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре институты эшчәнлеге

2017 елда ***Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре институты эшчәнлеге*** тагын да алга китте. «Балалар җәмәгать ярдәмчесе» проекты «Татарстан Республикасы балалар оешмасы советы» АҖ белән берлектә 2016 елда барлыкка килгән иде. 2017 елга Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегендә перспектив бурычларны берсе – җәмәгать ярдәмчеләре институтларын торгызу һәм үстерү булды. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне иҗтимагый башлангычларда эшләүче ярдәмчеләре булу хокукы «Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законыны 17 статьясында урын алган. Беренче җәмәгать ярдәмчеләре 2015 елда барлыкка килде. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне 2015 елны 19 ноябрендәге 20-О номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне җәмәгать ярдәмчеләре турында нигезләмә расланды. 2016 ел ахырына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карары белән 17 җәмәгать ярдәмчесе билгеләнде, шуның 15е Татарстан Республикасының Алабуга, Чүпрәле, Менделеевск, Буа, Арча, Тәтеш, Яа Чишмә, Бөгелмә, Алексеевск, Кайбыч, Зеленодольск, Теләче, Кама Тамагы, Чистай, Балтач муниципаль районнарыннан.

Җәмәгать ярдәмчеләренә түбәндәге вәкаләтләр бирелә:

шәхсән Вәкаләтле вәкил хәл итәргә тиешле язма мөрәҗәгатьләрне һәм материалларны кабул итү һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә җибәрү;

Вәкаләтле вәкил кушуы буенча балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу фактларын тикшерелгәндә мөстәкыйль катнашу яки иҗтимагый оешмалар һәм вазыйфаи затлар составында катнашу;

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә Татарстан Республикасында балалар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү механизмнарын камилләштерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр кертү;

массакүләм мәгълүмат чараларында балигъ булмаганнарның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу фактлары турында басылып чыккан белешмәләрне анлизлауда катнашу һәм нәтиҗәләре турында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә хәбәр итү;

балалар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча балаларны һәм өлкәннәрне хокукый агарту буенча эшләр башкару;

балалар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләренә кагылышлы фәнни-гамәли конференцияләр, киңәшмәләр һәм семинарлар оештыруда һәм үткәрүдә катнашу;

ел саен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил нотыгына хисап чорында эшчәнлек гамәлгә ашырылган муниципаль берәмлектә балалар хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлеше турында мәгълүмат бирү;

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең башка йөкләмәләрен үтәү.



Җәмәгать ярдәмчеләре эшендә өстенлек конкрет кешегә ярдәм итүгә бирелә.

Җәмәгать ярдәмчеләренең эшчәнлеген оештыру-методик тәэмин итү Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары белән берлектә гамәлгә ашырыла.



Җәмәгать ярдәмчеләренең компетенцияләрен күтәрү максатында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 2017 елда ***уку семинарлары*** оештырылды.

2017 елның 31 мартында Казан шәһәре Совет районының 178 нче Белем бирү үзгендә җәмәгать ярдәмчеләренең беренче уку семинары үткәрелде.

Семинарда катнашучылар алдында түбәндәгеләр чыгыш ясады:

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л.Удачина – «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең һәм аның җәмәгать ярдәмчеләре эшенең төп юнәлешләре турында», «Татарстан Республикасында балалар хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында» темалары буенча;




Татарстан Республикасының Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларны хокукларын яклау буенча республика комиссиясе җаваплы секретаре И.Х.Гарифуллина – «Балигъ булмаганнар арасында сукбайлыкны профилактикалау өлкәсендә актуаль мәсьәләләр» темасы буенча;





Татарстан Республикасы прокуратурасының балигъ булмаганнар һәм яшьләр турында законнарны үтәлешенә күзәтчелек итүче бүлек башлыгы А.Ф.Хөсәенов – «Балигъ булмаганнар һәм яшьләр турындагы законнарның үтәлешенә прокурор күзәтчелеге практикасы» темасы буенча;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека һәм попечительлек һәм педагогика ярдәме бүлеге башлыгы З.В.Мусабирова – «Татарстан Республикасында опеки һәм попечительлек органнары эшчәнлеге» темасы буенча;



Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе, «Параллель» Татарстан Республикасы мәктәп психологлары ассоциациясе» коммерциячел булмаган партнерлык җитәкчесе – «Бала һәм аның гаиләсе белән хезмәттәшлек итү системасында нәтиҗәле коммуникация нигезләре» темасы буенча.



19 июльдә Биектау муниципаль районы базасында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләренең һәм Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең уртак уку семнар-киңәшмәсе узды.

Семинар-киңәшмә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан оештырылды.

Семинар-киңәшмә барышында анда катнашучылар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Биектау районында «Өмет» КЦСОН» ГАУСОда булдылар, анда авыр хәлгә төшкән гражданнарга, гаиләләргә, балаларга социаль хезмәт күрсәтү, социаль-көнкүреш, социаль-медик, социаль-психологик, социаль-хокукый, социаль-педагогик ярдәм күрсәтү органнарының Биектау районы гражданнарына, гаиләләренә, балаларга социаль адаптация һәм реабилитация оештыру эше белән таныштылар.









Семинар-киңәшмәдә катнашучылар шулай ук «Биектау үзәк район хастаханәсе» сәламәтлек саклау автоном учреждениесенең эше белән таныштылар.

Чараның пленар өлешендә җәмәгать ярдәмчеләре алдында Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары С.А.Осипов чыгыш ясады, ул сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт ярдәме чаралары, медицина профилактикасын, медицина ярдәмен оештыру мәсьәләләре, шул исәптән медицина ярдәменең һәм медицина реабилитациясенең махсус төрләрен куллану мәсьәләләре һәм фармацевтика эшчәнлеге турында сөйләде.

Семинар-киңәшмәдә катнашучылар сораулар бирделәр һәм аларга җентекле җаваплар алдылар.

Казан шәһәренең Сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы И.Н.Хәлфиев семнарда катнашучыларны Казан шәһәре территориясендә эшләүче «дустанә поликлиникалар» эше белән таныштырды.








Семинар-киңәшмәнең икенче өлешендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Интернет челтәрендә балаларга мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге чаралар турында»гы нотык белән чыкты, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләренең беренче ярты еллык эшенә йомгаклар ясады һәм икенче ярты еллыкка перспектив юнәлешләр билгеләде.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре институты беренче елда ук республика шәһәрләрендә һәм районнарында балаларның хокукларын яклау буенча күп эш башкарды, дип әйтергә кирәк.

Беренчедән, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил кушуы буенча җәмәгать ярдәмчеләре үз районнарында балаларның җәйге савыктыру оешмаларын тикшерүдә катнаштылар. 2017 елның июнь – июль айларында алар тарафыннан 16 муниципаль районда 44 лагерь тикшерелде, шул исәптән көндез килеп йөри торган 34 мәктәп лагере, 7 шәһәр чите балалар лагере, 2 палатка лагере, 1 шифаханә-савыктыру балалар лагере.



Тикшерү нәтиҗәсендә 4 лагерьда хокук бозулар ачыкланды. Алар буенча балалар оешмалары җитәкчеләренә күрсәтмәләр бирелде.

Икенчедән, 2017 елда җәмәгать ярдәмчеләре тарафыннан 16 муниципаль районда һәм Казан шәһәрендә 150 мәртәбә гражданнарны кабул итү оештырылды, 218 кабул ителде.

Өченчедән, *җ*әмәгать ярдәмчеләре балигъ булмаганнарның, педагогларның хокукый культурасын күтәрүгә юнәлдерелгән чараларга актив кушылдылар. Җәмәгать ярдәмчеләре тарафыннан 155 чара үткәрелде, аларда гражданнарны хокукый агартуга зур игътибар бирелде.



Мәсәлән, 2017 елның февралендә Алабуга шәһәрендә мәдәният йортында урнашкан «Балалар һәм аналар дөньясы» бүлмәсендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Алабуга шәһәрендәге җәмәгать ярдәмчесе А.А.Алескеров сәламәтлеге ягыннан чикле балаларын тәрбияли торган ата-аналар белән очрашты.

Очрашу барышында торак йорт янында һәм поликлиника территориясендә парковка урыннары булдыру, белем бирү оешмасында бала хокуклары бозылу, социаль тәэмин итү кебек мәсьәләләр турында сөйләштеләр. Барлык мәсьәләләр Алабуга муниципаль районының социаль яклау бүлегенә тапшырылды, аерым мәсьәләләр Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә җибәрелде.





Татарстан Республикасы Кама Тамагы районында җәмәгать ярдәмчесе А.А.Хакимов 2017 елның апрелендә «Имин Интернет» темасына әңгәмә уздырды. Анда 200 кеше катнашты. Әңгәмә «сорау-җавап» форматында барды.





Зеленодольск муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесе И.В.Фесенко балалар савыктыру лагерьларенда «Минем хокукларым һәм бурычларым» дигән хокукый викторина-квест оештырды. Чараның максаты – яшүсмерләрне хокукый тәрбияләү, уеннар рәвешендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә хокуклар һәм бурычларны өйрәнү һәм мониторинг уздыру. Чараның бурычлары – балаларны өстәмә рәвештә хокукый мәгълүмат белән кызыксындыру, үз хокукларын һәм бурычларын үтәү мотивациясен арттыру.





Чистай муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесе С.М.Хасанова «Чистай күппрофильле көлләият» ДАһБУнең 1,2 курс студентлары белән очрашу уздырду, аның кысаларында психологик имин мохит, имин интернет-киңлек булдыру мәсьәләләре буенча фикер алыштылар.

«Йолдыз урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУендә (МБОУ) гомуми ата-аналар җыелышы уздырылды, аның максаты – ата-аналарның игътибарын тагын бер кат балалар укытуны һәм тәрбияләүне тәэмин итүгә юнәлтү.





Менделеевск муниципаль районы прокуроры урынбасары О.Г.Латыйпова белән бергә җәмәгать ярдәмчесе Э.Б.Вәлиева Менделеевск шәһәренең 4 нче урта белем бирү мәктәбендә урта звено укучыларының ата-аналары өчен «Интернет челтәрендә балалар һәм яшүсмерләр өчен мәгълүмат иминлеге» темасына укулар үткәрде.

Балигъ булмаганнарның һәм аларның ата-аналарының хокукый культурасын күтәрү мәсьәләләре буенча мәгариф оешмаларында ата-аналар җыелышлары Тюляче районында җәмәгать ярдәмчесе С.Н.Хаҗипова тарафыннан да үткәрелде. Ата-аналар җыелышлары районның хокук саклау органнары вәкилләре кактнашында үткәрелә.

Бөгелмә муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесе Г.М.Мортазина тарафыннан районда «Фемида мәктәбе» проекты оештырылды, ул Бөгелмә муниципаль районында 5-11 сыйныф укучылары белән граждан, гаилә, хезмәт, җинаять һәм административ хокук хокукый мастер-класслар, уку дәресләре оештырудан һәм үткәрүдән гыйбарәт. Проект яшьләрнең хокукый белемнәрен арттыруга, хокук прблемаларына җәлеп итүгә, Россия Федерациясенең хокукый системасын ныгытуга ярдәм итә. Шулай итеп, мәктәп укучылары өчен даими рәвештә аларның гражданлык җәмгыятенә карашларын арттыруга ярдәм итә торган шундый хокук дәресләре үткәрелә.





Балтач муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесе Р.И.Юнысова тарафыннан мәктәп лагерьларында 7 – 15 яшьлек укучылар өчен «Мин сине яратам, Россия» хокукый квест үткәрелде. Чараның максаты – яшьләрдә патриотик аң тәрбияләү һәм милли горурулык уяту, игътибарны, мантыйклылыкны үстерү. Этапларны берсендә Бала хокуклары турындагы конвенциягә бәйле мәсьәләләр каралды.

Балаларда хокукый культура булдыру, хокукый мәсьәләләрне өйрәнү белән кызыксынуны арттыру максатында, Тәтеш муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесе Е.С.Куранова тарафыннан «хокуклар һәм бурычлар иленә сәяхәт» оештырылды.





Кайбыч муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесе О.А.Сахарнова тарафыннан өлкән звенода укучы балалар һәм аларның ата-аналары өчен «Сезнең хокуклар: бала хокуклары» темасына мәктәптән тыш чара оештырылды. Аның кысаларында бала хокуклары турындагы конвенция өйрәнелде.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе Э.Х.Башлай тарафыннан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил кушуы буенча гражданнар мөрәҗәгате буенча берничә диагностик чара оештырылды, болар:

балигъ булмаган А.га Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә ата-аналары мөрәҗәгате нигезендә психологик диагностика һәм коррекция эше уздырылды;



тәрбиягә алган гаиләдә яшәүче балигъ булмаган баланың эмоциональ-психологик халәтенә диагностика ясалды (хәзерге вакытта үз атасы белән яши);

балигъ булмаган К. һәм М.га мәгариф оешмасында укытучылар һәм укучылар арасындагы стресс фактларын, мәктәптә балаларның психологик комфортына бәйле психологик травмаларны ачыклау өчен психологик диагностика үткәрелде.

Э.Х.Башлай тарафыннан шулай ук балаларны тәрбияләү өлкәсендә ата-аналарга психологик ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән мәгълүмати-агарту һәм консультация эше оештырылды.

2017 елда «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» Татарстан Республикасы региональ иҗтимагый оешмасы белән берлектә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан оештырылган **«Балалар җәмәгать кабул итүе»** проектын гамәлгә ашыру дәвам итте. Ул балаларда һәм яшүсмерләрдә актив граждан позициясен формалаштыруның яңа алымы буларак үзен нәтиҗәле күрсәтте.







Шулай итеп, республикада, 17 зурлар җәмәгать ярдәмчесе белән рәттән республиканың муниципаль районнарында һәм шәрләрендә 53 балалар җәмәгать ярдәмчесе эшли.

Ел дәвамында балалар өчен дүртукытк сменасы оештырылды. Бу хакта тулырак мәгълүмат әлеге нотыкның 1.9 «Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең проект эшчәнлеге» бүлегендә бирелде.

Проект балаларны хокукый агартуга, аларда актив тормыш һәм гражданлык позициясен булдыруга, позитив мораль-этик һәм әхлакый кыйммәтләр тәрбияләүгә, яшь гражданнарны үз тормышларына кагылышлы мәсьәләләргә җәлеп итүгә, балаларга һәм

яшьләргә хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруда һәм яклауда ярдәм итүгә юнәлдерелә. Ел дәвамында 260 чара үткәрелде, болар арасында социаль акцияләр, хокукый-агарту темаларына очрашулар, хокукый квестлар, җирле үзидарә органнары вәкиләре белән очраушалр.

Аграту эшләреннән гамәлгә ашырудан тыш, балалар үзләренең хокукларын һәм бурычларын яклауга кагылышлы мәсьәләләрне республика чараларында күрсәтүдә, үз фикерләрен белдерүдә арадашчылар буларак та эш иттеләр.

Җәмәгать ярдәмчеләре институтын үстерү Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2018 елгы эшчәнлегендә перспективалы бурычларның берсе булып кала. 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләт вәкил тарафыннан республиканың һәр муниципаль районында һәм шәһәрендә җәмәгать ярдәмчеләрен билгеләп кую, шулай ук аларның компетенциясен күтәрү буенча эшчәнлекне дәвам итү планлаштырыла. Җәмәгать ярдәмчеләре институты республикада бала хокукларын яклауның реаль механизмы булырга тиеш.

БҮЛЕК 2

2017 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛАЛАР ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕН ТӘЭМИН ИТҮНЕҢ ГОМУМИ МОНИТОРИНГЫ


2.1. 2017 елда Татарстан Республикасында төп демографик тенденцияләр

Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы белешмәләре буенча 2017 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында халык саны 3 885,3 мең кеше тәшкил итте.

2011 елдан алып республикада ***халыкның табигый артуы*** күзәтелә. 2017 ел йомгаклары буенча ул 4 158 кеше яисә 1000 кешегә (+)1,1 кеше тәшкил итте. 2016 ел күрсәткечләренә караганда кеше саны кимүгә карамастан, Россия Федерациясе дәүләт статистикасы хезмәте күрсәткечләреннәе күренгәнчә, Татарстан Республикасы 2017 елның 9 ае йомгаклары буенча Россия Федерациясе Идел буе федераль округында халыкның табигый артуы күзәтелә торган бердәнбер субъект булып тора.

16 нчы диаграмма


2009 - 2017 елларда Татарстан Республикасы халкының табигый артуы (кимүе) (кеше)



Республикада ***бала туу*** күрсәткечләре шактый югары сакланып кала. Мәсәлән, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, 2017 елда 48 115 бала туган. Һичшиксез, хатын-кызларның саны һәм аларның сәләмәтлек торышы зур йогынты ясый. Соңгы 10 елда аларның саны кими, бу узган гасырның 90 нчы елларында балалар тууның кинәт кимеп китүе белән аңлатыла. Бу чорда туган балалар хәзер үзләре ата-ана булып җитешә, шунлыктан киләсе елларда балалар тууның кимүе көтелә.

17 нче диаграмма

2013 – 2017 елларда Татарстан Республикасында балалар туу динамикасы (кеше)




Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС Идарәсе белешмәләренә караганда, 2017 ел йомгаклары буенча республикада 19 543 бала (40%) гаиләдә беренче бала булып туган, 20 382 (42%) – икенче бала,

6 766 (14%) – өченче, 1 905 (4%) – дүртенче һәм аннан күбрәк. Балалар туу структурасында икенче һәм аннан соңгы балаларның тууы 14%ка кимегән. Беренче балаларның тууы соңгы дүрт елда кимүе күзәтелә (2014 елда – 25 539 беренче бала булып туган, 2015 елда – 24 832, 2016 елда – 22 511, 2017 елда – 19 543).

18 нче диаграмма


2017 елда беренче һәм аннан соңгы балаларның туу өлеше



Соңгы елларда абортлар саны ки дә игътибарга лаек. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы күрсәткечләре буенча, 2017 елда 22 атналык срокта 17 535 аборт ясалган. Бу 2009 елдан соңгы чор эчендә иң түбән күрсәткеч. Шул ук вакытта хатын-кызларның үз теләге белән абортка барулары борчуга сала, мондый абортлар саны 9120гә җитә (52%) (12 атнага кадәр сроекта). Абортларның 48%ы медицина күрсәткечләре буенча ясалган (2016 елда – 53%).

19 нчы диаграмма


2009 елдан 2017 елга кадәр Татарстан Республикасында туган балалар һәм абортлар саны (мең кеше)



2017 ел йомгаклары буенча республикада халыкның гомуми үлем күрсәткече кимеде. 2017 елда 43 957 кеше үлде, 2016 елдагыга (44 894 кеше) караганда 937 кешегә кимрәк. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, 2016 ел белән чагыштырганда, гомуми үлем күрсәткече кимеде һәм ул 1000 кешегә 11,3 кеше туры килә. Бу 2009 елдан башлап иң түбән күрсәткеч.

20 нче диаграмма


2009 - 2017 елларда Татарстан Республикасында халыкның гомуми үлем динамикасы (кеше)



2017 ел йомгаклары буенча, Татарстан Республикасында аналар үлеме 100 000 кешегә 6,2 кеше (3 очракта бала исән кала), бу 2016 елга караганда 13,9%ка азрак (100 000гә 7,2). Анлар үлеме Казанда, Әлмәт, Баулы муниципаль районнарында теркәлгән.

21 нче диаграмма


2009 - 2017 елларда Татарстан Республикасында аналар үлем динамикасы (кеше)



2017 елда гомумроссия күрсәткечләре белән Татарстан Республикасындагы туу һәм үлү чагыштырмасы 21 нче диаграммада китерелә.

22 нче диаграмма


2012 - 2017 елларда Татарстан Республикасында туу һәм үлү күрсәткечләре чагыштырмасы



Республикада ***балалар саны*** 2017 ел башына 814 203 кеше тәшкил итә, ягъни барлык халыкның 21%ы. 2010 елдан статистика күрсәткечләрен анализлаудан күренгәнчә, республикада балалар саны елдан-ел арта бара.

23 нче диаграмма

2013 -2017 елларда тулаем һәм яшьләре буенча балалар динамикасы



Яшь балалар саны (0 яшьтән 13 яшькә кадәрге) 764 747 кеше, яшүсмерләр (14 яшьтән 17 яшькә кадәрге) – 149 456 кеше.


Балалар санын анализлаудан күренгәнчә, 2017 елда мәктәп балалары (7 – 17 яшь) саны арткан. Бу яшьтәге контингент 427 591 кешедән 536 548 кешегә җиткән, ягъни 108 957 кеше арткан.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны (0 – 6 яшь) 2018 ел башына республикада 377 655 кеше исәпләнә. Шул ук вакытта мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны кимегән. 2014 елда 2013 ел белән чагыштырганда 18 745 балага артык, 2015 елда 2014 ел белән чагыштыр-

ганда – 15 370 кеше, 2016 елда 2015 ел белән чагыштырганда – 11 663 кеше, 2017 елда 2016 ел белән чагыштырганда – 9 287 кеше.

24 нче диаграмма


2012 – 2017 елларда мәктәпкәчә әм мәктәп яшендәге балалар саны динамикасы



Республикада 2014 елдан алып халыкның гомуми үлем санынан балалар үлеме санының кимүе күзәтелә. 2017 елда 419 бала үлгән, бу 2016 елдагыга караганда 54 балага әзрәк. Бу соңгы җиде елда иң түбән күрсәткеч.

25 нче диаграмма

2013 – 2017 елларда Татарстан Республикасында балалар үлеме динамикасы (кеше)




Гаилә кору һәм аерылышулар балалар мәнфәгатьләренә турыдан-туры кагыла торган һәм күп очракта шуңа бәйле процесслар булып тора.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ЗАГС Идарәсе белешмәләре буенча, 2017 елда 26 983 никах теркәлгән, бу, 2016 ел белән чагыштырганда, 1 205 (4,7%) күбрәк. Аерылышулар саны 13 586 очракны тәшкил итте. Әлеге күрсәткеч узган елдагыдан 136га күбрәк.

26 нчы диаграмма

2013 – 2017 елларда Татарстан Республикасында теркәлгән никахлар һәм аерылышулар динамикасы




Теркәлгән никахлар һәм аерылышулар чагыштырмасы 2017 елда беркадәр уай якка үзгәрде: теркәлгән 1000 никахка 503 аерылышу (2013 елда – 467, 2014 елда – 464, 2015 елда – 440, 2016 елда – 522) туры килә.

Хисапта китерелгән төп демографик күрсәткечләр Татарстан Республикасында балалар һәм балалы гаиләләр хәлен бәяләүдә җитди белешмә булып тора.

2.2. 2017 елда Татарстан Республикасында балаларның хокукларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән төп гамәлләр һәм чаралар

Соңгы берничә елда Татарстан Республикасында республиканың социаль-демографик хәлен яхшыртуга, социаль өлкәдә хезмәт күрсәтүләр сыйфатын яңшыртуга, Россия Федерациясе Президентының стратегик инициативаларын гамәлгә ашыруга 37 социаль программа, шул исәптән балалар учреждениеләре (балалар бакчалары, гомуми белем бирү мәктәпләре, балалар савыктыру лагерьлары, сәламәтлек саклау учреждениеләре, спорт объектлары һәм мәйданнары, яшүсмерләр клублары, авыл клублары) челтәрләрен үстерүгә (төзүгә, капиталь ремонтлауга, реконструкцияләүгә, кирәкле җиһазлар белән тәэмин итүгә) юнәлдерелгән 10нан артык программа системалы һәм даими рәвештә дәрәҗәдәге бюджетлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.



2017 елда Татарстан Республикасында да республика халкының, беренче чиратта, балаларның, тормыш рәвешен яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар үткәрелде.

Балалар сәламәтлеген саклау өлкәсендә соңгы елларда амбулатор шартларда медицина-санитария ярдәмен оештыруны һәм балаларга махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүдән һәркемнең файдалана алу мөмкинлеген камилләштерү максатларында шактый эшләр башкарыла.

2012 елдан башлап республикада беренчел звено медицина учреждениеләре челтәрен, шул исәптән авыл җирендә, үстерүне һәм ныгытуны максат итеп куйган чаралар үткәрелә.





2017 елда гына да:

түбәндәгеләр гамәлгә кертелде:

42 модуль фельдшерлык-акушерлык пункты - 121 004,22 мең сумлык;

6 табиб амбулаториясе - 54 699,12 мең сумлык, шул исәптән «Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең гомуми практика һәм участок педиатрлары офислары:

Казан шәһәре Вознесение поселогында, «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасы филиалы, «Сарман үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең табиб амбулаториясе, «Питрәч үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең табиб амбулаториясе, «Зәй үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасының 3 нче филиалы, «Биектау үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Чыпчык табиб амбулаториясе;



капиталь ремонтланды:

республиканың ике муниципаль районында һәм ике шәһәрендә 34 балалар поликлиникасы (хастаханәләр) - 1418928,98 мең сумлык;

өч муниципаль районда үзәк район хастаханәләренең 3 акушерлык-гинекология бүлекчәләре - 153758,6 мең сумлык.

Республиканың ике сәламәтлек саклау учреждениесе Россия сәламәтлек саклау күзәтчелегенең «Медицина эшчәнлегенең сыйфаты һәм иминлеге» ихтыярый сертификацияләү системасына туры килү сертификатларын алдылар, болар: Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Кама балалар медицина үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе.





Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Кама балалар медицина үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе ГОСТ ISO 9001:2015 сертификатлар тәңгәллегенә ия булды.

2017 ел ашыгыч медицина ярдәмен модернизацияләү исеме астында узды. Татарстан Республикасы Президенты ярдәмендә республика 97 реанимобиль сатып алды, санитар авиациясеен үстерү программасында катнашты.

Республикада ***мәгариф өлкәсендә*** күрелә торган чаралар, беренче чиратта, республика мәгариф оешмаларының матди-техник базасын ныгытуга һәм үстерүгә юнәлдерелгән берничә программаны гамәлгә ашыру белән характерлана.

2011 елдан алып республикада мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә өстәмә урыннар булдыру буенча президент программасы гамәлгә ашырыла, ул мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында чиратны бетерүгә һәм балалар бакчаларында урыннарга кытлык проблемасын хәл итүгә юнәлдерелгән.

2012 – 2017 елларда республикада балалар бакчаларында 47 мең урын булдырылды, 203 яңа балалар бакчасы ачылды, 35 хосусый балалар бакчалары ачылды.

2017 елда әлеге программаны гамәлгә ашыру кысаларында 1240 урынлык яңа 7 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы ачылды, шул исәптән:

Арча районында Хәсәншәех авылында 50 урынлык;



Биектау районында Усат һәм Шахгали авылларында 220 һәм 80 урынлык ике балалар бакчасы;

Казан шәһәре Совет районының «Мамадыш тракты» һәм «ART City» торак комрлексларында 340 урынлые ике балаларбакчасы;

Кукмара районыны Нырса авылында 50 урынлык;

Питрәч районының «Усадьба Царево» торак комплексында 160урынлык балалар бакчасы ачылды.

2017 елда төзелешне гоммуи финанслау күләме 850 222,305 мең сум тәшкил итте.

Шул ук вакытта, яңа балалар бакчалары төзү белән бергә, мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен капиталь ремонтлау (реконструкцияләү) программасы да гамәлгә ашырыла. 2013 – 2017 елларда 3 409,48 млн. сумга 266 балалар бакчасы ремонтланды, шуларның 110ы - 2017 елда. 2017 елда капиталь ремонт үткәрү өчен бирелгән акчаның гомуми күләме 1 624,87 млн.сум тәшкил итте.

Башкарылган чаралар республикада 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балаларны балалар бакчасында урыннар белән тәэмин итү буенча өстенлекле бурычны тулысынча диярлек хәл итәргә мөмкинлек бирде. 2017 елда 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балаларны мәктәпкәчә мәгариф учреждениесендә урын белән тәэмин итү 99 % тәшкил итте.







2012 елдан республикада гомуми белем бирү мәктәпләрен капиталь ремонтлау буенча республика программасы гамәлгә ашырыла. Алты ел эчендә 1324 мәктәп капиталь ремонтланды. Программа кысаларында 2017 елда 36 белем бирү оешмасына, шул исәптән 6 махсус (коррекцияле) мәктәп, «Н.А. Галләмов ис. республика махсус гомуми белм бирү мәктәбе» девиант холыклы балалар өчен ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү гомуми белем бирү учреждениесенә капиталь ремонт ясалды.

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрен капиталь ремонтлау программасын финанслау күләме 2017 елда 864 461,08 сум тәшкил итте.

2017 елда 3 283,42 млн. сумлык 4 яңа гомуми белем бирү оешмасы файдалануга тапшырылды, шул исәптән:

МБОУ Казан шәһәрендә «Күппрофильле полилингваль гимназия №180» МББУ;

Казан шәһәрендә «Күппрофильле полилингваль гимназия №181» МББУ;

Чаллы шәһәрендә «Урта гомуми белем бирү мәктәбе № 41» МББУ;





Арча шәһәрендә «Арча урта гомуми белем бирү мәктәбе № 6» МББУ.

Моннан тыш, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга гомуми белем бирү мәктәпләренә керү мөмкинлеген тәэмин итү өчен 2012 елдан башлап республиканың гомуми белем бирү учреждениеләре биналарында уңайлы мохит булдыру эше башланды. 2013 – 2017 елларда 274, шул исәптән 36 махсус (коррекцияле) мәктәптә җайлаштыру чаралары үткәрелде. 2017 елда 5 гомуми белем бирү оешмасында, шул исәптән 2 махсус (коррекцияле) мәктәптә аз хәрәкәтләнүчән балалар төркемнәре өчен махсус объектлар барлыкка килде. Бу гамәлләр өчен 2013 елдан башлап 456,16 млн. сум акча тотылды.

Татарстан Республикасында төрле ведомстволарга карый торган 438 өстәмә белем бирү оешмасы эшли, аларда 317,5 мең бала шөгыльләнә, бу гомуми санның 81,2 % ын тәшкил итә.

1 нче таблица

2017 елда Татарстан Республикасында балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары һәм аларда укучы балалар саны

Ведомство исеме	Балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары бер.	Аларда укучы балалар саны, кеше
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы	153	187 424
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы	105	38 907
Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы	172	87 154
Балаларга өстәм белем бирү оешмаларының дәүләткә карамаган челтәре	8	4 061
Барысы	438	317 546

2017 елда сәнгать-эстетика юнәлешендәге түбәндәге ике өстәмә белем бирү учреждениесенә капиталь ремонт ясалды:



МБУДО Казан шәһәрендә «Б.М.Әлминов ис. Балалар сәнгать мәктәбе №3» МБӨБУ (МБУДО) ;

Әлмәт шәһәрендә «Р.Н. Нәгыймов ис. Балалар музыка мәктәбе № 1» балалар өчен өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында балалар өчен яңа «Балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе төзелде.



Федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, шулай ук хосусый инвесторлар акчаларыннан балаларга өстәмә белем бирүнең матди-техник базасын ныгытуга 2016 – 2017 елларда 200 миллион сумнан артык акча җәлеп ителде.

2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү буенча федераль максатчан программа кысаларында республикада JuniorSkills компетенцияләре буенча 9 база мәйданчык төзелде.

Укучыларның техник иҗат белән кызыксынуларының артуы JuniorSkills компетенцияләре буенча өстәмә белем бирүнең заманча программаларын гамәлгә ашыруга бәйле барлыкка килә. Ике ел эчендә федераль дәрәҗәдә шактый уңышларга ирешелде. Татарстан Республикасында 2015 елда - 7 алтын медаль, 2016 елда – 13 алтын, 2017 елда – 17 алтын медаль булды.



2016 елдан Татарстан Республикасында балаларга өстәмә белем бирүнең яңа моделе - беренче балалар технопаркы «Кванториум» гамәлгә ашырыла башлыды. Ул балаларны фән-техника иҗаты дөньясына җәлеп итәргә сәләтле, ә яңа технологияләр һәр баланың идеяләрен тормышка ашырырга ярдәм итәләр.



2016 елдан беренче балалар «Кванториум» технопаркы Чаллы шәһәрендә «ИТ-парк» югары технологияләр технопаркы» ДАУ һәм «КАМАЗ» гавами АҖ катнашында коммерциягә карамаган автоном оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла башлады.

2017 елда инде Татарстанда өч балалар технопаркы эшли, аларның икесе узган ел ачылды:

2017 елның мартында Түбән Кама шәһәрендә КНИТУның Нефть химиясе инжиниринг үзәге мәйданчыгында икенче технопарк ачылды, аның базасында 1 меңнән артык бала шөгыльләнә ала;

2017 елның 12 июлендә Әлмәт шәһәрендә республикада өченче «Кванториум» балалар технопаркы ачылды.

Мәгариф системасында балаларга өстәмә белем бирү, аларны тәрбимәләү системасын үстерү максатында республикада 2016 елдан башлап 50 меңәр сумнна 324 грант бирелә, гомумисуммасы - 15 млн. сум. Грантлар мәгариф оешмаларының тәрбия эше буенча директор урынбасарларына, балаларга өстәмә белем бирү оешмалары директорларына бирелә. Икенче ел 1,5 млн. сум күләмендәге грант «Созвездие – Йолдызлык» эстрада сәнгатенең республика телевизион ачык яшьләр фестиваленә җиңүчеләр һәм призерлар әзерләгән педагогларга җибәрелә.

Яшь буынның сәламәтлеген саклауга килгәндә, һичшиксез, республикада ***спорт объектлары челтәре инфраструктурасын,*** шул исәптән балалар өчен, үстерү өстенлек итә.



Соңгы алты елда 1 300дә артык спортив объекты булдырылды. Бүгенге көндә республикада барлыгы 10 844 спорт объекты эшли. Республиканың һәр районында бүген эре спорт корылмалары (күпфункцияле спорт йорты, боз спорт йорты, йөзү бассейны) бар.

2017 елда Татарстан Республикасында 2 069 886,49 мең сумлык 146 спорт корылмасы файдалануга тапшырылды, шул исәптән:

8 спорт корылмасы - 1 232,0 мең сумлык, шуннан:

Әгерҗе районында спорт-савыктыру комплексы, бассейн белән;

Бөгелмә шәһәрендә аз хәрәкәтләнүчән кешеләр төркеме өчен спорт залы;

Казан шәһәренең Дәрвишләр микрорайонында ябык бассейн;


Теләче муниципаль районының Теләче авылында ясалма боз белән ябык шугалак;

Мөслим районының Мөслим авылында универсаль спорт залы;


Лаеш районында «Идел» яшьләр үзәге» ДАУ стадионында, Югары Ослан районында «Республика махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр олимпия резервы спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү» ДБУ стадионында, Лаеш районында «Динамо» спорт базасы» стадионында (реконструкция).

27 нче диаграмма

ДЮСШ һәм СДЮСШОРлар саны



ДЮСШ һәм СДЮСШОРларда да шөгыльләнүче балалар саны







Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән универсаль спорт мәйданчыкларын төзү буенча масштаблы проект гамәлгә ашырыла. Универсаль спорт мәйданчыклары баскетбол, волейбол, футбол, шулай ук турникта һәм урам тренажерларында физик культуры һәм спорт белән шөгыльләнү өчен яссы корылмалар рәвешендә төзелә. Спорт мәйданчыклары спорт мәктәпләре белән бергә гомуми белем бирү учреждениеләре мәнфәгатьләрен дә исәпкә алып, дәресләрне сыйфатлы итәргә мөмкинлек бирәчәк. Балалар өчен махсус шәһәрчекләр булдыру күздә тотыла.





2013 – 2017 елларда республиканың 45 муниципаль берәмлегендә гомуми суммасы 1 839,33 мең сумлык 790 күпфункцияле спорт мәйданчыклары төзелде. 2017 елда гомуми суммасы 422,33 мең сумлык 120 күпфункцияле спорт мәйданчыгы файдалануга тапшырылды.

Татарстан Республикасында балаларны **ял иттерү һәм савыктыру** өчен кирәкле һәм тиешле шартлар тудыруга зур игътибар бирелә.

2014 елда Татарстан Республикасында шәһәр яны стационар савыктыру учреждениеләре объектларын капиталь ремонтлау һәм төзү буенча өчьеллык программа эшли башлады. Әлеге программа буенча 2014 – 2017 елларда гомумуи суммасы 475,59 млн. сумлык 43 шәһәр яны лагерена ремонт ясалды, бу республика һәм муниципаль буйсынудагы

стационар лагерьлар саныннан 58% тәшкил итә. 2017 елда 93,09 млн. сумлык 11 лагерь ремонтланды. Программаны гамәлгә ашыру балаларның һәм яшүсмерләрнең яшәү урынына якын урнашкан учреждениеләр челтәрен үстерергә, аларның ялын оештыру өчен шартлар тудырырга мөмкинлек бирә.

Балаларны һәм яшьләрне савыктыру кампаниясен оештыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан 2017 елда 1 431,3 млн. сум бүлеп бирелде, бу 2016 елдагыга караганда 84,8 млн. сумга күбрәк.

2017 елның җәйге чорында барлык ял итү рәвешләрендә 1 905 лагерь эшләде, бу планлаштырылганнан 10 лагерьга күбрәк (план буенча – 1 895 лагерь).

2017 елның савыктыру кампаниясе чорында 218 509 бала ял итте, бу 2016 елга караганда 3 503 кешегә күбрәк. 2017 елда балаларны һәм яшьләрне савыктыру кампаниясен финанслауның гомуми күләме 1 731,6 млн. сум булды, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1 431,4 млн. сум, муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан (җирле бюджетлардан) – 31,4 млн. сум, предприятиеләрдән – 94,1 млн. сум.

Ял программасы үзенең социаль юнәлшен сакелап калды. 2017 елда 54 468 кешегә ял һәм савыктыру юлламалары брелде, алар тулысынча республика бюджеты акчаларыннан түләнде, шул исәптән 16 251 юллама авыр тормыш шартларындагы балалар өчен бирелде.

Татарстан Республикасы балаларын ял иттерү һәм савыктыру программасы кысаларында 2017 елда хроник авырулардан интегүче балаларны шифаханәдә дәвалауны оештыруга дәвалаап бетерүгә, реабилитацияләүгә мохтаҗ балалар өчен шифаханә-курорт оешмаларына 7 890 юллама, шулай ук хроник авырулары булган балаларга «Балалар» һәм «Ана һәм бала» юлламалары, шул исәптән 4 790 юллама тормыш хәлләре авыр булган балаларга бирелде.



Республикада балалар һәм яшьләр өчен ***ял итү учреждениеләре челтәрен*** киңәйтүгә зур игътибар бирелә.

2015 елда Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов тарафыннан яшүсмерләр клубларын капиталь ремонтлау программасы хупланды. Программаны гамәлгә ашыруның өч елында 86 яшүсмерләр объектына 300 млн. сумлык капиталь ремонт ясалды, шуларның 29ы – 2017 елда. Программаны гамәлгә ашыру балаларның һәм яшүсмерләрнең яшәү урынына якын урнашкан учреждениеләр челтәрен үстерергә, аларның ялын оештыру өчен шартлар тудырырга мөмкинлек бирә.



Балаларның һәм яшүсмерләрнең культуралы ял итүен оештыруда, аларның ижади мөмкинлекләрен үстерүдә мәдәни, ял итү учреждениеләренең роле бик зур. Авыл халкының, шул исәптән авыл балаларының ялын оештыру һәм аларга ижади мөмкинлекләр өчен заманча шартлар тудыру максатында, Татарстан Республикасында 2012 елдан авыл клубларын капиталь ремонтлау программасы эшләп килә. 2017 елда республикада 34 авыл клубы төзелде, аларга тотылган суммма 274 969,81 млн.сум тәшкил итә һәм 44 авыл клубына капиталь ремонт ясалды, гомуми финанслау суммасы 338 208,66 млн. сум тәшкил итте.

Татарстан Республикасында 89 балалар китапханәсе эшли, балалар ялы оештырыла торган 1 956 мәдәният йорты бар.

2017 елда Татарстан Республикасы 500 меңгә кадәр халкы булган кече һәм урта шәһәрләрнең кинотеатрларына ярдәм итү буенча бөтенроссия конкурсында җиңүче бул-

ды, әлеге конкурс үзебезнең кинематографиягә социаль һәм икътисадый ярдәм буенча федераль фонд (Кино фонды) тарафыннан оештырылган иде. Конкурс йомгаклары буенча һәм кинозалны модернизацияләүгә 5 млн. сумлап акча бүлеп бирелде. Республиканың түбәндәге биш кинозалына ярдәм күрсәтелде:

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Район Мәдәният йорты» МБУК;

Нурлат муниципаль районының «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ;

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Саба үзәкләштерелгән авыл клуб системасы» (Район Мәдәният йорты) МБУ;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының МАУ «Чулман-Су мәдәни үзәге» МАУ;

«Әлки кино учреждениесе» МБУ.



2017 ел Казанда даими эшли торган яңа музей-күргәзмә экспозициясе – «Россия – минем тарихым» мультимедияле тарихи парк ачылуы белән дә танылды. 2017 елның 27 октябрендә Татарстан башкаласында «Казан ярминкәсе» күргәзмә үзәге территориясендә әлеге паркны ачу тантанасы узды. Тарихи паркта төрле мәгълүмат чаралары – сенсор өстәлләре, 3D-экраннар, кинотеатрлар, аудиогидлар – аша Россиянең күпгасырлы тарихы ачыла. Музей экспозициясе дүрт тематик бүлектән тора: «Рюриковичлар», «Романовлар», «Зур кыенлыклар аша Бөек Җиңүгә», «Россия – Минем тарихым. 1945 – 2016 еллар». Тарихи паркта Татарстан Республикасына багышланган экспозициягә аерым игътибар бирелә. Күргәзмәнең мәйданы 5,5 мең кв.метр тәшкил итә. Яңа күргәзмә Татарстанда яшәүче яшьләрнең белем һәм мәдәни куәтләре мөмкинлеген арттыра.



2015 елдан башлап паркларны һәм скверларны яңарту, су саклау зоналарын төзекләндерү программасы эшли. «Паркларны һәм скверларны арттыру» программасын гамәлгә ашыруның ике елы эчендә Татарстанда 189 парк һәм территорияләр тирәләре яңартылды, «Су саклау зоналарын төзекләндерү» программасы буенча 20 су объекты төзекләндерелде. 2017 елда «Уңайлы шәһәр мохитен булдыру» проект кысаларында 68 җәмәгатьчелек тирәлеге төзекләндерелде.

Социаль ярдәм чараларының гамәлгә кергән системасы өлешендә 2017 ел дәвамында пособиеләр һәм түләүләр сакланып калды һәм, инфляция үсеше темпларын исәпкә алып, индексацияләнде. Узган ел республика бюджетының балаларга һәм балалы гаиләләргә гамәлдәге законнарда каралган социаль ярдәм чараларын күрсәтүгә чыгымнары артты һәм 5921,7 млн.сум (2016 елда – 6 273,7 млн. сум) тәшкил итте.

2017 елның 1 гыйнвардан Татарстан Республикасында ятим балаларны уллыкка (кызлыкка) алган гражданнарга бер мәртәбәле түләү билгеләнде, ул 200 мең сум тәшкил итә.



Балаларга һәм гаиләләргә социаль ярдәм өлкәсендә 2017 елда да берничә матур вакыйга булды.

2017 ел өчен сентябрьдә Саба муниципаль районының Югары Отар авылында акылга зәгыйфьрәк булган балалар өчен яңа интернат-йорт ачылуы да мөһим вакыйга булды. Учреждение 1962 елдан бирле эшли. Анда 3 яшьтән 18 яшькә кадәрге 80 авыру бала яши. Бүгенге вакытта интернат-йортта



авыру балалар өчен 5 корпус эшли, биредә адаптация өчен һәм административ биналар, медицина блогы, аш-су блогы, мунча-кер юуу бинасы, яшелчәсаклагыч, теплицалар, складлар һәм башка ярдәмче корылмалар бар.

Балалы гаиләләрнең хокукый белемен арттыру максатларында смартфоннар һәм планшет компьютер өчен «Хокукый навигатор» мобиль кушымта эшләнде, аңа Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында мәгълүмат керә. Мәгълүмати продукт ярдәмендә онлайн-режимда шәхси кабинетка кереп була, анда тиешле гаилә категориясен табып, аңа тиешле дәүләт ярдәме чаралары һәм аны күрсәтергә тиешле учреждениене ачыкларга мөмкин. Моннан тыш, кушымтада төрле дәүләт органнарына гаризалар бирү өчен кирәкле шәхси документлар рәвешләре бирелә.

2017 елның сентябрендә «Бергә – балалар өчен! Бергә – гаилә белән» 8 нче Бөтенроссия күргәзмә-форумында Татарстан Республикасы «Иң яхшы IT-карары» номинациясендә авыр тормыш хәдендәге балалы гаиләләргә ярдәм өлкәсендә заманча мәгълүмати технологияләрне нәтиҗәле куллану өчен диплом алды.

Бала хокукларын тәэмин итүгә турыдантуры яисә якынча гына йогынты ясый торган гомуми характеристиканы күз алдына китергәндә, 2017 елда республикада балаларның һәм балалы гаиләләрнең ***торак мәсьәләсен*** хәл итүгә ярдәм чараларына тукталып китәргә кирәк.

Күпбалалы гаиләләргә торак төзелеше өчен җир кишәрлеген түләүсез бирү (тапшыру) күздә тотылган федераль һәм региональ закон нормалары Татарстан Республикасында уңышлы хәл ителә. 2017 ел ахырына дәүләт ярдәменең әлеге чарасына хокукы булган һәм бу хакта мөрәҗәгать иткән 44 721 күпбалалы гаиләнең 64 %ы, ягъни 28684 гаилә мондый хокукларыннан файдаланып, өлешле гомуми милеккә җир кишәрлекләре алдылар.

Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итүне Россия Федерациясе бюджетыннан финанслауның гомуми күләме кимегәнлектән, әлеге йөкләмәне үтәү өчен Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары 2017 елда шактый артты. Мәсәлән, 2016 елда гомуми финанслау күләме 339,2 млн. сум булса, Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары 288,7 млн. сум иде, ә 2017 елда гомуми финанслау күләме 346,7 млн.сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары 302,8 млн.сум тәшкил итте.

2017 елда күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуга дәүләт ярдәме чараларын региональ финанслау күләме артты. Бу биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы 50 гаиләгә торак субсидияләре түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 143,8 млн.сум (2016 елда – 137,1 млн.сум) акча бүлеп бирелде.

Гражданнарга торак мәсьәләсен социаль ипотека программасында катнашу юлы белән хәл итү мөмкинлеген бирә торган республика программасы кысаларында, балалы гаиләләргә ярдәм итү чарасы буларак 200 000 сум күләмендә акчалата компенсация бирү дәвам итте, ул, бала тугач, шулай ук уллыкка (кызлыкка) бала алгач, бирелә.

Әлеге чараны финанслауның гомуми күләме 514,7 млн. сум булды.

2.3. 2017 елда халыкара, федераль һәм республика законнарындагы бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре өлкәсенә караган яңалыкларга күзәтү

Бала хокукларынһәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру торышына гомуми бәя бирү өчен күрсәтелгән өлкәне хокукый җайга сала торган законнардагы үзгәрешләргә анализ ясарга кирәк.

2017 елда балаларның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы **халыкара хокук** өлкәсендә Россия Федерациясе өчен зур яңалыклар булмады.

Илкүләм хокук системасында 2017 елда кабул ителгән һәм бала хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы түбәндәге иң мөһим **федераль законнарны һәм закон актларын** билгеләп үтәргә кирәк.

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе законына һәм «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәмнең өстәмә гарантияләре турында» Федераль законның 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 1 маендагы 89-ФЗ номерлы Федераль закон белән эшсез ятим балаларга социаль ярдәмнең өстәмә гарантияләре билгеләнде.

Беренче мәртәбә эш эзләүче һәм беренче мәртәбә ятим балалар дип танылган балаларга һәшм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга эшсезлек буенча пособие һәм эш белән тәэмин итү органнары юлламасы буенча һөнәри белем алу вакытында стипендия билгеләнде.

Эшсезлек буенча пособиене һәм стипендияне гомуми түләү чоры Россия Федерациясенең тиешле субъектында билгеләнгән айлык уртача түләү күләмендә алты айдан артыграк була алмый.

Эшсез буларак теркәлгән көннән алты ай узгач, шулай ук 23 яшь тулгач эшсезлек буенча пособие һәм стипендия эшсезлек буенча пособие район коэффициенты күләменә арттырылган күләмдә түләнә.

Законда шулай ук, күрсәтелгән затлар оешма бетүгә бәйле яисә хезмәткәрләрнең штат саны кимүгә бәйле рәвештә кыскартылганда яки эштән җибәрелгәндә, эш бирүченең аларны үз акчалары исәбенә һөнәри укыту һәм соңыннан эшкә үзендә үк яки башка эш бирүчедә урнаштыру бурычы карала.

«Россия Федерациясе Гаилә кодексының 58 статьясына һәм «Граждан хәле актлары турында» Федераль законның 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 1 маендагы 94-ФЗ номерлы Федераль закон белән ата-аналар балага исем сайлаганда бала исемендә саннар, хәрефле-санлы билгеләмәләр, символлар һәм хәреф булмаган тамгалар булмаска тиешлеге билгеләнә. Шундый исемдәге баланы ЗАГС тарафыннан теркәү тыела. Шулай ук ата-аналарның фамилияләре төрле булганда, аларның үзара килешүе белән балага атасының яки анасының фамилиясе йә аларның икесенең фамилиясе теләсә нинди эзлеклелектә бирелә, әгәр Россия Федерациясе субъектлары законнарында башкасы каралмаган булса. Шул ук вакытта бертуган энеләре һәм сеңелләренең фамилиясендә дә шул ук эзлеклелек сакланырга тиеш. Баланың икеләтелгән фамилиясе дефис белән язылганда, ике сүздән артмаска тиеш.

«Балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законга һәм «Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәммгны яклау турында» Федераль законның 15.1 статьясына балаларда суицидка омтылыш уята торган эшчәнлеккә каршы юнәлдерелгән өстәмә механизмнар билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 7 июнендәге 109-ФЗ номерлы Федераль закон балаларны үз-үзләрен үтерүгә китерә торган җинаятьләрне ачыклауга һәм аларга чик куюга юнәлдерелә.

Балигъ булмаганнарны суицид гамәлләр кылуга этәрүче затларны ачыклау эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре буенча район, шәһәр бүлекләре (идарәләре) эшчәнлегенә, эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре буенча муниципаль бүлекләре, башка ябык административ-территориаль берәмлекләр бүлекләре (идарәләре), шулай ук эчке эшләр органнарының үз компетенциясе чикләрендә башка бүлекчәләре эшчәнлегенә кертелгән.

«Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясе җинаять-процессуаль кодексының 151 статьясына балаларда суицидка омтылыш уята торган эшчәнлеккә каршы юнәлдерелгән өстәмә механизмнар билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 7 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон балигъ булмаганнарны үз-үзләрен үтерүгә җәлеп иткән өчен дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелергә мөмкин булуын билгели.

Шулай ук түбәндәге гамәлләр өчен дә җинаять җаваплылыгы кертелә:

үз-үзеңне үтерүгә җәлеп итү яисә үз-үзеңне үтерүгә ярдәм итү;

үз-үзеңне үтерүгә омтылыш уятуга юнәлдерелгән эшчәнлекне оештыру;

балигъ булмаган затны аның гомеренә куркыныч тудыра торган гамәлләр кылуга җәлеп итү.

Моннан тыш, гаепле кешегә карата матди яктан яисә башкача бәйле булган балигъ булмаган затны яки йөкле хатын-кызны ике яисә аннан күбрәк затлар йә оешкан төркем алдан сөйләшү буенча, гавами чыгышларда, массакүләм мәгълүмат чараларында яисә «Интернет» челтәрендә кылган гамәлләре белән үз-үзен үтерүгә китергән өчен җинаять җаваплылыгы билгеләнә.

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 139-ФЗ номерлы Федераль закон белән җәйге каникулларда эшләүче 14 яшьлек граждannар өчен эш вакытының озынлыгы төгәлләштерелә.

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 63 статьясындагы 3 өлеше нигезендә ата-аналарның берсенең (попечительнең) һәм опека һәм попечительлек органының язма ризалыгы белән хезмәт шартнамәсе гомуми белем алучы һәм ундүрт яшькә җиткән зат белән аның сәламәтлегенә зыян китерми торган җиңел эш өчен төзелергә мөмкин, йә гомуми белем алучы һәм ундүрт яшькә җиткән зат белән аның сәламәтлегенә зыян салмый торган һәм уку программасын үзләштерүгә зыян китерми торган җиңел эшне укудан буш вакыттта башкару өчен төзелергә мөмкин.

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 94 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты нигезендә ундүрт яшьтән унбиш яшькә кадәрге хезмәткәрләр өчен (гомуми белем яисә урта һөнәри белем алучы һәм каникул вакытларында эшләүче затларны да кертеп) көндәлек эш (смена) озынлыгы 4 сәгать итеп билгеләнә, унбиш яшьтән уналты яшькә кадәрге хезмәткәрләр өчен – 5 сәгать. Элек ундүрт яшьтән унбиш яшькә кадәрге яшүсмерләр каникул вакытларында эшкә урнашканда аларга кыскартылган эш вакыты озынлыгы турындагы норма билгеләнә иде, ә уку белән эшне бергә алып баручы яшүсмерләр өчен каралган чикләүләр исәпкә алынмый иде.

«Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»2017 елның 18 июлендәге 162-ФЗ номерлы Федераль закон белән ата-анасының берсе дә мәгълүм булмаган балаларга социаль пенсия алу хокукы бирелә (туендыручысын югалту буенча пенсия.

«Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» Федераль законга кертелгән үзгәрешләр нигезендә ата-анасының берсе дә мәгълүм булмаган балаларга социаль пенсия 10 068,53 сум күләмендә билгеләнә. Әлеге пенсия балаларга 18 яшькә

җиткәнче билгеләнәчәк, шулай ук белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда төп гомуми белем программалары буенча көндез йөреп укучы 18 яшьтән олырак балаларга да билгеләнә, әмма 23 яшькә җиткән ул туктатыла. Бу пенсиягә хокуктан файдалану өчен туу турында акт язмасы төзелгән көн нигез булып тора. Ата-анасының берсе дә мәгълүм булмаган баланы уллыкка алганда социаль пенсия уллыкка алган айдан соң килүче айның 1 нче числосыннан түләнми башлый. Федераль закон вступил 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керде.

«Ата-аналары иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтүче балаларның хокукларын яклау максатларында Россия Федерациясе Җинаять-башкару кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 июлендәге 200-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә иректән мәхрүм итүгә хөкем ителүчеләргә аларның балигъ булмаган балалары белән күрешү өчен өстәмә мөмкинлекләр бирелә.

Бер үк вакытта, закон белән каралган чыгып йөрүләр рөхсәт ителми торган хөкел ителүчеләр категориясенең исемлеге дә киңәйтелә (бу, аерым алганда, җәза үтүнең билгеләнгән тәртибен еш бозучыларга, шулай ук балигъ булмаганнарга карата җинаять кылган затларга кагыла).

Моннан тыш, хөкем ителгән йөкле хатыннар, үзләре белән өч яшькә кадәрге балалары булган хатыннар закон нигезендә табиб бәяләмәсе буенча кереп-чыгып йөри алалар, әлеге бәяләмә нигезендә кирәк булганда - медицина хезмәткәрләре барында.

«Опека һәм попечительлек турында» Федераль законның 13 статьясына балигъ булмаган бала мәнфәгатьләрен яклау өлешендә үзгәреш кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон белән ата-аналарга балага опекунны яисә попечительне билгеләү хокукы бирелә, бу алар икесе бер вакытта үлгән очракка кагыла.

Элек «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон белән югарыда күрсәтелгән очракта ата-ананың берсенә генә балага опекун яисә попечитель билгеләү хокукы бирелә иде. Шул ук вакытта ата-ананың икесе дә, мәсәлән, юл-транспорт һәлакәтендә бер үк вакытта үлгәндәге вәзгыять җайга салынмаган. Хәзер аларның икесенә дә балага опекун яисә попечитель билгеләү хокукы бирелә (алар икесе дә бер көндә үлгәндә). Тиешле күрсәтмәне ата-ананың берсе яки аларның икесе дә баланың яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органына бирелгән гаризада күрсәтә алалар.

«Балалы гаиләләргә айлык түләүләр турында» 2017 елның 28 декабрендәге 418-ФЗ номерлы Федераль закон беренче яки икенче бала туу (уллыкка алу) уңаеннан айлык түләү алу хокукын билгели. Әлеге хокук гаиләдә җан башына айлык керем уртача хезмәткә сәләтле халыкның яшәү минимумы күләменнән 1,5-тапкырдан артып китмәгән очракта барлыкка килә. Җан башына керемне исәпләгәндә, аерым алганда, хезмәт һәм башка вазыйфаларны үтәгән өчен түләүләр, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр, пенсияләр, пособиеләр, стипендияләр һәм башка шуның ише түләүләр, иминләштерелгән вафат булучыларның хокук дәвамчыларына бирелә торган түләүләр, хәрбиләргә бирелә торган барлык түләүләр керә. Бер мәртәбә бирелә торган түләүләр исәпкә алынмый. Гаиләнең һәр әгъзасының керемнәре салымнар алынганчы булган күләмдә исәпкә алына.

Айлык түләү Россия Федерациясе субъектында балалар өчен билгеләнгән яшәү минимумы күләмендә башкарыла.

Икенче бала тууга (уллыкка алуга) бәйле рәвештә башкарыла торган түләүләр ана капиталы акчалары исәбеннән түләнә.

Түләү бер елга билгеләнә. Бу срок чыккач, бала яшь ярымга җиткәнче түләү билгеләү турында яңа гариза язарга, шулай ук аны билгеләү өчен кирәкле документларны (документлар күчермәләрен, белешмәләр) тапшырырга кирәк.

«Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 2017 елның 28 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру буенча түләүле белем бирү хезмәтләренә түләү өчен ана капиталы акчаларыннан файдалануга чикләүләрне бетерә. Хәзер мондый чикләүләр бар: ана капиталына хокук барлыкка килгән бала өч яшькә кадәр җитәргә тиеш. Закон гамәлгә кергәннән соң гаилә икенче бала тугач теләсә кайсы вакытта ана (гаилә) капиталын балаларның мәктәпкәчә белем алуына җибәрә ала.

Закон шулай ук югарыда күрсәтелгән «Балалы гаиләләргә айлык түләүләр турында» Федераль закон нигезендә айлык түләүләрне билгели.

Моннан тыш, Закон белән ана капиталы программасының гамәлдә булуы 2021 елның 31 декабренә кадәр озайтыла.

«Россия Федерациясе Торак кодексының 103 статьясына үзгәреш кертү турында» 2017 елның 31 декабрендәге Федераль законда, инвалид балалары булган гаиләләр һәм балачактан инвалид балалар башка торак урыннары бирелмичә хезмәт торакларыннан һәм тулай тораклардан чыгарыла алмыйлар, дип билгеләнә. Моңа социаль яллау шартнамәләре буенеча торак урыннарын яллаучылар яки мондый яллаучының гаилә әгъзалары йә торак урыннары милекчеләре яки мондый милекчеләрнең гаилә әгъзалары һәм торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптә торучы затлар керми.

Балаларның хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы законнардан килеп чыгучы Россия Федерациясенең норматив хокукый актлардагы яңалыклар түбәндәгеләр булды.

«Россия Федерациясенең Юл хәрәкәте кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 28 июнендәге 761 номерлы карары белән җиңел автомобильләрдә һәм йөк автомобиле кабинасында балаларны аларның авырлыгына һәм буена туры килә торган тиешле утырту системалары (җайланмалары) кулланып йөртү катгыйлана. 7 яшьтән 11 яшькә кадәрге (11 яшь тулганчы) балалар – авырлыгына һәм буена туры килә торган тиешле утырту системалары (җайланмалары) кулланып яисә иминлек каешлары белән эләктергән килеш йөртелә, ә җиңел автомобильнең алгы урындыгында – бары тик баланың авырлыгына һәм буена туры килә торган тиешле утырту системалары (җайланмалары) кулланып кына йөртеләләр. Элек балаларны йөрткәндә утырту системалары (җайланмалары) да, шулай ук транспорт чарасы конструкциясендә каралган иминлек каешлары ярдәмендә баланы эләктереп куя торган башка чаралар да кулланыла иде.

Моннан тыш, транспорт чарасы туктап торганда аның эчендә 7 яшькә кадәрге баланы балигъ яшьтәге заттан башка калдыру рөхсәт ителми.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 1 июлендәге 808 номерлы карары белән 2015 – 2017 елларда физик затларга автомобильләр сатып алу өчен Россия кредит оешмалары тарафыннан бирелгән кредитлар буенча алынмый калган керемнәрне каплауга Россия кредит оешмаларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертелде.

Кертелгән үзгәрешләр нигезендә, беренче мәртәбә автомобиль сатып алучы гражданнар, шулай ук ике һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган гражданнар автокредит алганда сатып алына торган автомобиль хакыннан 10% ташлама алалар.

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан 2017 елда ташламалы автокредит программасын гамәлгә ашыру дәвам итте, шулай ук автомобиль сәнәгатенә ярдәм итүнең яңа

адреслы чаралары: «Гаилә автомобиле» һәм «Беренче автомобиль» кебек программалар барлыкка килде, шулар кысаларында ташламалы кредит ставкасы буенча кимендә 58,35 мең автомобиль сату планлаштырыла, ул 2017 елның 1 июленнән кредитка алына торган машиналарга кагыла.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 2 сентябрендәге 1066 номерлы карары белән белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда төп гомуми белем программалары буенча көндез йөреп укучы ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, уку чорында ата-аналарының икесе дә яисә бердәнбер атасы йә анасы вафат булганда, шәһәр, шәһәр яны транспортында, авыл җирлегендә район эчендәге транспортта (таксидан тыш) түләүсез йөрүне, шулай ук елга бер мәртәбә уку урынына түләүсез барып кайтуны федераль бюджет акчалары исәбеннән тәэмин итү кагыйдәләре расланды.

Ятим балалар һәм ата-анасыз калган балалар укый торган белем бирү оешмалары уку тәмамланганчы аларның юлда бушлай йөрүләрен тәэмин итәргә тиешләр. Күрсәтелгән затлар ай саен шәһәр, шәһәр яны транспортында, авыл җирлегендә район эчендәге транспортта (таксидан тыш) түләүсез йөрү , шулай ук елга бер мәртәбә уку урынына түләүсез барып кайту белән тәэмин ителәләр.

Укучыларның теләге белән, юл йөрүгә бәйле чыгымнар белем бирү оешмасына юл йөрү документларын күрәткәч, капланырга мөмкин.

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 23 декабрендәге 1621 номерлы карары нигезендә 2018 елның 1 июленнән балаларны транспорт чараларында оешкан төстә йөрткәндә транспорт чараларында сары яисә кызгылт-сары төстәге ялтыравык маяк урнаштырылырга тиеш.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым актларына кертелгән башка төзәтмәләр белән - балаларны транспорт чараларында оешкан төстә йөрткәндә аларның иминлеген тәэмин итү максатларында, шул исәптән түбәндәгеләр карала:

балалар төркемен транспорт чараларында оешкан төстә йөрткәндә, югарыда күрсәтелгәннән тыш, маршрут программасын үтәүдә катнашучы туроператорлар, турагентлыклар яисә экскурсия хезмәтләре күрсәтүче оешмалар хезмәткәрләренең исемлекләре (фамилияләре, исемнәре, аталарының исеме (булса), һәр йөртүченең исеме (фамилиясе, атасының исеме, аның элемтә телефоны номеры) булырга тиеш (мондый хезмәткәрләр саны турындагы мәгълүматны балалар төркемен транспорт чараларында оешкан төстә йөртү башланганчы тиешле исемлек тапшырып хәбәр итәргә мөмкин);

транспорт чарасын йөртүченең эш стажына таләп билгеләнде – балалар төркемен транспорт чараларында оешкан төстә йөртү башланыр вакытка «D» категориясендәге транспорт чарасын йөртүченең өзлексез эш стажы кимендә бер ел булырга тиеш (элек – мондый стаж соңгы өч календарь елда кимендәбер ел булырга тиеш иде);

бу карарда шулай ук бер үк маршрут буенча берничә балалар төркемен транспорт чараларында оешкан төстә йөртү турындагы хәбәрнамәдә шундый йөртү планлаштырыла торган даталар һәм аларның вакыты күрсәтелергә тиеш, дип билгеләнгән;

карарда шулай ук маршрут программасын үтәүдә катнашучы туроператорлар, турагентлыклар яисә экскурсия хезмәтләре күрсәтүче оешмалар хезмәткәрләре, әгәр аларның туроператор, турагентлык яисә экскурсия хезмәтләре күрсәтүче оешма белән хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм мршрут программасын үтәүдә катнашуларын раслый торган документлары булса, автобуска утыра алулары билгеләнгән.

«Медицина ярдәме стандартлары нигезендә табиб (фельдшер) рецептлары буенча дару препаратлары белән, шулай ук инвалид балалар өчен махсус туклану продуктлары белән тәэмин итү буенча социаль хезмәт рәвешендәге дәүләт социаль ярдәмен алучы бер гражданга 2018 елда айга финанс чыгымнары нормативын билгеләү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 29 декабрендәге 864 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 25 декабрендәге 1628 номерлы карары белән медикаментлар һәм инвалид балалар өчен дәвалау туклануы продуктлары белән тәэмин итү буенча социаль хезмәт өчен бер гражданга финанс чыгымнары күләме 2018 елдан 823,4 сум тәшкил итә, дип билгеләнде.

Элек бу норматив федераль закон белән билгеләнә иде. 2016 елның 19 декабрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль закон белән 2017 елда 807,2 сум иде. Хәзер бу вәкаләт Россия Федерациясе Хөкүмәтенә бирелде.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1713 номерлы карары белән Ана (гаилә) капталы акчаларын (аларның бер өлешен) баланың (балаларның) белем алуына җибәрү һәм баланың (балаларның) белем алуына бәйле чыгымнарны гамәлгә ашыруга җибәрү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертелә. Әлеге карар нигезендә акчалар оешмалар тарафыннан түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү өчен җибәрелергә мөмкин.

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрәм калган балаларны гаилә тәрбиясенә урнаштыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1716 номерлы карары белән уллыкка алучылар булу мөмкинлеге турында бәяләмә алу өчен гражданнар тарафыннан бирелә торган документлар исемлеге кыскартылды.

Әлеге карар нигезендә күрсәтелгән затлар йорт (фатир) кенәгәсеннән торак урынныннан файдалану хокукын раслый торган өземтәне яисә торак урынына милкчелек хокукын раслый торган башка документны бирмәү хокукына ия; яшәү урынныннан шәхси финанс счеты күчермәсен бирмәү хокукына; эке эшәр органнарыннан опекун булырга теләүче затның хөкем ителмәгән булуын яисә җинаять эзәрекләве факты булмавын раслый торган белешмә китермәү хокукына ия; пенсия таныклыгы күчермәсен, Россия Пенсия фондының территориаль органыннан белешмә китермәү хокукына ия. Карар белән тиешле документларның опека һәм попечительлек органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә мөстәкыйль соратып алынырга тиешлеге билгеләнә.

Россия Федерациясе Хөкүмәтене 2017 елның 30 декабрендәге 1711 номерлы карары белән Россия кредит оешмаларына һәм «Ипотека торак кредиты агентлыгы» акционер җәмгыятенә Россия Федерациясенең балалы гражданнарына бирелгән торак (ипотека) кредитлары (заемнары) буенча алынмый калган керемнәрне каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү кагыйдәләре расланды. Мәсәлән, Россия гаиләсендә 2018 ел башыннан 2022 ел ахырына кадәр чорда икенче яисә өченче бала туса, алар 6 процентлы ташламалы ипотека кредиты белән яңа фатир ала алалар. Россия кредит оешмаларына һәм «Ипотека торак кредиты агентлыгы» акционер җәмгыятенә ташламалы кредитлар бирүгә бәйле алынмый калган керемнәрне каплау өчен федераль субсидияләр бирелә. Аларны алу өчен тиешле кредит шартнамәсе түбәндәге шартларга туры килергә тиеш:

кредит (займ) суммасы 8 млн. сумга кадәр булырга тиеш – Мәскәүдәге, Мәскәү өлкәсендәге, Санкт-Петербургтагы һәм Ленинград өлкәсендәге фатирлар өчен; 3 млн. сумга кадәр – Россия Федерациясенең башка субъектларындагы тораклар өчен;

займ алучы сатып алына торган торак суммасыннан кимендә 20 процентын үз акчалары исәбеннән түли;

кредитны (займны) түләү ай саен тигез өлешле (аннуитет) суммалар белән башкарыла (беренче һәм икенче түләүдән башка).

Субсидияләр алу өчен кредит оешмалары һәм Агентлык әлеге Кагыйдәләр гамәлгә кергән көннән 30 календарь көн эчендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгына тиешле документлар белән кәгазьдә килеш яисә электрон рәвештә заявка бирелә, аңа ай саен бирелә торган кредитларның (займнарының) яисә ай саен кредитлар (займнар) буенча таләпләр хокукын алуның 2013 елга кадәр план-графигы (ай саен кимендә 100 млн. сум) өстәлеп бирелә.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 22 маендагы 978-р номерлы күрсәтмәсе белән балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыруны дәүләт тарафыннан җайга салуның һәм аны тикшереп торуның нигезләре билгеләнде, балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыруның өстенлекле бурычлары билгеләнде. Кабул ителгән карарлар закон чыгаруны һәм норматив хокукый базаны камилләштерүгә, балаларны имин ял иттерү өчен шартлар булдыруга һәм балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру инфраструктурасын саклап калуга һәм үстерүгә юнәлдерелә.

«Балалар» мәсьәләләренҗайга сала торган тармак федераль норматив хокукый актлар арасында аеруча әһәмиятлеләреннән түбәндәге документларны атарга мөмкин.

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2017 елның 10 августындагы 514н номерлы боерыгы белән балигъ булмаганнарга профилактик медицина тикшерүе уздыру тәртибе расланды.

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2017 елның 21 мартындаг 124н номерлы боерыгы белән туберкулезны ачыклау максатларында гражданнарга (олыларга һәм балаларга) профилактик медицина тикшерүе уздыру кагыйдәләреюилгеләнде.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыны 2017 елның 29 декабрендәге 889н номерлы боерыгы белән беренче һәм (яисә) икенче бала тууга (уллыкка алуга) бәйле рәвештә айлык түләүләрне башкару, бу түләүләрне алу өчен мөрәҗәгать итү тәртибе, шулай ук беренче һәм (яисә) икенче бала тууга (уллыкка алуга) бәйле рәвештә «Балалы гаиләләргә айлык түләүләр турында» 2017 елның 28 декабрендәге 418-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә айлык түләүләр билгеләү өчен кирәкле документлар исемлеге расланды.

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2017 елның 22 мартындагы 38 номерлы карары белән балалар ялын регламентлаучы кайбер санитар кагыйдәләр һәм нормалар нигезләмәләренә үзгәрешләр кертелде.

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2017 елның 5 апрелендәге 511 номерлы боерыгы белән туристик маршрутларга (хәрәкәттәге башка маршрутларга) балалар төркемнәре беләне узу шартлары билгеләнде.

Балигъ булмаган туристлар туристик маршрутны узганда алар белән бергә җитәкче һәм 8-12 туристка бер йөртүче булырга тиеш.

Моннан тыш, куркыныч тудыра торган туристик маршрутта балигъ булмаган туристлар инструктор-проводник белән йөрергә тиеш. Туристик маршрут һәм алда очраргга мөмкин булган хәвефлелек турындагы мәгълүмат балигъ булмаган туристларга, аларның ата-аналарына маршрут башланганчы җиткерелергә тиеш. Шулай ук җитәкче яисә җитәкләп йөртүче һәм инструктор-проводник туристик маршруттагы иминлек мәсьәләләре турында инструктаж үткәрергә тиешләр.

Туроператорлар, турагентлар һәм экскурсия хезмәтләре күрсәтүче оешмалар Россия Федерациясенең Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының территориаль органына балигъ

булмаганнарның туристик маршрутлары башланырга 10 эш көненнән дә соңга калмыйча үтү кыен булган маршрутлар, хәвефлелек куркынычы булган су, тау, спелеологик һәм башка объектлар буенча уза торган мршрутлар турында хәбәр итәргә тиешләр.

Татарстан Республикасы законнарына килгәндә, 2017елда республика законнарын федераль законнарга яраклаштыруга бәйле закон актлары кабул ителде.

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга кагылышлы норматив хокукый актлары арасында түбәндәгеләргә игътибар итәргәкирәк.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 21 мартындагы 169 номерлы «Махсуслаштырылган торак фондында яшәүче ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны җитәкләп йөртү турында»гы карары белән махсуслаштырылган торак фондында яшәүче ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны җитәкләп йөртү аларның фактта яши торганурыннарында гамәлгә ашырыла, дип билгеләнә. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ярты елга бер мәртәбә мондый затлар турында җирле үзидарә органнарына, социаль яклауның территориаль органнарына мәгълүмат бирә. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы бу затларга Татарстан Республикасы милкендәге махсуслаштырылган торак фондынннан бирелгән торак урыннарга коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү буенча бурычлар мониторингын уздыра; квартал саен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы милкендәге махсуслаштырылган торак фондынннан бирелгән торак урыннарга коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү буенча бурычлар турында белешмәләр җибәрә.

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен балалар йортлары ата-аналар тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруга ярдәм итү, балалар алучы гаиләләрне әзерләү буенча дәүләт бюджет үзәкләре махсуслаштырылган торак фондында яшәүче һәм социаль хезмәтләр күрсәтелүгә мохтаҗ гражданнар реестрын алып баралар; махсуслаштырылган торак фондында яшәү урынында гражданнарга патронаж уздыралар (фатирлар буйлап тикшереп чыгалар); граждан гаиләсенең социаль паспортын төзиләр; махсуслаштырылган торак фондында яшәүчеләр арасында мөнәсәбәтләрне җайга салу буенча инициатив төркемнәр булдыралар; ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны җитәкләп йөрү буенча шартнамәләр төзиләр; ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны социаль йөртү буенча индивидуаль программаларны гамәлгә ашыралар; Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына махсуслаштырылган торак фонды биналарының бозылуы, торакның өченче затларга арендага бирелүе турында язмача хәбәр итәләр.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 24 мартындагы 179 номерлы карары белән «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 ел, 18 гыйнвар, 9 нчы карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация алу буенча мөрәҗәгать итү һәм аны түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 июнендәге 399 номерлы «Гаилә мәктәпкәчә төркемнәрен оештыру турында»гы карары мәктәпкәчә бе-

лем бирү оешмаларына йөрмәүче балалар өчен мәктәпкәчә белем алуны тәэмин итү, мәктәпкәчә белемнең вариатив формаларын үстерү максатларында кабул ителде. Гаилә мәктәпкәчә төркемнәре түбәндәге максатларда оештырыла:

күпбалалы гаиләләргә, шул исәптән сәламәтлеге чикле булган балалары булган гаиләләргә ярдәм итү;

күпбалалы ата-аналарга, балаларын тәрбияләү процессын үзмичә, эшкә урнашу мөмкинлеген бирү;

гаиләләрдә мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләренә халык ихтыяҗын канәгатьләнберү.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 17 июлендәге 493 номерлы «Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алуга бәйле гражданнарга өстәмә бер тапкыр акчалата түләү турында»гы карары инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алуга бәйле гаиләләргә социаль булышлык күрсәтүне көчәйтү максатларында кабул ителде. Әлеге карар белән түбәндәгеләр билгеләнде:

2017 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алу белән бәйле гражданнарга өстәмә бер тапкыр акчалата түләү 200 мең сум тәшкил итә;

Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алу белән бәйле гражданнарга өстәмә бер тапкыр акчалата түләү бирүгә чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына каралган бюджет ассигнованиеләре исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Ике яисә берничә инвалид бала уллыкка алынганда бер мәртәбә акчалата түләү һәр бала өчен башкарыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 8 сентябрендәге 641 номерлы «2018 елга айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре турында»гы кары белән 2018 елның 1 гыйнварыннан айлык акчалата түләүләрне һәм башка төр түләүләрне индексацияләү коэффициенты 1,04 итеп билгеләнде, шулай ук айлык акчалата түләүләрнең һәм башка түләүләрнең күләмнәре билгеләнде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 21 июлендәге 1739-р күрсәтмәсе белән Татарстан Республикасында 2017-2019 елларга медиакиңлектә балаларның мәгълүмат иминлеген тәэмин итү буенча чаралар планы («юл картасы») расланды. Әлеге күрсәтмә белән Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең әхлакый, физик, психологик һәм социаль сәламәтлеген тәэмин итү, саклау һәм ныгыту өчен имин мәгълүмати-белем бирү мохитен булдыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы башкарма дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм предприятиеләрнең, кызыксынучы ведомстволарның хезмәттәшлеген оештыру мәсьәләләре җайга салына.

2017 ЕЛДА ТОРМЫШ КӨНКҮРЕШЕНЕҢ ТӨП ӨЛКӘЛӘРЕНДӘ БАЛА ХОКУКЛАРЫНЫҢ САКЛАНУЫ

БҮЛЕК 3

3.1. 2017 елда гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлауга нигезләнгән Татарстан Республикасында балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше өлкәсендәге проблемалы мәсьәләләрнең гомуми мониторингы


Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше өлкәсендә проблемалы мәсьәләләрне ачыкларга мөмкинлек бирә торган мөһим индикатор була.

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 2 007 мәсьәлә буенча 1 938 мөрәҗәгать керде.

Мөрәҗәгатьләрне анализлау, тормыш эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә балаларның хокукларын гамәлгә ашыруның торышын чагылдыра торган шикаятьләр санына карап, аларны **тематика** буенча структураларга мөмкинлек бирә.

28 нче диаграмма


2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы



2017 ел йомгаклары буенча әлеге анализ нәтиҗәләреннән күренгәнчә, гражданнарның гадәттә мөрәҗәгать итә торган темалары үзгәрә. 2012-2016 елларда баланың торакка, гаиләгә һәм белемгә хокуклары бозылуга шикаять белдергән мөрәҗәгатьләр өстенлек итсә, ә 2017 елда баланың белемгә хокукын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча шикаятьләр күбрәк.

29 нчы диаграмма

2013 – 2017 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр тематикасының структурасы



2017 елда мөрәҗәгатьләр санының арту динамикасы, аерым алганда, балаларның белем алуга хокуклары бозылуга карата шикаятьләрнең күбрәк булуына бәйле.

2 нче таблица


2016-2017 елларда тематика буенча мөрәҗәгатьләр динамикасы

Мөрәҗәгатьләр тематикасы	Барысы		Үзгәрешләр динамикасы (абс., бер.)
	2016 ел	2017 ел	
Барлыгы	**1767**	**1938**	**+171**
Белемгә хокук	370	510	+140
Тораккa хокук	431	437	+6
Гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә хокук	423	434	+11
Лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокук	157	196	+39
Социаль тәэмин ителешкә хокук	171	128	-43
Яшәүгә хокук һәм сәламәтлек саклау хезмәтләренә хокук	114	109	-5
Көч кулланудан яклануга хокук	76	87	+11
Гражданлыкка хокук	25	16	-9
Фикер, әхлак һәм дин иректә хокук	0	1	+1
Башка мөрәҗәгатьләр		20	

2017 елда мөрәҗәгатьләр саны буенча беренче урынга ***балаларның белемгә хокукларын гамәлгә ашыру*** мәсьәләләре чыкты. Күрсәтелгән тематика буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 510 мөрәҗәгать керде, бу барлык кергән мөрәҗәгатьләр санының 26,3%ын тәшкил итә. Агымдагы елда бу тема буенча мөрәҗәгатьләр саны 37,8%ка артты (140 мөрәҗәгать), ягъни 2016 елдагы 370 мөрәҗәгатьтән 2017 елда 510 мөрәҗәгатькә кадәр җитте.

30 нчы диаграмма

2017 елда балаларның белем алу хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча кергән мөрәҗәгатьләр тематикасының структурасы



3 нче таблица

2016-2017 елларда балаларның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр динамикасы

Мөрәҗәгатьләр тематикасы	Барысы		Үзгәрешләр динамикасы (абс., ед.)
	2016 год	2017 год	
Барлыгы	**370**	**510**	**+140**
Мәктәпкәчә учреждениеләрдә урыннар бирү	63	122	+59
Белем бирү процессында катнашучылар арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләр	99	105	+6
Белем бирү оешмаларында тукланууны оештыру	12	93	+81
Белем бирү оешмаларында укыту-тәрбияләү процессын оештыру, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты	90	81	-9
Укучыларны белем бирү оешмаларына алу йә күчерү	52	36	-16
Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балаларны укыту	30	37	+7
Белем бирү оешмаларын бетерү, үзгәртеп кору	10	18	+8
Укучыларга һәм тәрбияләнүчеләргә транспорт хезмәте күрсәтү	14	11	-3
Башка мөрәҗәгатьләр		7	

Бу тематика буенча кергән мөрәҗәгатьләрнең чиреге (24%) диярлек (122 мөрәҗәгать) балаларның мәктәпкәчә белемгә хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләреңә карый. Узган ел белән чагыштырганда мондый шикаять саны ике мәртәбә артты. Гражданнарның мәктәпкәчә белемгә бала хокукын гамәлгә ашыруга кагылышлы мөрәҗәгатьләре (81 мөрәҗәгать) арасында 68%ы өч яшькә кадәрге баланы балалар бакчасына урнаштыруга ярдәм итүне сорап язылган, 12%ы (14 мөрәҗәгать – сәләмәтлек мөмкинлекләре чикле булган балаларга ярдәм итүне сорап язылган.

Белем бирү өлкәсендә аеруча игътибар үзәгендәге мәсьәләләрнең икенчесе – белем бирү процессында катнашучылар арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләр. Бу өлкәдә шикаятьләрнең артуы мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында белем бирү һәм тәрбияләү шартларында тискәре күренешләрнең сакланып калуын күрсәтә. Болар арасында мәктәпләрдәге конфликтларга кагылышлы шикаятьләр өстенлек итә. Мондый мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча белем бирү оешмаларын гамәлгә куючылар, аларның җитәкчеләре адресына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан укучыларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында 34 бәяләмә җибәрелде, бу гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча бәяләмәләр санының 66,6 % тәшкил итә.


Әлеге проблема белән үзара бәйле мәсьәләләрнең тагын берсе – белем бирү оешмаларында укыту-тәрбияләү процессын оештыру һәм белем бирү хезмәтләреңең сыйфаты. Мондый вәзгыятькә карата ата-аналардан кергән шикаятьләр саны рейтингның дүртенче баскычын тәшкил итәләр.

Анализлаган чордан күренгәнчә, укучыларны (тәрбияләнүчеләрне) тукландыруны оештыру мәсьәләләре буенча да мөрәҗәгатьләр артты. Бу темага Аппарат тарафыннан оештырылган «кайнар линия»гә 87 мөрәҗәгать керде. Бу өлкәгә караган мөрәҗәгатьләр аеруча Казан шәһәрендә яшәүчеләрдән күп килә.

Мөрәҗәгатьләр саны буенча икенче баскычта – ***балаларның торак хокукларын*** гамәлгә ашыру мәсьәләләре. Бу проблема буенча шикаятьләрнең шактый булуы әлеге өлкәдә балалрның хокукларын яклауның бик актуаль булуын раслый. Күрсәтелгән тема буенча анализлау чорында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә 437 мөрәҗәгать керде, бу барлык мөрәҗәгатьләр санынnан 22,5% тәшкил итә (2016 елда – 24,4%).

31 нче диаграмма

2017 елда балаларның торак хокукларын яклау мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасының структурасы



4 нче таблица

2016-2017 елларда балаларны торак хокукларын яклау мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр динамикасы

Мөрәҗәгатьләрнең тематикасы	Барысы		Үзгәрешләр динамикасы (абс., бер.)
	2016 ел	2017 ел	
Барлыгы	**431**	**437**	**+6**
Гаиләнең торак шартларын яхшырту мәсьәләләре	97	**110**	+13
Торак мәсьәләләрен судта хәл итү	122	**70**	-52
Күпбалалы гаиләләрне һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү	37	**55**	+18
Гаиләләрне авария хәлендәге торактан чыгару мәсьәләләре	13	**40**	+27
Кредит йөкләмәләре буенча бурыч булуга бәйле рәвештә балаларны торактан чыгару, теркәүдән төшерү	42	**38**	-4
Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү	41	**36**	-5
Ата-анасы аерылышуга бәйле рәвештә баланы теркәүдән төшерү, торактан чыгару	43	**18**	-25
Бу тематика буенча башка мөрәҗәгатьләр (шул исәптән торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү, торак төзү өчен җир бүлеп бирү мәсьәләләре буенча)	36	**70**	+34

Бу тематика буенча мөрәҗәгать санының былтыргы дәрәҗәсе сакланып калуга карамастан, 2017 елда гаиләләрне авария хәлендәге торактан чыгару мәсьәләсе буенча


мөрәҗәгатьләр саны өч мәртәбә диярлек артты, җир кишәрлекләре бүлеп бирү мәсьәләсен хәл итү буенча җирле үзидарә органнарына, торак-коммуналь хезмәтләре күрсәтү буенча идарәчел компанияләргә карата шикаятьләр саны ике мәртәбә диярлек артты. Гадәттәгечә, күпбалалы гаиләләрдән һәм инвалид балалары булган гаиләләрдән мөрәҗәгатьләр күп килә, шулай ук торак шартларын яхшыртуга кагылышлы мөрәҗәгатьләр саны да кимеми.

Безнеңчә, консультация эше уздыру нәтиҗәсендә узган ел торак мәсьәләсен хәл итү буенча суд органнарына карата мөрәҗәгатьләр саны кимеде (ике мәртәбә диярлек). Әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгатьләрнең күпчелеге Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең суд процессында катнашуын һәм (яисә) суд карарына шикаять бирү тәртибенә аңлатмалар бирүен үтенеп язылган.

Мөрәҗәгатьләр саны рейтингының өченче баскычын балаларның ***гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә*** хокукларын яклау мәсьәләләре били.

32 нче диаграмма

2017 елда гаилә мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематиксының структурасы



Агымдагы елда гаилә тәрбиясе, ата-ана бурычларын билгеләү һәм үтәү, балигъ булмаганнарның һәм башка туганнарның гаилә элемтәләренә хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча төрле мөрәҗәгатьләрнең артуы күзәтелә. Бу тематика буенча 434 мөрәҗәгать каралды, бу барлык мөрәҗәгатьләр санының 22,4% тәшкил итә.

5 нче таблица

2016-2017 елларда гаилә мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр динамикасы

Мөрәҗәгатьләр тематикасы	**Барысы**		**Үзгәрешләр динамикасы (абс., бер.)**
	2016 ел	**2017 ел**	
Барлыгы	**423**	**434**	**+11**
Ата-аналары аерылганнан соң, аларның берәрсе вафат булганнан соң балаларны тәрбияләү мәсьәләләре	174	149	-25
Опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеге, балаларны опекага (попечительлеккә) тапшыру, уллыкка алу мәсьәләләре	75	96	+21
Гаиләдәге ыгы-зыгылар турында хәбәр итү	73	86	+13
Балаларны законсыз рәвештә алып китү һәм җибәрмәү	39	36	-3
Ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү мәсьәләсен күтәреп чыгу	15	27	+12
Ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән ата-аналарның балаларын кире кайтару теләге	20	11	-9
Бу тематика буенча башка мөрәҗәгатьләр		29	

Агымдагы елда да, беркадәр кимесә дә, баланың ата-анасы аерылышканнан соң аның яшәү урынын ачыклауга бәйле бәхәсле вәзгыять турындагы, баланың аерым яшәүче атасы яисә анасы белән, башка туганнары белән аралашу тәртибен билгеләү, бала белән аралашуга киртәләрне юкка чыгару хакындагы мөрәҗәгатьләр шактый булды (2016 елда – 174, 2017 елда – 149). Гаилә эчендәге мондый бәхәсле мәсьәләләрне хәл итүдә булышуны сорап 2017 елда 149 кеше мөрәҗәгать итте (бу – әлеге тематика буенча кергән мөрәҗәгатьләрнең 34,3 %ы). 2016 елда мондый мөрәҗәгатьләр 174 булган иде (41,1%).

Балаларны бүтән гаилә тәрбиясенә тапшыру мәсьәләләрен хәл итүдә муниципаль районнардагы опека һәм попечительлек органнарының гамәлләренә, аларның битарафлыгына карата да гражданнардан шикаятьләр ешрак килә башлады, шул исәптән опекадагы балаларны тоту өчен бирелә торган акчаларның дөрес тотылмавына карата юлланганнары да бар. 2016 елда шул темага 75 мөрәҗәгать каралган булса, 2017 елда аларның саны 96га җитте, бу барлык мөрәҗәгатьләрнең 22,1%ын тәшкил итә.

2017 елда гаиләләрдәге социаль тотрыксызлык, гражданнарның үз ата-аналарына рәхимсезлеге, шул исәптән балаларга карата мәрхәмәтсезлек турындагы хәбәрләр 17,8%ка артты (2016 елда – 73, 2017 елда 86). Мондый категориядәге мөрәҗәгатьләр саны барлык мөрәҗәгатьләрнең 19,8%ын тәшкил итә.

Балаларны ата-ана хокуклары чикләнгән яисә ул хокуклардан мәхрүм ителгән гражданнар тарафыннан балаларны законсыз рәвештә гаиләдән алып китү һәм аларны җибәрмәү турындагы мөрәҗәгатьләр беркадәр кимеде. Андый очраклар 2017 елда 36 улды, ә 2016 елда – 39.

2017 елда ата-ана хокуклары чикләнгән яисә ул хокуклардан мәхрүм ителгән гражданнар тарафыннан балаларны үзләренә кире кайтаруда ярдәмитүне үтенеп язылган мөрәҗәгатьләр саны кимеде (2016 елда 20 булса, 2017 елда 11 булды). Шул ук вакытта ата-ана хокукларыннан мәхрүм итүгә ярдәм итүне үтенеп язылганнары артты (2016 елда 15 булса, 2017 елда 27гә җитте (80%ка артты). Мондый мөрәҗәгатьләрнең инициаторлары күпчелек очракта балаларның туганнары була.

Балаларның ***лаеклы тормыш дәрәҗәсенә*** хокукларын тәэмин итүгә бәйле проблемалар дүртенче урында тора, мондыйлар – 196 мөрәҗәгать (10%) (2016 году елда – 157 мөрәҗәгать иде яки 9%). Элеккечә үк шикаятьләрнең төп субъектлары – үз балаларына яшәү һәм тәрбия өчен кирәкле матди шартлар тудыру буенча ата-ана бурычларын тиешенчә үтәмәгән ата-аналар, бу мөрәҗәгатьләр, күбрәк, алимент йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәүгә кагыла. Мондый сораулар белән ел саен мөрәҗәгать итүче гражданнарның саны соңгы елларда гел бер чамада тора. 2017 елда мондый мәсьәләләр буенча 118 кеше мөрәҗәгать итте, бу әлеге темага кергән барлык мөрәҗәгатьләрнең 60,2%ын тәшкил итә, (2016 елда – 114 яки 72,6%). Бу ата-аналарның алимент йөкләмәләрен үтәмәү проблемасының актуальлеге елдан-ел сакланып калуын күрсәтә.

Балаларның ***социаль тәэминатка хокукларын тәэмин итү*** мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр бишенче урында тора. 2017 елда аларның саны 128 булды яки 6,6%. шулай да узган ел белән чагыштырганда алалрның саны кимеде. Узган ел йомгаклары буенча әлеге тематикага караган мөрәҗәгатьләр 171 иде, бу барлык мөрәҗәгатьләрнең 10 %ын тәшкил иткән иде. Бу күрсәткеч 25%ка кимеде. Һәр бишенче мөрәҗәгать диярлек (28 мөрәҗәгать яки 21,8%) инвалид балаларны шифаханә-курортта дәвалауга һәм заманча техник реабилитацияләү чаралары белән тәэмин итүгә кагыла.

2016 ел белән чагыштырганда 2017 елда төрле социаль түләүләр мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең саны 22гә кимеде һәм 2017 елда аларның саны 82 булды,

бу шушы темга гомуми мөрәҗәгатьләр саныннан 64 % тәшкил итә (2016 елда – 104 мөрәҗәгать иде).

Балаларның сыйфатлы медицина хезмәтләренә хокукларын яклау мәсьәләләре буенча язылган мөрәҗәгатьләр алтынчы урында тора (109 мөрәҗәгать, ягъни 5,6%). Гражданнар үз мөрәҗәгатьләрендә, элеккечә үк, ташламалы дарулар белән тәэмин итү, медицина ярдәме күрсәтүне оештыру, аңардан файдалана алу мөмкинлеге һәм аның сыйфаты мәсьәләләре турында язалар.

Гражданнар мөрәҗәгатьләре саны буенча җиденче урында б***алаларны барлык төр көч куллануларданһәм рәхимсезлекләрдән*** яклау мәсьәләләре булды. 2017 елда бу темага мөрәҗәгатьләр 2016 ел дәрәҗәсендә калды диярлек. 2016 елда 76 мөрәҗәгать (4,3%) булса, 2017 елда 87 мөрәҗәгать (4,4%) булды. Мөрәҗәгатьләрнең күбесендә гаиләдә балага карата көч куллану һәм аңа карата рәхимсезлек кылу гамәлләре (гаиләдә көч куллану) фактлары турында хәбәр ителә, бу мәсьәлә аерым борчу уята. 2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан балалар бакчаларында тәрбиячеләрнең балаларга карата мөнәсәбәтләренә кагылышлы мөрәҗәгатьләр дә каралды. Моннан тыш, тикшерү органнарына карата да шикаятьләр белдерелә, аларда, аерым алганда, җинаять эшләрен кузгатудан, гариза бирүче фикеренчә, нигезсез баш тартулар һәм процессуаль карарлар кабул итү яки процессуаль гамәлләр башкару сроклары бозылу турында сүз алып барыла.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына килгән мөрәҗәгатьләрнең тематикалары буенча иң соңгы урында паспорт алганда, теркәү исәбенә басканда, гражданлыкны билгеләгәндә ***балигъ булмаганнарның гражданлык хокуклары бозылу*** турындагы мөрәҗәгатьләр тора. Хисап чоры дәвамында әлеге мәсьәләләрне хәл итүдә ярдәм сорап 16 кеше мөрәҗәгать итте (2016 елда – 25).

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән ***гражданнар категорияләренә килгәндә, гадәттәгечә,*** 2017 елда да балигъ булмаганнарның ата-аналарыннан килгән мөрәҗәгатьләр өстенлек итә – аларның саны 1 342 булды (69,2%) (2016 елда – 1148 яки 66,4%).

Балаларның туганнарыннан 229 мөрәҗәгать (11,8%) алынды (2016 елда – 231 мөрәҗәгать, 13,4 %) алынды. Мөрәҗәгатьләрдә, нигездә, ата-аналарның үз вазыйфаларын намуссыз башкаруларына, балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм аларның хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарының битпрпафлыгына, туганнары белән аралашуда бала хокуклары бозылуга зарланалар.

Мөрәҗәгать итүчеләрдән өченче урында – балалар язмышына битараф булмаган чит гражданнар. Гомуми мөрәҗәгатьләр саныннан аларныңөлеше 8,5% тәшкил итә яки 164 мөрәҗәгать (2016 елда – 140 мөрәҗәгать яки 8,1%).

Опекуннар (попечительләр), тәрбиягә бала алган ата-аналар Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә 92 мөрәҗәгать юллаганнар, бу мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан 4,8 % тәшкил итә (2016 елда – 93 мөрәҗәгать, 5,4 %). Аларда күтәрелгән төп темалар опека һәм попечительлек, аларның тәрбиясендәге балаларның торак хокуклары үтәлү-үтәлмәү, алар тәрбиясендәге балаларның торак хокуклары үтәлеше, балигъ булмаганнарның акчаларын тоту өлкәсенә карый.

Шуны да әйтеп китәргә кирәк, 2016 ел белән чагыштырганда, 2017 елда балалар омбудсменына балигъ булмаганнарның үзләреннән килгән мөрәҗәгатьләр 12гә, ягъни 26%ка кимеде һәм ул 2017 елда аларның саны 34 булды, 2016 елда 46 мөрәҗәгать алынган иде.

2017 елда ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлардан килгән мөрәҗәгатьләр саны үзгәрмәде диярлек (2016 елда – 24, 2017

елда – 25). Аларның барысы да диярлек торак алу яисә торак шартларын яхшырту хокукын яклауга кагылышлы иде.

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә хезмәттәшлек итү, үзара мөнәсәбәтләр һәм балаларга ярдәм итү мәсьәләләре буенча иҗтимагый оешмалар вәкилләре ешрак мөрәҗәгать итә башладылар (2016 елда – 20 очрак булса, 2017 елда андый очраклар 30 булды).

6 нчы таблица

2015 – 2017 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән гражданнар категорияләре

Гражданнар категорияләре	**2015 ел**	**2016 ел**	**2017 ел**	
	Мөрәҗәгать итүчеләр саны			%
Ата-аналар	1093	1148	1342	69,2
Башка туганнар	190	231	229	11,8
Башка затлар (чит гражданнар, күршеләр һәм башкалар)	172	140	164	8,5
Опекуннар һәм попечительләр	63	93	92	4,8
Балигъ булмаганнар	49	46	34	1,7
Иҗтимагый оешмалар вәкилләре	54	20	30	1,5
Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар	31	24	25	1,3
Балалар бакчалары җитәкчеләре, хезмәткәрләре	12	27	22	1,2


Мөрәҗәгатьләрнең географиясенә килгәндә, шуны билгеләп китәргә кирәк, 2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән гариза бирүчеләрнең иң күп өлешен, узган еллардагы кебек үк, Татарстан Республикасында яшәүчеләр алып тора, алар тарафыннан 1 851 мөрәҗәгать җибәрелгән (95,5%), башка илләрдә һәм Россия Федерациясенең башка субъектларыннан – 51 граждан (2,7%). 36 граждан (1,8%) үзләренең яшәү урыннарын белә торып күрсәтмәгәннәр яисә онытканнар.

Республиканың муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча карасак, элеккечә, мөрәҗәгатьләрнең иң күп саны – 1 131 мөрәҗәгать (58,4%) – Казан шәһәре халкыннан алынды. Мөрәҗәгатьләр саны буенча икенче урында Чаллы шәһәрендә яшәүчеләрдән килгән мөрәҗәгатьләр – 115 мөрәҗәгать, бу мөрәҗәгатьләрнең гомуми санының 5,9 % тәшкил итә, өченче урында – Зеленодольск районыннан килгән мөрәҗәгатьләр (81 мөрәҗәгать, ягъни 4,2%), дүртенчедә – Алабуга районы (64 мөрәҗәгать, ягъни 3,3%), бишенчедә – Бөгелмә районы (44 мөрәҗәгать, ягъни 2,3%), алтынчыда – Әлмәт районы (39 мөрәҗәгать, ягъни 2,0%), җиденчедә – Түбән Кама районы (36 мөрәҗәгать, ягъни 1,8%).

Республиканың башка муниципаль районнарыннан кергән мөрәҗәгатьләр саны диаграммада күрсәтелде.

33 нче диаграмма

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрнең республика муниципаль районнары буенча саны




2017 елда республиканың Теләче һәм Чирмешән муниципаль районнары халкыннан мөрәҗәгатьләр булмады.

2017 елда шулай ук Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына турыдан-туры яисә төбәкләрдәге бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр аша Россиянең башка төбәкләреннән 44 мөрәҗәгать (гомуми мөрәҗәгатьләр санынан 2,3%) керде: Ульяновск, Мәскәү, Төмән, Свердловск, Владимир, Киров, Иркутск, Оренбург, Саратов өлкәләреннән, Башкортостан Республикасыннан, Удмуртия Республикасыннан, Марий Эл Республикасыннан, Бурятия Республикасыннан, Чувашия Республикасыннан, Пермь краеннан, Хантый-Манси автоном округыннан – Югры, Мәскәү шәһәреннән, Санкт-Петербург шәһәреннән, 7 мөрәҗәгать – чит ил гражданнарыннан (Үзбәкстан, Украина, Төркия, Германия, Италия).

Мөрәҗәгатьләрнең төрләрен анализлаудан күренгәнчә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрнең 989ы – шикаять, калган 949ы – башка төр мөрәҗәгатьләр (мәгълүмат, аңлатма, консультацияләр бирү, ярдәм күрсәтү турында үтенечнамәләр). 2017 елда мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынан шикаятьләр 51%ын тәшкил итә.

34 нче диаграмма


2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрне төрләре буенча бүлү



2017 елда елда 2016 елдагыга караганда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә шикаятьләр белән ешрак мөрәҗәгать иттеләр (42%тан 51%ка кадәр артты). Шул ук вакытта консультацияләр бирү, гамәлдәге законнарның нормаларын аңлату һәм проблеманы яки каршылыклы очракны хәл итүдә ярдәм күрсәтү үтенече белән язылган мөрәҗәгать дә бар (949 мөрәҗәгать, ягъни 49%).

35 нче диаграмма

2011 – 2017 елларда шикаятьләр һәм башка мөрәҗәгатьләр өлешләренә чагыштырма анализ




Шикаятьләрнең тематикасы буенча иң күп санда шикаятьләр белем өлкәсендә ***балаларның хокукларын һәм законлы*** мәнфәгатьләрен яклауга кагылышлылар булды (31%). Шулардан барлык дәрәҗәдәге хакимият органнарының, җитәкчеләрнең, вазыйфаи затларның мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә баланы урын белән тәэмин итү, укучыларны тукландыру, белем бирү процессында катнашучылар арасындагы каршылыкларны бетерү мәсьәләләрен хәл итү гамәлләренә яки аларның битарафлыгына карата булган шикаятьләр өстенлек итә.

Икенче урынны балалы гаиләләрнең торак хокукларын яклауга карата шикаятьләр били. Бу темага 437 мөрәҗәгатьнең 205ендә (47 %) төрле дәрәҗәдәге хакимит органнарының, суд органнарының балаларны лаеклы торак шартлары белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итүдә кылган-кылмаган гамәлләре, балаларны торактан «урамга» чыгару турында карарлар кабул иткәндә аларның битрафлыгы яктыртылган.

Шикаятьләрнең өченче баскычын балаларның ***гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә*** хокукларын яклау мәсьәләләре били (22%). Шуларның күбесендә гражданнарның ата-ана аерылышканнан соң бала тәрбияләү процессында катнашу мөмкинлеге булма яисә аның чикле булуы, баланың туганнары белән аралашу мөмкинлеге булма мәсьәләләре хәл ителгәндә җирле үзидарә органының битарафлык күрсәтүе турында языла.

36 нчы диаграмма


2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән шикаятьләр тематикасы



Шикаять бирелү субъектлары буенча шикаятьләрне түбәндәгечә структуралаштырырга мөмкин.

37 нче диаграмма

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән шикаятьләрнең шикаять бирелү субъектлары буенча бүлү



2017 елда шикаять бирелү субъектларына барлык дәрәҗәдәге гавами хакимият органнары (федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары), суд органнары, төрле оешмаларның җитәкчеләре һәм гражданнар керә.

2017 елда шикаять бирелү субъектлары арасында алты ел эчендә беренче мәртәбә төрле оешмаларның җитәкчеләренә һәм вазыйфаи затларына карата шикаять ләр өстенлек итә (306 шикаять, 31%).

Шикаять бирелү субъектлары арасында икенче урында (267 шикаять, 27%) җирле үзидарә органнары тора.

Өченче урында гражданнар гамәлләренә карата шикаятьләр (150 шикаять, 15,2%).


федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына карата шикаятьләр белән гражданнар 140 очракта (14,2%) мөрәҗәгать иттеләр.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына карата 72 шикаять булды, ягъни 7,2%).

Суд органнары карарлары белән канәгать булмаган 54 граждан (ягъни (5,4%) мөрәҗәгать итте.

38 нче диаграмма

2011-2017 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә шикаять бирелү субъектлары буенча кергән шикаятьләр саны



Чагыштырма анализдан күренгәнчә, барлык шикаятьләрнең 48%ында гражданнар гавами хакимиятнең кылган гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) канәгать түгел. Шула да, 2016 ел белән чагыштырганда аларның өлеше 2%ка диярлек кимегән (2016 елда – 50%, 2015 елда – 53%). Әмма гомуми күләмдә кпраганда,хакимият органнарына шикаятьләр 365тән 479га арткан. Бернчедән, җирле үзидарә органнарының кылган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләр артты – 2016 елда 196 булса, 2017 елда 267гә җитте. Гражданнардан федераль дәүләт хакимияте органнарына карата шикаятьләр саны 27,3%ка артты, 2016 елда – 110, 2017 елда 140 шикаять булды. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына шикаятьләр саны 22%ка да артты, 2016 елда – 59, 2017 елда – 72 шикаять.

Төрле оешмаларның җитәкчеләренә һәм вазыйфаи затларына карата шикаятьләр ике мәртәбә диярлек артты, 2016 елда – 158 булса, 2017 елда алар 306га җитте.

Башка гражданнарга карата шикаятьләр саны шул ук дәрәҗәдә диярлек калды (2016 елда – 162, 2017 елда – 150).

Суд карарларыннан канәгать булмаган гражданнар саны шактый кимеде (2016 елда – 89 шикаять, 2017 елда – 54 шикаять).

Бала хокуклары гарантияләнгәндә генә түгел, ә гамәлгә ашырылганда һәм яклангандачын кыйммәткә әверелүен аңлап, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегендә баланың бозылган хокукларын торгызу, Татарстан Республикасы территориясендә балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре яклануын тәэмин итү бурычларын үтәү аерым урын алып тора.

Гомумән алганда, 2017 елда гражданнар шикаятьләрен карау нәтиҗәләре буенча 44,7% очракта бала хокукларын яклау ысуллары һәм чаралары турында квалификацияле консультацияләр һәм аңлатмалар бирелде. 55,3% очракта баланың бозылган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызуда ярдәм күрсәтелде, шул исәптән 265 очракта (48,5%) мәсьәләнең асылы буенча уңай хәл итүгә ирешелде.

Гражданнар шикаятьләре нәтиҗәләре буенча тиешле органнар һәм вазыйфаи затлар адресына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бала хокуклары бозылу турында 51 бәяләмәсе җибәрелде.

3.2. Баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч кулланудан якланууга һәм иминлеккә хокукын тәэмин итү

Баланың яшәүгә һәм аның иминлеген тәэмин итүгә хокукы бала конвенциясе хокукларының аерылгызсыз һәм читләштерелми торган өлешләренең берсе булып тора.

3.2.1. Балаларның тышкы сәбәпләр (бәхетсезлек очраклары, суицидлар, җинаятьләр) аркасында үлүен анализлау

Балалар үлеме структурасы анализында балаларның тышкы сәбәпләр аркасында вафат булу очраклары аеруча игътибар талҗп итә. Балаларның гомерен куркыныч астына куя торган шартлар булып, кызганычка каршы, бәхетсезлек очраклары, суицидлар, җинаятьләр кала бирә.


Ләкин балалар үлеменең табигый булмаган сәбәпләрен кисәтеп тә яки алар белән идарә итеп тә була торган категориягә керә һәм тиешле дәүләт һәм муниципаль хаки-

мият органнары, «балачак өлкәсендә» эшләүче төрле оешмалар мондый фаҗигаләрне кисәтү буенча профилактика эшен, массакүләм мәгълүмат чаралары, ата-аналар белән тыгыз элемтәдә торып, оешкан рәвештә тиешле дәрәҗәдә башкарсалар, бу югалтуларны юк дәрәҗәсенә киметергә мөмкин булыр иде.

2017 елда, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, тышкы сәбәпләр аркасында балалар һәлак булуның 87 очрагы теркәлгән, бу вафат булган балаларның гомуми санының 20,8% тәшкил итә (419). 2017 елда суицидлар, бәхетсезлек очраклары һәм җинаятьләр аркасында балалар үлеме 2016 ел дәрәҗәсендә калды диярлек.

39 нчы диграаамма


2013-2017 елларда тышкы сәбәпләр аркасында һәлак булган балаларның гомуми саны (кеше)



Тышкы сәбәпләрдән балалар үлемен анализлаудан күренгәнчә, 2017 елда да, гадәттәгечә, балигъ булмаган балаларның үлеме төрле бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә килеп чыга. Балалар суицидлары буенча вәзгыять тә шул дәрәҗәдә тора. Җинаять кылулардан һәлак булган балигъ булмаганнар саны беркадәр артты.

40 нчы диаграмма

2015 2017 елларда тышкы сәбәпләр аркасында һәлак булган балалар саны (кеше)




Балаларның ***бәхетсезлек очракларыннан*** һәлак булу куркынычы бүген дә югары дәрәҗәдә сакланып кала.

2017 елда балаларның бәхетсезлек очракларыннан һәлак булу структурасы түбәндәге диаграммада китерелә.

41 нче диаграмма

2017 елда балаларның бәхетсезлек очракларыннан һәлак булу структурасы



2017 елда балалар белән бәхетсезлек осраклары булган муниципаль берәмлекләрне күрсәтергә кирәк дип саныйбыз.

7 нче таблица

2017 елда бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә һәлак булган балалар саны (муниципаль берәмлекләр буенча, кеше)

Муниципаль берәмлек исеме	Бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә һәлак булган балалар саны
Казан шәһәре	20
Чаллы шәһәре	9
Чистай	6
Әлмәт	5
Түбән Кама	5
Бөгелмә	4
Зәй	4
Яңа Чишмә	3
Буа	2
Азнакаий	1
Аксубай	1
Актаныш	1
Алексеевск	1
Баулы	1
Биектау	1
Зеленодольск	1
Лаеш	1
Лениногорс	1
Менделеевск	1
Минзәлә	1
Тукай	1
Барлыгы	**70**

2017 елда төрле су объектларында 14 бала ***батып үлде.***

Җәйге коену сезонында сулыкларда ел саен бәла-казалар булып тора.


2017 елның җәен дә мондый бәла-казалар, кызганычка каршы, читләтеп узмады. Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (алга таба – ТР Оборона министрлыгы) мәгълүматларына караганда, сулыклардагы бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә 2017 елда 6 бала үлгән. Тагын өч бала сулыкларда табылмаган. Шулай итеп, 2017 елның җәендә ачык сулыкларда 9 бала үлгән, дип санала.

Бәхетсезлек очракларын анализлаудан күренгәнчә, балалар белән мондый фаҗигаларның булуы җәйге лагерьларда балаларны ял иттерү тиешенчә оештырылмаганлык нәтиҗәсе дип карарга кирәк. Сулыкларда балалар үлүнең төп сәбәпләре аларны күзәтүчесез калдырудан һәм сулыкларда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен бозудан гыйбарәт.

2016 ел белән чагыштырганда су объектларында үлгән балалар саны 18,2%ка кимрәк (2016 елда – 11 очрак, 2017 елда – 9).

42 нче диаграмма


2013-2017 елларда сулыкларда үлгән балалар саны (кеше)



2017 елда су объектларында үлгән балалар арасында бюер бала 6 яшькәкадәр, ике – 7 яштән 13 яшькә кадәр, алты балигъ булмаган бала – 14 яштән 17 яшькә кадәр.

43 нче диаграмма

2013-2017 елларда су объектларында үлгән балалар саны (яшьләре буенча)



2013-2017 елларда суда балалар үлү очракларының географиясе 8 нче таблицада күрсәтелә.

8 нче таблица

2015-2017 елларда су объектларындаүлгән балалар саны (муниципаль берәмлекләрдә, кеше)

Муниципаль берәмлек исеме	2015 ел	2016 ел	2017 ел
Чаллы шәһәре	1	-	2
Чистай муниципаль районы	-	-	2
Зәй муниципаль районы	1	-	1
Түбән Кама муниципаль районы	-	1	1
Зеленодольск ммуниципаль районы	-	-	1
Лаеш муниципаль районы	-	-	1
Биектау муниципаль районы	-	-	1
Югары Ослан муниципаль районы	1	1	-
Арча муниципаль районы	-	2	-
Баулы муниципаль районы	-	1	-
Мамадыш муниципаль районы	-	1	-
Питрәч муниципаль районы	-	2	-
Әгерҗе муниципаль районы	-	1	-
Мөслим муниципаль районы	-	1	-
Бөгелмә муниципаль районы	-	1	-
Әлмәт муниципаль районы	1	-	-
Алабуга муниципаль районы	1	-	-
Теләче муниципаль районы	1	-	-
Чирмешән муниципаль районы	1	-	-
Казан шәһәре	-	-	-
Әлки муниципаль районы	-	-	-
Минзәлә муниципаль районы	-	-	-
Спас муниципаль районы	-	-	-
Тукай муниципаль районы	-	-	-
Кама Тамагы муниципаль районы	-	-	-
Нурлат муниципаль районы	-	-	-
Балык Бистәсе муниципаль районы	-	-	-
Тәтеш муниципаль районы	-	-	-
Барлыгы	**7**	**11**	**9**


Сулыклардагы бәхетсезлек очраклары буенча 2017елда Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре тарафыннан балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район (шәһәр) комиссияләре исеменә суда балалар фаҗигасенә китергән сәбәпләрне ачыклау һәм андый очракларны кисәтү өчен бер материал да җибәрелмәгән. Шундый ук хәлне Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 2015 – 2016 елларда да күзәтелгән иде. Йогынты ясауның һәм бәхетсезлек очракларының сәбәпләрен белүнең әлеге механизмыннан файдалану мондый фаҗигаларны кисәтү буенча кирәкле профилактик чара буларак каралырга тиеш.

Шул ук вакытта, 2017 елда балалар сулыкларда һәлак булган очраклар коену чорында гына түгел. Мәсәлән, мартта сәламәтлеге чикле булган бала югала, соңгы тапкыр аны Зөя елгасы ярында күрәләр. Кызганычка каршы, беркадәр вакыттан соң, аның гәүдәсен елгада табалар. Тагын ике бала бассейнда баталар, бер бала – ванныйда. Бер бала сулар аыгп төшә торган базда суга тыгылып үлә.

ТР Оборона министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2017 елда 26 ***янгын очрагы*** була, аларда 26 балигъ булмаган бала зыян күргән, шулардан 5есе – һәлак булган, 21 бала – төрле җәрәхәтләр алган. Узган ел белән чагыштырганда, 2017 елда янгыннарда һәлак булган балалар саны 28,6%ка кимегән (2016 елда – 7бала үлгән).

44 нче диаграмма

2013-2017 елларда янгыннарда һәлак булган һәм җәрәхәтләнгән балалар саны (кеше)




Балигъ булмаганнар катнашында була торган янгыннанр саны елдан-ел кими бар дип әйтергә була. 2015 елда 65 янгын очрагы булса, 2016 елда 42 очрак булды, 2017 елда – 26 янгын очрагы (35%ка кимегән).

Элеккечә, анализдан күренгәнчә, мәктәпкәчә яшьтәге балалар аеруча хәтәр төркемгә керә. Бу кече яшьтә булуга, килеп чыккан хәлне тиз генә аңлап, хәл итү юлын таба белмәүгә бәйле. Һәлак булучылар арасында 3 бала 6 яшькә кадәрге, 1 бала – 7 яшьтән 13 яшькә кадәрге, 1 бала – 14 яшьтән 17яшькә кадәрге категориягә керә.

45 диаграмма

2013–2017 елларда янгыннарда һәлак булган һәм җәрәхәтләр алган балалар саны (яшьләре буенча, кеше)



2017 елда балалар үлеме белән дүрт янгын очрагы булды – Чистай, Алексеевск районнарында һәм Казан шәһәрендә. Чаллы, Лениногорск, Бөгелмә, Азнакай, Әлмәт, Арча, Югары Ослан муниципаль районнарынд балалар җәрәхәтләр алдылар.

9 нчы таблица

2015–2017 елларда янгыннарда һәлак булган һәм җәрәхәтләр алган балалар саны (муниципаль берәмлекләр буенча, кеше)

Муниципаль район, шәһәр исеме	*2015 ел*		*2016 ел*		*2017 ел*	
	һәлак булган	*җәрәхәт алган*	*һәлак булган*	*җәрәхәт алган*	*һәлак булган*	*җәрәхәт алган*
Казан шәһәре	*3*	*11*	*-*	*7*	*2*	*10*
Чистай районы	*-*	*-*	*-*	*-*	*2*	*-*
Алексеевск районы	*-*	*-*	*-*	*-*	*1*	*-*
Чаллы шәһәре	*-*	*2*	*-*	*5*	*-*	*2*
Лениногорск районы	*-*	*-*	*5*	*-*	*-*	*2*
Бөгелмә районы	*-*	*1*	*-*	*-*	*-*	*2*

Азнакай районы	-	-	-	-	-	*2*
Әлмәт районы	-	*2*	-	-	-	*1*
Арча районы	*2*	-	-	-		*1*
Югары Ослан районы	-	-	-	-	-	*1*
Сарман районы	-	-	*1*	-	-	-
Алабуга районы	-	-	*1*	*1*	-	-
Зеленодольск районы	-	-	-	*2*	-	-
Кайбыч районы	-	-	-	*1*	-	-
Зәй районы	-	-	-	*1*	-	-
Минзәлә районы	-	-	-	*1*	-	-
Чирмешән районы	-	-	-	*1*	-	-
Актаныш районы	*4*	-	-	-	-	-
Спас районы	*2*	-	-	-	-	-
Чүпрәле районы	*1*	-	-	-	-	-
Түбән Кама районы	-	*1*	-	-	-	-
Тукай районы	-	*1*	-	-	-	-
Барлыгы	***12***	***18***	*7*	***19***	***5***	***21***

2017 елда янгыннарның күпчелеге олылар гаебе белән булган: 26 янгыннан 23е.

10 нчы таблица

2013-2017 елларда янгыннарның сәбәпләре

Янгыннарның сәбәпләре	***2013 ел***	***2014 ел***	***2015 ел***	***2016 ел***	***2017 ел***
Электр җиһазларын урнаштыру һәм эшләтү кагыйдәләрен бозу	*8*	*5*	*4*	*7*	***14***
Олыларның ут белән саксыз булуы	*4*	*1*	*3*	*3*	***6***
Белә торып мөлкәтне бозу (зарарлау), кеше гомеренә зарар китерү (ут тертү)	-	-	*2*	*1*	***1***
Тәмәеке тартканда саксыз кылану	*5*	*4*	*1*	-	***1***
Көнкүреш газларыннан, керосинда, бензинда эшләүче җайланмалардан файдалану кагыйдәләрен бозу, шулай ук аларны шартлатуга китерерлек итеп файдалану	*2*	_	_	*2*	***1***
Балаларның ут белән шаяруы	*46*	*53*	*51*	*27*	***1***
Мичләрне урнаштыру һәм эшләтүкагыйдәләрен бозу	*2*	-	*2*	-	-
Башка сәбәпләр	*2*	*3*	*2*	*2*	***2***


Янгыннарны тикшерү нәтиҗәләрке буенгча, муниципаль районнарда балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре исеменә Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре тарафыннан 23 ата-ананы (аларның законлы вәкилләрен) Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә (ата-ана вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен) административ җаваплылыкка тарту турында материаллар җибәрелгән. Бу узган елна караганда шактый артык, 2016 елда бу күрсәткеч 8 булган. Шулай да әлеге эшне җитәрлек дип бәяләп булмый, чөнки янгыннар турында муниципаль комиссияләргә материаллар җибәрү янгыннарда балаларныңфаҗигале һәлак булуына китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны карау һәм өйрәнү кебек мөһим бурычны башкаруга ярдәм итә. Балаларны тәрбияләүдә җаваплылыкны арттыру күзлегеннән ата-аналарга тәэсир

итү механизмы буларак әлеге алымны куллану алга таба мондый фаҗигаләрне булдырмау һәм кисәтү, профилактика буларак каралырга тиеш.

Бәхетсезлек очраклары аркасында балаларның үлеменә китергән сәбәпләр структурасында ***юл-транспорт һәлакәтләрендә*** җәрәхәтләр алу аерым урын алып тора. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе (алга таба – ТР буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе) мәгълүматлары буенча, 2017 елда балигъ булмаганнар катнашында 705 юл-транспорт һәлакәте (ЮТҺ) теркәлгән, аларда 18 бала һәлак булган һәм 740 бала җәрәхәт алган.

46 нчы диаграмма

2013-2017 елларда Татарстан Республикасында балалар катнашындагы ЮТҺ саны (кеше)



2016 ел белән чагыштырганда балигъ булмаганнар катнашындагы ЮТҺ 6,7%ка кимрәк (2016 елда – 756 очрак, 2-017 елда – 705).

ЮТҺ нәтиҗәсендә җәрәхәт алган балалар саны 7,8%ка кимрәк (2016 елда – 803, 2017 елда – 740). Һәлак булган балалар саны узган ел дәрәҗәсендә диярлек – 18 бала (2016 елда – 19 бала).

47 нче диаграмма


2013-2017 елларда ЮТҺендә һәлак булган һәм җәрәхәт алган балалар саны (кеше)



Узган ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында ЮТҺендә җәрәхәт алган балалар арасында башлангыч һәм урта сыйныфларда укучы 7 яшьтән 14 яшькә кадәрге балалар күбрәк. Шул ук вакытта ЮТҺ нәтиҗәсендә һәлак булган 14-17 яшьтәге яшүсмерләр саны шактый күп.


48 нче диаграмма

2013-2017 елларда ЮТҺендә һәлак булган балалар саны (яшьләре буенча) (кеше)



49 нчы диаграмма

2013 – 2017 елларда ЮТҺ нәтиҗәсендә җәрәхәт алган балалар саны (яшьләре буенча) (кеше)



ЮТҺ нәтиҗәсендә һәлак булучылар саны кимү Татарстан Республикасы муниципаль районнары җирле үзидарә органнарының нәтиҗәле эшчәнлеген күрсәтә, шуны исәпкә алып, муниципаль берәмлекләрдә балалар алган юл-хәрәкәт җәрәхәтен анализлау әһәмиятле булыр.

11 нче таблица

2015 – 2017 елларда юл-транспорт һәлакәтендә һәлак булган һәм җәрәхәтләнгән балалар саны (муниципаль берәмлекләрдә, кеше)

Муниципаль берәмлек	***2015 ел***		***2016 ел***		***2017 ел***	
	һәлак булган	*җәрәхәт-ләнгән*	*һәлак булган*	*җәрәхәт-ләнгән*	*һәлак булган*	*җәрәхәт-ләнгән*
Казан шәһәре	*1*	*247*	*2*	*297*	*0*	*283*
Чаллы шәһәре	*0*	*99*	*1*	*159*	*1*	*113*
Әгерҗе	*0*	*2*	*0*	*1*	*0*	*1*
Азнакай	*0*	*8*	*0*	*5*	*0*	*7*
Аксубай	*0*	*0*	*0*	*1*	*1*	*6*
Актаныш	*1*	*2*	*1*	*5*	*0*	*3*
Алексеевск	*0*	*7*	*0*	*4*	*0*	*2*
Әлки	*0*	*2*	*1*	*2*	*0*	*1*
Әлмәт	*6*	*43*	*0*	*36*	*1*	*27*
Апас	*0*	*1*	*0*	*0*	*0*	*3*

Арча	*0*	*6*	*1*	*8*	*0*	*9*
Әтнә	*1*	*1*	*0*	*2*	*0*	*3*
Баулы	*0*	*2*	*0*	*1*	*1*	*1*
Балтач	*0*	*1*	*0*	*5*	*0*	*5*
Бөгелмә	*1*	*19*	*0*	*20*	*1*	*17*
Буа	*1*	*8*	*1*	*6*	*0*	*3*
Югары Ослан	*1*	*5*	*0*	*6*	*1*	*5*
Бипектау	*1*	*16*	*0*	*5*	*0*	*5*
Чүпрәле	*0*	*2*	*0*	*0*	*0*	*0*
Алабуга	*0*	*18*	*0*	*17*	*0*	*25*
Зәй	*0*	*8*	*2*	*9*	*4*	*8*
Зеленодольск	*2*	*28*	*1*	*18*	*0*	*18*
Кайбыч	*0*	*3*	*0*	*0*	*0*	*2*
Кама Тамагы	*0*	*3*	*0*	*0*	*0*	*3*
Кукмара	*0*	*7*	*0*	*12*	*0*	*5*
Лаеш	*2*	*3*	*3*	*3*	*1*	*13*
Лениногорск м.б.	*0*	*14*	*0*	*6*	*0*	*8*
Мамадыш	*0*	*17*	*0*	*10*	*2*	*6*
Менделеевск	*1*	*4*	*1*	*0*	*0*	*1*
Минзәлә	*0*	*7*	*0*	*5*	*0*	*4*
Мөслим	*0*	*2*	*0*	*2*	*0*	*1*
Түбән Кама	*0*	*57*	*0*	*68*	*1*	*66*
Яңа Чишмә	*2*	*6*	*0*	*4*	*1*	*3*
Нурлат	*0*	*8*	*0*	*4*	*0*	*3*
Питрәч	*0*	*14*	*2*	*17*	*0*	*18*
Балык Бистәсе	*0*	*4*	*0*	*9*	*0*	*12*
Саба	*1*	*4*	*0*	*2*	*0*	*4*
Сарман	*0*	*11*	*1*	*17*	*1*	*2*
Спас	*0*	*0*	*0*	*0*	*0*	*2*
Тәтеш	*0*	*3*	*0*	*0*	*0*	*4*
Тукай	*0*	*19*	*1*	*12*	*0*	*13*
Теләче	*0*	*1*	*1*	*2*	*1*	*10*
Чирмешән	*0*	*4*	*0*	*2*	*0*	*1*
Чистай	*1*	*18*	*0*	*20*	*1*	*12*
Ютазы	*0*	*1*	*0*	*1*	*0*	*2*

Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе мәгълүматлары буенча, 2017 елда 149 ЮТҺ – бу балигъ булмаганнар катнашындагы ЮТҺ гомуми санының 21% – балалар гаебе белән килеп чыккан. Шулай итеп, балалар гаебе белән килеп чыккан ЮТҺ саны соңгы өч ел дәрәҗәсендә калган диярлек, бу исә балаларга юлларда куркынычсызлык нигезләрен укыту методикасын камилләштерү, анда инновацион технологияләр кертү зарурлыгы турында сөйли.

Балалар гаебе белән килеп чыккан ЮТҺнең төп сәбәпләре түбәндәгеләр булды: велосипедчылар, скутерчылар, мотоциклчыларның юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуы (33 очрак), каршылыклар артыннан кинәт юлга йөгереп чыгу (31 очрак), транспорт якынлашканда, махсус билгеләнмәгән урында юлны аркылы чыгу (18 очрак), светофорның тыелып калусигналына чыгу аркасында (15 очрак).

12 нче таблица

2013 – 2017 елларда балалар гаебе белән ЮТҺ сәбәпләре

ЮТҺ сәбәпләре	*2013 ел*	*2014 ел*	*2015 ел*	*2016 ел*	*2017 ел*
Велосипедчылар, скутерчылар, мотоциклчыларның юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуы	*57*	*53*	*31*	*29*	*33*
Каршылык артыннан кинәт юлга йөгереп чыгу	*41*	*40*	*34*	*38*	*31*
Транспорт якынлашканда, махсус билгеләнмәгән урында юлны аркылы чыгу	*32*	*26*	*68*	*66*	*18*
Светофорның тыю сигналына юлны аркылы чыгу	*6*	*7*	*6*	*8*	*15*
Балаларның юлга чыгып уйнавы	*2*	*6*	*1*	*5*	*0*
Автомобиль юлыннан хәрәкәт итү	*1*	*1*	*0*	*2*	*2*
Юл хәрәкәте кагыйдәләрен балаларның башкача бозуы	*48*	*20*	*11*	*5*	*50*
Барлыгы	*187*	*153*	*151*	*153*	*149*

Олылар (транспорт йөртүчеләр) гаебе белән булган ЮТҺнең төп сәбәпләренә тизлек режимын сакламау, каршы хәрәкәт өчен билгеләнгән полосага чыгу, юл аша чыгу урыннарында җәяүлеләрнең өстенлекләре булса да, аларны уздырмау, транспорт чарасы белән исерек хәлдә идарә итү керә.


ЮТҺ китергән шартларны караганнан соң, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район (шәһәр) комиссияләре исеменә Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе хезмәткәрләре тарафыннан 541 ата-ананы (аларның законлы вәкилләрен) Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә (ата-ана вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен) административ җаваплылыкка тарту турында **материаллар җибәрелгән**.

2017 елда 10 бала ***егылып төшү*** аркасында үлгән, бу очраклар суицидка бәйле түгел

Болар – мәктәпкәчә яшьтәге һәм сабый балалар тәрәзәдән егылып төшү аркасында булган очраклар. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының оператив белешмәләренә караганда, 2017 елда 5 мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп баласы тәрәзәдән егылып төшеп үлгәннәр. 2016 елда мондый очрак 4 булган.

50 нчы диаграмма

2015-2017 елларда тәрәзәдән егылып төшеп үлгән балалар саны (кеше)



Тәрәзәдән егылып төшү очраклары Казанда (2 очрак), Әлмәттә (1 очрак), Бөгелмәдә (1 очрак), Түбән Камада (1 очрак) теркәлгән.

13 нче таблица

2016 – 2017 елларда тәрәзәдән егылып төшеп үлгән балалар саны (муниципаль берәмлекләрдә, человек)

Муниципаль район, шәһәр исеме	***2016 ел***	***2017 ел***
Казан шәһәре	*2*	*2*
Түбән Кама	*1*	*1*
Бөгелмә	*1*	*1*
Әлмәт	*-*	*1*
Барлыгы	***4***	***5***

Иң олы балага 8 яшь була, иң кечкенәсенә – яшь ярым.

2017 елда, тәрәзәдән егылып төшү очракларыннан тыш, тагын түбәндәге очраклар булган:

бер яшьлек бала подъезд мәйданчыгында баскыч тишегеннән егылып төшеп үлгән;

бер кыз бала аттан егылып төшеп үлгән;

өч яшүсмер бина түбәсеннән егылып төшеп үлгәннәр.

Моннан тыш, өч баланы ***электр тогы сугып*** үтергән.

Тагын дүрт бала үз кысыгына буылып үлгәннәр (өч сабый бала һәм бер инвалид (ДЦП) бала.

Өч бала ***эссе сугудан*** үлгән, аның берсе автомобильдә калдырылган булган, ике бала әниләре белән мунчада үләләр.

Балаларның үлеменә китергән фаҗигале бәхетсезлек очракларының сәбәпләренә һәм шартларына ясалган анализдан күренгәнчә, әлеге очракларның күбесенең олыларның үз ата-ана вазыйфаларына җавапсыз караулары аркасында барлыкка килә.

Бәхетсезлек очраклары аркасында балаларның үлемен һәм җәрәхәтен профилактикалау максатында түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк дип саныйм:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) эшчәнлеге күрсәткечләре исемлегенә бәхетселек очраклары нәтиҗәсендә балалар үлеме буенча күрсәткечләрне кертү мәсьәләсен карарга, моның өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) эшчәнлегенең нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау туроында» 2015 елның 22 апрелендге 275 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә кирәк;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ның ЮХИДИ идарәсе, иҗтимагый волонтерлык оешмалары белән берлектә янгыннарда, суда, юлларда, урманда, өйдә һәм башка вәзгыятьләрдә куркынычсызлык нигезләренә өйрәтү предметларына гомуми белем бирү оешмаларында һәм мәктәпкәчә балалар бакчаларында системалы өйрәтә һәм әзерләү дәресләре алып баруны тәэмин итәргә, шулай ук балалар белән бәхетсезлек очракларын профилактикалау максатыннан һәм ата-аналарның җаваплылыгын арттыру йөзеннән атааналар җыелышлары үткәрү;

Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр исеменә суда балаларның фаҗигале үлеменә китерү торган сәбәпләрне һәм шартларны карау һәм өйрәнү буенча һәм ата-аналарны (аларның законлы вәкилләрен) Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә административ җаваплылыкка тарту турында материаллар җибәрү эшен активлаштырырга;

балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә балалар катнашында булган бәхетсезлек очраклары шартларын һәм сәбәпләрен ачыклау максатларында профилактика рәвешендәге системалы чаралар эшләү, шул исәптән ата-аналарны (аларның законлы вәкилләрен) Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы буенча җаваплылыкка тарту өчен нигезләрне тикшерергә;


«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына балалар катнашында булган бәхетсезлек очракларын, халыкта ата-ана җаваплылыгының нинди урын алып торуын аңлый башлавына ирешү күзлегеннән чыгып, массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуда ярдәм итәргә.

Балалар үлеменең тышкы сәбәпләре арасында ***суицидлар*** бүген аерым урын алып тора.

2017 елда республикада балигъ булмаганнар арасында теркәлгән суицид очраклары узган елгы дәрәҗәдә калган диярлек. 2017 елда алдан уйлап, үз-үзләрен үтергән балалар саны 12 булды.

51 нче диаграмма

2011 – 2017 елларда балигъ булмаганнар арасында суицидлар саны



Идел буе федераль округы субъектлары буенча (алга таба – ПФО) балигъ булмаганнар арасында суицидаль вәзгыять түбәндәгечә тасвирлана.

14 нче таблица

2017 елда ПФО субъектлары буенча балигъ булмаганнар арасында суицидлар саны

ПФО субъекты исеме	Балалар саны (мең кеше)	Балигъ булмаганнар арасында суицидлар саны (кеше)	10 мең балага суицидлар саны чагыштырмасы
Башкортостан Республикасы	904,3	35	0,4
Чуаш Республикасы	257,4	8	0,3
Ульяновск өлкәсе	224,1	7	0,3
Оренбург өлкәсе	443,2	10	0,2
Саратов өлкәсе	451,3	8	0,2
Түбән Новгород өлкәсе	583,0	10	0,2
Киров өлкәсе	252,2	5	0,2

Удмуртия Республикасы	330,0	16	
Пермь крае			
Марий Эл Республикасы			
Пензенская өлкәсе	234,0	4	
Мордовия Республикасы	136,8	2	0,1
Татарстан Республикасы	814,2	12	0,1
Самара өлкәсе	583,9	8	0,1

2017 елда Татарстан Республикасында булган суицидларның күпчелеге Казан (3) һәм Чаллы (3) шәһәрләрендә, Түбән Камада 2 очрак булды. Бөгелмә, Баулы, Минзәлә, Тукай муниципаль районнарында берәр факт теркәлде. Балигъ булмаганнарның үзләренә кул салу алымнары: 6 очракта – биектән егылып төшү, 5 очракта – асылыну, 1 очракта – агулану.

15 нче таблица

2012 – 2017 елларда балигъ булмаганнар арасында суицидлар саны (муниципаль берәмлекләр буенча)

Муниципаль район, шәһәр исеме	***Суицидлар саны***						
	2012 ел	***2013 ел***	***2014 ел***	***2015 ел***	***2016 ел***	***2017 ел***	***2012 – 2017 еллар***
Казан шәһәре	*3*	*1*	*8*	*5*	*5*	***3***	***25***
Чаллы шәһәре	*-*	*2*	*5*	*3*	*-*	***3***	***13***
Түбән Кама	*1*	*1*	*1*	*-*	*-*	***2***	***5***
Бөгелмә	*2*	*1*	*3*	*-*	*-*	***1***	***7***
Баулы	*1*	*-*	*1*	*1*	*-*	***1***	***4***
Тукай	*-*	*-*	*1*	*-*	*1*	***1***	***3***
Минзәлә	*-*	*-*	*-*	*-*	*-*	***1***	***1***
Әлмәт	*2*	*2*	*-*	*-*	*2*	***-***	***6***
Актаныш	*-*	*1*	*-*	*-*	*1*	*-*	***2***
Кукмара	*-*	*-*	*-*	*-*	*1*	*-*	***1***
Лаеш	*-*	*-*	*-*	*-*	*1*	*-*	***1***
Ютазы	*-*	*-*	*-*	*-*	*1*	*-*	***1***
Балтач	*1*	*1*	*-*	*-*	*1*	*-*	***3***
Зеленодольск	*1*	*3*	*-*	*1*	*-*	*-*	***5***
Югары Ослан	*1*	*-*	*-*	*1*	*-*	*-*	***2***
Нурлат	*-*	*1*	*-*	*1*	*-*	*-*	***2***
Азнакай	*-*	*-*	*-*	*1*	*-*	*-*	***1***
Апас	*-*	*-*	*-*	*1*	*-*	*-*	***1***
Спас	*-*	*-*	*-*	*1*	*-*	*-*	***1***
Чистай	*-*	*-*	*-*	*1*	*-*	*-*	***1***
Яңа Чишмә	*-*	*1*	*1*	*-*	*-*	*-*	***2***
Алексеевск	*1*	*-*	*1*	*-*	*-*	*-*	***2***
Чүпрәле	*-*	*-*	*1*	*-*	*-*	*-*	***1***
Питрәч	*-*	*-*	*1*	*-*	*-*	*-*	***1***
Зәй	*-*	*2*	*-*	*-*	*-*	*-*	***2***
Лениногорск	*1*	*1*	*-*	*-*	*-*	*-*	***2***
Балык Бистәсе	*2*	*-*	*-*	*-*	*-*	*-*	***2***
Аксубай	*1*	*-*	*-*	*-*	*-*	*-*	***1***
Әлки	*1*	*-*	*-*	*-*	*-*	*-*	***1***
Арча	*1*	*-*	*-*	*-*	*-*	*-*	***1***
Барлыгы	***19***	***17***	***23***	***16***	***13***	***12***	***100***


Республика районнары һәм шәһәрләре арасында соңгы алты елда суицидаль хәлне анализлаудан күренгәнчә, шундый афәт булган шәһәрләрдән Казан (25 суицид), Чаллы шәһәре (13 суицид), Бөгелмә районы (7 суицид), Әлмәт районы (6 суицид). Күпмедер дәрәҗәдә бу һәр муниципаль берәмлектәге балалар санына бәйле. Шуның белән бергә, бер генә очрак та булырга тиеш түгел дигән фикердән чыгып эш итәбез икән, бирелгән абсолют саннар әлеге муниципаль районнарда профилактика эшенең җитәрлек булмавын раслый.

Профилактик характердагы чаралар һәм механизмнар булдыру эшчәнлегендә алга таба профилактика эшен алып бару өчен суицидаль тәртип күзлегеннән хәтәр төркемне билгеләргә мөмкинлек бирә торган анализ үткәрергә кирәк.

Соңгы 5 елда яшүсмерләр арасындагы суицид проблемасының социаль портретын анализлаудан күренгәнчә, аның күбесе 15-16 яшьлекләр тарафыннан кылынган. Шулай да ***яшәрә бару*** тенденциясе чагыла: балалар-суицидантлар арасында 14 яшьтән 16 яшькә кадәргеләре һәм кече яшьтәге балалар да күренә. Мәсәлән, 2016 елда ике суицид корбанына нибары 12 яшь була.

52 нче диаграмма

2013–2017 елларда суицид кылган балаларның яшь составы




Җенси билгедән чыгып караганда, суицидантлар арасында ит-атлар күпчелекне тәшкил итә. «В.П.Сербский исемендәге федераль медицина тикшеренү психиатрия һәм наркология үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе материаллары буенча малайлар суицидларны кылалар, ә кызлар суицид кылырга маташалар. Бу рәвешле бирелгән нәтиҗәне Татарстан Республикасында балалар суициды мониторингы да беркадәр раслый: 2017 елда 8 малай һәм 4 кыз суицид кылган.

Яшәү урыны буенча караганда, суицидантлар арасында (шәһәр, авыл) шуны билгеләп үтәргә кирәк, 2017 елда 12 суицидның 11е (яисә 928 %) шәһәр балалары тарафыннан, 1се (яисә 8%) – авыл балалары тарафыннан кылынган. Шуңа күрә балалар суициды темасы – эре мегаполислар проблемасы дип кенә әйтеп булмый.

Эксперт белешмәләреннән күренгәнчә, шәһәрдә яшәүчеләр арасында суицидаль хәтәр, аның авылда яшәүче халыкка таралуы чагыштырмача аз йогынты ясый. Балаларның ***мәшгульлегеннән чыгып*** караганда, һәлак булучыларның барысы да укучылар булган: 11 бала мәктәптә укыган, 1 яшүсмер урта һөнәри белем бирү оешмасында укый торган булган.

53 нче диаграмма

2013 – 2017 елларда суицид кылган балаларның эш мәшгульле



Суицид кылучылар арасында ***тәртипсез гаиләдә*** тәрбияләнүче балаларның булуы аерым мәсьәлә булып тора. Суицид кылучылар арасында ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның булуы аеруча борчу тудыра. 2017 елда бер ятим бала алдан уйлап үз-үзенә кул сала.

Соңгы алты елда (2012 – 2017) еллардагы суицидларны гомумиләштерү 12 ятим баланың (яки суицид кылган барлык балаларның гомуми санының 11,9%) суицид корбаны булуын күрсәтте, берсе – балалар йортында тәрбияләнүче, икесе – урта һөнәри белем бирү оешмасы укучысы, бишесе – опекага алынган, дүртесе уллыкка алынган балалар. Ә бит бу балалар опека һәм попечительлек органнарының игътибар һәм контроль зонасында торганнар.

Моннан тыш, 2017 ел йомгаклары буенча балигъ булмаган суицидантларның берсенең исәптә яисә социаль хезмәтләр күзәтчелегендә (тәртипсез гаилә булганлыктан) торганлыгы ачыкланды. 2016 – 2017 елларда анасы баласы белән Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.11 статьясында каралган хокукны (балаларның сәламәтлегенә һәм аларны тәрбияләүгә зыян китерүне булдырмау чараларын тәэмин итү таләпләрен үтәмәү турында) бозган өчен 10 тапкыр балигъ Булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе утырышларында тикшереледеләр.

2017 елда үлгән ике яшүсмер закон бозучылар буларак балигъ булмаганнарның эшләре буенча бүлекчәләрдә исәптә торганнар.

Соңгы дүрт дүрт елда (2014 – 2017 еллар) балалар арасында суицид вәзгыятен анализлау йомгаклары буенча 64 баланың 12се (18,8%) тиешле хезмәтләр – балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрнең игътибар үзәгендә тора.

Шулай итеп, 2017 елда балалар арасында суицид вәзгыятен анализлау йомгаклары буенча 3 баланың 2се тиешле балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрдә исәптә тора. Соңгы дүрт елдагы мәгълүматны гомумиләштерүдән күренгәнчә, мондый балалар күрсәтелгән органнар игътибарыннан читтә тормый. әлеге балаларның үлеме шушы органнар тарафыннан башкарылган профилактикага бәйле эшләрнең җитәрлек булмавын дәлилли.

2017 елда, Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ министрлыгы күрсәткечләре буенча, ике яшүсмер (16,7%) суицидны ***алкоголь (наркотик) кулланган*** халәттә кылган. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, алкоголь эчкән халәт 53 суицидаль омтылышның икесенә хас була (3,8%). Шулай итеп, исерек халәттәге 6% суицидаль вәзгыять яшүсмернең суицидаль халәтен тагын да катлауландыра торган фактор булып тора.

Суицид кылган һәм кылырга теләгән балаларның психик саулыгын анализлаудан күренгәнчә, 2017 елда суицид кылган яки шуңа омтылган дүрт яшүсмер (30,8%) психиатрда исәптә торган. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белгечләре фикеренчә, күпсанлы тикшеренүләр күрсәткәнчә, яшүсмернең суицидаль кәефе нерв системасы авырулары булуга бәйле түгел.

2017 елда яшүсмерләрнең үз-үзләренә кул салудан үлүләре сәбәпләрен анализлау, балалар ***үлеменә китергән сәбәпләрдән*** түбәндәгеләрне билгеләргә нигез бирде:

өч очракта – гаиләдә мобиль телефоннар аркасында килеп чыккан үзара каршылыклар;

бер очракта – 11 нче сыйныф укучысының БДИ сынаулары нәтиҗәсенең түбән булуы аркасында;

өч очракта суицид вәзгыяте балаларның психик авыруына бәйле;


ике очракта үз-үзенә кул салуның сәбәпләре ачыкланмыйча кала.

Ләкин яшүсмерне нинди фаҗигале фикерләрнең үлемгә китергәнен белү мөмкин булмаса да, шунысы мөһим: аны шушы барлыкка килгән хәлдән арындырырга, ярдәм итәргә якында бер кеме дә булмаган. Шуңа күрә балаларда стрессқа каршы торучанлык, тотрыклылык тәрбияләү бик мөһим. Балалар белән профилактик эш нәкъ менә шуңа юнәлдерелгән булырга тиеш. ә ата-аналар белән профилактик эшнең максаты – барыннан да элек, авыр минутларда балаларга аннан чыгу юлын күрсәтә торган кешеләрнең янда булуын аңлату.

Суицид кылырга маташучы балигъ булмаганнарның саны тотрыклы калу аеруча борчый. 2017 елда балигъ булмаганнар арасында ***суицид кылырга маташучылар*** саны 53 булган, (2013 елда – 59, 2014 елда – 55, 2015 елда – 60, 2016 елда – 74).

54 нче диаграмма

2014 – 2017 елларда балигъ булмаганнар арасында суицид кылырга маташучылар саны



Республиканың муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында ***балигъ булмаганнар арасында суицид кылырга маташучылар вәзгыяте түбәндәгечә тора***.

16 нчы таблица


2014 – 2017 елларда балигъ булмаганнар арасында суицид кылырга маташучылар саны (по муниципаль берәмлекләр буенча)

Муниципаль район, шәһәр исеме	Ссуицид кылырга маташучылар саны	
	2016 ел	**2017 ел**
Казан шәһәре	41	23
Чаллы шәһәре	10	12
Әлмәт	2	3
Нурлат	2	3
Арча	3	2
Бөгелмә	2	2
Түбән Кама	1	2
Алабуга	2	1
Лениногорск	2	1
Мамадыш	-	1
Кукмара	-	1
Тукай	-	1
Чистай	-	1
Зеленодольск	2	-
Лаеш	2	-
Яңа Чишмә	1	-
Питрәч	1	-
Саба	1	-
Спас	1	-
Барлыгы	**74**	**53**

Яшь буенча караганда балигъ булмаганнарның төп өлеше 16 яшьтән18 яшькә кадәргеләр тәшкил итә. Шулай да яшәрә бару тенденциясе чагыла: балалар-суицидантлар арасында 14 яшьтән 16 яшькә кадәргеләре һәм кече яшьтәге балалар да күренә.

55 нче диаграмма

2014 – 2017 елларда суицидка омтылган балаларның яшь составы



Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләреннән күренгәнчә, суицидаль омтылыш ясаган балаларның гомуми саныннан 81%ы кызларга туры килә.

Балигъ булмаганнарның суицидаль омтылышларының төп алымнары – кан тамырын кисү һәм агулану.

Ведомстволарның – проблемалы балалар арасында профилактика субъектларының суицидларны кабатлау булмасын өчен чаралар күрү буенча үз вакытында һәм төгәл үзара эшчәнлек мөһим профилактика чарасы булып тора. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: 2017 елда балаларның начар хәлдә калуын профилактикалау системасы субъектлары – ведомстволарның кабат башкарыла торган суицидларны кисәтү чараларын күрү буенча үзара хезмәттәшлеге республикада беркадәр яхшырды. Мәсәлән, суицидаль омтылышыннан 53 очрагыннан 40 очрагы балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрдә тикшерелде. Моннан тыш, Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ белешмәләре нигезендә 2017 ел дәвамында Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ территориаль бүлекчәләренә сәламәтлек саклау учреждениеләреннән 50 омтылыш турында хәбәр алынган.

Ясалган анализ нигезендә нәтиҗә ясарга мөмкин, түбәндәге балаларны хәтәр төркемгә кертергә кирәк: балаларның һәм гаиләләрнең начар хәлдә калулары, төрле ведомствода (социаль яклау, опека һәм попечительлек органнары, балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләр) һәм ведомствоара контроль һәм исәп органнарында торучы балигъ булмаган балалар; элек суицидаль омтылыш булган балалар. Гамәлдә һәр суицид омтылышы буенча Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе тарафыннан Россия Федерациясе җинаять кодексының 110 статьясы нигезендә («үзенә кул салуга җиткерү») җинаять эше ачыла, аның кысаларында булган эшнең бөтен фактлары ачыклана. 2017 елда 12 суицидның 9ы буенча һәм 53 суицид омтылышының 11е буенча җинаять эше ачылды.

Балаларның һәм яшүсмерләрнең үз-үзләрен суицидаль тотуны профилактикалау максатларында түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк дип уйлыйбыз:

«Балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июлендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе һәм муниципаль комиссияләргә, балалар һәм гаиләләр иминлеген профилактикалау системасының башка органнарына үз карамагындагы һәм ведомствоара буйсынудагы игътибар, контроль һәм исәпкә алу зоналарындагы суицидаль хәтәр төркем балаларын профилактикалау буенча эшчәнлекне камилләштерү чараларын күрергә;

Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе балаларның үз-үзләрен суицидаль тотышларын профилактикалау һәм кисәтү буенча эшчәнлеге кысаларында балаларның һәм гаиләләрнең начар хәлдә калуларын профилактикалауның барлык субъектлары арасында үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү буенча эшне дәвам итәргә, шул исәптән балигъ булмаганның суицид ясарлык кәефе булуын ачыклаганда, аңа квалификацияле ярдәм күрсәтү регламентын эшләү һәм кабул итү турындагы мәсьәләне карарга кирәк;

мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләре тарафыннан укучыларга тәрбияви йогынты ясауның балаларны суицид кылуга этәрергә мөмкин рөхсәт ителмәгән алымнарын куллануларын булдырмау буенча республика сәламәтлек саклау учреждениеләренең балигъ булмаганнар тарафыннан башкарып каралган һәм аларга билгеле булган суицид очраклары турында балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә үз вакытында һәм мәҗбүри мәгълүмат бирүне билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә кирәк;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ

номерлы Федераль закондагы 13 статьясының табибның пациент турындагы мәгълүматны тапшыруны чикли торган нормасын исәпкә алып, балигъ булмаганнарның кабат суицидка омтылуларын профилактикалау регламентын эшләргә һәм эшләнгән регламент нигезендә эшләүне оештырырга;

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына республиканың мәгариф оешмаларында конфликтлы очракларны хәл итүнең профессиональ һәм нәтиҗәле алымнарын эшләү һәм куллану, мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләре тарафыннан укучыларга тәрбияви йогынты ясауның балаларны суицид кылуга этәргә мөмкин рөхсәт ителмәгән алымнарын куллануларын булдырмау буенча чаралар күргә кирәк;

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына түбәндәгеләр буенча профессиональ һәм нәтиҗәле методикалар эшләү һәм куллану чараларын күргә:

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына түбәндәгеләр буенча профессиональ һәм нәтиҗәле методикалар эшләү һәм куллану чараларын күргә:

мәгариф оешмаларында конфликтлы хәлләрне хәл итү буенча;

мәгариф оешмалары педагогик хезмәткәрләренең суицидаль хәтәр билгеләрне тану өлкәсендә, шундый хәтәрне җиңеп чыгу, бала белән уртак тел таба белү буенча компетенцияләрне арттыру буенча;

укучыларга тәрбияви йогынты ясауның балаларны суицид кылуга этәргә мөмкин рөхсәт ителмәгән алымнарын куллануларын булдырмау буенча, бала белән партнерлык һәм дуслык юлларын эзләп табарга;

балалар белән аларда стессларга каршы торучанлык күнекмәләрен булдыру эшләре алып барырга, позитив һәм дуслык алымнары табу юлын күрсәтергә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына хәтәр төркемдәге балаларга үз вакытында һәм тиешле дәрәҗәдәге психологик ярдәм күрсәтү максатларында психологик хезмәтләр белгечләренең һөнәри квалификация дәрәҗәсен камилләштерү һәм арттыру буенча чаралар күргә кирәк.


Балалар үлеменең табигый булмаган сәбәпләренең берсе – ***аларга карата башкарылган җинаятьләр аркасында балаларның һәлак булуы***. Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ биргән мәгълүматлар буенча, 2017 елда 3 бала үтерелгән (Россия Федерациясе җинаять кодексының 105 статьясы) (алга таба – Россия Федерациясе ҖК) (2016 елда – 1, 2015 елда – 4 бала). Үз аналарының корбаннарына әверелгән яңа туган сабыйларның саны тотрыклы кала, РФ җинаять кодексының 106 статьясы буенча кузгатылган җинаять эшләре буенча – елына 2 бала. Саксызлык аркасында зыян китереп, 10 балигъ булмаган бала вафат булган (2016 елда -15) (РФ җинаять кодексының 109 статьясы).

3.2.2. Обеспечение права на защиту от жестокого обращения и насилия

Балаларга карата көч куллануны һәм рәхимсезлекне кисәтү мәсьәләләре эшчәнлекнең актуаль һәм өстенлекле юнәлеше булып тора. Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ биргән мәгълүматлар буенча, 2017 елда балаларга карата төрле характердагы 1 705 җинаять кылынган (балаларны тәрбияләп торуга акча бирүдән явыз ният белән качу фактлары буенча җинаятьләрдән тыш).

56 нчы диаграмма

2013 – 2017 елларда балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләр саны



Диаграммадан күренгәнчә, балаларга карата кылынган җинаятьләр саны узган елга караганда беркадәр артты (5%ка ягъни 86 җинаятькә артты).

Шулук вакытта балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләрнең гомуми саны арту фонында, җинаять эшләре буенча зыян күрүчеләр дип танылган балалар саны, узган ел белән чагыштырганда, 24 %ка, ягъни 254 җинаятькә кимрәкбулды һәм 812 кешене тәшкил итте.

17 нче таблица

2013-2017 елларда җинаять эшләре буенча зыян күрүчеләр дип танылган балалар саны


Җинаять төрләре	***Зыян күрүчеләр дип танылган балалар саны (кеше)***				
	2013 ел	***2014 ел***	***2015 ел***	***2016 ел***	***2017 ел***
Зыян күрүчеләр дип танылган балалар саны, *шул исәптән*	**1349**	**1491**	**1638**	**1066**	**812**
РФ ҖК ст. 105 («Үтерү»)	21	19	12	8	8
РФ ҖК ст.106 («Ананың яңа туган баласын үтерүе»)	1	2	2	2	2
РФ ҖК ст. 109 («Саксызлык аркасында үлемгә китерү»)	17	27	12	15	10
РФ ҖК ст. 110 («Үз-үзен үтерүгә җиткерү»)	4	19	2	5	7
РФ ҖК ст. 111 («Аңлы рәвештә сәламәтлеккә зур зыян китерү»)	14	8	7	5	8
РФ ҖК ст. 112 («Аңлы рәвештә сәламәтлеккә уртача авырлыктагы зыян китерү»)	26	14	21	29	21
РФ ҖК ст. 115 («Аңлы рәвештә сәламәтлеккә җиңелчә зыян китерү»)	50	39	50	55	51
РФ ҖК ст. 116 («Кыйнаулар»)	350	356	378	275	24
РФ ҖК ст. 117 («Җәфалау»)	6	19	36	28	30
РФ ҖК ст. 119 («Үтерү белән янау»)	45	48	58	37	63
РФ ҖК ст. 125 («Куркыныч астында калдыру»)	4	0	7	4	4
РФ ҖК ст. 127 («Законсыз рәвештә иректән мәхрүм итү»)	2	3	7	1	5
РФ ҖК ст. 131 («Көчләү»)	27	20	70	15	24
РФ ҖК ст. 132 («Сексуаль характердагы көч куллану гамәлләре»)	73	74	139	48	82

РФ ҖК ст. 133 («Сексуаль характердагы гамәлләр кылуга мәҗбүр итү»)	0	5	1	4	3
РФ ҖК ст. 134 («16 яше тулмаган зат белән җенси мөнәсәбәткә керү»)	66	84	177	66	73
РФ ҖК ст. 135 («Бозыклык гамәлләре кылу»)	44	35	63	9	45
РФ ҖК ст. 156 («Балаларга карата рәхимсезлек кылу белән бәйле ата-аналар бурычларын үтәүдән баш тарткан өчен җинаятьләр»)	54	101	104	82	71
РФ ҖК ст. 150, 151, 151.1 («Балигъ булмаган затны җинаять кылуга, җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итү белән бәйле җинаятьләр»)	9	19	13	92	49
РФ ҖК ст. 240–242 («Фәхишәлек белән шөгыльләнүне, порнография материалларын яисә предметларын законсыз эшләү һәм таратуны оештыру һәм шуңа җәлеп итү белән бәйле җинаятьләр»)	1	7	27	19	6
РФ ҖК ст. 158, 159, 161–163 («Милеккә каршы җинаятьләр (караклык, мошенниклык, талау, юлбасарлык, куркытып алу»)	498	377	323	234	193

Әлеге җинаятьләр буенча зыян күрүчеләр дип танылган балалар турындагы белешмәләргә ясалган анализ 2017 елда яшүсмерләргә карата кылынган хокуксыз гамәлләрнең сабый балаларга карата кылынган җинаятьләрдән 10% ка күбрәк булуын, ә кызларга каршы башкарылган җинаятьләр саны малайларга карата башкарылганнарыннан 40% ка күбрәк булуын күрсәтте.

57 нче диаграмма

2013–2017 елларда балаларга карата кылынган җинаятьләр саны, яшь һәм җенес буенча






Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ белешмәләреннән күренгәнчә, 2017 елда ***балаларга карата көч кулланып башкарылган җинаятьләр*** 2016 ел белән чагыштырганда 5% ка арткан**.** Балаларга карата кылынган җинаятьләрнең гомуми саныннан 53%ын алып тора.

58 нче диаграмма

2013-2017 елларда балигъ булмаганнарга карата көч кулланып башкарылган җинаятьләр саны һәм шулар буенча зыян күргән дип танылган балалар саны



Шуны әйтергә кирәк, 2017 елда көч кулланылган җинаятьләрнең корбаннары булган балигъ булмаганнарның саны 164 балага (25%ка) кимеде. (2013 елда – 766, 2014 елда – 769, 2015 елда – 975, 2016 елда – 647, 2017 елда 483). Бу җинаять эшләре буенча зыян күрүчеләр дип танылган балаларның гомуми саныннан 59% бала көч кулланылган җинаятьләрнең корбаннары булган дигәнне аңлата.

Балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләргә ясалган мониторинг гаилә әгъзалары тарафыннан кылынган җинаятьләрнең саны арту турында сөйли. Аларның гомуми саны 2017 елда 505 җинаять булды (2016 еллда – 441 җинаять). Шуның белән бергә, 2016 елдагы кебек үк, ул балаларга карата көч кулланып кылынган җинаятьләрнең ярты-сыннан артыгын тәшкил итә (56%). Әлеге категориягә кергән 901 җинаяттән:

162 – ата-аналар тарафыннан кылынган (2016 елда – 270, 2015 елда – 234, 2014 елда – 168, 2013 елда – 104);

292 – үги аталары тарфыннан;

7 – аналары белән бергә яшәүче ир-ат тарафыннан (2016 елда – 142, 2015 елда – 169, 2014 елда – 22, 2013 елда – 2);


44 – гаиләнең башка әгъзалары тарафыннан.

Җинаятьләрнең алалар оешмалары хезмәткәрләре тарафыннан кылынган очраклары аерым игътибар бирүне һәм моңа каршы чаралар күрүне таләп итә, 2017 елда мондый 9 очрак булган. Бу көч куллану характерындагы гомуми җинаятьләрнең 1%ын тәшкил итә (2016 елда шундый 29 очрак булып, гомуми җинаятьләрнең 3,4% ын тәшкил итте).

Балигъ булмаганнарның җенси кагылгысызлыгына каршы башкарылган җинаятьләр дә шактый. 2017 елда 891 шундый җинаять теркәлгән. Мондый җинаятьләрнең күпчелеге купэпизодлы характерда.

59 нчы диаграмма

2013–2017 елларда балигъбулмаган балаларга карата кылынган сексуаль характердагы җинаятьләр һәм алардан зыян күрүчеләр саны




Балигъ булмаганнарның җенси кагылгысызлыгына каршы башкарылган җинаятьләр 2017 елда 59%ка артты һәм аларның саны 227гә җитте.

Әлеге категориягә караган 376 (42%) җинаять 16 яшькә җитмәгән зат белән җенси мөнәсәбәткә керүгә бәйле (Россия Федерациясе Җинаять кодексының 134 статьясы). 73 яшүсмер зыян күрүче дип танылды. Бу эрпизодлар аларның ризалыгы белән һәм мәҗбүр итмичә башкарылган. Шулай итеп, җенси кагылгысызлыкка каршы 515е көч кулланып кылынган, шуннан 154 бала зыян күргән.

2017 елда 411 җинаять яшүсмерләрнең җенси кагылгысызлыгына каршы башкарылган (2016 елда – 388), 480 – кече яшьтәге балаларның җенси кагылгысызлыгына каршы башкарылган (2016 елда – 131).

60 нче диаграмма


2013–2017 елларда җенси кагылгысызлыкка каршы кылынган җинаятьләр саны (яшьләре буенча)



2017 елда күпчелек очракта кыз балаларның җенси кагылгысызлыгына каршы җинаятьләр кылынган,кылынган җинаятьләрнең 97%ы бу категориягә керә. Кече яшьтәге балаларның җенси кагылгысызлыгына каршы кылынган җинаятьләрнең арту тенденциясе игътибарны җәлеп итә. Күрсәтелгән җинаятьләрне анализлаудан күренгәнчә, җинаятьләр олылар каравыннан тыш калган балаларга карата кылынган.

61 нче диаграмма

2013–2017 елларда җенси кагылгысызлыкка каршы кылынган җинаятьләр саны (җенесләре буенча)



Балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләргә ясалган мониторинг җенси кагылгысызлыкка каршы гаилә әгъзалары тарафыннан кылынган җинаятьләрнең саны арту турында сөйли. Аларның гомуми саны 2017 елда 319 җинаять булды, ягъни әлеге юнәлештәге барлык җинаятьләрнең 36% гаиләдә башкарылган (2016 елда – 25%):

3 – ата-аналар тарафыннан (2013 елда – 2, 2014 елда – 0, 2015 елда – 8, 2016 елда – 2);

292 – үги аталары тарафыннан (күпэпизодлы җинаятьләр, өч кыз балага карата кылынган);

1 – анасы белән бергә яшәүче ир-ат тарафыннан (2013 елда – 0, 2014 елда – 6, 2015 елда – 96, 2016 елда – 122);

23 – гаиләнең башка әгъзалары тарафыннан (2013 елда – 94, 2014 елда – 5, 2015 елда – 120, 2016 елда – 7).

Әлбәттә, үги аталар һәм аналары белән яшәүче ир-атлар янәшәсендә яшәүче балигъ булмаганнарның җенси кагылгысызлыгына каршы җинаятьләр кылу ихтималы зур.

> ***Мисал:*** *Чирмешән авылында 2010 елның сентябреннән алып 2017 елның апреленә кадәр гр. Г. системалы рәвештә 2003 елгы үги кызына карата сексуаль характердагы гамәлләр кылган. Җинаять кылучы бу эшне башкару өчен йә өйдә үзе генә кала торган булган, йә машинада урманга алып киткән, йә мунчага алып керә торган булган. Үги ата, әгәр кыз бу хакта берәсенә сөйләсә, үзен, анасын, кечкенә сеңелләрен үтерү белән янаган. Кыз эче авыртуга зарланып, тикшерелергә баргач кына, бу җинаять ачылган. Көчләүчегә карата җинаять эше гаепләү бәяләмәсебелән судка җибәрелгән.*

Административ күзәтчелектәге затлар (гаилә әгъзалары) белән яшәүче балалар шулай ук хәтәр төркемгә керә. Балигъ булмаган балалары булган гаиләләрдә җенси кагылгысызлыкка һәм шәхеснең җенси ирегенә каршы җинаять кылу аркасында административ күзәтчелектәге затларның яшәве балаларның тормышына һәм сәламәтлегенә реаль куркыныч тудыра, балаларга каршы җинаять кылу куркынычы яный торган социаль хәвефле вәзгыять китереп чыгара.

> ***Мисал:*** *Алабуга шәһәрендә гр. К., исерек килеш, үги кызын – 2004 елгы «Т»ны көчли. Җинаять кылганнан соң К. Тикшерү органнарыннан качып йөри. Ул элек кылган җинаять өчен дә административ күзәтү астында булган.*

Балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләрне профилактикалау максатында җенси кагылгысызлыкка каршы җинаять кылган өчен административ күзәтчелектә торган затларга карата мәгълүматны балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль (шәһәр) комиссияләре адресына вакытында тапшыру эшен төгәл оештыру сорала. Шушы уңайдан 2017елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасында Эчке эшләр министры А.В.Хохорин адресына тиешле мөрәҗәгать җибәрелде.

Көч кулланып, балаларга карата җинаятьләр кылуга ярдәм итә торган шартларга килгәндә, болар – балаларның тәртипсез гаиләләрдә яшәве, балаларны күзәтүчесез калдыру, үзләренең ата-ана бурычларына салкын, җавапсыз кару.

2017 елда балигъ булмаганнарга карата балалар учреждениеләре хезмәткәрләре тарафыннан кылынган 9 җинаять теркәлү факты да мәгълүм. Алардан 6 очрак ул балаларга карата җенси кагылгысызлыкка каршы кылынган җинаять иде. Бу 2016 ел белән чагыштырганда 3 тапкырга кимрәк үзе (2016 елда – 27). Бу барлык җинаятьләр бер затка карата, Казан мәктәпләренең берсендәге психологка карый. Ахырда ул үз-үзен үтергән.

Моны республикада ел дәвамында алып барыла торган профилактик эшләрнең уңай нәтиҗәсе дип әйтергә мөмкин. Шул рәвешле, тиешле хокук саклау органнарының, дәүләт хакимиятенең, муниципаль хакимиятнең тиешле органнарының һәм хокук саклау органнарының балаларның көчләүләрдән һәм аларга карата башка төр рәхимсезлекләр кылудан дәүләт тарафыннан яклануына гарантияләрне тәэмин итү эше дәвам ителергә тиеш.

Шуны истә тотып, Татарстан Республикасында көч кулланып, җинаять кылынган балаларны яклау буенча профилактиктик чаралар комплексын кабул итәргә кирәк дип саныйбыз, шул исәптән:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәге мәсьәләләрне карарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына балаларга карата рәхимсезлекләргә каршы тору, көчләүләрнең булырга тиеш түгеллеге турында халыкка аңлату буенча, баланы көчләгән һәм аңа карата рәхимсезлек кылган өчен җаваплылык турындагы, балаларның үзаңын һәм аларда үз-үзләрен яклауны, үз-үзләре белән горурлануны арттыру буенча; балаларга һәм гаиләләргә ярдәм күрсәтә торган төрле социаль хезмәтләр эшчәнлеге турындагы мәгълүмат кампанияләрен даими уздыру хакындагы мәсьәләсен;

үзләренә карата көч кулланып, җинаятьләр кылынган балаларны социаль-психологик реабилитацияләүнең нәтиҗәле системасын булдыру турында;

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы, Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән берлектә ведомство балалар оешмаларында балаларны аларга карата җинаять кылудан яклау һәм саклау буенча чаралар күрүне тәэмин итәргә тиешләр;

Татарстан Республикасы буенча Эче эшләр министрлыгына балигъ булмаганнарның җенси кагылгысызлыгына каршы җинаятьләр кылган өчен административ күзәтчелек астында булучы затларга карата мәгълүматны вакытында балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль (шәһәр) комиссияләренә җибәрүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы буенча Эче эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләр буенча тикшерү чараларын башкарганда тиешле

органнарның – балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау субъектларының балалар проблемаларын профилактикалау буенча үз вазыйфаи бурычларын тиешенчә башкару мәсьләсе буенча гамәлләренә (гамәлкылмауларына) хокукый бәя бирергә;

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә, башка органнарга – балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау субъектларына түбәндәгеләр буенча чаралар күрүне көчәйтергә:

проблемалы гаиләләрдә яшәүче, административ күзәтү астында булган кешеләр, аналары белән бергә яшәүче ирләре булган гаиләләрдә яшәүче хәтәр төркемгә кергән балаларны ачыкларга;

игътибар, контроль, ведомство һәм ведомстводан тыш объект булган гаиләләрдә яшәүче хәтәр төркемгә кергән балаларга карата җинаять кылуларны булдырмаска.

3.2.3. Тискәре мәгълүматтан яклау хокукын тәэмин итү

Шактый кыска – 15 – 20 ел вакыт эчендә интернетның, мәгълүмат технологияләренең алга ургылуы барлык төр мәгълүматны дигитализацияләп, саннарга күчереп кенә калмыйча, безнең бөтен чынбарлыгыбызны саннар эченә алды. Кеше, шәхес буларак, мәгълүмат чолганышында тәрбияләнә һәм формалаша. Бөтен дөнья буйлап милионлаган кешеләрнең эше һәм тормышы виртуаль өлкәгә күчеп бара. Яңа «санлы җәмгыять» дигән термин барлыккакилде.

Бүген балаларның үсеше, белем алуы, аларны тәрбияләү һәм социаль мохиткә яраклаштыру гипермәгълүматка ия җәмгыять шартларында бара. Шик тә юк, бүгенге көндә мәгълүмат кыры дигәндә, иң элек, замана баласының һәрьяклы үсеше өчен кирәк булган куәтле белем бирү, танып белү, күңел ачу ресурсы күз алдына килә. Интернет ул технология генә түгел, ул – замана баласы үсеше өчен чыганак булган яшәү тирәлеге дә.

Шул ук вакытта, Рунет үсеше белән бергә, мәгълүмат технологияләренең зур тизлекләрдә үсүе балаларны һәм яшьләрне безнең җәмгыять өчен яңа булган, аларның физик, психик, әхлакый һәм рухи үсешенә тискәре йогынты ясарга һәм аны имгәтергә сәләтле шартларга да куя.

«Интернет» челтәре – иң глобаль, шул ук вакытта мәгълүмат урнаштыру ягыннан да, балаларның мондый мәгълүматтан файдалануы ягыннан да контрольдә тоту иң кыен булган чыганак. Планшет компьютерлар һәм смартфоннар кебек чыбыксыз электрон җайланмалар таралуга бәйле рәвештә «Интернет» челтәренә керү фактта контрольдә тотып булмаслык дәрәҗәгә җитте. Ата-аналарның һәм балалар белән эшләүче белгечләрнең заманча гаджетлар белән эшләгәндә түбән компетенцияле булуы әлеге мәгълүмат чыганагын контрольдә тотуны тагын да кыенлаштыра.

Интернеттан файдаланучы балигъ булмаган балаларга очрый торган интернет-янаулар классификациясен түбәндәге биш хәтәр типка бүлергә мөмкин:

коммуникация хәтәрлекләре кешеләрнең «Интернет» челтәрендә үзара аралашу һәм хезмәттәшлек итү процессында барлыкка килергә мөмкин:

виртуаль котырту, Челтәрдә куркыныч агрессия (кибербуллиг);

Челтәрдә законсыз элемтәләр: (груминг («кайгырту, карау») – сексуаль масатлар белән баланың ышынычын яулап, балалар белән элемтәгә керү, сексуаль эзәрлекләү, рекрутинг (куркыныч бергәлекләргә персонал сайлау, җәлеп итү);

контент хәтәрлекләре**,** Челтәрдә законсыз, куркыныч мәгълүмат белән танышканда барлыкка килә. Соңгы вакытта интернет-контент куркынычлылык дәрәҗәсе буенча бе-

ренче урынга чыкты, ул балаларны суицидка һәм балаларның гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч яный торган башка хәтәр гамәлләргә өнди: төрле үлем төркемнәре («Киты», «Порезы»), куркыныч уеннар төркемнәре («Беги или умри», «Волшебная фея», зацепинг, трейнсерфинг (поезд түбәсендә йөрү), руфинг (биек йортлар түбәсенә менү); башка илләрдә шундый контентка керүчеләр очрамады, ул Россия өчен генә хас;

интернет-бәйлелек: Интернетка чамадан тыш бәйлелек. Мәктәп мохитендә видеоуеннар белән белән мавыгулар рәвешендә (гейминг) барлыкка киләтүлекләр буе фильмнар һәм сериаллар карау;

куллану хәтәрлекләре: Интернет аша товарлар сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану процессында барлыкка килә, алар арасында сыйфатсыз, ялган товар алу, мошенниклар кулына эләгү, акча югалту һәм башкалар;

техник хәтәрлекләр: компьютерны программачыл тәэмин итүдән файдалану һәм аны зарарлау процессында барлыкка килә, зарарлы программалар (вируслар, черви, троян атлары, шпион программалары, боты һәм башкалар) кертү юлы белән шәхси мәгълүматны урлау.

1 нче схема




Интернетны үстерү фонды сораштырулары буенча, Россия укучыларының 32%ы челтәрләрдә тәүлеккә 8 сәгать, ягъни елга 3,5 ай утыралар. Балаларның онлайн-активлыгы арта, «интернет-инициации» – Челтәргә беренче мәртәбә керүчеләрнең яше кими. Моннан җиде ел элек балалар беренче мәртәбә 9-10 яшьтә Челтәргә кергән булсалар, хәзер бу яшь 2-6 яшькә төште. Мондый бәйлелек бик иртә яшьтән барлыкка килә хәзер.

«Кеше яшәми торган утрауга үзегез белән нәрсә алыр идегез?» дигән сорауга Фонд тарафыннан уздырылган сораштыруларда, дуслардан һәм туганнардан кала, икенче урынга Интернет чыга. Яшүсмерләр өчен Интернет һәм туганнар бер үк дәрәҗәдә. Интернетка ихтыяҗ ризыкка һәм канга караганда да өскәрәк чыга.

62 нче диаграмма

12 – 17 яшьтәге яшүсмерләрдән «Кеше яшәми торган утрауга үзегез белән нәрсә алыр идегез?» дигән сорауга җаваплар



Балаларның һәм яшүсмерләрнең Глобаль челтәргә бәйлелеге Россия Федерациясе өчен генә түгел, ә бөтен дөнья өчен актуаль проблема.

Шуны әйтергә кирәк, балаларның мәгълүмат иминлеген тәэмин итү халыкара хокукның гомумтанылган принцибы. Бала хокуклары турында БМО Конвенциясенең 13 һәм 17 статьяларында, дәүләтнең балалар хокукын тәэмин итү бурычын игълан итеп, бер үк вакытта катнашучы оешмалардан балалар өчен мәгълүматка керүгә тиешле чикләүләр билгеләүне дә таләп итә.

Европа илләрендә 1999 елдан, Европа берлеге Еврокомиссиясенең *(Европа берлеге башкарма хакимиятенең иң югары коллегиаль органы)* масштаблы Safer Internet программасы гамәлгә ашырыла башлады. Ул балалар өчен имин онлайн-мохит булдыру өчен гамәлләр плынан эшләүгә һәм тикшернүләр уздыруга юнәлдерелә. 2016 елда Европа парламенты депутатлары белешмәләрне яклау турында гомумевропа законының төгәлвариантын кабул иттеләр. Аның бер нигезләмәсендә балигъ булмаган балаларның (16 яшькә кадәр) соцчелтәрләрдә аккаунтларын («исәпкә алу», интернет-паспорт, кулланучы турында мәгълүмат) ата-аналары яисә опекуннары рөхсәтеннән башка теркәүгә чик куела. Яңа кагыйдә барлык соцчелтәрләргә кагыла, Facebooktан башлап, Snapchat, Twitter, Instagramларга кадәр. Аны бозган өчен глобаль табыштан 4% күләмендә штраф салына. Соцчелтәрләрдә аккаунт ачу өчен минималь яшьне (13 яшь) билгеләгән тиешле тыю АКШ законнары белән 1998 елда кертелде. Мондый чаралар очраклы гына түгел: бер яктан, социаль челтәрләр – бу балалар үсеше һәм аларның белеме өчен файдалы мәгълүмат чыганагы түгел, икенче яктан – законга каршы контентның төп өлеше бүген сайтларда урнашкан, хәтта ачык сайтларда гына да түгел, ябык төркемнәрдә дә. Шулай итеп, балалар өчен Интернетның уңай ресурсларын чикләмичә, тискәресе блокировкалана.

Бүген шундый инициативалар Россия Федерациясесендә дә бар. 2017 елның 10 апрелендә депутат В.В.Милонов тарафыннан Дәүләт Думасына «Социаль челтәрләр эшчәнлеген хокукый җайга салу һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» закон проекты кертелде. Аның белән социаль челтәрләрдә 14 яшькә кадәр теркәлүгә тыю билгеләнә. Заокн проектының балигъ булмаганнарның (18 яшькә кадәр) аккаунтларын теркәү нигезләмәсен көчәйтү өчен мөмкинлек барлыкка килә. Бу ата-аналар контролен җаваплылыгын көчәйтә.

Дәүләт Думасы Аппаратының Хокукидарәсе Россия Федерациясе Федераль Собрание-се Дәүләт Думасы Регламентының 107 статьясындагы 31 өлеше нигезендә закон проектын закон чыгару инициативасы субъектларына Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясындагы 3 өлешендә һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Регламентының 105 статьясында каралган таләпләрне үтәү өчен кайтару турында карар кабул ителде, шуңа бәйле рәвештә әлегә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең бәяләмәсе юк.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясенең илкүләм законнары күпмедер дәрәҗәдә формалашты һәм 2012 ел ахырыннан гамәлгә керде. Балаларны аларның сәламәтлегенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында Россия Федерациясе законнары федераль законнар нормалары белән чикләнә.

Федераль законнар балаларны тискәре мәгълүматтан яклау буенча төп чара буларак тыюлы хокукый механизмнар билгели.

«Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» 2010 елның 29 декабрендәге 436-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 436-ФЗ номерлы Закон) балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү өлкәсендә төп норматив хокукый акт булып тора. Әлеге законның норматив нигезләмәләре 2012 елның 1 сентябреннән гамәлгә керде. Закон балаларны аларның сәламәтлегенә һәм (яисә) үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклауга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала. Аның гамәли көче Россия Федерациясе территориясендә алда телгә алынган барлык чыганакларның продукцияләре әйләнеше өлкәсендәге мөнәсәбәтләргә кагыла.

Нәкъ менә шул закон балалар сәламәтлеге һәм (яисә) үсеше өчен зыян китерә торган мәгълүмат төшенчәсен кертә:


1) балалар арасында тарату тыелган мәгълүмат (№ 436-ФЗ, 5 статья, 2 өлеш);

2) билгеле бер яшь төркемнәрендәге балалар арасында тарату тыелган мәгълүмат.

436-ФЗ номерлы закон белән балалар өчен, аларның яшьләренә карап, бүген гамәлдә булган мәгълүмат продукциясен классификацияләү кертелә.

«Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон имин-интернет өлкәсендә төп акт булып тора.

2 нче схема



Бүген балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында Россия Федерациясе законнарының үтәлешен үз компетенцияләре чикләрендә тикшереп торучы дәүләт органнарының аерым бер системасы барлыкка килде:

Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) Бердәм реестрны формалаштыра һәм алып бара, балигъ булмаганнарның порнографик сыннары төшерелгән «Интернет» челтәре аша тарала торган материалларда һәм (яисә) порнографик характердагы тамаша чараларында балигъ булмаганнарны башкаручы буларак катнашырга җәлеп итү турында белдерүләрдә тыелган мәгълүмат булу-булмау карарлар кабул итә;

«Интернет» челтәре аша таратыла торган массакүләм мәгълүмат чаралары продукциясендә наркотик чараларны, психотроп матдәләрне һәм аларның прекурсорларын ясау, әзерләү һәм куллану ысуллары, мондый чараларны, матдәләрне һәм аларның прекурсорларын сатып алу урыннары турында, составында наркотик матдә булган үсемлекләрне үрчетү ысуллары һәм урыннары турында карарлар кабул итә;

мондый оешма әлегә кадәр билгеле түгел әле, ачыклау вәкаләтләрен Роскомнадзор үзе башкара, бу функционалны Россия Федерациясендә үзенең территориаль органнарына бирми. Роскомнадзорга мөрәҗәгатьләр кергәннән соң бер тәүлек эчендә электрон рәвештәге тиешле запрос, югарыда телгә алынган компетенция нигезендә, вәкаләт бирелгән федераль органнарга җибәрелә. Мөрәҗәгать буенча кабул ителгән карар тәүлек эчендә Роскомнадзорга тапшырыла. Шул ук вакытта бүген Роскомнадзор гражданнарга, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына Интернет челтәрендәге сайтларда хокукка каршы мәгълүмат булу турында хәбәр итәргә куша. Моннан нәтиҗә, законга каршы контентны ачыклау буенча Роскомнадзор тарафыннан башкарыла торган эш җитәрлек түгел.

Тискәре интернет-контентны блокировкалый торган чаралар күрүне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге домен исемнәренең, сайтларга күрсәткечләрнең Россия Федерациясендә таралуы тыелган мәгълүмат урнаштырылган «Интернет» челтәре сайтларын танырга мөмкинлек бирә торган бердәм реестры» автоматлаштырылган бердәм мәгълүмат системасын булдыру, формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре (алга таба – Бердәм реестр) гамәлгә ашыра.

Тискәре йогынты ясый торган интернет-контентны туктату буенча чаралар күрү вәкаләте бүген бары тик федераль дәүләт хакимияте органнарына гына бирелгән һәм ул Бердәм реестр автоматлаштырылган бердәм мәгълүмат системасы кысаларында башкарыла.

Бу функцияләрне үтәү өчен Роскомнадзорның рәсми сайтында (https://rkn.gov.ru/) «Интернет» челтәрендәге сайтларда, социаль челтәрләрдә тыелган мәгълүмат булуы турында мөрәҗәгатьләр кабул итү өчен интерактив форма урнаштырылган. Мөрәҗәгатьләр дәүләт органнарыннан, муниципаль органнардан, оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән, һәм, шулай ук физик затлардан да булырга мөмкин.

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы «Интернет» челтәре аша таратыла торган мәгълүматта наркотик чараларны, психотроп матдәләрне һәм аларның прекурсорларын ясау, әзерләү һәм куллану ысуллары, мондый чараларны, матдәләрне һәм аларның прекурсорларын сатып алу урыннары турында, шулай ук составында наркотик матдә булган үсемлекләрне үрчетү ысуллары һәм урыннары турында карарлар кабул итә;

Роспотребнадзор – Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәт (Роспотребнадзор) «Интернет» челтәре аша таратыла торган мәгълүматта үз-үзеңә кул салу ысуллары, үз-үзеңә кул салырга өндәүләр турында тыелган мәгълүмат булу-булмау турында карарлар кабул итә;

Федераль салым хезмәте (РФ ФСХ) «Интернет» челтәре аша таратыла торган мәгълүматта «Интернет» челтәрен һәм башка элемтә чараларын кулланып, «Комарлы уеннар оештыруны һәм үткәрүне дәүләт җайга салуы турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон таләпләрен һәм «Лотерея турында Федераль закон таләпләрен боза торган тыелган мәгълүмат булу-булмау турында карарлар кабул итә;

Роскомнадзор – балигъ булмаганнарның порнографик сыннары төшерелгән «Интернет» челтәре аша тарала торган материалларда һәм (яисә) порнографик характердагы тамаша чараларында балигъ булмаганнарны башкаручы буларак катнашырга җәлеп итү турында белдерүләрдә тыелган мәгълүмат булу-булмауны ачыклый;

Аннары гарызнамә буенчакабул ителгән карар турында мәгълүмат тәүлекәчендә Роскомнадзорга кертелә.

Әгәр хокукка каршы мәгълүматның булуы расланса, Роскомнадзор аны алу буенча процедура башлана. Хостинг хуҗасы мәгълүматны бетерми икән, бу ресурсны туктату буенча «скальпель» механизмы эшли башлый.

201 елда мәгълүмат иминлеген тәэмин итү өлкәсендә гамәлдәге законнарда булган җитешсезлекләрне бетерүгә юнәлдерелгән федераль законнар эшли башлавына игътибар итәргә кирәк.

«Балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалауның төп нигезләре турында» Федераль законга һәм «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» Федераль законның 15.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2017елның 7 июнендәге 109-ФЗ номерлы Федераль закон балаларны үз-үзләрен үтерүгә өндәүгә бәйле җинаятьләрне ачыклауга һәа булдырмый калуга юнәлдерелгән.

Балигъ булмаганнарны суицидаль гамәлләргә җәлеп итүче затларны ачыклау эчке эшләрнең район (шәһәр) бүлекләрен (идарәләре), муниципаль берәмлекләрнең эчке эшләр бүлекләре (идарәләре), ябык административ-территориаль берәмлекләрнең эчке эшләр бүлекләре (идарәләре), транспортта эчке эшләр бүлекләре (идарәләре), шулай ук эчке эшләр органнарының башка бүлекчәләре эшчәнлеге юнәлешләренә кертелгән.

«Россия Федерациясе җинаять-процессуаль кодексының 151 статьясына балигъ булмаганнарны суицидка китерүгә юнәлдерелгән эшчәнлеккә каршы өстәмә механизмнар билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 7 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон белән балигъ булмаганнарны үз-үзен үтерүгә җәлеп итү өчен дүрт елга кадәр ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җаваплылыгы билгеләнергә мөмкин.

Шулай түбәндәге гамәлләр өчен дә җинаять җаваплылыгы кертелә:

үз-үзеңне үтерүгә җәлеп итү яисә аңа булышу;

үз-үзеңне үтерүгә теләк уятуга юнәлдерелгән эшчәнлекне оештыру;

балигъ булмаганнарны аның гомеренә куркыныч яный торган гамәлләр кылуга җәлеп итү.

Моннан тыш, ярдәмгә мохтаҗ балигъ булмаганнарны, гаепле затка бурычлы яисә башкача бәйле булган хатын-кызны, йөкле хатын-кызны, ике яисә берничә кешедән торган төркемне «Интернет» челтәрендә , массакүләм мәгълүмат чараларында ачыктан-ачык күрсәтеп, алдан уйлап, белә торып үз-үзләрен үтерүгә китергән затлар өчне җинаять җаваплылыгы билгеләнә. средствах массовой информации или сети «Интернет».

Балаларның мәгълүмати иминлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтенең тагын бер җитди өстенлекле бурычы балаларның һәм яшүсмерләрнең медиагыйлемен арттырудан, аларда мәгълүмат кырында кылган гамәлләре өчен җаваплылык хисе булдырудан, танып-белү ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән, десоциальләшү куркынычын, яшүсмерләрнең девиант һәм хокукка каршы гамәлләрен бетерүдән гыйбарәт.

Балаларның мәгълүмати иминлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтенең тагын бер җитди өстенлекле бурычы балаларның һәм яшүсмерләрнең медиагыйлемен арттырудан, аларда мәгълүмат кырында кылган гамәлләре өчен җаваплылык хисе булдырудан, танып-белү ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән, десоциальләшү куркынычын, яшүсмерләрнең девиант һәм хокукка каршы гамәлләрен бетерүдән гыйбарәт. Бары тик тыю гамәлләрен генә кулланып, балаларны алар өчен куркыныч булган һәм арта барган куркынычлардан саклап калып булмый. Балаларны һәм яшүсмерләрне мөстәкыйль рәвештә мәгълүмат чолганышында имин яшәргә өйрәтергә кирәк. Ләкин әлеге бурычны гамәлгә ашыру бик авыр, чөнки үзенчәлекле механизмнар эшләү һәм балалар белән эшчәнлекнең яңа алымнарын булдыру таләп ителә.

Бары тик тыю гамәлләрен генә кулланып, балаларны алар өчен куркыныч булган һәм арта барган куркынычлардан саклап калып булмый. Балаларны һәм яшүсмерләрне мөстәкыйль рәвештә мәгълүмат чолганышында имин яшәргә өйрәтергә кирәк. Ләкин әлеге бурычны гамәлгә ашыру бик авыр, чөнки үзенчәлекле механизмнар эшләү һәм балалар белән эшчәнлекнең яңа алымнарын булдыру таләп ителә, бу юнәлештә эшләүне дәвам итәргә кирәк.

Хәтәр төркемгә керә торган балаларның һәм яшүсмерләрнең суицидаль һәм башка төрле деструктив гамәлләргә тартылуын профилактикалау буенча эшчәнлекне оештыру игътибар үзәгендә булырга тиеш.

Мондый хәтәр төркемнәргә түбәндәгеләр керә:

хокукка каршы төркемнәргә керүче балалар;

суицидаль омтылышларны кылган балалар.

2015 елдан Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм сукбайлыгын профилактикалау системасы субъектлары балигъ булмаганнар арасында бәхетсезлек очракларын һәм суицидларны булдырмау юнәлешендә эшлиләр. Алар арасындагы хезмәттәшлек һәм мәгълүмат алмашу Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм сукбайлыгын профилактикалау системасына керүче органнар һәм учреждениеләр арасында балигъ булмаганнарның бәхетсезлек очракларын һәм суицидларны булдырмау буенча үзара хезмәттәшлек итү һәм мәгълүмат алмашу тәртибен раслау турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 01-15 номерлы карары белән җайга салына.

Балаларның мәгълүмати иминлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтенең тагын бер җитди өстенлекле бурычы балаларның һәм яшүсмерләрнең медиагыйлемен арттырудан, аларда мәгълүмат кырында кылган гамәлләре өчен җаваплылык хисе булдырудан, танып-белү ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән, десоциальләшү куркынычын, яшүсмерләрнең девиант һәм хокукка каршы гамәлләрен бетерүдән гыйбарәт. Бары тик тыю гамәлләрен генә кулланып, балаларны алар өчен куркыныч булган һәм арта барган куркынычлардан саклап калып булмый. Балаларны һәм яшүсмерләрне мөстәкыйль рәвештә мәгълүмат чолганышында имин яшәргә өйрәтергә кирәк. Шул уңайдан Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координация комитеты карары беләна түбәндәге документларга үзгәрешләр кертелде:

2015 елның 16 гыйнварындагы 01-15 номерлы «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм сукбайлыгын профилактикалау системасына керүче органнар һәм учреждениеләр арасында балигъ булмаганнарның бәхетсезлек очракларын һәм суицидларны булдырмау буенча үзара хезмәттәшлек итү һәм мәгълүмат алмашу тәртибен»ә;

Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең 2015 елны 13 июнендәге 18-16 номерлы карары белән расланган Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм сукбайлыгын профилактикалау системасы субъектлары эшчәнлеге алгоритмына.

Хәтәр төркемдәге балалар белән профилактик эшчәнлекне оештыруда төп проблема – мондый балаларны ачыклау. Суицидент-балалар турындагы белешмәләр ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән балаларны исшпкә алып бара торган сәламәтлек саклау органнарында саклаып кала. Проблемалы балалар арасында профилактика субъектларының суицидларны кабатлау булмасын өчен чаралар күрү буенча үз вакытында һәм төгәл үзара эшчәнлеге мөһим профилактика чарасы булып тора. Бу эшне башкару өчен .»**Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның** пациент турындагы мәгълүматны тапшыруда сәламәтлек саклау учреждениесенең хокукларын чикли торган нормасы тоткарлык тудыра.

Бүген ремспубликаның профилактикалау системасындагы органнар һәм учреждениеләр хәтәр төркемдәге зыян күргән балаларга үз вакытында һәм тиешле дәрәҗәдә психологик ярдәм күрсәтергә әзерләр дип әйтергә кирәк. Шул ук вакытта бу эштә балалар өчен эшли торган психологик хезмәт звеносы канәгатьләнерлек түгел әле. Хәтәр төркем балалары белән психологлар эшләргә тиеш. Аларның профилактик эш нәтиҗәсе псиолог-белгечләрнең тәэмин ителеш дәрәҗәсенә бәйле.

Бүгенгекөндә педагог-психологлар ставкасы 1413 учреждениедән бары тик 384 (27%) мәктәптә генә кертелгән.

Шуңа бәйле рәвештә, республикада һәр мәктәптә педагог-психологлар ставкасы кертеп, психологик хезмәтне ныгытырга кирәк.

Балаларның мәгълүмати иминлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтенең тагын бер җитди өстенлекле бурычы балаларның һәм яшүсмерләрнең медиагыйлемен арттырудан, аларда мәгълүмат кырында кылган гамәлләре өчен җаваплылык хисе булдырудан, танып-белү ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән, десоциальләшү куркынычын, яшүсмерләрнең девиант һәм хокукка каршы гамәлләрен бетерүдән гыйбарәт. Балаларны һәм яшүсмерләрне мөстәкыйль рәвештә мәгълүмат чолганышында имин яшәргә өйрәтергә кирәк.

Балаларның мәгълүмат иминлеген тәэмин итү буенча балалар белән профилактик чаралар үткәрү ***балаларның һәм яшүсмерләрнең санлы грамоталылыкны арттыруга*** юнәлдерелгән булырга тиеш, бу 21 гамыр балалары өчен мөһим күнекмә һәм мәгълүмати җәмгыятьтә иминлек нигезе булырга тиеш. Медиагыйлемен арттыруны без балалар бакчасыннан башларга тиеш. Укырга, язарга өйрәтү кебек бер дәрәҗәдә булырга тиеш. Безгә бүген балаларны һәм яшүсмерләрне мәгълүмат киңлегендә мөстәкыйль һәм имин эш итәргә, Глобаль челтәр мөмкинлекләреннән файдалана белергә өйрәтергә кирәк. Киберкуркынычсызлык дәрәҗәсен арттыру, «Интернет» челтәрендә балаларның иминлеге проблемасына ата-аналарны һәм педагогларны җәлеп итү һәм мәктәп балаларының санлы грамоталылыгын арттыру максатларында, «Файдалы һәм имин интернет дәресе» проктын гамәлгә ашыру турында сүз бара.

Балалар белән эшләү чараларының тагын бер комплексы тискәре Интернет контенты аркасында балаларның суицидаль һәм деструктив халәтен профилактикалауга юнәдерелә. Балаларны имин мәгълүматка хокукын тәэмин итү мәсьләләренең актуальлеген исәпкә алып, муниципаль хакимият органнары, хокук саклау органнары вәкаләтләрен һәм компетенцияләрен истә тотып, балалар өлкәсендә эшләүче оешмаларны балаларны аларны сәламәтлегенә һәм физик, психик, рухи, әхлакый үсешен арттыруга юнәлдерелгән «Балаларның һәм яшүсмерләрнең шәхес булрак үсеше дәресләре» проектын гамәлгә ашыру сорала.

Ике мәгариф проекты да Татарстан Республикасында күпмедердәрәҗәдә гамәлгә ашырыла дипә йтергә кирәк. Балаларның мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында Т*атарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы* буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «МТС» ГАҖ

белән берлектә Татарстан Республикасында 2017 елның октябрендә республиканың барлык мәктәпләрендә файдалы һәм куркынычсыз Интернет айлыгы үткәрелде. Проекты гамәлгә ашыру турында тулы мәгълүмат нотыкның 1.9 бүлегендә бирелде.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан эшләнгән 68 сәгатьлек «Лидерлык нигезләре» белем бирү программасы да балаларның һәм яшүсмерләрнең шәхес булып җитешү мәсьәләләренә юнәлтелгән.

Бүген бу проектларны үстерүнең һәм киңәйтүнең зарурлыгы турында барлык мәктәпләрдә һәм белем бирү учреждениеләрендә сүз алып барырга кирәк. Куркынычсыз интернет проекты барлык балаларны, мәктәпкәчә булганнарны да кертеп, үз эченә алырга тиеш.

Имин мәгълүмат пространствосын булдыру өлкәсендә тагын бер мөһим юнәлеш булып ата-аналарны медиаагарту эшләре тора. Ата-аналар балалары «яши» һәм «кереп йөри» торган параллель, виртуаль дөнья турында мәгълүматлы булырга, балаларны сагалап торучы хәвефләр хакында белергә, ярдәм, яклау, киңәш кирәк очракта алар белән янәшә булырга тиеш. Һичшиксез, алда язылган ике бурычны гамәлгә ашыру өчен медиаиминлек өлкәсендә балалар белән эшләүче педагогларның һәм башка белгечләрнең компетенция дәрәҗәсен арттырырга кирәк.

Шул ук вакытта республикада балигъ булмаганнар өчен белем бирү учреждениеләренә (балалар бакчаларына, мәктәпләргә, һөнәри белем бирү учреждениеләренә) санлы грамоталылыкны арттыру һәм суицидаль халәтне профилактикалау максатларында тиешле экспертиза узмаган материаллар кертүне тыю чараларын күрергә икрәк. Без балалар янын кем килгәнен һәм аның нәрсә белә килгәнен яхшы аңларга тиеш!

Һәм тагын бер нәрсәгә игътибар юнәлтәсе килә: агарту һәм профилактикалау эшен Интернетның үзендә – балалар «яши» торган дөньяда алып барырга кирәк.

Интернетта балаларның иминлеген тәэмин итүнең нәтиҗәлерәк ысуллары турында ата-аналар үзләре ни уйлавы да кызыклы. Интернетны үстерү фонды һәм М.В.Ломоносов ис. МДУның Психология факультеты тарафыннан үткәрелгән сораштырулардан күренгәнчә, сораштыруда катнашкан ата-аналарның 18%ы моңа мәктәп җаваплы дип карый, дәүләт -19%, интернет-индустрия – 15%. Аларның бик азы гына инфокампаниялəр, махсус сайтлар яисә или ярдәм хезмәтләре тиеш дип уйлый. Һәр дүртенче ата-анагына үз баласының интернеттагы иминлеге өчен үзләре җаваплы дип карый.

63 нче диаграмма

Интернетта балалар иминлген нәтиҗәлерәк тәэмин итү ысуллары турындагы мәсьәләгә ата-аналарның җаваплвры, %



Ата-аналар балалар өчен онлайн-куркыныч янауларның тәэсир көчен аңлап бетермиләр, күрәсең.


Белгечләр фикеренчә, балаларны онлайн-куркыныч янаулар тәэсиреннән яклауда балаларның һәм ата-аналарның үзара ышынычлы мөнәсәбәте төр рольне уйный. Ата-аналар параллель, виртуаль мәгълүмат дөньясының барлыгын булса да белергә һәм моның белән кызыксынырга, балалары өчен аның ни дәрәҗәдә куркыныч һәм файдалы икәнен белергә тиешләр.

Мондый хезмәттәшлек итүнең иң гади ысулы – белем бирү оешмаларында үткәрелә торган җыелышларда катнашу. Алдан методик материал әзерләү дә мөһим роль уйный. Ата-аналар җыелышларын методик материалларсыз үткәрү аларны бүгенге реаль чынбарлык белән куркыту булып калырга мөмкин. Бу очракта ата-аналар яклавының, профилактик чараларның ысуллары тәкъдим ителергә тиеш.

Ата-аналар берлеге белән аралашу кысаларында аларның үзләренә тискәре контентны ачыклау эшчәнлегенә кушылырга тәкъдим итү максатка ярашлы булыр иде. Бу, бер яктан, интернетны чистартырга ярдәм итәчәк, икенче яктан – ата-аналар үзләренең һәм алар янындагы балаларының санлы компетенция дәрәҗәсен арттырачак, балаларын күбрәк аңларга ярдәм итәчәк.

3 нче схема

Ата-аналар медиациясе формалары



Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 2017 елда Россия Федерациясе субъектларына педагогик хезмәткәрләр өчен аларның компетентлыгын күтәрү һәм интернет янауларын профилактикалау мәсьәләләре буенча Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының «В.П.Сербский ис. Психиатрия һәм наркология буенча федераль медицина тикшерүүзәге» ФДБУ тарафыннан экспертиза узган методик материаллар җибәрелде.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгыннан эксперт бәяләмәләре булган профилактик характердагы күпсанлы материаллар алучы булуын истә тотып, Татарстан Республикасы

Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына балалар коллективларында куллану өчен әлеге материалларны җибәрергә тәкъдим итәргә кирәк дип саныйбыз.

Һичшиксез, алда күрсәтелгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен педагогларның медиааминлек өлкәсендә балалар белән эшләүче педагогларның һәм башка белгечләрнең компетенция дәрәҗәсен арттырырга кирәк.

Татарстан Республикасында балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерүгә бәйле хәвефләрдән яклау системасының торышы мәсьәләсе хакында республика дәрәҗәсендә массакүләм мәгълүмат чараларында, төрле гавами мәйданчыкларда фикер алышу аеруча мөһим.

Татарстан Республикасында хокук тәртибен тәэмин итү буенча 17 апрельдә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов рәислегендә узган Татарстан Республикасының Иминлек советы һәм Координация киңәшмәсенең уртак утырышында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Интернет-янауларны һәм балалар һәм яшүсмерләр гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янауларны профилактикалау өлкәсендә өстәмә чаралар күрү турында» төп нотык белән чыгыш ясады.

Татарстан Республикасының Иминлек советы һәм Координация киңәшмәсенең Татарстан Республикасында хокук тәртибен тәэмин итү буенча уртак утырышы беркетмәсен (03.05.2017 № Пр-124) үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 21 апрелендәге 1739-р номерлы күрсәтмәсе кабул ителде, анда республикада балаларның мәгълүмат иминлеген тәэмин итү буенча системалы чаралар комплексын гамәлгә ашыру күздә тотыла (2017 – 2019 елларга медиакиңлектә балаларның мәгълүмат иминлеген тәэмин итү буенча чаралар план («юл картасы») расланды.

Тискәре мәгълүмат агымыннан яклау хокукын тәэмин итү мәсьәләләренең актуальлеген истә тотып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, министрлыкларның һәм ведомстволарның игътибарын 2018 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 21 апрелендәге 1739-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2017 – 2019 елларга медиакиңлектә балаларның мәгълүмат иминлеген тәэмин итү буенча чаралар план («юл картасы») гамәлгә ашыруга юнәлтергә кирәк, дип саный.

3.3. Баланың сәламәтлеген саклауга һәм сәламәт үсешкә хокукын тәэмин итү

БМОның бала хокуклары турындагы Конвенциясе нормалары нигезендә сәламәтлеккә һәм сәламәт үсешкә хокук балалар хокуклрының аерылгысыз өлеше булып тора. Баланың сәламәтлеге аның тормышы камил һәм тулы хокуклы булуның төп нигезе. Балаларга күрсәтелә торган медицина хезмәтләреннән файдалана алу мөмкинлеген, бу хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртуны, төрләрен арттыруны тәэмин итүгә, балаларга медицина ярдәме күрсәтүне заманча тәртипләр һәм стандартлар нигезендә үтемле оештыруга һәм медицина технологияләрен кертүгә, балаларны дарулар, махсус дәва продуктлары, медицина әйберләре белән тәэмин итүне оештыруга, балаларга хезмәт күрсәтә торган наркология хезмәтен үстерүгә, балаларны сыйфатлы туклану белән тәэмин итү системасын камилләштерүгә, балаларны һәм яшүсмерләрне ял иттерү һәм савыктыру системасын үстерүгә, мәгариф учреждениеләренең сәламәтлек саклау эшчәнлеген арттыруга нигезләнә торган заманча технологияләр – бала хокуклары турындагы конвенция нигезендә Россия федерациясе законнары белән беркетелгән гарантияләр яшь буынның сәламәтлеген саклау, аның сәламәт үсешен тәэмин итүне күздә тота.

3.3.1. Балалар үлеменә гомуми анализ


Балаларның сәламәтлек торышын характерлый торган күрсәткечләрнең берсе ***балалар үлеме*** дәрәҗәсе була.

Әлеге бүлектә балалар үлемен анализлау нигезен 2018 елның 15 февраленә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан ясалган якынча (оператив) белешмәләр тәшкил итә.

2017 елда республикада балалар үлеме кимеде һәм 10000 балага 5,26 очракны тәшкил итте. Бу 2016 ел күрсәткеченә (6,13 очрак) һәм 2013 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең республика стратегиясен гамәлгә ашыру индикаторларына (10000 балага 7,9 очрак) караганда түбәнрәк. 2017 елда барлыгы 419 бала үлде, бу, 2016 ел белән чагыштырганда, 54 балага кимрәк.

64 нче диаграмма

2013 – 2016 елларда Татарстан Республикасында балалар үлеме (кеше)




Балалар үлеме структурасы бик катлаулы. Ул, нигездә, үлемнең сәбәпләренә һәм үлгән балаларның яшенә бәйле.

Балалар үлеменең яшь буенча бүленеше, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләренә нигезләнеп, түбәндәге диаграммада бирелә.

65 нче диаграмма

2013 – 2017 елларда балалар үлеменең яшь буенча бүленеше



Соңгы биш елда балалар үлеменең сәбәпләре түбәндәге таблицада бирелә.

18 нче таблица

2013–2017 елларда балалар үлеменең сәбәпләре


Сәбәпләре	**2013** ел		**2014 ел**		**2015 ел**		**2016 ел**		**2017 ел**	
	кеше	%	кеше	%	кеше	%	кеше	%	кеше	%
Авыру	**468**	77,3	**483**	81,7	**427**	83,2	**383**	81,8	**332**	79,2
Башка сәбәпләр	**137**	22,6	**108**	18,2	**86**	16,8	**85**	18,2	**87**	20,8
Барысы	**605**		**591**		**513**		**468**		**419**	

Җәмгыять имнлегенең торышын һәм халыкның социаль иминлеген характерлый торган мөһим күрсәткечләрнең берсе – ***сабыйларның үлем дәрәҗәсе.*** Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы күрсәткечләре нигезендә сабыйлар үлеме илләрне халыкның тормыш дәрәҗәсе буенча классификацияләгәндә төп фактор булып санала. Шул ук вакытта бу саннар дәүләтнең балалар иминлеге өчен шартлар тудыру дәрәҗәсен дә күрсәтә. Хисап чоры күрсәткечләре буенча, республикада соңгы биш елда сабыйлар үлеме кимүнең уңай тенденциясе саклана, шулай да балалар үлеменең шактый өлешен тәшкил итә: 2013 елда – 65 %, 2014 елда – 62 %, 2015 елда – 66 %, 2016 елда – 63 %, 2017 елда – 59,6%.

Анализдан күренгәнчә, 2017 елда сабыйлар үлеме 16%ка кимеде: бер яшькә кадәр 250 бала үлгән, бу исән туган 1000 балага 5,07 очрак, (2016 елда – 5,3).

66 нчы диаграмма


2013–2017 елларда сабыйлар үлеме (бер яшькә кадәр)



2017 елда ***перинаталь үлем*** очраклары шактый кимеде. Болар – үле туган балалар һәм туганнан соң *(иртә неонаталь үлем)* 7 тәүлек булганчы үлгән балалар. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2017 елда перинаталь чорда барлыкка килә торган җитешсезлекләрдән 483 бала вафат булган, бу 2016 елның шушы чорына караганда 110га кимрәк. Бу – соңгы биш елдагы иң түбән күрсәткеч. Перинаталь үлем дәрәҗәсенең кимүе иртә неонаталь үлем очракларының 19,6% %ка (29 очрак) кимүе һәм үле туган балалар санының 18,2%ка яисә 81 очракка азрак булуы белән аңлатыла.

67 нче диаграмма

2013–2017 елларда Татарстан Республикасында перинаталь үлем



Соңгы биш елда сабыйлар үлеме 36,5%ка, перинаталь үлем очраклары 29%ка кимеде, бу республикада күрелгән чараларның һәм кабул ителгән карарларның нәтиҗәсе булып тора. Һичшиксез, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында Перинаталь үзәк ачылу да биредә зур роль уйнады. Ул профессиональ кадрлар белән тәэмин ителү белән бергә, заманча югары технологияле җайланмалар белән дә җиһазландырылган.


Шуны да әйтергә кирәк, бала тудыру учреждениеләрен реструктуризацияләү нәтиҗәсендә яңа туган балалар өчен реанимация койкалары саны кимителде. Алар 104кә калды (2013 елда – 95, 2014 елда – 104, 2015 елда – 98 койка, 2016 елда – 109 койка). Неонатологларның саны бераз артты. 2016 елда бу өлкәдә 122 белгеч булса, 2017 елда 128 булды (2013 елда – 121 белгеч, 2014 елда – 122 белгеч, 2015 елда – 120 белгеч). Тәэмин ителеш 23% дәрәҗәсендә.

3.3.2.Балалар сәламәтлеге торышына гомуми анализ

Ел саен балаларга уздырыла торган профилактик тикшерүләр балалар сәламәтлеге торышын билгеләргә мөмкинлек бирә. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, мондый тикшерүләр нәтиҗәләре балаларның сәламәтлеге торышын түбәндәге төркемнәргә бүләргә ярдәм итте.

68 нче диаграмма

2013–2017 елларда балигъ булмаганнарның сәламәтлеге торышын төркемнәргә бүлү



Югарыда китерелгән саннар күрсәткәнчә, медицина тикшерүе үткән балаларның гомуми саныннан күбесенең сәламәтлеге икенче төркемгә карый (2017 елда – 67,5%), әммам 2017 елда төркемнәр структурасында үзгәрешләр барлыкка килде. Беренче һәм икенче төркемнәргә кергән балалар саны 86,6%тан 91,9%ка җитте. 2017 ел йомгаклары буенча өченче, дүртенче һәм бишенче төркемгә керүче балалар саны кимеде.

Балалар авыруларын анализлау балигъ булмаганнарның сәламәтлеге торышын бәяләргә мөмкинлек бирә.

Соңгы биш елда балалар авыруларын динамикада анализлау түбәндәге таблицада бирелде.

19 нчы таблица

2013 – 2017 елларда балаларда беренче мәртәбә ачыкланган авырулар

2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел	2017 ел	2016 елга %	*Беренче мәртәбә ачыкланган авырулар*
101472	93247	99007	100447	100937	+0,5%	Җәрәхәтләнүләр, агуланулар һәм тышкы сәбәпләрдән килгән кайбер башка зыяннар
25497	22780	25164	25865	24065	-7,0%	Нерв системасы авырулары
3252	2778	3129	3012	3044	+1,1%	Психик тайпылышлар һәм тәртипнең үзгә булуы (барлыгы)
_	80	85	92	97	+5,4%	Шул исәптән, аутистик тайпылышлар
85	100	100	107	128	+19,6%	Шешләр (Яман шеш авырулары)
-	22	25	26	34	+30,7%	Сирәк очрый торган (орфан) авырулар
14	8	4	7	9	+28,6%	Менингококк инфекция
55	37	20	13	18	+38,5%	Гонококк инфекция
64	55	45	44	26	-40,9%	Трихомоноз
28	17	12	11	8	-27,3%	Сифилис (барлык рәвешләре)
18	13	23	14	10	-28,6%	ВИЧ (барлык рәвешләре)
142	116	124	75	46	-38,7%	Вируслы гепатит
80	67	70	67	41	-38,8%	Туберкулез
686	364	348	255	210	-17,6%	Корчаңгы
983	1140	1309	1207	901	-25,3%	Педикулез (бет)
56	19	11	34	17	-50,0%	Дизентерия

Республикада ел имгәнүләр, агуланулар һәм кайбер башка тышкы сәбәпләр аркасында 100 меңләп балалар авырган очраклар ачыклана. 2017 елда аларның саны 2016 елга караганда 490га артты.

2017 елда нерв системасы белән авырган очракларның кимүе күзәтелә (7%). Шул ук вакытта беренче мәртәбә ачыкланган авырулар структурасында аларның саны тотрыклы рәвештә икенче урында тора (24 065 очрак).

Балалар арасында психик тайпылышларның артуы аеруча борчу тудыра. 2017 елда беренче тапкыр шундый авырулар белән авырган балалар саны 3 044 булды, 2016 елга караганда 32гә (1%ка якын) күбрәк. Шул ук вакытта аутистик спектр белән авырган очраклар саны да арта, 2017 елда шундый 97 очрак ачыкланды, үсеш 5,4%.

Балаларда ел саен арта яман шеш авыруларының арта баруы да борчый. 2017 елда беренче мәртәбә 128 балага шундый диагноз куелды.

2017 елда 34 балада сирәк очрый торган (орфан) авырулары ачыкланды.

2017 елда балаларның корчаңгы, педикулез, туберкулез кебек социаль авырулары белән чирләү очраклары кими бара (7,6%, 25,3% и 38,8%).


Балаларның вируслы гепатит, ВИЧ (барлык рәвешләре), дизентерия белән авырулары шулай ук кимеде.

2017 елда җенси юл белән күчә торган инфекцияләр белән авырган 198 очрак ачыкланган (2016 елда – 214 очрак). Сифилис һәм трихомониаз авыруларының кимүе фонында гонококк инфекциясе арткан.

Балигъ булмаганнарның һәм яшүсмер кыз балаларның йөклелек очраклары аерым игътибар таләп итә. Статистика мәгълүматлары балигъ булмаганнар арасында йөклелек очракларының тотрыклы рәвештә кимүен күрсәтә. Мәсәлән, 2017 елда 2016 елдагыга караганда 94кә, ягъни 28 %ка кимегән, 2017 елгы күрсәткеч (241кыз) соңгы еллардагы иң түбән күрсәткеч. 2013 ел белән чагыштырганда, йөккә узган кызларның саны ике тапкырдан артыкка кимеде (2013 елда – 513 очрак, 2017 елда – 241).

69 нчы диаграмма

2013–2017 елларда балигъ булмаганнар арасында йөклелек статистикасы




Һәр йөклелек очрагы да баланы тудыру белән тәмамланмый. Аборт – туарга өлгерми калган сабый гына түгел, ә кыз-баланың – булачак ананың репродуктив сәламәтлегенә җитди куркыныч янау да әле ул.

Балигъ булмаганнарның йөклелек очракларының 30 %тан артыгы аны өзү (аборт) белән төгәлләнә. 2017 елда 241 очракның 148ендә бала туу белән тәмамланган, 93 очракта – аборт белән. Абортлар өлеше – 38,6%, бу соңгы биш елда иң зур күрсәткеч. (2013 елда – 38,2%, 2014 елда – 31,9%, 2015 елда – 33,4%, 2016 елда – 31,3%, 2017 елда – 38,6%).

70 нчы диаграмма

2013–2017 елларда балигъ булмаганнар арасында йөклелек статистикасы



Югарыда китерелгән анализның республикада балигъ булмаганнар арасындагы йөклелек очраклары һәм балаларның венерик авырулар белән авыру очраклары динамикасының уңай үзгәрешен раславын танырга кирәк. Шулай да балалар тормышында мондый хәлләр булмасын өчен без профилактика эшен дәвам итәргә тиеш. Профилактика эшенең бер варианты буларак, балалар арасында агарту эшләре алып бару нәтиҗәле булыр иде. Аны республиканың гомуми белем бирү учреждениеләрендә «Гаилә» дәресе кысаларында оештырырга мөмкин. Кызганычка каршы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, белем бирү учреждениеләренең әлеге эшчәнлек юнәлешендәге проблемалары, беренчедән, педагогларның әхлакый тәрбия, укучыларга җенси белем бирү мәсьәләләрендә һөнәри компетенцияләренең түбән дәрәҗәдә

булуга, профилактика эшен оештыруда заманча интерактив технологияләрдән файдалана белмәвенә бәйле.

Балалар сәламәтлеге өлкәсендә социаль әһәмияткә ия тагын бер кискен проблема – ***балалар наркоманиясе һәм алкогольгә бәйлелек.***

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 11 февралендәге 90 номерлы карары белән расланган 2013 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең республика стратегиясендә (алга таба – Балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең республика стратегиясе) балаларга хезмәт күрсәтүче наркология хезмәтләрен үстерү сәламәтлек саклау өлкәсендәге төп бурычларның берсе буларак карала.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, нарколог ярдәменә мохтаҗ балалар саны 2017 елда 78 кешегә кимеде һәм 359 кеше тәшкил итә. Шул ук вакытта наркология ярдәме таләп ителә торган балаларның 69 %ы гына мондый ярдәм белән тәэмин ителә. Шуңа карамастан, мондый ярдәмне күрсәтә алырлык медицина оешмалары саны һәм балалар наркологлары кими бара.

20 нче таблица

2013 – 2017 елларда балигъ булмаганнарга наркология ярдәме күрсәтүнең торышы

Күрсәткеч	2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел	2017 ел
Нарколог ярдәменә мохтаҗ балалар саны	449	491	518	437	359
Наркология хезмәте белән тәэмин ителгән балалар саны	269	309	336	301	247
Балигъ булмаганнарга наркология ярдәме күрсәтү оештырылган медицина оешмалары саны, шул исәптән:	37	38	37	34	32
амбулатор	37	38	37	34	32
стационар	2	2	2	2	2
Балалар наркологлары (кеше/% тәэмин ителеш)	28/62%	26/57%	23/51%	21/46%	21/46%

Югарыда китерелгән белешмәләр бүгенге көндә Татарстан Республикасында балаларга нарколог хезмәте күрсәтүнең торышын тиешенчә дип бәяләргә мөмкинлек бирми, шуңа бәйле рәвештә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк дип саный:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты алкоголь һәм наркотик бәйлелектән интегүче балигъ булмаганнар өчен социаль-реабилитация үзәге булдыру мәсьәләсен карарга тиеш;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

Балаларга наркология ярдәме күрсәтү системасын үстерү мәсьәләсен карарга тиеш;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр белән бергәләп балигъ булмаганнарның наркотик чараларны һәм (яисә) психотроп матдәләрне медицинадан тыш куллану предметына профилактик медицина тикшерүләре буенча эшне активлаштырырга тиеш;

Министерству образования и науки Республики Татарстан:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:


җирле үзидарә органнары белән берлектә мәгариф учреждениеләрендә, шулай ук һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларга наркотик чараларны һәм (яисә) психотроп матдәләрне, башка агулы матдәләрне медицинадан тыш куллану предметына психологик тестлар үткәрүнең нәтиҗәлелеген арттыру чаралары күрергә тиеш.

Балалар сәламәтлеге торышын билгели торган критерийларның берсе – ***балаларның инвалидлык дәрәҗәсе.***

Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе белешмәләренә караганда, 2018 елның 1 гыйнварына республикада 14 768 инвалид бала яши, бу барлык балаларның 1,8 %ы. 2016 ел белән чагыштырганда, бу саннар үзгәрмәгәндиярлек.

71 нче диаграмма

2012 – 2017 елларда Татарстан Республикасында инвалид балаларның гомуми саны




Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча медик-социаль экспертиза баш бюросы» ФКУ (алга таба – Баш бюро) белешмәләре буенча, 2017 елда инвалидлык алу өчен 6 912 бала мөрәҗәгать иткән, бу, 2016 ел белән чагыштырганда, 4,3 %ка кимрәк (2016 елда – 7 220 бала). Шуларның 6 339ы яисә 92 %ы инвалидлык алды (2013 елда – 7 919 бала, яисә 95 %, 2014 елда – 7 418 бала яисә 91 %, 2015 елда – 6 623 бала яисә 85 %, 2016 елда – 86%).

2017 елда инвалидлыкка тикшеренү узган балалар 573 очракта инвалид дип танылмады (2013 елда – 5%, 2014 елда – 9%, 2015 елда – 15%, 2016 елда – 14%).

Шул исәптән 2017 елда 573 очракта, тикшеренү нәтиҗәсендә инвалидлык статусын бирү кире кагылды 2013 елда – 5%, 2014 елда – 9%, 2015 елда – 15%, 2016 елда – 14%).

72 нче диаграмма

2013 – 2017 елларда балаларга инвалидлык бирелү (бирелмәү) турында белешмәләр




«Инвалид бала» категориясе беренче мәртәбә тикшерү узган балага инвалидлык билгеләү 573 очракның 338ендә кире кагылган, 235 очракта – кабат мөрәҗәгать иткәндә кире кагыла.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, кабат тикшерү узган барлык 235 очракта да кире кагу тулысынча реабилитациялү белән аңлатыла (2013 елда – 290, 2014 елда – 398, 2015 елда – 770, 2016 елда – 540). 2017 елда мондый кире кагулар өлеше 41% тәшкил итә.

73 нче диаграмма

2013–2017 елларда балалар инвалидлыгын билгеләүне кире кагу турында белешмәләр




Баланы инвалид дип танудан баш тарту турында чыгарылган 573 карарның 216сына югарырак инстанцияләргә – Баш бюрога яисә «Федераль медик-социаль экспертиза бюросы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенә (2013 елда – 76, 2014 елда – 149, 2015 елда – 293, 2016 – 264) шикаять белдерелде, бу гомуми каршы килүләрнең 37,7 %ын тәшкил итә. 199 очракта карар үзгәртелмәде (2013 елда – 66, 2014 елда – 143, 2015 елда – 285, 2016 елда – 264).

Инвалид дип танылган балаларның гомуми саныннан 1 642 балага (26%) «инвалид бала» категориясе беренче мәртәбә бирелгән, 4 697 балага (74%) – кабат тикшерү узганнан соң. Беренче мәртәбә тикшерү узганнан соң инвалид дип танылган балалар саны 2016 ел белән чагыштырганда 4,8%ка артты.

74 нче диаграмма

2013–2017 елларда балалар инвалидлыгы күрсәткечләре



Балалар беренче мәртәбә инвалидлык билгеләнү дәрәҗәсе 2017 елда 0,5%ка артты һәм ул 10 000 балага 20,2 бала булды (2013 елда – 26,6; 2014 елда – 26,1; 2015елда – 22,6, 2016 елда – 19,7). Кабат инвалидлык билгеләү дәрәҗәсе кимегән һәм ул 10 000 балага 57,7 бала тәшкил итә (2013 елда – 92,5; 2014 елда–71,6; 2015 елда – 62,6, 2016 елда – 58,9).

Югарыда китерелгән 2015-2017 елларга анализдан күренгәнчә, 2017 елда кимү түбәндәгечә булган:

тикшеренүгә җибәрелгән балалар саны (4,3%ка);
инвалидлык бирү кире кагылуга шикаятьләр санык (23,4%ка);
инвалидлык бирү кире кагылган балалар саны (40,6%ка).
Шул вакытта арткан:
инвалид дип танылган балалар саны (1,3%ка);
инвалидлыкны беренче тапкыр алган балалар саны (4,8%ка);
инвалидлыгы кабат расланган балалар саны (0,17%ка).


Шуны билгеләп үтәргә кирәк, 2017 елда баланың инвалидлыгын танудан баш тартулар турында Медик-социаль экспертиза бюросы органнары карарларына шикаятьләр саны 5кә кимеде. Барлык очраклар буенча, Медик-социаль экспертизасының баш бюросы һәм Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил арасындагы килешүгә таянып, Медик-социаль экспертизасының баш бюросы җитәкчесе Р.Х.Низамов адресына кабул ителгән карарларны яңадан карау һәм мөрәҗәгать итүчеләргә аңлатмалар бирү үтенече белән мөрәҗәгать җибәрелде.

Беренче мәртәбә инвалидлык бирү вәзгыяте аерым бәяләүне таләп итә.

Республика муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча беренче тапкыр инвалид дип танылган балалар саны 65нче диаграммада күрсәтелде.

75 нче диаграмма

2017 елда республика муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча балаларның беренче тапкыр инвалид дип танылу дәрәҗәсе (10000 балага)



Бу күрсәткеч Спас (20,3), Яңа Чишмә (20,7), Кукмара (20,8), Мамадыш, Баулы, Әлки муниципаль районнарында (21,0), Казан шәһәрендә (21,3), Арча (21,8), Чистай (22,0), Буа (22,1), Нурлат (23,4), Биектау (24,4), Саба (24,8), Аксубай, Лаеш (26,3), Балык Бистәсе (26,4), Әгерҗе, Сарман (27,2), Менделеевск (27,5) муниципаль районнарында республика буенча уртача күрсәткечтән югарырак.

Минзәлә һәм Балтач районнарында беренче мәртәбә инваликлык алучы балалар саны арткан. 2016 елда Балтач районында бу күрсәткеч республика буенча иң түбән күрсәткеч иде (11,8), 2017 елда бу күрсәткеч 30,5б булды. Минзәлә районында бу күрсәткеч 14,9дан 30,0га җитте.

Кайбыч районында бу күрсәткеч ел буена арткан, 2016 елда – 26,9 һәм 2017 елда – 52,0, республика буенча уртача күрсәткечтән 2,6 мәртәбә артык.


Беренче мәртәбә инвалидлык алучы балалар саны Кама Тамагында да сөенерлек түгел (2016 елда – 31,2, 2017 елда – 31,2) һәм Мөслим районында да шундый ук хәл (2016 елда – 32,8%, 2017 елда – 30,8) .

Югарыда китерелгән белешмәләр чыгып, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Медик-социаль экспертиза бюросы белән берлектә күрсәтелгән 2017 елда районнарда балалар инвалидлыгы буенча барлыкка килгән хәлне бетерү буенча чаралар комплексы эшләү һәм кабул итү максатларында балаларның инвалидлыгын, аңа китергән сәбәпләрне һәм шартларны җентекләп анализларга тиеш дип саныйбыз.

Беренче тапкыр инвалид булып танылган балалар яшь төркемнәре буенча түбәндәгечә бүленде.

76 нчы диаграмма

2013 – 2017 елларда балаларны беренчел тикшерү белешмәләре (яшь категорияләре буенча)




Югарыда китерелгән белешмәләр күрсәткәнчә, соңгы дүрт елда тикшерү нәтиҗәләре буенча инвалидлык беренче тапкыр билгеләнгән иң күп очрак 0дән 3 яшькә кадәр булган балалар арасына туры килә.

2017 елда балалар инвалидлыгының башлангыч сәбәбе булган авырулар структурасын анализлау 67 нче диаграммада күрсәтелә.

77 нче диаграмма

2017 елда балаларның беренчел инвалидлыгының авыру төрләре буенча структурасы (кеше)



2013 – 2017 елларда балалар арасында класслар буенча беренче инвалидлык түбәндәге таблицада күрсәтелә.

21 нче таблица

2013 – 2017 елларда балаларның беренчел инвалидлыгының авыру төрләре буенча структурасы (кеше)

Нозологик формалар	2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел	2017 ел
Психика какшау һәм үз-үзен таркау тоту	368	440	445	471	439
Нерв системасы авырулары	350	356	350	312	324
Тумыштан килгән аномалияләр (үсештәге кимчелекләр), деформацияләр һәм хромосомаларның бозылуы	464	475	335	198	276
Эндокрин система авырулары, туклану һәм матдәләр алмашы бозылу	138	163	149	167	146
Шешләр	74	93	84	83	94
Күз һәм күрү аппараты авырулары	111	81	82	71	71
Колак авырулары	57	55	65	69	65
Сөяк-мускул һәм тоташтыргыч тукымалар авырулары	90	107	72	53	82
Сидек юллары һәм җенес органнары авырулары	40	36	26	26	13
Җәрәхәтләр, агуланулар һәм башка тышкы сәбәпләр	53	31	19	25	20
Перинаталь чорда барлыкка килә торган авырулар	12	20	23	16	29
Кан ясау системасы авырулары	22	17	16	15	17
Ашкайнату органнары авырулары	23	19	18	12	18
Сулыш органнары авырулары	39	23	13	8	6
Туберкулез	1	1	1	2	0
Барлыгы	1 947	1 982	1 754	1 567	1 642

Соңгы өч елда балаларда беренче инвалидлык якынча өч сәбәп нигезендә бирелә: психика какшау һәм үз-үзен таркау тоту, нерв системасы авырулары, тумыштан килгән аномалияләр. Бу сәбәпләр беренчел инвалидлыкның 63%ын тәшкил итә.

2015 елдан башлап балаларның инвалидлык структурасында беренче урынны психик яктан какшау һәм үз-үзен таркау тоту алып тора. Башка еллардагы кебек үк, әлеге күрсәткеч буенча үсеш югары: гомуми структурада аның өлеше 26,7%. 2017 елда бу класс буенча 439 кеше инвалид булып таныла, яисә 2016 елга караганда 32 кешегә артыграк. Моннан тыш, югарыда әйтеп үтелгәнчә, психик яктан какшау һәм үз-үзен таркау тоту ел саен 3 меңгә якын балада ачыклана. Шуңа карамастан, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, республикада 2017 елда балалар психиатрлары белән тәэмин ителеш 21 белгечне тәшкил итә (2013 елда – 17 белгеч, 2014 елда – 17 белгеч, 2015 елда – 15 белгеч), балалар психотерапевтлары белән тәэмин ителеш – 2 белгечне тәшкил итте (2013 елда – 1 белгеч, 2014 елда – 2 белгеч, 2015 елда – 2 белгеч, 2016 елда – 19 белгеч). Әлеге вәзгыять, психика какшаудан интегүче балаларның

квалификацияле һәм һәркем файдалана алырлык психиатр ярдәме белән тәэмин ителеше күзлегеннән чыгып караганда, җентекләп анализ ясауны һәм кадрлар белән тәэмин итү буенча карарлар кабул итүне таләп итә.

Икенче урынны, гадәттәгечә, нерв системасы авырулары алып тора, бу юнәлештәге интенсивлык күрсәткече гомуми структурада 19,7%. тәшкил итә.

Әлеге классбуенча инвалид дип танылган балалар саны 2016 ел дәрәҗәсендә калды диярлек (2016 елда – 312 кеше, 2017 елда – 324 кеше).

Өченче урыннны тумыштан килгән аномалияләр (үсештәге кимчелекләр), деформацияләр һәм хромосомаларның бозылуы били. Гомуми структурада аларның өлеше 19,7% тәшкил итә. Шулай ук әлеге сәбәпләр аркасында беренче тапкыр инвалидлык алган очракларның шактый артуы игътибарны җәлеп итә: 2016 елда 198 очрак булса, 2017 елда – 276 очрак.

Шуның белән бергә, 2016 һәм 2017 елларны чагыштырсак, яман шеш буенча (83тән 94кә кадәр), сөяк-мускул системасы (53тән 82гә кадәр), перинаталь чордабарлыкка килгән (16дан 29га кадәр), ашкайнату органнары авырулары буенча (12дән 18 очракка кадәр) беренчел инвалидлык алучыларның саны арту да күзәтелә.

Бу чорда эндокрин система авырулары буенча инвалидлык бирү очраклары кимүен дә билгеләп китәргә кирәк (167дән 146га), сидек юллары, җенси органнар авырулары буенча инвалидлык бирү очраклары да кимеде (26дан 13кә кадәр).

Балаларның авыруларга бирешүчәнлегенә һәм балаларның инвалидлык алуларына бәйле вәзгыятьне истә тотып, Татарстан Республикасында нәтиҗәле һәм һәркемгә җитәрлек дәрәҗәдә эшли торган медицина тернәкләндерүе системасын булдыру аеруча әһәмиятле һәм мөһим булып тора. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, әлеге система бүген балаларны тернәкләндерү буенча ике дәүләт үзәгеннән гыйбарәт, аларның берсе – балалар поликлиникасы составында, икенчесе – төрле медицина учреждениеләре составындагы биш бүлектән торган медицина тернәкләндерү үзәге. Тернәкләндерү учреждениеләренең мондый челтәре, әлбәттә, бу хезмәткә булган ихтыяҗны канәгатьләндерә алмый, бу хакта без 2016 елгы докладта да күрсәткән идек.

Шулай итеп, республикада балалар авыруларын һәм инвалидлыгын анализлап, якын киләчәктә Татарстан Республикасы балалар сәламәтлеген саклау системасын үстерүнең төп бурычлары түбәндәгеләр булырга тиеш саныйбыз:

1. Балаларның тышкы сәбәпләр аркасында килеп чыга торган авыруларын профилактикалау буенча нәтиҗәле чаралар эшләү һәм кабул итү;

2. Балаларны медицина тернәкләндерүе системасын үстерү;

3. Балаларга психиатрия ярдәме системасын үстерү;

4. Балаларга наркология ярдәме күрсәтү системасын үстерү;

5. Балалар инвалидлыгын профилактикалау буенча түбәндәге юллар белән чаралар күрү:

балаларны медицина тернәкләндерүе буенча нәтиҗәле һәм һәркем файдалана алырлык система булдыру;

балаларның беренче тапкыр инвалидлык алу күрсәткечләре зур булган республика муниципаль районнарында, балалар инвалидлыгының сәбәпләрен һәм моңа китерә торган шартларны анализлау;

6. Балигъ булмаганнарның йөклелеген профилактикалау буенча нәтиҗәле чаралар эшләү һәм кабул итү.

3.3.3. Балаларның сәламәтлеккә хокукларын тәэмин итүнең проблемалы аерым мәсьәләләре

Сәламәтлек саклау мәсьәләләре буенча гражданнардан кергән мөрәҗәгать барлык мөрәҗәгатьләр өлешендә бик аз (5,6%) булса да, аларны карау Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым контролендә тора.

Яңа туган балаларны нәсел авыруларына тикшерү

Җәмгыятьнең һәм бүгенге медицинаның актуаль проблемаларыннан берсе балаларда алдан патологияне ачыклау һәм аларның генетик авырулар белән тууын кисәтүдән гыйбарәт.

Неонаталь чорда генетик авыруларны диагностикалауның нәтиҗәле ысулларыннан берсе – дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау учреждениеләрендә яңа туган балаларны тикшерү (алга таба – неонаталь скрининг) уздыру. Мондый авыруларны соңга калып ачыклау хәтәр нәтиҗәләргә, инвалидлыкка һәм балалар үлеменә китерергә мөмкин.

Гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре буенча ел саен раслана торган программалар нигезендә (алга таба – Дәүләт гарантияләре программасы) неонаталь скрининг катгый диагностик чаралар исемлегенә кертелгән һәм ул биш иң куркыныч патологиягә тикшерелә (адреногенитальсиндром, галактоземия, тумыштан гипотиреоз, муковисцидоз, фенилкетонурия), алар бик иртә срокта барлыкка килә.

Татарстан Республикасында неонаталь скринингны гамәлгә ашыру 2011 елдан 2014 елга кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы арасында төзелгән килешүләр нигезендә финанслашу шартларында алып барылды. 2015 елдан Дәүләт гарантияләре программалары нигезендә бу чараларны тәэмин итү Россия Федерациясе субъектлары бюджеты акчалары исәбеннән башкарылырга тиеш.

2015 һәм 2016 елларда неонаталь скринингка 23,3 млн. сум бирелде, ел саен 56 меңгә якын яңа туган балага нәсел авыруларына тикшерү уздырылды.

«2017 елга һәм 2018, 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль фонды бюджеты турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 94-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында скринингларны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау каралмаган. Финанслау булмау аркасында 2017 елның 10 февраленнән республикада яңа туган балаларны неонаталь скрининг кысаларында тумыштан гипотиреозга һәм галактоземиягә тикшерү туктатылды, 2017 елның мартыннан – адреногенитальсиндромга һәм муковисцидозга, ә 2017 елның апреленнән – фенилкетонуриягә.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнардан мөрәҗәгатьләр керә башлады.

Мисал. *2017 елның 6 сентябрендә туган бала П.да, туганнан соң, дүртенче көндә – 2017 елның 10 сентябрендә неонаталь скринингка кан алына һәм «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының РКБ» ДАСУга (ГАУЗ) медико-генетика тикшерүенә җибәрелә. Әмма реактивлар булмау сәбәпле тикшерүләр уздырылмый.*

2017 елның 06 декабрендә бала»Ашыгыч медицина ярдәме» бригадасы белән «Кама балалар медицина үзәге» ГАУЗга педиатрия бүлегенә китерелә, биредә «муковисцидоз» диагнозы шик астына кула. Уздырылган терапия нигезенедә баланың торышы яхшыра, әмма алга таба тикшерү уздыру өчен Балалар республика клиник хастаханәсенә китерелә, анда 2017 елның 3–декабернә кадәр була.

Реактивлар барлыкка килгәннән соң бала канын тикшергәч, иммунореактив трипсинның чикдәрәҗәсе югарыбулуы ачыклана. Бала ата-анасы белән «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының РКБ» ДАСУга (ГАУЗ) молекуляр-генетик тикшерү уздыру өчен чакыртыла.

Моңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тиешле гарызнамә белән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына мөрәҗәгать итте. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 27 июлендәге 1788-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә неонаталь скрининг уздыру өчен материаллар сатып алуга 9,6 млн. сум акча бүлеп бирелде. Бүленгән акчалар исәбеннән 2017 елның октябреннән «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының РКБ» ДАСУга (ГАУЗ) медико-генетика консультациясендә неонаталь скрининг буенча тиешерүләр яңартылды, ә 2017 елның гыйнвар-сентябрь айларында алынган кан үрнәкләре буенча барлык анализлар да тикшерелде.

22 нче таблица

2013–2017 елларда яңа туган балаларга нәсел авыруларына* тикшерү уздыру *(неонаталь скрининг) күрсәткечләре

Күрсәткечләр	2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел	2017 ел *
Неонаталь скрининг уздыруга бүлеп бирелгән бюджет акчаларының гомуми сумммасы *(млн.сум)*	19,487	20,412	18,3	5,0	9,6
Яңа туган балаларга адреногенитальсиндромга, галактоземиягә, тумыштан гипотиреозга, муковисцидозга, фенилкетонуриягә уздырылган тикшерүләрнең гомуми саны	55 600	55 840	56 160	55770	30880 14400 30960 17040 48720
Шулардан ачыкланган патология очраклары, барлыгы *(кеше)*	30	33	27	43	19
шул исәптән: адреногенитальный синдром	4	2	1	11	1
галактоземия	0	2	1	0	0
тумыштан гипотиреоз	14	21	18	21	15
муковисцидоз	4	3	4	6	1
фенилкетонурия	8	5	3	6	2

** 2017 елдан яңа туган балаларга адреногенитальсиндромга, галактоземиягә, тумыштан гипотиреозга, муковисцидозга, фенилкетонуриягә тикшерү уздыруның исәпкә алып бару аерымалыпбарыла.*

Югарыда күрсәтелгән биш авыру буенча ачыкланган балалар диспансер исәбенәдә торалар, тиешле терапияне алалар.

Неонаталь скрининг һәм пренаталь (бала туганчы) диагностика уздыру өчен 2018 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 15 декабрендәге күрсәтмәсе нигезендә (17.01.2018 күрсәтмәсе үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы бюджетыннан материаллар сатып алуга «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының РКБ» дәүләт автономсәламәтлек саклау учреждениесенә 26,2 млн.сум акча бирелде.

Балаларны дарулар белән тәэмин итү проблемалары

2017 елда да инвалид балаларны дарулар белән тәэмин итү проблемалы тема булып калды.

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә г***омер озынлыгына тәэсир итә торган яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авырулардан*** – муковисцидоздан ***интегүче балаларның ата-аналары балаларына*** тобрамицин (брамитоб) препаратын сорап мөрәҗәгать итте.

«Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге Федераль закон нигезендә (алга таба – № 323-ФЗ Федераль закон) Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына даруларга мохтаҗ гражданнарны алар белән тәэмин итүгә бәйле оештыру-идарә вәкаләтләре дә, бюджеттан финанслау буенча финанс йөкләмәләре дә йөкләнгән.

№ 323-ФЗ Федераль законның 83 статьясындагы 9.2 өлеше һәм 44 статьясының 7 өлеше нигезендә муковосцимдоз белән авыручыларны дарулар белән тәэмин итү федераль бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 23 октябрендәге № 2323-р күрсәтмәсе (элек 26.12.2015г. № 2724-р күрсәтмәсе) белән расланган исемлек буенча (№3 кушымта) гамәлгә ашырыла. Табиблар билгеләгән тобрамицин (брамитоб) препараты бу исемлеккә кермәгән.

Муковисцидоз белән авыручы балалар бер үк вакытта инвалид балалар буларак федераль ташламаларга да ия. «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – закон 178-ФЗ Федераль закон) 6.1 статьясындагы 9 пункты нигезендә инвалид балалар социаль хезмәт күрсәтүләр җыелмасы рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен алырга хокуклы. № 323-ФЗ номерлы Федераль законның 6.2 статьясы нигезендә социаль хезмәт күрсәтүләр җыелмасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 23 октябрендәге №2323-р номерлы күрсәтмәсенең 2 нче кушымтасы нигезендә расланган дару препаратлары исемлегенә кертелгән. 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әлеге преапаратлар белән тәэмин итү аерым дәүләт вәкаләтләре бирелгән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт органнары тарафыннан башкарыла. Әмма табиблар билгеләгән тобрамицин (брамитоб) препараты әлегә кадәр бу исемлеккә кертелмәгән.

Шул ук вакытта 323-ФЗ номерлы Федераль законның 81 статьясы нигезендә Дәүләт гарантияләре программасының V бүлеге гражданнарга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 декабрендәге 1403 номерлы карары белән расланган 2017 елга һәм 2018, 2019 еллар план чорына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү гарантияләре программасында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 29 декабрендәге 1044 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә 2017 елга һәм 2018, 2019 еллар план чорына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү гарантияләре программасында (территориаль программа) Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет ассигнованияләре исәбеннән Исемлек нигезендә халыкның аерым категорияләрен «Медицина сәнәгатен үстерүгә дәүләт ярдәме һәм халыкны, сәламәтлек саклау учреждениеләрен дару препаратлары һәм медицина әйберләре белән тәэмин итүне яхшырту турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1994 елның 30 июлендәге 890 номерлы карары белән расланган дару препаратлары белән амбулатор дәваланганда алар белән түләүсез тәэмин итү каралган булырга тиеш. Исемлеккә инвалид балалар да кертелгән. Әмма муковисцидоз белән авыручыларны югарыда күрсәтелгән препарат белән тәэмин итү шулай ук республика бюджетына кертелмәгән.

Мондый вәзгыять инвалид балаларның дару препаратлары белән тәэмин ителү хокукын боза.

2017 елда Татарстан Республикасында гомер озынлыгына тәэсир итә торган яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авырулардан интегүче балаларны дарулар белән тәэмин итү бурычын тиешенчә үтәү проблемасы да Татарстан Республикасында актуаль булып калды.

«Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль закон нигезендә (алга таба – Закон) Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына даруларга мохтаҗ гражданнарны алар белән тәэмин итүгә бәйле оештыру-идарә вәкаләтләре дә, бюджеттан финанслау буенча финанс йөкләмәләре дә йөкләнгән.

2017 ел азагына гомергә куркыныч яный торган һәм хроник көчәя баручы, гомер озынлыгын кыскартуга яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авырулардан интегүче затларның федераль регистрының региональ исемлегендә 271 бала теркәлгән.

22-1 таблица

2013 – 2017 елларда Гомергә куркыныч яный торган һәм хроник көчәя баручы, гомер озынлыгын кыскартуга яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авырулардан интегүче затларның федераль регистрының региональ исемлегендә теркәлгән балалар саны

Т/с №	**Гомергә куркыныч яный торган һәм хроник көчәя баручы, гомер озынлыгын кыскартуга яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авырулар исеме**	**Балалар саны, кеше**				
		2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел	2017 ел
1	Гемолитик-уремик синдром	26	29	30	32	40
2	Пароксизмаль төнге гемоглобинурия	1	1	1	0	0
3	Ачыкланмаган апластик анемия	7	5	6	8	9
4	II (фибриноген), VII (лабиль), X (Стюарт – Прауэр) факторларның нәселдән килгән кытлыгы	2	2	5	7	6
5	Идиопатик тромбоцитопеник пурпура (Эванс синдромы)	44	43	41	43	47
6	Иртә җенси өлгерү	42	41	40	36	25
7	Аромат аминокислоталар алмашы бозылу (классик фенилкетонурия, гиперфенилаланинемиянең башка төрләре)	93	90	91	92	90
8	Тирозин алмашы бозылу	2	2	2	3	2
9	Май кислоталары алмашы бозылу	0	1	1	2	2
10	Галактоземия	8	9	10	10	10
11	Мукополисахаридоз, I төр	2	3	3	2	4
12	Мукополисахаридоз, II төр	2	2	3	4	0
13	Бакыр алмашы бозылу (Вильсон авыруы))	4	3	2	3	2
14	Төгәлләнмәгән остеогенез	14	14	15	14	12
15	Үпкә (артериаль) гипертензия (идиопатик) (беренчел)	2	4	4	2	4
16	Системалы башлана торган яшүсмерләр артриты	16	16	16	14	16
	БАРЛЫГЫ	**265**	**265**	**270**	**272**	**271**

Бу балаларның бары тик 128е генә бюджет акчалары исәбеннән дарулар белән, 92есе бюджет акчалары исәбеннән махсус туклану белән тәэмин ителде.

Россия Федерациясе субъектларының мондый чыгым вәкаләтен үтәүдәге төп проблемасы сирәк очрый торган (орфан) авыруларны дәвалау өчен кирәкле даруларның кыйммәт булуында. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, гомергә куркыныч яный торган авырулардан интегүче балаларны дарулар һәм махсус дәвалау продуктлары белән тәэмин итү өчен 2017 елда ихтыяҗ 254,23 млн.сум иде. Ләкин хисап чорында бары тик 119,48 млн. сум (47%) бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирелде. Мондый финанслауның әлеге йөкләмәләрне тулысынча үтәргә мөмкинлек бирмәве көн кебек ачык.

2017 елда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгын гомер озынлыгына тәэсир итә торган яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авырулардан интегүче балаларны дарулар белән тәэмин итү бурычын һәм суд карарларын тиешенчә үтәргә мәҗбүр итү буенча үткәрелгән судлар фонында әлеге проблема тагын да кискенрәк төс ала.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, сирәк (орфан) авырулардан интегүче балаларны дарулар белән тәэмин итү йөкләмәләрен тиешенчә үтәлми.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы бюджет йөкләмәләренең сирәк (орфан) авырулардан интегүче балаларны дарулар белән тәэмин итүне финанслау өлешен арттырырга кирәк дигән мәсьәләне хәл итәргә кирәк.

Шул ук вакытта, барыбыз өчен дә уртак булган төбәкләр проблемасын хәл итү юлларын эзләү өчен федераль үзәк белән эшләүне дәвам итәргә кирәк. Аерым алганда, э гомер озынлыгын кыскартуга яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авырулардан интегүче балаларны федераль бюджет ассигнованияләреннән балаларны Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы Указы беән расланган 2012-2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендәге гамәлләрнең илкүләм стратегиясе нигезләмәләре гигезендә адреслы финанслауны оештыру турында тәкъдим кертелә.

Балаларга профилактик вакцина ясау һәм туберкулез диагностикасы

Иммунопрофилактикалау өлкәсендә дәүләт сәясәте йогышлы авыруларны кисәтү, таралуын кисәтү һәм бетерүгә юнәлдерелә. Профилактик прививка – йогышлы авыруларга каршы тору өчен кеше организмына медицина иммунодару препаратлары кертү ул. Россия Федерациясендә йогышлы авыруларны иммунопрофилактикалау «Йогышлы авыруларны иммунопрофилактикалау турында» Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла. Әлеге Законның 5 статьясы нигезендә халык профилактик прививкалардан баш тартырга хокуклы, бу очракта ул аны язмача расларга тиеш. Прививкадан баш тарту кешенең үз гомеренә дә, шулай ук тирә-юньдәгеләргә дә зарар китерергә мөмкин.

Татарстан Республикасында 2017 елда балаларга профилактик вакцина ясауның торышын анализлау күрсәткәнчә, ата-аналарның барлык төр авырулар буенча да, бума ютәлдән һәм туберкулездан тыш, балаларына профилактик вакцина ясатудан баш тарту очраклары 2016 елдагы белән чагышытырганда 3 621 очракка (8,3%) кимегән. 2016 елда 43 822 очрак булган, 2017 елда – 40136.

23 нче таблица

2013 – 2017 елларда балаларга профилактик вакцина ясаудан һәм туберкулез диагностикасыннан баш тарту статистикасы

Профилактик вакцина ясау һәм туберкулез диагностикасы		**Баш тартулар саны**					
		2013 ел	**2014 ел**	**2015 ел**	**2016 ел**	**2017 ел**	**% к 2016 г.**
Профилактик вакцина ясау, шул исәптән:	дифтерия	3380	4170	4200	5700	5697	-0,05%
	бума ютәл	2118	2447	2443	2940	3766	+28,1%
	полиомиелит	2837	3758	3546	5437	5144	-5,40%
	кызамык	3393	4159	4100	6219	5287	-15,0%
	эпидемиологик паротит	3381	4169	4100	6176	5338	-13,5%
	кызылча	3451	4242	4210	6308	5333	-15,4%
	В гепатиты вирусы	3898	4918	4554	6678	5580	-16,4%
	туберкулез	472	626	722	678	805	+18,7%
Туберкулин диагностикасы		4200	5032	4421	3686	3251	-11,8%
Барлыгы		**27 130**	**33 521**	**32 296**	**43 822**	**40 201**	**-8,30%**

Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсе белешмәләре буенча, 2017 елда профилактик прививкалардан 15 436 кеше (25%) баш тарткан, шул исәптән полиомиелиттан – 1957 баш тарту очрагы, ягъни теркәлгән баш тартулардан 26%, бума ютәлдән – 1471, ягъни 26%, кызамыктан – 3428, ягъни 26%, эпидемик паротиттан – 1753, ягъни 24%, В гепатитыннан – 2537, ягъни 24%, пневмокок белән йогышланудан – 4290, ягъни 24%. Аксубай, Тәтеш, Минзәлә, Балтач, Питрәч, Сарман муниципаль районнарында профилактик прививкалардан баш тартуны карау дәрәҗәсе нең түбән булуы күзәтелә.

Профилактик вакцина ясауга каршы чыгу йогышлы авырулар артуның төп сәбәпләреннән берсе. 2017 елда Татарстан Республикасында 63 очрак бума ютәл белән авыру теркәлгән, моның 57се (91%) прививка ясалмаган очрак. Вакцинация экстрен тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбенә ясалган.


Бүгенге көндә туберкулез авыруы социаль куркыныч авыруларның берсе аны профилактикалау авыруны кисәтүдә зур әһәмияткә ия. Туберкулездан профилатикалауга каршы чыгу да борчу уята. Туберкулез йоктыру куркынычын бәяләп бетермәү көтелмәгән нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Туберкулин диагностикасы ясалмаган бала чирнең башлангыч стадияләрдә табылуына һәм үз вакытында күрсәтелгән медицина ярдәменә өметләнә алмый, димәк, башка балалар өчен авыру йоктыру куркынычы туа. 2017 елда 805 кеше моннан баш тарткан, бу узган 2016 ел белән чагыштырганда 127 кешегә артык, ягъни 19%.

2017 елда 2016 елның шушы чоры белән чагыштырганда иммунодиагностикадан баш тартучылар арасыннан альтернатив ысуллар белән туберкулезга тикшерелгән балалар саны 20,3%ка артты (2016 елда – 33,7%, 2017 елда – 54,0%) һәм тикшерелмәгәннәр саны 11,8%ка кимеде (2016 елда – 3 686, 2017 елда – 3 251). тикшерелмәгән балалар арасыннан күбрәге (2 211 бала, ягъни 68%) мәктәп яшендәге тиешенчә тәрбияләнми торган балалар.

Узган ел биш елга беренче мәртәбә балаларда беренчел туберкулез авыруы ачыкланган очраклар (туберкулезның актив рәвешләре) шактый ким булды. 2017 елда Татарстан Республикасында 1300 очрак теркәлде (100 000 кешегә 33,5), шул исәптән 17 яшькә кадәрге балаларда – 41кеше (100 000 кешегә 5,15), 2016 елга караганда 38,8%ка кимрәк.

78 нче диаграмма

2013 – 2017 елларда балалар арасында туберкулез авыруы беренче тапкыр табылган очраклар (кеше)



Балаларның законлы вәкилләренең профилактик вакцина ясаудан һәм туберкулин диагностикасыннан баш тартуының сәбәбе булып, кагыйдә буларак, баланың әлеге гамәлләрдән соң өзлегеп китүеннән курку тора. Ләкин, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, балаларда профилактик вакциналардан соң өзлегүләр бик сирәк очрый.

2017 елда яшүсмерләрне – урта һөнәри белем бирү оешмалары студентларына медицина тикшерүе уздыру җитди проблема булып саналды. Аларның 90%ында медицина тикшерүе уздыру оештырылмаган, нәтиҗәдә укучылар уку урынында да, яшәү урынында да тиешле беренче медико-санитар ярдәмне ала алмыйлар (шул исәптән профилактик прививкаларны да).

Мисал. *Казан шәһәренең бер техникумында 17 яшьлек укучыда туберкулез авыруы табыла. Соңгы ике елда аңа муниципаль районда яшәү урынында да, уку урынында да манту ясалмаган. Шул хәл балада туберкулез авыруын вакытында ачыклауны тоткарлый, нәтиҗәдә аңарда бу авыру көчәя.*

Баш тартулар проблемасы балаларның сәламәтлек саклауга һәм белем алуга хокукларын тәэмин итү ягыннан җитди әһәмияткә ия. Ата-аналарның профилактик вакцина ясаудан һәм туберкулин диагностикасыннан баш тартуы баланың белем алу хокукын гамәлгә ашыруга турыдан-туры йогынты ясый, чөнки бу гамәл аркасында бала мәгариф учреждениеләренә кертелмәскә мөмкин. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бу хактагы дәлилләнгән хокукый позициясе 2015 һәм2016 еллар йомгаклары буенча ясалган докладта бәян ителгән иде, алар бүген дә үзгәрешсез кала: профилактик вакцина ясау һәм туберкулин диагностикасы, беренче чиратта, баланың сәламәтлеген саклауга хокукын тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Балаларга профилактик вакцина ясаудан һәм туберкулин диагностикасыннан баш тартулар вәзгыятен анализлау нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына профилактик вакцина ясауның һәм туберкулин диагностикасы үткәрүнең максатка ярашлы һәм зарури булуы турында балаларның законлы вәкилләре белән агарту, аңлату һәм профилактик эш алып баруны дәвам итәргә тәкъдим итә.

Республика балаларына паллиатив ярдәм оештыру

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил республикада балаларга паллиатив ярдәм системасын өйрәнде.

Кызганычка каршы, дәвалау чаралары табылмаган авырулар бөтен илдә бар, бу онкология авырулары гына түгел. Дөньяда үсештән туктаган балалар да бар. Мондый балаларга дөньякүләм медицина паллиатив медицина ярдәмен тәкъдим итә.


«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законда дәвалап булмый торган авырулар белән интегүчеләрнең хәлен җиңеләйтү өчен комплексы паллиатив медицина ярдәме билгеләнә.

Кагыйдә буларак, мондый пациентлар дәвалап булмый торган хроник авырулар белән авырыйлар, алар диагностикалау курсын да узганнар, шулай ук стационарда да дәвалганнар, интенсив-консерватив һәм оператив дәвалау да узганнар. Мондый кешеләр алга таба хастаханәгә салуга да мохтаҗ түгелләр. Әмма мондый балаларны дәвалап булмый һәм аларга даими рәвештә симптоматик терапия, психосоциаль ярдәм, аларны озак вакыт карау таләп ителә. Менә шуның өчен паллиатив хезмәт органы кирәк.

Татарстан Республикасында медицина оешмалары хисаплары буенча 515 шундый ярдәмгә мохтаҗ бала яши. Паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ пациентларны нозологик формалар буенча бүлүгә анализ астагы диаграммада күрсәтелде.

79 нчы диаграмма

2017 елда Татарстан Республикасында балаларга паллиатив медицина ярдәме күрсәтү ихтыяҗы



Шулар арасында:

1) **355** бала – нерв системасы белән авыручылар, шул исәптән:

305 бала – ДЦП диагнозы белән, гомуми саннан 59,2% ,

38 бала (7,3 %) – эчке окклюзион гидроцефалия белән,

12 бала (2,3%) – В.Гоффман амиотрофиясе белән;

2) **98** бала (19%) – үсештә тумыштан аномалияләр, деформацияләр һәм хромосом авырулар булган;

3) **26** бала (5%) – яман шеш авырулары белән;

4) **12шәр** бала (2,3%) – эндокрин системасы һәм кан әйләнеше авырулары белән;

5) **6** бала (1,2%) – сулыш алу органнары авырулары;

6) **4** бала (0,8%) – җәрәхәтләр һәм агуланулар, тышкы сәбәпләр нәтиҗәсендә башка авырулар;

7) **3** бала (0,7%) – иммунодефицит авырулары.

Федераль законнар нигезендә паллиатив медицина ярдәме:

«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 80 статьясы нигезендә медицина оешмаларында гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтелү;

Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән гражданнарга бушлай паллиатив медицина ярдәмен финанслауны тәэмин итү (Федераль законның 83 статьясы);

паллиатив медицина ярдәме амбулатор шартларда патронаж хезмәт тарафыннан күрсәтелергә мөмкин һәм балаларга паллиатив медицина ярдәме күрсәтелә торган бүлекчәләрдә (койкаларда) стационар рәвештә күрсәтелергә мөмкин.

2012-2017 елларга Балалар мәнфәгатьләрендә илкүләм гамәлләр стратегиясендә дәвалап булмый торган авырулардан интегүче балаларга паллиатив медицина ярдәме күрсәтүче учреждениеләр (бүлекчәләр), хезмәтләр челтәрен булдыру бурычы каралган.

Республикада балаларга паллиатив ярдәм челтәрен булдыру 2010 елда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Анжела Вавилова фонды арасында дәүләт-хосусый партнерлык турында килешү төзелгәннән соң башланды. Шул килешү нигезендә Татарстан Республикасында беренче балалар хосписы төзелде.

Соңгы биш елда Татарстан Республикасы балаларына паллиатив ярдәм итү программачыл документ –«Балаларга балаларга паллиатив ярдәм» ярдәмче программасы һәм «2020 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы кысаларында алып барыла. Программа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан 2013 елның 1 июлендә 461 номеры белән кабул ителгән иде.

Республикада балаларга паллиатив ярдәм өч дәрәҗәле системадан тора. Әлеге модель беренчел, районара һәм республика дәрәҗәсендә ярдәм итүне күздә тота:

беренче дәрәҗә – үзәк район хастаханәләрендә, шәһәр поликлиникаларында, шәһәр, район һәм участок хастаханәләрендә, ашыгыч медицина ярдәме станцияләрендә беренчел ярдәм күрсәтү ул; беренче дәрәҗәдә медицина ярдәме күрсәтү вариантларының берсе – өйдә стационар технологиядән, телемедицина мониторингыннан файдаланып, паллиатив паллиатив бригаданың урыннарга чыгып эшләве;

икенче дәрәҗәдә – балаларга паллиатив ярдәм үз структурасында махсуслаштырылган муниципальара бүлекчәләр һәм (яисә) үзәкләр булган медицина оешмаларында, шулай ук күппрофильле (югары профильлеләрдән тыш) хастаханәләрдә һәм диспансер хастаханәләрендә күрсәтелә;

өченчн дәооәҗәдә – балаларга паллиатив ярдәм «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» ДАССУның (ГАУЗ) махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтелә торганнарында, күрсәтелә. ДРКБ – бөтен эшне җайга сала, берләштерә.

4 нче схема

Модель паллиативной медицинской помощи детям в Республике Татарстан



Балаларга паллиатив медицина ярдәме амбулатор һәм стационар базада күрсәтелә:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» ДАССУ (ГАУЗ) (9 койка);

«Республика махсуслаштырылган балалар йорты» ДАССУ (ГАУЗ) (10 койка);

«Балалар хосписы» коммерциягә карамаган хосусый медицина учреждениесе (17 койка һәм күчмә бригада);

ГАУЗ «Кама балалар медицина үзәге» ДАССУ (ГАУЗ) (күчмә бригада).

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында балаларга паллиатив (хоспис) ярдәм күрсәтү өчен 36 койка урнаштырылган. Койкалар белән тәэмин ителеш 100 мең балага 4,5 бала тәшкилитә (республика программасы нормативы буенча – 2,43).

Бүгенге көндә хастаханәләрнең реанимация һәм соматика бүлекчәләренең балаларга дәвамлы паллиатив ярдәм күрсәтү мөмкинлекләре җитәрлек түгел. Моннан тыш,гамәлдәге норматив актлар һәм бүлекчәләрнең эш шартлары пациентларның үзләренең якын кешеләре белән очрашуларын чикләргә мәҗбүр итә.

Шуңа бәйле рәвештә, өйдә балаларга паллиатив ярдәм күрсәтү (Homecare) эшчәнлеген гаилә әгъзаларыныңактив катнашында оештыру өстенлекле юнәлеш ала. Әмма пациентлар өйдә булганда аларга махсус шартлар булдыру һәм авыручының хәлен даими контрольдә тоту таләп ителә, моның белән амбулатор-поликлиника хезмәтенең беренчел звено педиатрларының эше арта.

Мисал өчен, Татарстан Республикасында дәвамлы респиратор ярдәменә мохтаҗ 22 бала яши. Бу балаларның диагнозы – СМА (спиналь мускул атрофиясе). Үпкәләргә ясалма вентиляция кирәк булганга, андый балалар гел хастаханәдә булырга тиеш. «ИВЛ на дому» проектын гамәлгә ашыру өчен 2017 елда кирәкле финанс чаралары (ИВЛ аппараты, трахеостомия өчен Амбуснабором инструментлар капчыгы һәм маскалар, электроотсос, кислород концентраторы, пульсоксиметр, энтеромат, шулай ук респиратор ярдәме өчен материаллар һәм энтераль туклану әйберләре) җитәрлек. Бу барлык җайланмаларны СМА белән авыручы балаларның гаиләләренә тапшыру планлаштырыла. Һичшиксез,

проектны гамәлгә ашыру өйдә балаларга поликлиника белгечләре тарафыннан ярдәм күрсәтергә дә мөмкинлек бирәчәк.

Татарстан Республикасында Мәскәүдә, Санкт-Петербургта эшли торган системалар белән балаларга паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештыру тәжрибәсе бүген илдә алдынгыларның берсе.

Мәгариф оешмаларында укучыларның сәламәтлеген саклауны һәм ныгытуны тәэмин итү

Белем бирү учреждениеләрендә балаларның сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга хокуклары үтәлеше Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең һәрвакыт игътибар үзәгендә тора.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда беркетелгән төп академик хокукларның берсе – укучыларның гомерне һәм сәламәтлекнең саклауга хокукы. Мәгариф оешмасы, үз чиратында баланың сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен кирәкле бөтен шартларны тудырырга тиеш. Белем бирү оешмасының балаларның сәламәтлеген саклау компетенциясенә түбәндәгеләр керә (28 статья):

сәламәтлек саклау өлкәсендәге законнарда билгеләнгән тәртиптә беренче медицина-санитария ярдәме күрсәтү;

медицина тикшерүләре һәм диспансеризацияләр уздыру;

балаларның тукланuын оештыру;

укуның, мәктәптән тыш укуның оптималь йөкләнешен, уку дәресләре режимын билгеләү; сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау; укучыларның авыруларын профилактикалау һәм аларны савыктыру өчен, аларга физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру;

мәгариф оешмасында булганда, балаларның иминлеген һәм бәхетсезлек очракларын профилактикалауны тәэмин итү.

Белем алучыларга беренче медицина-санитария ярдәме күрсәтүне оештыру эшләрен сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы башкара, күрсәтелгән ярдәм укучыларга медицина оешмалары, шулай ук сәламәтлек саклау өлкәсендәге законнарда билгеләнгән тәртиптә медицина эшчәнлеген алып бара торган белем бирү оешмалары тарафыннан күрсәтелергә мөмкин. Билгеләнгән тәртипләр буенча, мәгариф оешмасы медицина эшчәнлеген башкару өчен тиешле шартларга һәм таләпләргә туры килә торган урынны медицина оешмасына түләүсез бирә. Мәгариф оешмасы биргән бүлмә санитария-эпидемиология нормаларына һәм медицина эшчәнлеген башкару өчен билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш. Медицина хезмәткәрләренә эшләү өчен тиешле шартлары булган бүлмә бирелмәгән очракта яисә медицина оешмасының мәгариф оешмасы биргән бүлмә урнашкан җирдә аерым эшләргә (хезмәт күрсәтүләргә) лицензиясе булмаса, балигъ булмаганнарга белем һәм тәрбия алу чорында медицина ярдәмен медицина оешмасы биналарында күрсәтү рөхсәт ителә.

Укучыларга беренче медицина-санитария ярдәмен мәгариф оешмасында белем алу урынында лицензияләнгән *медицина кабинетларында* күрсәтүне оештыру оптималь вариант булыпсанала.

Мәгариф учреждениеләрендә белем алучыларга һәм тәрбияләнүчеләргә беренче медицина-санитария ярдәмен оештыру вәзгыятен анализлау күрсәткәнчә, 2017 елда лицензияләнмәгән таләпләргә туры килми торган медицина кабинетлары базасында беренчел медико-санитар ярдәм күрсәтү кимеде.

Әгәр 2016 елда балалар бакчаларының 22%ында һәм мәктәпләрнең 23,5%ында беренче медицина-санитария ярдәмен күрсәтү тиешенчә оештырылмаган булса, 2017 елда бу күрсәткеч 12% һәм 19%ка төште.

24 нче таблица

2013 – 2016 елларда мәгариф оешмалары тарафыннан беренчел медико-санитар ярдәме күрсәтү өчен шартлар тәэмин итүнең торышы

Күрсәткеч исеме			2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел	2017 ел
Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары саны, барлыгы:			**1876**	**1924**	**1889**	**1 836**	**1788**
шул исәптән	медицина кабинетлары булганнар		1026	1040	1084	1 098	1 083
	шулардан	медицина эшчәнлеген башкаруга лицензиясе булганнар	495	557	1 070	702	872
	фельдшер-акушерлык пунктларында хезмәт күрсәтелүчеләр		932	1367	805	738	705
Гомуми белем бирү оешмалары саны, барлыгы:			1 486	1 459	1 403	1 419	1 413
шул исәптән	медицина кабинетлары булганнар		642	667	702	710	706
	шулардан	медицина эшчәнлеген башкаруга лицензиясе булганнар	235	227	332	377	439
	фельдшер-акушерлык пунктларында хезмәт күрсәтелүчеләр		844	792	701	687	707

Шул ук вакытта, мәгариф оешмаларындагы (211 балалар бакчасында һәм 267 мәктәптә) медицина бүлмәләрен санитария-эпидемиология нормаларына һәм медицина эшчәнлеген башкару өчен кирәкле нормаларга һәм кагыйдәләргә туры китерү буенча комплексны чаралар күрелергә тиеш.

Укучыларның сәламәтлеген саклау хокукын тәэмин итүнең тагын бер гарантиясе – мәктәптә *балаларның тукланууын оештыру*.

Россия Федерациясендә Мәгариф турында Федераль законның 37 статьясындагы 1 өлеше нигезендә укучыларны тукландыру бурычы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмага йөкләнә.

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 14 муниципаль районыда һәм шәһәр округында 23 гомуми белем бирү оешмасында укучыларның тукланууы тикшерелде. Һәр икенче учреждениедә диярлек (23тән 12) санитария-эпидемиология таләпләре һәм кагыйдәләре бозылган.

Аеруча күп очраган кимчелекләр түбәндәгеләр:

белем бирү учреждениесе җитәкчесе һәм башкарма хакимитнең санитария-эпидемиология күзәтчечлеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы җитәкчесе тарафыннан эшләнгән һәм расланган якынча 10-14 көнлек меню булмау, балаларны тукландыру, укучыларның яшь төркемнәрен (7 – 11 һәм 12 – 18 яшь) исәпкә алмыйча, бертөрле меню буенча оештыру: «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов ис. Казан кадетлар интернат мәктәбе» ДББУ (ГБОУ), Казан шәһәренең «Казанның сәламәтлек ягыннан

мөмкинлекләре чикле балалар өчен 1 нче интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Лаеш интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Әлмәт 19 нчы мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Актүбә интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Азнакай интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Рус Акташы интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Әлмәт интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Е.Г.Ласточкина ис. Казан интернат мәктәбе» ДББУ, Балтач муниципаль районының «Кече-Лыза урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ, Биектау муниципаль районының «1 нче Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Югары Чаллы интернат мәктәбе» ДББУ;

интернат мәктәпләрдә икенче кичке аш юк, аерым ризыкларның энергетик кыйммәте түбән булу, факттагы туклану рационының билгеләнгән һәм расланган менюга туры килмәве: «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов ис. Казан кадет-интернат мәктәбе» ДББУ, «Советлар Союзы Герое Николай Волостнов ис. Васильево кадетлар интернат мәктәбе» ДББУ, Казан шәһәренең «Казанның сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен 1 нче интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Лаеш интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Әлмәт 19 нчы мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Актүбә интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Азнакай интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Рус Акташы интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Е.Г.Ласточкина ис. Казан интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Югары Чаллы интернат мәктәбе» ДББУ;

ашханәләрнең һәм склад биналарының торышлары канәгатьләнерлек булмау: «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов ис. Казан кадетлар интернат мәктәбе» ДББУ, «Советлар Союзы Герое Николай Волостнов ис. Васильево кадетлар интернат мәктәбе» ДББУ, Казан шәһәренең «Казанның сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен 1 нче интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Е.Г.Ласточкина ис. Казан интернат мәктәбе» ДББУ, Биектау муниципаль районының «1 нче Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ;

алынган продукция сыйфатына контроль булмау, мәктәп ашханәсендә продуктларны куллануга контроль булмау, бракераж комиссиясе эшебеләнканәгатьбулмау: «Генерал-майор Хапаев Владимир Аверкиевич ис. Тәтеш кадетлар интернат мәктәбе» ДББУ, «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов ис. Казан кадетлар интернат мәктәбе» ДББУ, «Советлар Союзы Герое Николай Волостнов ис. Васильево кадетлар интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Е.Г.Ласточкина ис. Казан интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Актүбә интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Рус Акташы интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Әлмәт 19 нчы мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Азнакай интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Лаеш интернат мәктәбе» ДББУ, Биектау муниципаль районының «1 нче Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ, Балтач муниципаль районының «Кече-Лыза урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ;

продуктларны саклау срокларының, шартларының бозылуы (ашханәләрдә срогы чыккан, сыйфатсыз продуктлар булу)**:** «Генерал-майор Хапаев Владимир Аверкиевич ис. Тәтеш кадетлар интернат мәктәбе» ДББУ, «Советлар Союзы Герое Николай Волостнов ис. Васильево кадетлар интернат мәктәбе» ДББУ, «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов ис. Казан кадетлар интернат мәктәбе» ДББУ, Балтач муниципаль районының «Кече-Лыза урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ;

аерым ризыклар әзерләү өчен технологик карталарның булмавы**:** «Генерал-майор Хапаев Владимир Аверкиевич ис. Тәтеш кадетлар интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Әлмәт интернат мәктәбе» ДББУ, Биектау муниципаль районының «1 нче Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ, Балтач муниципаль районының «Кече-Лыза урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ;

укучыларны туклануны оештырганда китек савыт-сабалар булу, тәүлеклек пробаларны саклау сроклары һәм шартлары үтәлмәү (тәүлеклек пробаларның булмавы):

Биектау муниципаль районының «1 нче Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ, Балтач муниципаль районының «Кече-Лыза урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ, «Советлар Союзы Герое Николай Волостнов ис. Васильево кадетлар интернат мәктәбе» ДББУ, «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов ис. Казан кадетлар интернат мәктәбе» ДББУ;

өйдә укытыла торган балаларны тукландыруны оештыру:

«Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Азнакай интернат мәктәбе» ДББУ, «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен Актүбә интернат мәктәбе» ДББУ.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 12 гомуми белем бирү учреждениесенең гамәлгә куючылары адресына балигъ булмаганнарның хокуклары бозылу турында бәяләмәләр җибәрелде, шулардан 11 бәяләмә кадетлар интернат мәктәпләрендә, мәктәпләрдә, сәламәтек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен мәктәпләрдә туклануны оештырудагы кимчелекләр турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына бәяләмәләр җибәрелде.

Роспотребнадзорны Татарстан Республикасы идарәсе белгечләре тарафыннан ел дәвамында укучыларны тукландыруны оештыруга карата җитди санитария-эпидемиология таләпләре бозылу очраклары ачыкланды.

Роспотребнадзор мәгълүматы буенча, 2017/2018 уку елында 1 041 мәктәптә (68,1%) Роспортебнадзор идарәсе раслаган һәм килештерлгән ике атналык меню буенча эшлиләр. Саба, Әлмәт, Зәй, Лениногорс, Баулы, Буа, Тәтеш, Чүпрәле, Апас, Алабуга, Әгерҗе, Нурлат, Аксубай, Чирмешән, Арча, Биектау, Балтач, Әтнә, Мөслим, Актаныш, Тукай, Минзәләм, Теләче, Кукмара, Мамадыш, Түбән Кама, Чистай, Алексеевск, Спас, Яңа Чишмә муниципаль районнарында, Чаллы шәһәрендә меню Роспортебнадзор идарәсе белән 100% мәктәп раслаган.

Әмма Кама Тамагы, Зеленодольск, Менделеевск, Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе, Әлки, Бөгелмә, Азнакай, Ютазы муниципаль районнарында һәм Казан шәһәрендә укучылар өчен меню берничә мәктәптә генә расланган. Сарман, Югары Осланәм Кайбыч муниципаль районнарында килештерелгән меню бөтенләй юк.

2017 елда туклану сыйфатын тикшергәндә 30 муниципаль берәмлек мәктәбендә әзер продуктларның микробиолог таләпләргә туры килмәгән очраклары ачыкланды. Тикшерүләр күрсәткәнчә, республика мәктәпләрендә 2,4% әзер ризык таләпләргә туры килмәде (2016 елда – 2,3%). Күпчелек очракта микробиологик күрсәткечләргә килмәгән

ризыклар табылды, мәсәлән, Спас (11,1%), Лаеш (11,5%), Әлки (18,8%) муниципаль районнарында.

Узлдырылган анализлардан күренгәнчә, республика мәктәпләрендә әзер ризыкның 6,4%ы туклыклылыгы буенча туры килми (2016 елда – 5,4%). Бу Яңа Чишмә, (30,8%), Әтнә (33,3%), Лаеш (33,3%), Менделеевск (40,0%) муниципаль районнарында күзәтелде. Актаныш, Мөслим, Теләче һәм Буа муниципаль районнарында ризыкларның туклыклылыгына һәм химик составына ел буе контроль ясалмаган.

Моннан тыш, мониторинг чараларыуздыру барышында Роспотребнадзор тарафыннан түбәндәге фактлар ачыкланды:

фальсификацияле сөт продукциясе – Әлки, Чүпрәле, Лаеш, Азнакай, Биектау, Минзәлә, Нурлат муниципаль районнарында;

мәктәп яны участокларында үстерелгән яшелчәләрдә нитратлар ачыкланды: Кайбыч, Апас, Арча, Кама Тамагы, Арча муниципаль районнарында;

факттагы менюда ит, яшелчә, җиләк-җимеш, балык, соклар аз булу (748 мәктәптә, 42%);

төп туклану продуктлары буенча нормалар үтәлмәү – Лаеш, Питрәч, Буа, Әтнә, Балтач районнарында, Казан шәһәрендә (166 мәктәптә, 9,3%);

проддуктларның йөртү документлары, этикеткада мәгълүмат булмау, продуктлар китерүнең вакыты үтәлмәү – Балык Бистәсе, Лаеш, Зәй, Кукмара районнарында (132 мәктәптә, 7,4%);

килештерлегән менюны бозу – Зәй, Лениногорск, Лаеш, Түбән Кама, Кукмара районнарында (81 мәктәптә, 4,5%);

ризыкка технологик картаныбулмавы яисә карталар таләпләрне бозып тутырылган – Буа, Апас, Лаеш, Спас, Алексеевск, Кукмара районнарында (36 мәктәптә, 2%).

Мәктәп ашханәләрендә бөтен җирдә диярлек санитария-эпидемиология законнарының бозылган очраклары ачыкланды (биналарның чиста булмавы, савыт-сабаларны һәм продуктларны эшкәртү, әзерләү технологияләре үтәлмәү, кухня җайланмаларының, вентиляция системасынң җитәрлек яисә төзек булмавы һ.б.)

Бәян ителгәннәрдән чыгып, республиканың белем бирү оешмаларында балаларны сыйфатлы тукландыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән кайбер чараларны күрергә кирәк дип саныйм.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

мәктәпкәчә һәмгомуми белем бирү оешмаларында хроник авырулары (шикәр диабеты, ризыкка аллергия, еш авыры йторган балалар) булган балалар өчен төбәк законнары дәрәҗәсендә дәвалау һәм профилактикалау тукландыруын оештытырга;

укучыларның яшен (7 – 11 һәм 12 – 18 яшь) исәпкә алып, интернат мәктәпләрдә 10-14 көнлек якынча меню төзергә;

балаларны, шул исәптән өйдә укучы балаларны, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балалар укый торган оешаларда түләүсез ике мәртәбә туклану хокукын тәэмин итү өчен балаларның туклануын оештыру регламентын эшләргә («Россия Федерациясендә белем бирү турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясы);

җирлеү зидарә органнары белән бергә:

белем бирү оешмаларында балаларны тукландыруны оештыру өчен белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең шәхси җаваплылыгын арттырырга;

туклануны оештыруның ачыклыгын һәм ата-аналарны хәбәрдарлыгын арттыру өчен мәктәп сайтларында көндәлек менюны урнаштырырга;

барлык кызыксынучы якларның үзара хезмәттәшлеге кысаларында белем бирү оешмаларында балаларның имин тукланuын тәэмин итүгә ярдәм имтүдә ата-аналар комитетларының ролен көчәйтүне оештырырга.

Белем бирү оешмаларында Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе белгечләре тарафыннан ачыкланган *тәрбия һәм укыту таләпләре үтәлешенә карата* кимчелекләр буларак түбәндәгеләр билгеләнде:

белкм бирү процессына таләпләрне.үтәлмәве: аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган гиназияләрдә, мәктәпләрдә, лицейларда ике сменалда укыту, башлангыч, шулай ук өлкән сыйныф укучылары өчен дә, дәресләр расписаниеләрен төзү таләпләре үтәлмәү;

балаларны эчерү режимын оештыруга таләпләрнең үтшәлмәве;

балаларны утыртуга карата таләпләрнең үтәлмәве, аларның яшь-буйларына туры килерлек җиһазларның җитәрлек булмавы;

уку классларында, коридорларда, ял урыннарында яктырткычларда лампаларның җитәрлек булмавы, аларны вакытынла алыштырмау, яктырткычларда яклау плафоннар булмау, санитар урыннарын яктырту таләпләре үтәлмәү.

«Россия Федерациясендә белем бирү турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә мәгариф оешмасы компетенциясенә билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә түбәндәгеләр керә:

белем бирү эшчәнлеген дәүләт һәм җирле нормалар, таләпләр нигезендә, шул исәптән дәүләт белем стандартлары, федераль дәүләт таләпләре, белем бирү стандартлары нигезендә матди-техник тәэмин итү;

Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында башкасы билгеләнмәгән булса, штат расписаниесен билгеләү;

әгәр югарыда күрсәтелгән Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, хезмәткәрләрне эшкә алу, алар белән хезмәт шартнамәләре төзү, вазыйфаи бурычларны бүлү, өстәмә һөнәри белем бирү белән шөгыльләнүне оештыру һәм моңа шартлар тудыру;

интернатта торучы балалр өчен тиешле шартлар булдырырга;

укучыларны һәм хезмәткәрләрне саклау һәм аларның сәламәтлекләрен ныгыту өчен тиешле шартлар булдыру.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, тикшерү йөмгакларыннан чыгып, гомумибелем бирү оешмалары администрациясенең профессиональ компетенцияләре дәрәҗәсн һәм җаваплылыгын арттырга кирәк, дип саный.

Укучыларның сәламәтлеген тиешле дәрәҗәдә оештыруның катлаулылыгын истә тотып, кайбер төбәкләредә (Саха (Якутия) Республикасы, Ямал-Ненец автоном округы, Ростов, Смоленск һәм Тамбов өлкәләре) Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган «Мәктәп медицинасы» проекты игътибарга лаек. Монда төп идея – балаларның авыруларын профилактикалау. Мәктәптә сәламәт балалар булсын өчен медицина оешмалары ярдәме булырга тиеш. Сангигиениа медикларыннан һәм мәктәп медицинасы белгечләреннән торган команда булырга тиеш. Пилот кысаларында мәктәп медхезмәткәрләре өчен махсус укулар оештырылачак, алар үз эшләрен укучылар авыруларн профилактикалауга юнәлдерәчәк, санитар таләпләрнең үтәлешенә игътибарна арттырачаклар, физик һәм уку йөкләеншен тикшереп торачаклар. Мәктәп медицинасының яңа моделе, һичшиксез, Татарстан Республикасы өчен кызыклы.

3.3.4. Балаларның ялы һәм аларны савыктыру

Балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру сәламәтлек саклау өлкәсенең өстенлекле юнәлешләренең берсе буларак билгеләнгән.

2017 елда республикада балалар ялын һәм аларны савыктыруны оештыру түбәндәгеләр белән регламентланды:

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында физик культураны, спортны, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 7 февралендәге 73 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган «2014 – 2020 елларга балаларның һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне оештыру» ярдәмче программасы;

«Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 2016 елның 31 мартындагы 191 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында нигезләмә;

«2016 елга балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2015 елның 9 октябрендәге 756 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;


«Балаларның һәм яшьләрнең ялы, аларны савыктыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфат стандартын раслау турында» 2015 елның 3 мартындагы 130 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Балаларның һәм яшьләрнең ялы, аларны савыктыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфат стандарты.

Балаларның һәм яшьләрнең җәйге ялы, аларны савыктыру системасын үстерү, аның и*нфраструктурасын үстерүгә ярдәм итү* максатларында республикада 2013 елдан бирле балаларның стационар җәйге савыктыру лагерьларын капиталь ремонтлау программасы гамәлгә ашырыла, ул ел саен Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары белән раслана. Мәсәлән, 2017 елда савыктыру лагерьларын җәйге сезонга әзерләү барышында 10 дәүләт һәм муниципаль балалар савыктыру лагерьларында капиталь ремонт һәм реконструкция эшләре үткәрелде (2016 елда – 12 лагерьда, 2015 елда – 20 лагерьда, 2014 елда – 15 лагерьда, 2013 елда – 6 лагерьда). Биш ел эчендә 43 шәһәр чите стационар лагеренда ремонт ясалды, гомуми лагерьларның 58%ын тәшеил итә. Гамәлгә ашырылган эшләр комплексы лагерьга килә торган балалар санын артытырга мөмкинлек бирде, 4500ләп бала ял итте.

2017 елгы җәйге кампаниянең программа чараларын гамәлгә ашыру кысаларында барлык төрләрдәге 1 905 ял оешмасы җәлеп ителде, бу, 2016 елга караганда, 564кә күбрәк (2016 елда – 1 341, 2015 елда – 1 400, 2014 елда – 1 383, 2013 елда – 1310). Бу хезмәт һәм ял лагерьларының (569 оешма) , шәһәр чите лагерьларының (14 оешма) артуына бәйле. Шул ук вакытта 2017 елда мәктәпләрдә оештырыла торган көндезге лагерьлар саны кимеде (3 оешмага ким), балалар ялы оештырыла торган шифаханә-курорт оешмалары 4кә кимеде, палата тибындагы лагерьлар 11гә кимеде, 2017 елда җәйге кампаниядә катнашучы Краснодар краенда һәм Кырым Республикасындагы лагерьлар 1гә кимеде.


80 нче диаграмма

2013 – 2017 елларда балалар өчен ял һәм савыктыру учреждениеләре челтәре структурасы (оешма рәвеше)



81 нче диаграмма

2013–2017 елларда Татарстан Республикасында балалар өчен шәһәр яны ял һәм савыктыру учреждениеләре челтәре структурасы (милек төрләр буенча)



2017 елда Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы тарафыннан балаларны савыктыру кампаниясендә катнаша торган барлык гамәлдәге Татарстан Республикасы лагерьлары Реестры (алга таба – Реестр) төзелде. Әлеге Реестр «Балаларны һәм яшүсмерләрне савыктыру, аларның ялын һәм мәшгульлеген оештыру буенча республика үзәге «Лето» ДБУның рәсми сайтында (http://rcleto.ru) урнаштырылды. Реестр балалар лагерьлары, алардагы шартлар турында объектив мәгълүмат алу мөмкинлеген бирә.

Шул ук вакытта, Реестрны анализлаудан күренгәчә, лагерьлар буенча анда мәгълүмат әле бик тулы түгел, аерым лагерьлар эше турында мөһим белешмәләр җитешми.


Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил җәйге савыктыру кампаниясен әзерләү чорында Реестрны эшләп бететергә һәм балаларны савыктыру буенча эшли торган лагерьлар турында 2018 елның 1 маеннан да соңга калмыйча белешмәләр белән тулыландырырга тәкъдим итә.

2017 елгы җәйге савыктыру кампаниясе чорында 218 509 кеше ял итте 2016 елда – 217 981, 2015 елда – 216 685, 2014 елда – 213862), бу 2016 елдагыдан 528 балага күбрәк. 2017 елда балаларны һәм яшьләрне савыктыруны финанслауга 1 731,6 млн. сум акча бирелде, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1 431,4 млн.сум, муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан (җирле бюджетлардан) – 31,4 млн.сум, предприятиеләр акчаларыннан – 94,1 млн. сум.

Җәйге чорда 168 808 бала ял итте, бу 2016 елга караганда 3 300 кешегә күбрәек (2016 елда – 165 508, 2015 елда –170 087, 2014 елда – 171 968).

82 нче диаграмма


2017 елда төрле рәвештә ял иткән балалар һәм яшүсмерләр саны



Бүгенге көнгә балалар ялын оештыруның төп нәтиҗәлелек күрсәткечләре савыктыру эффектыннан гыйбарәт. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләренә караганда, 2017 елда җәйге савыктыру чорында барлык ял итүчеләрнең 94,6%ы нәтиҗәле ял итте, бу күрсәткеч 2016 елгы дәрәҗәдә сакланып калды. 5,1%ында нәтиҗәлелелек кимрәк булды, 0,3%ында савыктыру эффекты бөтенләй булмады.

83 нче диаграмма

2013 – 2017 елларда җәйге ялның нәтиҗәлелеге



Балаларның ялын һәм аларны савыктыруны әйбәт оештыру күп очракта профессиональ оештырылган педагогик, тәрбияви эшләргә бәйле. Балигъ булмаганнарның ял

итү оешмаларыннан башбаштакланып чыгып китү, балаларның җәрәхәтләнү очраклары, балигъ булмаганнар тарафыннан яисә аларга карата башкарылган җинаять эшләре педагогларның эше, ялны оештыру, балаларга тәрбия бирү һәм күз-колак булу сыйфатын бәяләүнең индикатив күрсәткече булып тора.

25 нче таблица

2013 – 2017 елларда савыктыру кампаниясе чорында балигъ булмаганнар тарафыннан җәрәхәтләнүләр, йогышлы чир белән күпләп авырулар, башбаштакланып китүләр, җинаятьләр

Вакыйгалар	2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел	2017 ел
Җәрәхәтләр	75	72	32	145	45
Йогышлы чир белән күпләп авырулар	-	1	-	-	-
Башбаштакланып китүләр	18	10	8	3	4

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы биргән мәгълүмат буенча җәйге ял кампаниясе чорында түбәндәгеләр аычкланды:

1 факт – Мамадыш муниципаль районының «Берсут» балалар савыктыру лагеренда (алга таба – БСЛ) *балалар белән рәхимсез эш итү;*

4 факт – балигъ булмаганнарга карата хокук бозулар:

Казан шәһәренең Авиатөзелеш районының «Крутушка» БСЛ;

Тукай муниципаль районының «Крылатый» БСЛ;

Казан шәһәре Киров районының «Яшь гвардия» БСЛ.

4 очрак – ике савыктыру оешмасыннан башбаштакланып китү:

Зеленодольск муниципаль районының «Пионер» БСЛ (2 очрак);


Минзәлә муниципаль районының «Полянка» БСЛ (2 очрак).

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белешмәләренә караганда, 2017 елда күпләп йогыәлы авырулар белән авыручылар булмаган. Балаларның җәрәхәтләнү очраклары да шактый кимегән.

Соңгы еллар динамикасыннан күренгәнчә, оешкан төстә ял итүче балалар арасында хроник авырулар белән авыручылар саны арткан. 2017 елда «Балалар һәм яшьләр ялын оештыру» ярдәмче программа кысаларында, хроник авырулары булган 4 322 бала ял итте.

84 нче диаграмма

2014 – 2017 елларда оешкан төстә ял итүче балалар арасында хроник авырулары булган балалар саны



Җәйге савыктыру кампаниясен әзерләү һәм уздыру чорында балалар ялын оештыру күп ***контроль-күзәтчелек органнары тикшерүе аша уза.***

Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе (алгатаба – Идарә) 2017 елгы җәйге савыктыру кампаниясе (алга таба – ҖСК) чорында балалар ялы инфраструктурасы объектларына даими рәвештә санитария-эпидемиология тикшерүен уздырды.

Идарә мәгълүматы буенча, ҖСК-2017 чорында җәйге савыктыру учреждениеләренә план буенча да, шулай ук планнан тыш та тикшерүләр үткәрде.

Идарә 1 269 җәйге лагерьда тикшерү уздыра, шул исәптән 93,4%ы лаборатор тикшерүләр белән. Эчәр суга 3 587 проба алына, коену урыннарында һәм бассейннарда – 511 проба, 376 проба – туфракка, 5 548 проба – әзер ризыкларга, 14 305 проба – әйләнәтирә объектлардан агып чыгучы суларга. 97,5% тикшерүләрдә кимчелекләр табыла, болар буенча административ хокук бозу турында 1 157 беркетмә төзелә, шул исәптән юридик затларга – 54; 3 980 200 сумга штраф салу турында карарлар чыгарыла, аларның үтәлеше контрольдә тора.

Административ йогынты ясау чараларын кулланыга түбәндәге хокук бозулар сәбәпче булды: тәүлеклек пробаны саклау шартлары һәм сроклары бозылу, ризык әзерләүнең технологик процесслары бозылу, аш бүлмәсе кирәк-яракларын, ашханә табак-савытын эшкәртү режимы бозылу; азык әзерләгәндә санитария кагыйдәләрен, технологияне үтәмәү, матди-техник җиһазлар (җайланмаларның төзек булмавы, йомшак инвентарь җитешмәү), территорияне, гомуми файдалану урыннарын, медицина хезмәте күрсәтү урыннарын карап тоту буенча кимчелекләр, эчәр су белән тәэмин итүдәге җитешсезлекләр, ризыкларда С витамины, аларның туклылыгы җитешмәү.

Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19,5 статьясындагы 1 өлеше нигезендә (тиешле органнарның, вазыйфаи затларның законлы күрсәтмәләрен (карарларын) срогында үтәмәгән өчен .

Идарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан ҖСК-2017 сезонында эшчәнлекне вакытлыча тыю рәвешендәге административ йогынты ясау кулланылмады.

Балаларның җәйге ялын һәм аларны савыктыруны оештыруга Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан күзәтчелек итү ел саен гамәлгә ашырыла.

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасының 18 муниципаль районында (шәһәр округларында) урнашкан 51 ял оешмасы, шул исәптән: 31 мәктәп лагере, 2 палата лагере, 18 шәһәр яны лагере тикшерелде, шул исәптән:

Әлмәт муниципаль районының «Березка» шәһәр яны балалар савыктыру лагере;

Азнакай муниципаль районында өч шәһәр яны савыктыру лагере: «Солнышко», «Березка», «Орленок»);

Алексеевск муниципаль районының мәктәпләрдәге көндезге ике лагере («Светофорик» – 2 нче номерлы мәктәптә, «Солнышко» – 1 нче номерлы мәктәптә);

Арча муниципаль районында ике лагерь, шул исәптән палата лагере, шәһәр яны савыктыру лагере («Шатлык», «Азимут»);

Баулы муниципаль районында ике шәһәр яны савыктыру лагере («Ласточка» һәм «Иволга»);

Балтач муниципаль районының «Балтач гимназиясе» каршындагы көндезге лагерь;

Буа муниципаль районында: 6 лагерь – мәктәпләр каршындагы көндезге лагерьлар, бер палата лагере, бер шәһәр яны савыктыру лагере («Лицей-интернат (сәләтле балалар өчен)» МББУ каршындагы, «Гимназия № 5» МББУ, «М.Вахитов ис. гимназия» МББУ,

«Лицей № 2» МББУ, «1 нче номерлы урта белем бирү мәктәбе» МББУ, Буа шәһәренең «Р.З.Сәгъдив ис. урта белем бирү мәктәбе» МББУ каршындагы лагерьлар, «Чайка» БСЛ, «Рюкзачок» палата лагере);

Бөгелмә муниципаль районында мәктәпләр каршындагы өч лагерь (6 нчы номерлы мәктәп каршындагы «Шик», 12 номерлы мәктәп каршындагы «Солнышко», 4 нче мәктәп каршындагы «Муравейник» лагерьлары);

Алабуга муниципаль районында өс лагерь: («Космос», «Яшь төзүче») һәм бер көндезге лагерь – 3 нче номерлы мәктәп каршындагы «Орленок» лагере);

Чүпрәле муниципаль районында мәктәпләр каршындагы дүрт лагерь (Иске Чыкалы урта мәктәбе каршындагы «Ласточка», «Марс урта мәктәбе» каршындагы «Планета», «П.В.Дементьев ис. Үби урта мәктәбе» каршындагы «Солнышко» лагерьлары);

Зеленодольск муниципаль районында өч лагерь, шул исәптән ике көндезге лагерь һәм бер шәһәр яны лагере («5нче гимназия» каршындагы «Муравейник», 10 нчы гимназия каршындагы «Радужная страна» лагерьлар, Муса Җәлил ис. лагерь);

Кайбыч муниципаль районында мәктәпләр каршындагы дүрт лагерь (А.Е.Кошкин ис. Зур Каенлык урта мәктәбе» каршындагы «Радуга» (Салават күпере), «Улыбка» лагерьлары, «Федоровка урта мәктәбе» каршындагы «Непоседы» лагере);

Лениногорск муниципаль районында ике шәһәр яны лагере («Дружба» (Дуслык) һәм «Олимпия» лагерьлары);

Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпләр каршындагы көндезге ике лагерь;

Нурлат муниципаль районында «Заречный» шәһәр яны савыктыру лагере;

Мөслим муниципаль районында «Лесная страна» шәһәр яны савыктыру лагере;

Тәтеш муниципаль районында «Чайка» шәһәр яны савыктыру лагере;

Теләче муниципаль районында «Олы Мишә урта мәктәбе» каршындагы көндезге лагерь;

Чистай муниципаль районында мәктәпләр каршындагы алты көндезге лагерь, шул исәптән бер – хезмәт һәм ял лагере (4 нче мәктәп каршындагы «Краски лета», 16 нче мәктәп каршындагы «Крепыш»6», ике лагерь – «Чистай-Выселька урта мәктәбе» карышндагы, «Йолдызурта мәктәбе» каршындагы «Радуга лета» лагере).

Тикшерү барышында өч лагерьда санитария-эпидемиология таләпләренә туры килмәү очраклары билгеләнде:

моңа азык-төлек блоклары һәм балаларны тукландыру таләпләренең үтәлмәве, шулай ук балаларның ялын һәм аларны савыктыру буенча стационар оешмаларга куелган таләпләрнең үтәлмәве керә. Шулай ук балалар оешмаларындагы җитәкчеләрнең һәм җаваплы хезмәткәрләрнең компетенциясе югары булмау да игътибарны җәлеп итә (Азнакай муниципаль районының «Солнышко» БСЛ, Нурлат муниципаль районының «Заречный» БСЛ, Мамадыш муниципаль районының «Берсут» ҖЧҖенең «Берсут» БСЛ);

бинага, җайланмаларга, балалар яши торган бүлмәләрнең чисталыгына таләпләрнең бозылуы: (Азнакай муниципаль районының «Солнышко» БСЛ, Нурлат муниципаль районының «Заречный» БСЛ, Мамадыш муниципаль районы «Берсут» ҖЧҖенең «Берсут» БСЛ).



Җәйге ялны оештыру чорында Мамадыш муниципаль районы «Берсут» ҖЧҖенең «Берсут» БСЛ Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым игътибарында булды.

2017 елның 2 июнендә «Берсут» БСЛга 271 бала килә, шулардан 80%ы – Татарстан Республикасы муниципаль

районнарының социаль приютларыннан 3 – 17 яшьлек балалар. Тәрбияче-педагог вазыйфасына һәм тәрбияче-оештыручы вазыйфасына «Берсут» БСЛена Казан дәүләт мәдәният институтыннан 13 студент эшкә алына. Бу вожатыйлар 2017 елда «Вожатыйлар мәктәбен» узып, тиешле таныклыклар алганнар иде.

4 июньдә, лагерь җитәкчесе белән бәхәскә кереп, барлык студентлар, балаларны күзәтүчесез калдырып, китеп баралар.

Бәхәсле вәзгыять турында вожатыйлар Министрлыкка да, ведомстволаргша да, Казан дәүләт мәдәният институтына да хәбәр итмиләр.



Тикшерүдән шул ачыкланды, «Казан дәүләт мәдәният институты» югары һөнәри белем ФДБМУенә студентларны «Берсут» лагерена эшкә җәлеп итү һәм студентларның «Вожатыйлар мәктәбен» узулары турында рәсми хәбәр ителмәгән булган.

2017 елның 5 июнендә күзәтүчесез калган балаларның икесе – 7 һәм12 яшьлек – (Түбән Кама муниципаль районы приютыннан) башбаштакланып китеп баралар һәм Түбән Кама шәһәренә кайталар.

Тикшерү барышында тагын шул ачыкланды, лагерьга беренче сменага (02.06.2017 – 22.06.2017) 305 яшьлек 22 бала килә (Саба һәм Азнакай муниципаль районнары социаль приютларыннан). Әмма «Берсут»та бу яшьтәге балалар тору өчен шартлар булмый.

«Берсут» БСЛ (2017 елга кадәр «Надежда» БСЛ була) 2013 елдан бирле Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җитди күзәтүендә тора.

Бу оешмаларны гамәлгә куючылар адресына Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә бәяләмәләр җибәрде:

«Берсут» ААҖ җитәкчесе адресына;

Нурлат муниципаль районы башлыгы адресына;

Азнакай муниципаль районы башлыгы адресына.

2017 елда ***санкцияләнмәгән*** лагерьлар, төрле конфессияләрнең якшәмбе мәктәпләре тарафыннан оештырыла торган лагерьлар да Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең игътибар үзәгендә булды.

Әлеге мәсьәләне өйрәнү нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов адресына республика территориясендә санкцияләнмәгән лагерьлар эшчәнлеген булдырмау тәкъдиме белән мөрәҗәгать җибәрелде.

2017 елда җәйге савыктыру кампанисяе йлмгаклары буенча «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе Президиумына тәкъдим ителде:

1) муниципаль районнар (шәһәр округлары) башлыкларына түбәндәге вәкаләтләрне йөкләргә:

тиешле муниципаль район (шәһәр округы) территориясендә, ведомство буйсынуына һәм милек рәвешләренә карамастан, балигъ булмаганнар өчен барлык ял һәм савыктыру оешмаларыны, шул исәптән санкцияләнмәгән лагерьларны мониторинглау буенча;

тиешле муниципаль район (шәһәр округы) территориясендә санкцияләнмәгән палата лагерьлары һәм туристик маршрутлар эшчәнлеге турында контроль-күзәтчелек органнарына мәгълүмат бирү;

2) контроль-күзәтчелек органнарына компетенция чикләрендә кергән хәбәрләр буенча санкцияләнмәгән палата лагерьлары һәм туристик маршрутлар эшчәнлеген тикшерүнегамәлгә ашырырга.

3) Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) башлыкларына балаларсавыктыру лагерьларына үтеп керү юлларының торышы турындагы мәсьәләне карарга, юлларга комплексы анализ ясарга һәм ачыкланган проблемалар буенча чаралар күрергә;

4) тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына, җирле үзидарә органнары белән бергәләп, балалар савыктыру лагерьларында телефон элметәсе белән тәэмин ителешне өйрәнергә.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, балаларның ялын оештыруның иминлеген тәэмин итү, халыкның, ата-аналар җәмәгатьчелегенең балалар савыктыру лагерьлары турында дәүләт хәбәрдарлыгын арттыру максатында, муниципаль хезмәтләре порталында савыктыру кампаниясендә катнашучы лагерь Реестрын урнаштырырга.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балаларялын һәм мәшгульлеген тикшерү кысаларында 24 муниципаль берәмлектә (шәһәр округында) булды. Аларда ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, гаиләгә тәрбиягә алган балаларның (алга таба – гаиләгә алынган ятим балалар) һәм сәламәтлеге ягыннан чикле балаларның ялын оештыру мәсьәләләре каралды.

«Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 2016 елның 31 мартындагы 191 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына дәүләт мәгариф оешмаларында тәрбияләнүче ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның билгеләнгән тәртиптә ялын оештыруны тәэмин итү йөкләнгән иде. Гаиләгә алынган балалрның ялын оештыруны тикшерүләрдән күренгәнчә, андый балаларның күбесенең җәйге ялы оештырлмаганлыгы ачыкланды, балалар мәктәп лагерьларына да йөрмиләр, шәһәр лагерьларында да булмыйлар. Шул уквакытта опека һәм попечительлек органнары бу закта белмиләр дә.

Шулай ук *сәламәтлеге ягыннан чикле балаларның* ялын оештыру мәсьәләләре дә тулы хәл ителмәгән.

Әйтелгәннәрне истә тотып, балаларның ялы һәм аларны савыктыру кампаниясе йомгаклары буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ел саен сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен ял һәм савыктыру системасын үстерү буенча алынган йөкләмәләрнең үтәлешен тәэмин итү чараларын күрү кирәклеге турындагы мәсьәләне күтәрә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләренә караганда, 2017 елда 1 370 инвалид бала гына оешкан төстә ял итә (инвалид балаларның гомуми саныннан 9,3%). Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларның ял итүе турында мәгълүмат юк.

Гамәлдәге лагерьларның булган инфраструктурасы торышы һәм штатта кирәкле белгечләрнең булмавы ишетү, күрү, сөйләм бозылу, терәк-хәрәкәт функцияләре бозылган, акылга зәгыйфь балаларның ялын, шул исәптән инклюзия принципларында сәламәт балалар белән бергә оештырырга мөмкинлек бирми. Республикда андый балалар өчен җайлаштырылган 6 шәһәр яны лагере бар. 2017 елда сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны ял иттерү 25 савыктыру оешмасында, шул исәптән 14 шифаханә-курорт тибындагы оешмаларда оештырылган.

Бүген сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны, инвалид балаларны ял иттерүне тәэмин итүгә республика ведомстволары дәрәҗсендә дә, җирле үзидарәләр дәрәҗәсендә дә системалы алымнар эшләнмәгән.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен тиешле шартлар тудыру максатларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк дип саный:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шәһәр яны лагерьларында азмобильле төркем балалар өчен уңайлы инфраструктура белән тәэмин ителгән уңайлы мохит булдыру, инклюзив алым принципларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларның ялын оештыру тәҗрибәсен сынап карау буенча ресурс үзәкләре булдыру мәсьәләсен карарга;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә, еллык мониторинг уздыруны, шуның нәтиҗәсендә сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларның ялга һәм савыктыруга хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча бердәм белешмәләр базасын булдыру мәсьәләсен карарга.

Савыктыру кампаниясенең уңышлы булуында белеп һәм сайлап алынган кадрлар составының роле бик зур. Җәйге савыктыру кампаниясе чорында ачыкланган искәрмәләр һәм проблемалар балалар ялын һәм савыктыруын ***оештыручы кадрлар составына*** яңа таләпләр куя.

Шуны әйтергә кирәк, күзәтчелек органнарының максатчан һәм даими контроле аркасында эш бирүчеләр тарафыннан Хезмәт кодексының 331, 351.1 статьяларындагы педагогик һәм техник персоналны эшкә алгандагы таләпләре үтәлде дип әйтергә мөмкин (хөкем ителү, җинаять кылу фактларын тикшереп алуга кагылышлы өлешләре).

Шул ук вакытта, кадрлар составын әзерләгәндә түбәндәгеләр актуаль мәсьәләләр булып кала:

хәтәр төркем балалар белән эшләү өчен квалификацияле педагогик персонал белән тәэмин итү. Балаларның җәйге ялы кампаниясе чорында дәвамлы срокларга приют балаларын шәһәр яны лагерьларына җибәрү мәсьәләсе каралды. Бу балаларның имин булмаган гаиләләрдән булуын истә тотып, алар бу учреждениеләргә социаль һәм психологик тернәкләндерү өчен җибәрелә. Ял итү учреждениеләренә аларны вакытлыча урнаштыру реабилитация процессын үзәргә тиеш түгел. Шуңа күрә мондый балалар җибәрелә торган лагерьларның үзләрендә аларны реабилитацияләү бурычы үтәлергә, йә алар белән бергә приютлардан тиешле белгечләр килергә тиеш;

сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балаларның ялын һәм савыктыруыноештыру өчен квалификацияле педагогик һәм медицина персоналы белән тәэмин итү;

балигъ булмаганнарның башбаштакланып китеп йөрүләре психологик (балада шәхси характердагы үзенчәлекләр барлыкка килү, җәрәхәтли торган вәзгыятьләрдән баш тарту теләге, якын кешеләр белән элемтә булмау), социаль (өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән үзара начар мөнәсәбәтләрдә булу, физик йә психологик көчләү, лагерьда кызык булмау), медицина характерындагы («дромомания» диагнозы) сәбәпләре аркасында булырга мөмкин, болар үзләренә карата да, шулай ук аларны җинаятькә этәрергә мөмкин. Моннан чыгып, «Вожатыйлар мәктәбе» кысаларында:

балаларның балалар оешмаларыннан башбаштакланып китеп йөрүләрен профилактикалау буенча укыту модулен кертергә;

сменаны планлаштырганда тәрбияләү эшчәнлеге һәм мәдәни-массакүләм чаралар программасын эшләүгә бик җитди карарга.

Болар барысы да җирле үзидарә органнарының, лагерьлар җитәкчеләренең ялны оештыру сыйфатына, балигъ булмаганнарның лагерьларда хәвефсез торуы өчен шартлар булдыруга җаваплылыгын арттырырга кирәклекне раслый.

Социаль приютлардагы балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын оештыруда ачыкланган проблемалар Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгыннан, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан мондый категория балаларның ялын оештыруга карата аерым карашта булуларын таләп итә.

Лагерьларда балигъ булмаганнарны реабилитацияләү, аларга социаль, психологик һәм башка төр ярдәм күрсәтү буенча программаларны гамәлгә ашыру эшләре дәвам ителергә тиешлекне истә тотып, аларның ата-аналарына (законлы вәкаләтләренә) балигъ булмаганнарны авыр тормыш вәзгыятеннән чыгару, яшьтәшләре арасында, коллективта, уку, эш, яшәү урыннарында социаль статусын торгызу, аларны үз гаиләләренә кире кайтаруга ярдәм итү өчен әлеге балаларны ял иттерү гамәлләре һәм мондый сменаларда эшләү өчен кадрлар әзерләү программага кертелергә тиеш.

3.4. Баланың яшәү һәм гаиләдә тәрбияләнү хокукын үтәү

Баланың яшәү һәм гаиләдә тәрбияләнү хокукы – бала хокукларының иң мөһимнәреннән берсе, чөнки гаиләдә тәрбияләнү аның физик, әхлакый, интеллектуаль һәм социаль үсеше өчен гаять әһәмиятле. Нәкъ менә гаилә тирәлеге баланың шәхес булып җитешүенә һәм җәмгыять тормышына әзер булуына ярдәм итә. Бу хокукны үтәмәү бала өчен аеруча җәрәхәтле, шуңа күрә аны үтәмәү очракларын катгый чараралар күрелергә тиешле һәм аны профилактикалау һәм торгызуның нәтиҗәле механизмнарын кулланууны таләп итә торган тупас хокук бозуларга кертергә кирәк.


3.4.1. Гаиләдә иминлек булмау проблемалары

Гаиләдә иминлек булмау бүген баланың лаеклы тормыш шартларына хокукын бозуга, ятимлеккә, балигъ булмаганнар арасында һәм аларга карата җинаять кылуга китерә торган, үз балаларын тәрбияләү, карау һәм тоту бурычларын ата-аналары тарафыннан тиешенчә үтәмәү аркасында балаларга физик һәм психик зыян китерә торган төп сәбәп булып тора.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белешмәләре буенча, 2017 ел азагына балигъ булмаган балалары булган һәм авыр тормыш хәлендә калган һәм социаль яклау органнарының ведомство исәбендә тора торган гаиләләр саны узган ел белән чагыштырганда 20,6%ка (1 227 гаиләгә) кимеде һәм 4 736 гаилә тәшкил итә. Бу гаиләләрдә ел ахырына барысы 9 010 бала яши иде, бу 2016 елга караганда 683 кешегә, ягъни 7,0%ка кимрәк. Бу барлык балалар санының 1,1% тәшкил итә (2016 елда елда 1,2% иде).

85 нче диаграмма


2013-2017 елларда социаль яклау органнарының ведомство исәбендә торучы гаиләләр һәм аларда тәрбияләнүче балалар саны (кеше)



2017 елда Татарстан Республикасы территориаль эчке эшләр органнарының полиция хезмәткәрләре тарафыннан 3 996 ата-ана профилактик исәпкә куелган, бу 2016 ел белән чагыштырганда 598 кешегә, ягъни 17,6%ка күбрәк. Татарстан Республикасында Эчке эшләр министрлыгының статистик белешмәләре нигезендә 2017 елда балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрдә ведомство исәбендә торучы гаиләләр саны соңгы җиде елда максималь дәрәҗәгә җитте һәм 4592 булды (2016 елга караганда 3,3%ка артыграк). Шул ук вакытта аларда яшәүче балалар саны 37 кешегә кимеде. Барлык балаларның гомуми саныннан мондый балалар өлеше 2016 ел дәрәҗәсендә һәм ул 0,9% тәшкил итә (2015 елда бу күрсәткеч 0,5% иде).

85 нчы диаграмма

2011-2017 елларда эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрендә ведомство исәбендә торучы гаиләләр һәм аларда яшәүче балалар саны (кеше)




«Социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне исәпкә алу һәм мониторинглау» бердәм мәгълүмат банкында ведомствоара исәптә торучы гаиләләр аеруча борчый. 2017 елда социаль куркыныч шартларда булган 1 052 гаилә бердәм базага кертелде, аларда 2 118 балигъ булмаган бала яши. 2016 ел белән чагыштырганда мондый категориядәге гаиләләр 105кә, ягъни 9ка кимеде.

2017 ел азагына Социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрнең бердәм банкында 1 105 гаилә исәпкә куелган иде, аларда яшәүче балигъ булмаган балалар саны – 2 163.

Шулай да, республикада социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр һәм аларда яшәүче балалар саны кимү ягына таба бара. 2017 елда 2016 ел белән чагыштырганда 248гә кимегән, бу 18,3% тәшкил итә. Шуңа күрә социаль куркыныч хәлдә яшәүче балалар саны да кимегән, алар – 2 163 бала, 16,3%ка кимегән. Мондый балалар гомуми балалар саныннан 0,26% тәшкил итә (2015 елда – 0,3%).

87 нче диаграмма

2011–2017 елларда социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрнең һәм аларда тәрбияләнүче балаларның саны



Шулай итеп, 2017 ел ахырына Татарстан Республикасында:

8 223 гаилә төрле төрдәге исәпләрдә торган (2016 елда – 9 905 семей);

14 183 бала, яки балаларның гомуми санының 1,7%, төрле дәрәҗәдәге начар гаиләләрдә яшәүләрен дәвам иткән (2016елда – 16 087 бала, ягъни 2%).

Соңгы еллардагы начар гаиләләр мониторингы төрле рәсми исәпләрдә торучы гаиләләрнең һәм аларда яшүче балаларның саны кимүен күрсәтә. 2016 ел белән чагыштырганда, 1 682 гаиләгә, ягъни 17%ка кимрәк, ә шундый шартларда яшәүче балалар саны 1904кә, ягъни 11,8% кимүен күрсәтә.

Начар гаиләләр һәм аларда яшүче балалар хәлен профилактикалау системасы субъектларының (алга таба – профилактика субъектларының) эшчәнлеге Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең даими һәмаерым контролендә тора.

Балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектларының (алга таба – органнар – профилактика субъектлары) гаиләләрнең начар яшәү шартларын иртә ачыклау, аларга ярдәм итү, реабилитацияләү эшчәнлеге елдан-ел камилләшә, бу, һичшиксез, уңай нәтиҗәләр бирә.


Шул ук вакытта, органнарның– профилактика субъектларының эшчәнлеге тагын да камилләштерүне һәм аның буенча чаралар күрүне таләп итә.

Беренчедән, начар гаиләләрне профилактикалау эшчәнлегенең сыйфатын билгели торган төп күрсәткечләрнең берсе – ***республикада социаль ятимлек дәрәҗәсе***.

Республикада 2012 елдан бирле ачыкланган ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар санының арту тенденциясе сакланып кала. 2017 елда беренче мәртәбә ачыкланган ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саны 1 029га җитте, бу социаль ятимнәрнең 80%ын тәшкил итә, 2016 елда бу күрсәткеч – 885 булган, 2015 елда – 791).

88 нче диаграмма

2008 –2017 елларда ачыкланган ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның саны (кеше)



Ел саен ачыклана торган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саны, кызганычка каршы, соңгы елларда начарг аиләләрне профилактикалау эшчәнлегендә җитди уңай үзгәрешләрнең булмавын күрсәтә.

Икенчедән, органнар – профилактика субъектлары эшчәнлегендә начар гаиләләрне үз вакытында ачыклап өлгермәү һәм ата-аналарга авыр тормыш хәленнән чыгу буенча индивидуаль тернәкләндерү ярдәмен күрсәтүне үз вакытында оештырмау тәҗрибәсе дәвам итә. Профилактикалау һәм социаль ярдәм никадәр иртәрәк күрсәтелсә, баланың гаиләдә калу мөмкинлеге дә шулкадәр күбрәк була. Начар гаиләләрне, балаларның хокук бозуларын иртә ачыклау буенча ведомствоара система социаль ятимлекне профилактикалау күзлегеннән караганда үзен тулысы белән аклый. Монда бер нәрсәне истә тотарга кирәк,

ярдәм күрсәтү авыр тормыш хәле социаль куркыныч дәрәҗәгә җиткәнче күрсәтелергә тиеш.

2017 елда мәгълүмат системасы чаралары ярдәмендә 3 189 гаиләгә ***сигнал карталары*** җибәрелде, шуның 1 1 052се социаль куркыныч хәлдәге гаилә буларак ведомствоара исәпкә куелды, җибәрелгән сигнал карталарының 31%ын тәшкил итә (2016 елда – 1 157 гаилә, ягъни 31%), шул исәптән:

эчке эшләр органнары – 1 612 сигнал картасы (җибәрелгән сигнал карталарының 50,5%), 510 гаилә исәпкә куелды (җибәрелгән сигнал карталарының 48,5%);

социаль яклау органнары һәм учреждениеләре – 372 сигнал картасы (җибәрелгән сигнал карталарының 11,7%ы), 208 гаилә (җибәрелгән сигнал карталарының 19,8%ы);

мәгариф идарәсе органнары – 333 сигнал картасы (10,4%), 90 гаилә исәпкә куелды (8,5%);

сәламәтлек саклау идарәсе органнары – 391 сигнал картасы (12,3%), 88 гаилә исәпкә куелды ((8,4%);

опека һәм попечительлек органнары – 252 сигнал картасы (7,9%), 70 гаилә исәпкә куелды (6,6%);

җинаятькә каршы-башкарма инспекциясе – 107 сигнал картасы (3,4%), 43 гаилә исәпкә куелды (4,1%);


авыл җирлекләре башлыклары – 24 сигнал картасы (0,7%), 12 гаилә исәпкә куелды (1,1%);

яшьләр эшләре һәм спорт органнары – 9 сигнал картасы (0,3%), 4 гаилә исәпкә куелды (0,4%);

башка оешмалар (башка муниципаль берәмлекнең муниципаль социаль-реабилитация консилиумы, ведомствоара рейдлар һ.б.) – 89 сигнал картасы (2,8%), 27 гаилә исәпкә куелды (2,6%).

79 нчы диаграмма

2017 елда «Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмат системасына органнар – профилактика субъектлары җибәргән сигнал карталары саны



Гадәттәгечә, сигнал карталарын тутыру буенча авыл җирлекләре башлыкларының, яшьләр эшләре һәм спорт, опека һәм попечительлек органнарының активлыгы түбән булды.

Аерым очракларда органнар – профилактика субъектлары профилактикалау системасы субъектларының гаиләләрнең начар яшәү шартларын иртә ***ачыклау эшчәнлегенә карата битарафлык, эшлексезлек*** күрсәтә. Тиешле органнарның – профилактика субъектларының актив гражданардан, туганнардан, башка чыганаклардан гаиләдәге тавыш турында җиткерелгән мәгълүматка игътибар итмәү фактлары бар.

Мисал. *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына Казан шәһәрендә яшәүче гр. М., ике яшьлек бала яши торган гаиләдәге начар хәлләр турында мөрәҗәгать итә. Галәдә 4 кеше яши, шул исәптән түшәктә ятучы авыру, коммуналь фатирда антисанитар шартларда тораллар. Баланың ата-анасы беркайда да эшләмиләр, спиртлы эчемлекләр белән мавыгалар.*

Гр. М., бала язмышына битараф булмаган башкалар белән бергә, берничә мәртәбә әлеге фактлар буенча опека һәм попечительлек органнарына, хокук саклау органнарына бала мәнфәгатьләрен яклау буенча чаралар күрүне үтенеп мөрәҗәгать иткән. Әмма гаиләдәге хәлләрне тиешле хезмәтләр тарафыннан тикшерү уздырылмаган һәм чаралар күрелмәгән.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан, социаль яклау органнары һәм районның балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе вәкилләрен җәлеп итеп, бу факт буенча, гаиләгә барып, тикшереү уздырылды. Хәбәрдә күрсәтелгән фактлар расланды, начар шартлар ачыкланды. Тикшерү йомгаклары буенча гаилә, социаль куркыныч хәлдәге гаилә буларак, исәпкә куелды.

Беркадәр вакыттан соң гаиләдә бала сәламәтлегенә һәм гомеренә куркыныч тудыра торган хәл булды, шуннан соң балигъ булмаган баланың анасының – гр. Г.ның – ана хокукын чикләү турында карар кабул ителде.

Бала яши торган гаилә белән тиешле профилактик эшләр оештырмыйча ата-аналар яисә балалар гаризасы буенча йә тиешле органнар карары белән балаларны проблемалы гаиләләрдән тартып алу практикасы дәвам итә. Республика социаль приютларын тикшерүләр барышында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил социаль приютларга дәүләт кайгыртуына вакытлыча урнаштырылган балаларны яши торган гаиләләрнең исәпкә куелмавын һәм шундый гаиләләргә реабилитация чараларының күрелмәвен билгеләп үтте.

Мондый очраклар 2017 елда түбәндәге районнарның органнарында – профилактика субъектларында ачыкланды:

Азнакай муниципаль районы;
Әлки муниципаль районы;
Баулы муниципаль районы;
Буа муниципаль районы;
Биектау муниципаль районы;
Алабуга муниципаль районы;
Зеленодольск муниципаль районы;
Кама Тамагы муниципаль районы;
Лениногорск муниципаль районы;
Минзәлә муниципаль районы;
Нурлат муниципаль районы;
Тәтеш муниципаль районы;
Чаллы шәһәре.

Моннан тыш, гаиләләрдә проблемаларны ачыклау буенча кайбер органнарның – профилактика субъектларының эше тиешенчә куелмаганлыктан балалар гомеренә һәм сәламәтлегенә карата җинаятьчел очраклар барлыкка килде.

Мәс., 2017 елның октябрендә гр. Г.ның Бөгелмәдә яшәү урыны буенча үле гәүдәсе табылу турында хәбәр килде. Әлеге җинаятьне кылуда аның белән бергә яшәүче кеше сак астына алынды.

Гр.Г. элек балалар йортында торган булган, 2016 елның декабрендә махсуслаштырылган торак фондыннан аңа фатир бирәләр һәм ул кечкенә балалар һәм никахсыз килеш ир-ат белән бергә тора башлый.

Гр.Г. 2015 елдан бирле органнар – гаиләне профилактикалау субъектлары күзәтүендә торган, Бөгелмә шәһәрендә ата-аналар бурычларын тиешендә үтәмәгән өчен Административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә административ җаваплылыкка тартылган. 2016 елда балалар социаль приютта яшәгәннәр.

2016 елның октябрендә гр.Г. Балалары һәм никахсыз ире белән Әлмәткә күчеп киләләр, анда да балаларына тиешле тәрбия бирмәгән өчен 2017 елның июлендә Административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә административ җаваплылыкка тартылган. Балаларны гаиләдән алып, вакытлыча балалар шәһәр хастаханәсенә урнаштыралар.

2017 елның 30 августында гр.Г. никахсыз ире белән Бөгелмәгә яңадан кайта, балаларныда ала, 2017 елның 6 оетябрендә өченче бала тудыра. 2017 елның октябрь ахырында берничә мәртәбә хөкем ителгән, никахсыз ире гр. Г.ны үтерә. Балаларны үлгәнаналары белән бергә бикләп калдыра. Фатирга беркемне дә кертми, ә балалар белән аналарын киттеләр дип аңлата.

Менә шулай балалар гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янавы ачык булса да, гр.Г. профилактик исәптә тормаган. Бөгелмә һәм Әлмәт муниципаль районының гаиләне профилактикалау органнарының битарфлыгы, вакытында ведомствоара контроле оештырылмаганлыктан аныс ахыры трагедия белән тәмамалана, балаларны көчкә коткарып калалар.

Шуларданчыгып, балалар проблемаларын профилактикалау органнарының – субъектларының гаиләләрдәге проблемаларны вакытында ачыклаган һәм аларны җиңеп чыгу буенча нәтиҗәле эш оештырган өчен җаваплылыгын арттырырга кирәк дип саныйбыз. Бүген начар хәлдәге гаиләләрне вакытында ачыклау вазыйфаи затның хокукы дип түгел, ә аның бурычы дип саналырга тиеш.

Өченчедән, балаларны гаиләдән тартып алу вәзгыятен мониторинглау бу өлкәдә органнарның – профилактикалау субъектларының эше җитәрлек булмавын дәлилли. Федераль законнар нигезендә балаларны гаиләдән тартып алу һәм аларны социаль приютларга, балалар йортларына, сабыйлар йортына урнаштыру өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

ата-аналарны ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яисә аны чикләү турында суд карары нигезендә (Россия Федерациясе Гаилә кодексының 69, 73 статьялары);

баланың гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркынч янганда Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 статьясы нигезендә опека һәм попечительлек органнары карары белән;

балигъ булмаганнарның сукбайлыгы һәм күзәтүчесез калуы эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләренең актлары буенча ачыклануы;

авыр тормыш хәленә бәйле рәвештә ата-аналарының гаризасы буенча;

балигъ булмаган баланың шәхси үз мөрәҗәгате буенча.

Әлеге нигезләр исемлеге хәлиткеч була һәм киңәйтеп алатылмый.

Балигъ булмаганнарны гаиләдән тартып алу практикасын (күрелә торган чараларның чамадан тыш булу-булмавын һәм гаиләгә хокукны бозып тыкшынуларны) һәрьяклап анализлау максатларында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның 2017 елның 30 гыйнварындагы № 4606-МР йөкләмәсен үтәү йөзеннән Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында Эшче төркем төзү турында» 2017 елның

3 февралендәге № 5 боерыгы белән Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында Эшче төркем төзелде.

Аның составына кызыксынучы министрлыклар, ведомстволар вәкилләре, Россия Федерациясенең иҗтимагый палатасы әгъзалары, балалар мәнфәгатьләрендә эшли торган коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләре керде. Эшче төркемнең рәисе булып Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил билгеләнде.

Күчмә тикшерүләр йомгаклары буенча гаиләдән балаларны алуның 7 фактыннан 5есендә (Казан – (2), Елабуга, Зәй, Чаллы шәһәрләрендә) мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылган дигән дәлилләре акланмады. Башкарылган гамәлләр законлы һәм балаларны яклау мәнфәгатьләрендә булган.

Ә калган 2 факт буенча (Чистай һәм Зеленодольск шәһәрләрендә) мөрәҗәгать итүчеләрнең муниципаль район хакимияте органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар хокуклар бозылган дигән дәлилләре расланды. Шуңа бәйлерәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан районнар җитәкчеләре исеменә балаларны социаль приютлардан гаиләләренә кичекмәстән кайтарып бирү турында тиешле таләпләр җибәрелде, һәм алар үтәлде.

Мөрәҗәгатьләрне анализлаудан күренгәнчә, 2017елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына кергән мөрәҗәгатьләрнең 11еннән 9 очракта гаиләләрдән балаларның законсыз алынуы турында иде. Урыннарга чыгып тикшерү нәтиҗәсе буенча 7 факт буенча (Казан ш.– (3 факт), Чаллы ш. – (1 факт), Алабуга ш. – (1 факт), Минзәлә м.р. – (1 факт) Зәй м.р. – (1 факт) гаиләдән балаларны алу законлы, нигезле һәм балалар мәнфәгатьләрендә эшләнгән дип танылды.

Чистай шәһәрендә балларны гаиләдән алу факты буенча: 2017 елның 7 февралендә Чистай шәһәренең «16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУендә ПДН хезмәткәрләре дәрес вакытында ике баланы алып китәләр, бу «Балигъ булмаганнарны социаль реабилитациягә мохтаж балигъ булмаганнар өчен учреждениегә урнаштыру турында» ПДН акты нигезендә башкарыла. Балаларны Алексеевск муниципаль районындагы «Забота» («Кайгырту») балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют» ДКУенә урнаштыралар.

Әлеге акт балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссия инспекторы тарафыннан төзелгән була. Балаларны приютка урнаштыру өчен нигез буларак, ата-аналарының балаларын тәрбияләүдән баштаруы һәм аларның спиртлы эчемлекләр белән мавыгуы күрсәтелә. Актта балаларның күзәтүчесез калуы һәм сукбайлыгы турында мәгълүмат юк, ә балаларны белем бирү учреждениесеннән алып китәләр. Ә шул ук вакытта калган ике балигъ булмаган бала (2005 һәм 2014 елгылар) гаиләдә ата-аналары белән яшиләр.

Эшче төркем тикшергән әлеге факт буенча, балаларны мәктәптә, шулай ук гаиләдән алып, социаль приютка урнаштыру нигезсез дип танылды. Гаилә контроль,гә алынды, балаларгаиләгә кайтарылды.

Зеленодольск районында балигъ булмаган баланы гаиләдән алу факты буенча түбәндәгеләр ачыкланды. 2016 елның 13 декабрендә Зеленодольск районының опека һәм попечительлек органына балигъ булмаган Б.ның әнисе гр.Б.ның исерек хәлдә булуы турында хәбәр килә. Ә бала бу вакытта югары температура белән туганнарында була. Бала булган фатирга килгәч, ведомствоара комиссия вәкилләре ашыгыч медицина ярдәме чакыралар.

Ә ашыгыч ярдәмнең килү тоткарлана, шуңа күрә опека һәм попечительлек органы баланы «Зеленодоль ҮРХ (ЦРБ)» ДАССУенә алып китү турында карар кыла. Бала опека һәм попечительлек бүлеге белгече һәм ПДН инспекторы белән берлектә хастаханәгә китерелә. Элек бала авария хәлендәге фатирда әнисе белән яшәгән, анасы еш кына алкоголь белән мавыкканлыктан, опека һәм попечительлек органы башлыгы тарафыннан баланы «Гнездышко» балалар һәм яшүсмерләр приюты» ДКУенә урнаштыру турында мөрәҗәгать әзерләнә.

Икенче көнне иртән бала хастаханәдән «Гнездышко» балалар һәм яшүсмерләр приютына китерелә. Баланың анасы исерек хәлдә булганга күрә аңа баланы бирмиләр.

Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең 2017 елның 12 гыйнварындагы карары белән ЭЭМның Зеленодольск районы буенча вәкаләтле участок комиссиясенә һәм балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау бүлегенә Б.ны ата-ана хокукыннан мәхрүм итү өчен материаллар җыю йөкләнә. 2017 елның 13 гыйнварында Б.ны ата-ана хокукыннан мәхрүм итүгә материал опека һәм попечительлек органына керде. 2017 елның 15 гыйнварында Зеленодольск шәһәр судына гр. Б.ны ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турында дәгъва бирелә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Эшче төркем тарафыннан вакыйганы анализлау буенча опека һәм попечительлек органының гамәлләре законсыз дип таныла. Бала приюттан вакытлыча туганнары опекасына тапшырыла.

Әлеге фактлар социаль приютларда тәрбияләнүче балаларны һәм алар турында материалларны өйрәнү барышында ачыкланган законсыз гамәлләр кылу очраклары булуын күрсәтә. Республиканың түбәндәге районнарында балаларны гаиләдән законсыз тартып алу очраклары дәвам итә

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр карарлары нигезендә:

Азнакай муниципаль районында;

Баулы муниципаль районында;

Буа муниципаль районында;

Тәтеш муниципаль районында;

Нурлат муниципаль районында;

Зеленодольск муниципаль районында;

опека һәм попечительлек органнары карарлары буенча:

Азнакай муниципаль районында;

Тәтеш муниципаль районында;

Нурлат муниципаль районында;

Зеленодольск муниципаль районында;

Буа муниципаль районында;

белем бирү оешмалары карарлары буенча:

Азнакай муниципаль районында;

Баулы муниципаль районында;

Чаллы шәһәрендә.

Бигеләп үтелгәнчә һәм тикшерү йомгаклары буенча, күпчелек очракта күрсәтелгән органнарның гаиләдән балаларны алулары балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатында башкарылган дип танылды. Әмма аларны юридик яктан рәсмиләштерү законга таянып эшләнмәгән очраклар бар.

Һәр шундый очрак буенча адекват чаралар күрелде. 2017 елда эш визитлары һәм тикшерү йомгаклары буенча муниципаль районнар башлыклары адресына шул темага Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 17 бәяләмәсе җибәрелде.

Моннан тыш, 2017 елда баланың гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч туганда баланы гаиләдән алу турында *опека һәм попечительлек органнарының карарлары* Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 статьясы буенча *тиешенчә рәсмиләштерелмәгән булу* фактлары да ачыкланды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Биектау районына визитлары буенча 2016-2017 еллар чорында Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 ст. нигезендә балигъ бул-

маганнарны кичекмәстән ата-аналарыннан алу турында җиде акт төзелде. Нәтиҗәдә суд карарлары белән ата-ана хокукларынннан мәхрүм ителделәр яисә аларның хокуклары чикләнде.

Шул ук вакытта балаларны ата-аналарыннан алуга нигез булган документларның юридик яктан төгәл рәсмиләштерелмәгән булулары да ачыкланды. Опека һәм попечительлек органнары тарафыннан Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 ст. буенча балаларны гаиләдән алуга карата тиешенчә рәсмиләштерелмәгән йә законсыз рәсмиләштерелгән карарлар кабул итүне булдырмау максатларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Прокуроры И.С.Нәфиков адресына опека һәм попечительлек органнарының Гаилә кодексының 77 статьясындагы 2 өлеше тәртибендә гаиләләрдән балаларны алу турындагы актларының законлылыгына прокурор күзәтчелеген көчәйтү тәкъдиме белән мөрәҗәгать җибәрде.

Дүртенчедән, хәтәр төркем гаиләләрен ***реабилитацияләү эшенең сыйфатына*** җитди дәгъвалар керү дәвам итә. Бу эшне оештыруга карата балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча буенча муниципаль комиссияләр ягыннан тиешле контроль булмау да борчый.

1. Кызганычка каршы, элеккечә, индивидуаль реабилитацияләү программаларын (алга таба – ИПР) төзегәндә һәм чараларын үткәргәндә билгеле бер калыплардан чыгып кына эш йөртелә, *формаль ысуллар* кулланыла. Бу балалар өлкәсендә эшләүче белгечләрнең квалификациясе түбән булуны һәм үз вазыйфаларына салкын карауны раслый. Мәсәлән, гаиләләрнең начар тормышлы булу сәбәпләренә ясалган анализ начар гаиләләрнең авыр һәм куркынычлы яшәү шартларында калуның төп сәбәбе – ата-аналарның алькогольле эчемлекләр белән мавыгуы. Начар гаиләләрне тернәкләндерү эшенең индивидуаль программасына алкоголизм бәйлелегеннән дәвалауның кермәве дә гаҗәп тоела. ә бу исә программаның башка тернәкләндерү чараларын үткәрүнең мәгънәсез һәм файдасыз булуын раслый.

Мисал: *Әлки муниципаль районында социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрнең шәхси эшләрен өйрәнгәндә ата-аналарның алкогольгә бәйлелеген бетереүгә карата бернинди дә үтемле гамәлләр башкарылмаган булуы ачыкланды. Ведомствоара исәптә торучы 14 гаиләнең 8е ата-аналарның эчкечелеккә бәйле булулары аркасында тора, әмма ИПРда бу проблеманы хәл итүгә юнәлдерелгән чаралар юк. ИПР чаралары социаль яклау органнары тарафыннан оештырыла торган эшләр белән чикләнә. Аерым алганда, болар әңгәмәләр кору юнәлешендә, алар алкогольгә бәйлелекне профилактикалауда уңай нәтиҗәләр бирми.*

Мисал: *Балтач муниципаль районында социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрне реабилитацияләү программасын һәмбалаларны гаиләдән алып приютларга озату буенча документларны өйрәнгәндә законнарның тупас бозылуы, ведомствоара эшнең түбән дәрәҗәдә булуы, программаны гамәлгә ашыруның барышына контроль булмау ачыкланды. Гаиләләрне реабилитацияләү программасына субъектларның барысы да кертелмәгән. Особую озабоченность вызывает отсутствие межведомственного взаимодействия в Балтасинском муниципальном районе при реализации проекта Бигрәк тә «Аек акыл» проектын гамәлгә ашырганда Балтач муниципаль районында ведомствоара хезмәттәшлекнең булмавы борчу тудыра.*

Татарстан Республикасында «Аек акыл» пилот проектын гамәлгә ашыру нигезенә балалар мәнфәгатьләрендә һәм балигъ булмаганнарның әниләрен алкогольгә бәйлелелектән дәвалауга социаль юнәлдерелгән алым салынганын истә тотып, аларның ата-ана хокукларын чикләү йә аларны ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү мәсьәләсен билгеләнгән тәртиптә караганда проектта катнрашучы гаиләләр социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр буларак ведомствоара исемлеккә кертелергә тиеш иде.

Шул ук вакытта, Балтач муниципаль районында әлеге проектта катнашучы 4 гаиләнең берсе генә ведомствоара исәптә тора. Ә калган өч гаилә профилактикалау субъектлары игътибарыннан читтә калды. «Аек акыл» пилот проектында катнашучы гаиләләрне

анализлаудан күренгәнчә, аларга карата да формаль чаралар гына күрелгән, проект чаралары гаиләне яләү программасында юк.

Шулай итеп, ведомствоара эш башкарылмау, кызыксынмау, проектны гамәлгә ашыруга формаль карау, проектта катнашучы гаиләләргә контроль булмау аркасында проектта катнашучы дүрт гаилә дә алкоголь куллануны дәвам итәләр.

Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр эшчәнлегендә ведомствоара исәптә торучы уңышсыз гаиләләрнең нәтиҗәле адекват ИПРларын төзү эшенең түбәндәге районнарда җитәрлек булмавын билгеләп үтәргә кирәк:

Алабуга муниципаль районында,

Лениногорск муниципаль районында,

Минзәлә муниципаль районында.

2. Имин булмаган гаиләләрне тернәкләндерү эшенең барышына тиешле контроль булмау ***гаиләләрнең озак вакыт социаль куркыныч хәлдә калуларына*** китерергә мөмкин. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белешмәләре буенча, 2017 елда ведомствоара исәптә торган 865 гаиләнең тернәкләндерү срогы 1 елга кадәр сузылды, 1 елдан 2 елга кадәр – 187 гаилә һәм 2 елдан артыкка – 53 гаилә. Шуны да әйтергә кирәк, 2016 ел белән чагыштырганда тернәкләндерү срогы 1 елдан кимрәк булган гаиләләр саны 229 гаиләгә (48%ка) кимеде.


Моннан тыш, балигъ булмаганнарны социаль тернәкләндерүнең уртача срогы 4,9 ай булды, 367 бала 6 айдан 1 елга кадәр булды, приютта 1 елдан артык 14 бала торды (2016 елда 80 бала)., кимүгә һәм 5,4 айга калуга карамастан, приютта 474 бала 6 айдан алып бер елга кадәр, 80 бала елдан артык яшәгән (2015 елда – 63 бала). Безнең фикеребезчә, социаль приютларда яшәүче балигъ булмаганнарның тормышларын алга таба яхшырту бурычларын тиз арада хәл итүгә комачаулый торган төп сәбәпләргә, элеккечә, гаиләдә тернәкләндерү чараларын оештыруның һәм уздыруның нәтиҗә бирми торган һәм һөнәри дәрәҗәдә булмаган алымнарын куллану да керә.

3. Начар гаиләләрне тернәкләндерү эшчәнлегенең сыйфатын билгели торган төп критерийны мондый эшчәнлекнең ***нәтиҗәлелеге*** күрсәтә.

2017 елдагы ведомствоара мәгълүмат системасындагы исәптән төшерүләр тернәкләндерүнең уңай нәтиҗәсен күрсәтә. 2016 ел белән чагыштырганда ул 84%ка кадәр җитте. Уңай тернәкләндерүгә ирешмичә исәптән төшерелгән гаиләләр саны 17,7%тан 16,0%ка калды.

90 нче диаграмма

2013-2017 елларда гаиләләрне ведомствоара исәптән төшерү нигезләре динамикасы




Моннан тыш, социаль куркыныч хәлдә булган гаилә буларак кабат ведомствоара исәпкә куелган гаиләләрнең саны 10 мәртәбәгә кимүе игътибар җәлеп итә. 2016 елда 71 гаилә кабат исәпкә куелган булса 2017 елда бары тик шундый 7 гаилә генә теркәлгән.

Һичшиксез, институциональ учреждениеләрдә тернәкләндерелгәннән соң балаларның тормышларын җайга салу вәзгыяте дә әһәмияткә ия. Мондый вәзгыятькә анализ диаграммада күрсәтелә.

91 нче диаграмма

2017 елда социаль приютларда тернәкледерелгәннән соң балаларны тормышка җайлаштыру



Шулай итеп, 2017 елда махсуслаштырылган учреждениеләрдә тәрбияләнүчеләрнең 76%тан артыграгы үз гаиләләренә кире кайтарыла.

Монда социаль куркыныч хәлдә булган гаилә буларак 2016 елда кабат ведомствоара исәпкә куелган гаиләләрнең саны игътибар җәлеп итә. әгәр 2015 елда 73 гаилә кабат исәпкә куелган булса (143 бала), 2016 елда 71 шундый гаилә теркәлгән (147 бала).

Шуны билгеләп китәргә кирәк, 2017 елда элек тернәкләндерү узып, кабат приютларга эләккән балалар саны 27гә кимеде, ел дәвамында 7 бала гына приютка кире кайтарылды (2016 елда – 38 бала, шулардан ел дәвамында 38е дә кире кайтарылды).

4) Тернәкләндерү эшен оештыруны бәяләүнең тагын бер критерийларыннан берсе – *ата-ана хокуклары вакытлыча чикләнгән ата-аналар белән тернәкләндерү эшләрен алып баруның уңышлы булуы.*

Кызганычка каршы, республикада бу юнәлештә артык үзгәрешләр күзәтелми. Берничә ата-анага карата гына чикләүләр юкка чыгарылган иде. 2017 елда суд карары белән 162 гражданның ата-ана хокуклары чикләнде, алты ай узгач 18 ата-ананың гына чикләүләре бетерелде һәм ата-аналар үз балаларын тәрбияләү хокукларын кайтара алдылар (2015 елда – 16 кеше, 2016 елда – 17 кеше).

2017 елда ата-ана хокукларына чикләү чарасы бөтенләй кулланылмады һәм түбәндәге муниципаль районнар органнары – профилактика субъектлары тарафыннан башта ук ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турындагы мәсьләлә куелды: Әлки (8 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Апас (7 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Арча (3 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Әтнә (4 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Буа (9 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Чүпрәле (1 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Мамадыш (7 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Мөслим (1 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Яңа Чишмә (3 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Спас (7 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Тәтеш (5 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Теләче (3 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Тәтеш (5 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Тукай (9 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде). Бу

чара Баулы, Бөгелмә, Биектау, Түбән Кама, Нурлат, Чистай муниципаль районнарында да актив кулланыла.

5) Гаиләләрне авыр яшәү шартларыннан чыгару буенча тиешле хезмәтләрнең эше торышын бәяләүнең тагын берсе – *баланың тормышына яки сәламәтлегенә җитди һәм чын куркыныч янаганда* опека һәм попечительлек органының баланы тиз арада ата-анасыннан тартып алуы. Бу чара Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 статьясында каралган, һәм ул баланың гаиләгә хокукы аның башка нигез хокуклары белән каршылыкка килгәндә балаларның хокукларын яклауның иң соңгы чарасы буларак кулланыла.

Әлеге чара түбәндәге үзенчәлекләргә ия:

1) баланың гомеренә, сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янау, бу балага физик, психик йогынты ясауда, баланы куркыныч хәлдә, караучысыз, киемсез, азыксыз калдруда чагыла;

2) балага куркыныч янауны оператив рәвештә бетерү;

3) әлеге чара ата-аналарга карата гына түгел, ә бала тәрбиядә торган башка затларга карата да кулланылырга мөмкин;

4) баланы тартып алу турындагы карар административ характерга ия; баланы тартып алу Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органының тиешле акты йә муниципаль берәмлек башлыгы акты (Россия Федерациясе субъекты законы белән җирле үзидарә органыннарына опека һәм попечительлек буенча вәкаләтләр тапшырылганда) нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан башкарыла;

5) мондый чараны куллану турында прокурорга хәбәр ителергә тиеш. Әгәр прокурор бу чара белән килешмәсә, кеше һәм граждан хокукларын боза торган актны чыгарган органга яисә вазыйфаи затка карата каршылык чыгарырга йә Россия Федерациясе процессуаль законнарында каралган тәртиптә судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы;

6) административ акта чыгарылган көннән җиде көн дәвамында опека һәм попечительлек органы ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү яисә чикләү турындагы дәгъва белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы;

7) административ органнарның теләсә нинди гамәлләренә, опека һәм попечительлек органнарының гамәлләренә карата судка шикаять бирелергә мөмкин.

Баланы тартып алу иң чик һәм оператив чара булып тора, моның өчен баланың гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янау фактын билгеләү таләп ителә. Баланы тәрбиләү өчен уңайрак шартлар тудыру дигән факт аны ата-аналарыннан тартып алу буенча чаралар куллану чарасы үзен акламый; гаилә тормышында ата-ана хокукларына мондый тыкшыну зарурлыгын күрсәтә торган башка шартларның булуын таләп итә, болар Кеше хокукларын һәм аны ирекләрен яклау турындагы конвенциянең 8 статьясында беркетелгән.

Республикада бала гомеренә һәм сәламәтлегенә җитди һәм реаль куркыныч янаганда балаларны ата-аналарыннан алу (77 статья, Россия Федерациясе Гаилә колексы) процедурасы белән вәзгыятьнең ничек булуы түбәндәге таблицада күрсәтелә.

26 нчы таблица

Күрсәткеч	2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел	2017 ел
Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 статьясында каралган нигезләр буенча гаиләдән алынган балалар саны	108	99	122	63	50
шулардан социаль– тернәкләндерү уздырылганнан соң ата-аналарына кире кайтарылган балалар саны	39 (36,1%)	39 (39,4%)	24 (19,6%)	23 (36,5%)	13 (26%)

Шуны да танырга кирәк, 2017 ел йомгаклары буенча бала гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янау аркасында ата-аналарыннан алынган балалар саны 13кә (20,6%) кимеде һәм 50 бала тәшкил итте. Шул ук вакытта социаль– тернәкләндерү уздырылганнан соң ата-аналарына кире кайтарылган балалар саны да 13кә (26%) кимеде.

Имин булмаган гаиләләр проблемаларын анализлау йомгаклары буенча шуны әйтергә кирәк, бу юнәлештәге эшләр түбәндәге төп принципларга нигезләнергә тиеш:

ата-аналарның үз балаларын тәрбияләү хокукы башка затларныкыннан өстенрәк булуы;

баланың ата-анасыннан аерылмау һәм гаиләдә тәрбияләнү хокукын, аның гармоние-ле үсешенең һәм иминлегенең катгый шарты буларак, дәүләт тарафыннан тәэмин ителү өстенлеге;

ата-аналар тарафыннан балигъ булмаган балаларын тиешенчә карауны, укытуны, ял иттерүне һәм савыктыруны, аларның хокукларын яклауны, җәмгыятькә яраклаштыруны тәэмин итү максатларында дәүләтнең гаиләгә һәрьяклап ярдәм итүе;

балигъ булмаган балалары булган гаиләләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозган өчен вазыйфаи затларның һичшиксез җаваплы булуы.

Шулай итеп, республикада проблемалы гаиләләр белән эшләүне камилләштерүгә юнәлдерелгән чаралар күрелә дип танырга кирәк. Шулай да, имин булмаган гаиләләр белән индивидуаль профилактика һәм тернәкләндерү эшен оештыру эшчәнлеген көчәйтү, камилләштерү, активлаштыруның өстәмә чараларын күрүне һәм инновацион эш модельләрен булдыруны таләп итә.


3.4.2. Социаль ятимлек проблемалары

Социаль ятимлек Россия чынбарлыгының аеруча аянычлы күренешләреннән берсе.

Татарстан Республикасында 2017 ел азагына ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган һәм опека һәм попечительлек органнарында исәптә торучы балаларның саны 11 482 кешебулды, шулардан бары тик 2 340 кеше, ягъни 20,4%,ы гына ятитм бала статусында.

92 нче диаграмма


2008 – 2017 елларда ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар саны



2017 елда әлеге категориядәге беренче тапкыр ачыкланган балаларның гомуми санында ятим балалар 20,6% яки 212 бала тәшкил итте (2016 елда – 19%, яисә 207 кеше).

93 нче диаграмма

2008 – 2017 елларда беренче мәртәбә ачыкланган ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар саны




Шулай итеп, гаилә мохитеннән мәхрүм ителгән балаларның иң зур өлешен, гадәттәгечә, ата-ана каравыннан мәхрүм ителгән балалар, икенче төрле әйткәндә, ***социаль ятимнәр*** алып тора. 2017 ел йомгаклары буенча ул 79,4% тәшкил итте.

Беренче мәртәбә ачыкланган ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм ителгән балалар арасында социаль ятимнәрнең беркадәр кимүе күзәтелә (2016 елда – 885, 2017 елда 817).

Социаль ятимлекнең төп сәбәпләреннән берсе булып ата-аналарның берсен яисә икесен дә ***ата-ана хокукыннан мәхрүм итү*** кала. 2017 елда 624 бала, яки 76,4%, тулы булмаган гаиләдә атасының яки анасының яисә ата-анасының икесенең дә ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителүе сәбәпле ятим булып калды.

94 нче диаграмма

2008-2017 елларда ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калуы ачыкланган балалар саны




Ата-ана хокукларыннан мәхрүм итүнең төп сәбәпләренә ата-аналарның үз балаларын тәрбияләү вазыйфаларын үтәүдән качулары, үз гамәлләре белән яки гамәл башкармаулары белән балаларның гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч яный торган шартлар тудыру, ата-аналарның үз балаларына карата рәхимсезлек кылу яисә аларга карата җинаять башкару керүдән күренгәнчә, ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү һәрвакытта да балаларның һәм гаиләнең начар тормышлы булуын аңлата. Шуңа күрә ***төп сәбәпләрнең берсе имин булмаган гаиләләр кала***.

Шуңа бәйлерәвештә, социаль ятимлекне профилактикалауның бүгенге көнгә булган төп бурычы имин булмаган гаиләләрне башлангыч вакытында ук ачыклау һәм тернәкләндерү буенча эшчәнлекне тиешенчә оештырудан гыйбарәт (әлеге мәсьәлә буенча вәзгыятькә бәя 3.3.1 бүлегендә бирелде).

Социаль ятимлекнең төп сәбәпләреннән берсе – ата-аналарның яңа туган үз балаларын медицина оешмаларыннан алып чыгудан ***баш тартуы*** бүген дәактуаль булып кала. 2017 елда ата-аналары гаиләгә алудан баш тарткан яңа туган сабыйлар санының кими бару тенденциясе дщвам итте. Соңгы ун елда бу иң түбән күрсәткеч.

95 нче диаграмма

2008-2017 елларда ата-аналары балаларын гаиләгә алудан баш тарткан балалар саны



Республикада социаль ятимлекнең тагын бер проблемасы – бүгенге җәмгыятьнең корылышы: туганлык җепләре өзелгән, еш кына кешеләр ярдәмгә мохтаж булып берүзләре кала. Шуңа бәйле рәвештә гаиләнең финанс-матди яктан авыр хәлгә юлыгуы балалардан баш тартуга китерә.

Үз балаларын медицина оешмаларыннан алып чыгудан ***баш тартуны профилактикалау максатларында*** авыр тормыш хәлендә калган хатын-кызларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән органнарның һәм хезмәтләрнең эшчәнлеген популярлаштыру эшен дәвам итәргә кирәк.

Мондый балаларны алга таба гаиләгә урнаштыру хәле тотрыклы булып кала. 2017 елда 65 «баш тартылган» яңа туган баланың 57се (яки 87,7%) ел дәвамында гаиләләргә урнаштырылды (2016 елда бу күрсәткеч 81,4% тәшкил итте).

Социаль ятимлек проблемаларын хәл итү буенча вәзгыятьне анализлау барышында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең еллык докладларында ***ата-аналарны ата-ана хокукларында чикләү тәҗрибәсенең*** тиешле дәрәҗәдә үсеш алмавында күренә. Бу проблема быел да сакланып кала.

Ата-ана хокукларын чикләүнең төп максаты балага имин тормыш тәэмин итүдән, аның хокукларын һәм сәламәтлеген саклаудан гыйбарәт. Суд тарафыннан ата-ана хокукларын чикләү түбәндәге функцияләрне үти:

кисәтү функциясен яисә профилактикалау): хокукларны чикләү бала тәрбияләүгә җавапсыз карау аркасында тагын да хәлләрне тагын да катлауландырырга мөмкин булу сигналы итеп каралырга мөмкин;

каратель функциясе: ата-ана вазыйфасын башкара алмаучыга карата суд тарафыннан билгеләмә чыгаруны җәза чарасы дип карарга кирәк;

тәрбияләү функциясе:үз гаепләрен таныган һәм торак шартларын, матди хәлен һәм тормыш рәвешен нигездән үзгәртү чараларын күргән ата-аналар суд тарафыннан чикләүләрдән аәат ителергә һәм баласын гаиләгә кайтарырга мөмкин.

Шулай итеп, балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләр кылуның илкүләм стратегиясендә ата-ана хокукларыннан мәхрүм итүнең ата-ана хокукларын чикләүгә алмаштырылуының максатка ярашлы булуы балаларга сакчыл булу гаилә сәясәтенең өстенлекле юнәлеше буларак каралган. Мондый механизмны куллану бала өчен аның гаиләсен саклап калуда тагын мөмкинлек. Ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү гаилә-хокук җавалылыгының иң чик чарасы булырга тиеш.

Шул ук вакытта, 2017 елда ата-ана хокукларын чикләүне куллану тәҗрибәсе 2016 ел белән чагыштырганда үзгәрмәде диярлек. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматына караганда, 2017 елда ата-ана хокуклары чикләнгән гражданнарның саны 162 кеше тәшкил итте, 2015 елда – 160 кеше.

27 нче таблица

2010-2017 елларда ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән һәм ата-ана хокуклары чикләнгән гражданнар саны

Гражданнар категориясе	2010 ел	2011 ел	2012 ел	2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел	2017 ел
Ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән һәм ата-ана хокуклары чикләнгән гражданнар, шул исәптән:	1230	1134	994	971	990	915	869	998
ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән	1135	1030	902	876	849	784	709	836
ата-ана хокуклары чикләнгән	95	104	92	95	141	131	160	162
ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән һәм ата-ана хокуклары чикләнгән гражданнарның гомуми санныннан ата-ана хокуклары чикләнгән гражданнар өлеше	7,7	9,2	9,3	9,8	14,2	14,3	18,4	16,2

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәлүен тикшереп торуны тәэмин итүче орган буларак, түбәндәге тәкъдимнәргә игътибар итәргә кирәк:

республикада ата-ана хокукларыннан мәхрүм итүне кисәтергә мөмкинлек бирә торган гаилә-хокук җаваплылыгы чараларының күпбаскычлы системасын куллануны аерым контрольгә алырга;

ата-аналарны ата-ана хокукларыннан мәхрүм итүгә кадәр ата-ана хокукларын чикләүгә өстенлек бирү практикасын файдалануны дәвам итәргә кирәк;


гаиләсеннән баланы алып һәм алмыйча ата-ана хокукларын чикләүне куллану тәжрибәсен анализларга кирәк.

Татарстан Республикасында социаль ятимлекнең ***дүртенче проблемасы*** итеп ***ата-ана хокукларын кире кайтару һәм аларга карата чикләүне бетерү институтының үсә алмавын*** күрсәтергә кирәк.

Кызганычка каршы, 2017 елда ата-ана хокуклары торгызылган ата-аналар саны 2016 ел дәрәҗәсендә диярлек кала (2016 елда – 37 кеше, 2017 елда – 35 кеше).

96 нчы диаграмма


2010-2017 елларда гражданнарның ата-ана хокукларын кире кайтару (кеше)



Ата-ана хокукларын чикләү кире алынган ата-аналарның саны һәрвакыттагыча бик аз санда. 2017 елда суд аша бары тик 18 ата-ананың ата– ана хокукларын чикләү кире алынды һәм алар үз балаларын тәрбияләү хокукларын кире кайтардылар (чагыштыру өчен: 2015 елда – 16 кеше, 2016 елда – 17 кеше).

97 нче диаграмма

2010-2017 елларда ата-ана хокукларын чикләүне бетерү (кеше)



Статистика күрсәткәнчә, ата-ана хокуклары чикләнгән 162 гражданнан бары тик суд аша 18е генә чикләүне бетерүгә ирешкәнен исәпкә алсак, димәк, республикада чикләү институты, ул кулланыла дип уйлаганда да, чынбарлыкта, эшләми дигәнне аңлата. Тиешле органнарның – гаилә һәм балалар иминлеген профилактикалау субъектларының төп бурычы – аны иң чик, соңгы чара итеп кулланырга, әмма бала өчен үз ата-анасында тәрбияләнү хокуын саклап калу мөмкинлеген дә табарга.

3.4.3. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру

2017 ел ахырына Татарстан Республикасында ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саны 11 482 кеше, ягъни гомуми балалар санының 1,4% тәшкил итте, бу индикаторның иң чик күрсәткеченнән 1,5%ка түбәнрәк.


Россия законнары, һичшиксез, балаларны гаиләдә тәрбияләүгә өстенлек бирә. Россия Федерациясе Гаилә кодексының 123 статьясы нигезендә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар гаилә тәрбиясенә (уллыкка (кызлыкка), опекага (попечительлеккә) яисә гаиләгә бирелергә тиеш, ә андый мөмкинлек булмаганда, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен булган барлык типтагы учреждениеләргә биререлгә тиеш.

Республикада максатчан юнәлештә эш алып бару нәтиҗәсендә төрле сәбәпләр аркасында ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру мәсьәләсендә

тотрыклылык күзәтелә. Хисап елы азагына бала алган гаиләләрдә 10 889 бала исәпләнә иде, ул ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның (алга таба – ятим балалар) гомуми санынннан 94,8% тәшкил итә. Әмма 2016 ел белән чагыштырганда гражданнар гаиләләрендә яшәүче балаларның гомуми саны да, шулай ук ятим балалар өлеше 261 балага кимеде, ягн 0,5%ка. Ятим балалар өчен булган дәүләт учреждениеләрендә 502 (4,4%) бала тәрбияләнә.

98 нче диаграмма


2008-2017 елларда ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру



Статистика хисапларына ясалган анализ шуны күрсәтә: 2017 елда 1012 ятим бала төрле рәвештәге гаиләләргә тәрбиягә урнаштырылды. Шулардан 634 (62,7%) бала түләүсез нигездә опекага (попечительлеккә) тапшырылды, 282 (27,8%) бала алучы гаиләләргә, 96 (9,5%) уллыкка алынды.

99 нчы диаграмма

2017 елда ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гражданнар гаиләләренең тәрбиясенә урнаштыру




Ел дәвамында гаиләләр тәрбиясенә тапшырылган ятим балаларның төп өлеше беренче мәртәбә ачыкланган балалар. Шулай итеп, гаиләгә тәрбиягә тапшырылган 1 012 ятим бала 2017 елда беренче мәртәбә ачыклана. Шул ук вакытта 693 (77,6%) бала, статуслары билгеләнгәч, тулысынча туганнары опекасына (попечительлегенә) бирелә.

2018 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында яшәүче ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның урнашуы диаграммада күрсәтелә.

100 нчы диаграмма


Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның 2018 елның 1 гыйнварына урнашуы



Балаларны гаиләгә урнаштыруның иң таралган рәвеше ***баланы бушлай туганнар гаиләсенә тәрбиягә бирү.*** 2018 елның 1 гыйнварына 4 235 опекун гаиләсендә 5 383 бала тәрбияләнде. Ләкин опекун гаиләләр санының да (2016 елда аларның саны 4 526), туганнарга опекага тапшырыла торган балаларның да саны кими (2016 елда -. 5 384 бала).

101 нче диаграмма


2008-2017 елларда опекада (попечительлектә) тәрбияләнүче балалар саны



2017 елда тәрбиягә бала алучы гаиләләр саны артты: 2016 елда 1 513 гаиләдән 2017 елда 1 527 балага кадәр. 2018 елның 1 гыйнварына 1 527 шундый гаиләдә 2 878 бала тәрбияләнде, шуның 5 һәм аннан күбрәк бала алган – 96 гаилә, 3 – 4 бала алган – 201 гаилә, 1–2 бала алган – 1 230 (80%) гаилә теркәлде. Шуны билгеләп үтәргә кирәк, 5 һәм аннан күбрәк балалар алучы гаиләр саны 84тән 96га кадәр артты, ягъни – 14,3%ка.

102 нче диаграмма

2008-2017 елларда бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар саны



2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гражданнар шикаятьләренә бәйле рәвештә ***8 һәм аннан күбрәк балалар алган күпбалалы гаиләләрдә*** балаларның хокукларын һәм иреклерен гмәлгә ашыруның торышын анализлый.

Балалар алучы гаиләләрне булдыру һәм балалар алган гаиләләрдә баланың (балаларның) тормыш шартларын тикшереп торуның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балигъ булмаган гражданнарны опекага һәм попечительлеккә алуны гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында» 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрендә балалар алучы гаиләләрдә, кагыйдә буларак, 8кә кадәр бала тәрбияләнә, дип язылган. Бу норма императив түгел, һәм аерым очракларда балалар алган гаиләләрдә аннан күбрәк бала да булырга мөмкин. Әмма конкрет очракта мондый карар опека һәм попечительлек органнары тарафыннан индивидуаль кабул ителергә тиеш, бары тик балалар мәнфәгатьләрен истә тотып кына. Балага гаилә сайлаганда шуны истә тотарга кирәк – бала алган гаилә ул – иң мөһиме гаилә булырга тиеш, шуннан соң гына яшәү һәм үзара хезмәттәшлек рәвеше карала.

Шуны да танырга кирәк, гаиләгә 8 һәм аннан күбрәк бала алган гаиләләр – тәрбиягә алган балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тиешенчә тәэмин итү күзлегеннән караганда, хәтәр төркемгә керүче гаиләләр булып санала. 2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан шундый гаиләләрдә балаларның хокуклары бозылу очраклары ачыкланган.

Шуңа күрә бу вәзгыять агымдагы елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең опека һәм попечительлек органнары белән бергә өйрәнү предметы булды. Анализдан күренгәчә, 2017 елның 1 ноябренә республика гаиләләрендә үзләренең һәм алган балаларының саны 8дән артык булган 30дан артык гаилә бар иде. «Күпбалалы» гаиләләр Азнакай муниципаль районында шактый күп яшиләр (4 гаилә, шулардан 2 гаиләдә 10нан артык бала тәрбияләнә), Нурлат муниципаль районында (5 гаилә, аларның 3сендә – 10нан артык бала), Мөслим муниципаль районында (3 гаилә). Тәрбиягә балалар алган 2шәр гаилә Бөгелмә, Зеленодольск, Лениногорск, Мамадыш муниципаль районнарында һәм Казан шәһәрендә. Иң күпсанлы гаиләләр Алексеевск муниципаль районында яшиләр (14 балалы, аларның барысы да алынган балалар) һәм Лаеш муниципаль районында (13бала, аларның 8е алынган балалар).


Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 8дән артык балалар булган гаиләләргә тәнкыйди карашта.

Шуңа бәйле рәвештә без балаларны гаиләләргә биргәндә опека һәм попечительлек органнарына тәрбиягә бирелә торган балалар санын чикләү турындагы Кагыйдәләргә таянырга тәкъдим итәбез.

2018 елны 1 гыйнварына 2 750 гаиләдә 2 876 уллыкка (кызлыкка) алынган балалар тәрбияләнә иде. Шулардан 5 балалылар – 5 гаилә, 3 – 4 уллыкка алынган – 10 гаилә, 1 – 2 балалылар – 2 735 гаилә.

103 нче диаграмма


2008–2017 елларда уллыкка (кызлыкка) алынган балалар саны



2017 елда ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруның өстенлекле рәвеше – уллыка (кызлыкка) алуның кимүгә таба бару тенденциясе сакланып калды. 2017 елда ел дәвамында уллыкка тапшырылган балалар саны 2016 ел дәрәҗәсендә калды диярлек (2016 елда – 92 бала, 2017 елда – 96 бала). Соңгы 10 елда уллыка (кызлыкка) тапшырыла торган балалар саны өч мәртәбә диярлек кимеде.

104 нче диаграмма


2008 – 2017 елларда уллыка (кызлыкка) алынган балалар саны



Уллыка (кызлыкка) алу процедурасын башкарганда балаларны Россия гражданнары гаиләләренә урнаштыруга өстенлек бирелә. Шулай итеп, 2017 елда уллыкка алынган 96 баланың 95е Россия Федерациясе гражданнарына тапшырылды, 1 – Италия гражданнары тарафыннан уллыкка алынды.

105 нче диаграмма

2008-2017 елларда уллыкка (кызлыкка) алу



Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә 2016 – 2017 еллардагы докладларында гражданнарны уллыкка (кызлыкка) балалар алуга, ***инвалид балаларны, сәламәтлеге чикле балаларны гаилә тәрбиясенә алуга*** кызыксындыру өчен өстәмә чаралар күрү мөмкинлеген карарга тәкъдим ителде. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алуга бәйле бер мәртәбәле өстәмә түләү турында» 2017 елның 13 июлендәге № 493 карары белән 2017 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алуга бәйле бер мәртәбә 200 мең сум күләмендә өстәмә түләү билгеләнде. 2017 елда республикада бу ярдәм чарасыннан 7 гаилә файдаланды.

Моңа уңай бәя буларак, шуны әйтергә кирәк, 2017 елда 45 инвалид бала гаиләгә бирелде, 2016 елда бу күрсәткеч – 39 бала иде, аларның 7се уллыкка (кызлыкка) алынды, ә 38е опекага һәм попечительлеккә тапшырылды, шул исәптән 26сы – гаиләгә алу шартнамәсе буенча.

Ел йомгаклары буенча, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда тәрбияләнүчеләр саны 485тән 502гә артты, шуннан 2017 ел ахырына тәрбиядә калучылар:

сабыйлар йортында – 52 бала;

балалар йортларында – 189 бала;

ятимнәр өчен VIII төрдәге интернат мәктәпләрдә – 62 бала;

интернат йортларда – 199 бала.

Башлыча, бу оешмаларда тәрбияләнүчеләрнең саны арту республика балалар йортларында тәрбияләнүче балалар саны артуга бәйле, ул 31%ка артты, 2016 елда 144 булса, 2017елда 189га җитте.

Региональ банк белешмәләренә караганда, ата-анасыннан мәхрүм калган балалар 2018 елның 1 гыйнварына 593 бала исәпләнә, бу узган елга караганда 26 кешегә күбрәк (01.01.2017 ел башына – 567 бала иде) (4,5%ка арткан). Аларның яшь составы түбәндәге таблицада бирелә.

28 нче таблица

2018 елның 1 гыйнварына ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар турында мәгълүматлар банкында булган балаларның яшь составы

Балаларның яше	Балаларның гомуми саны	Шулардан		Инвалидлыгы булганнар	Сәламәтлек мөмкинлеге чикле булганнар
		малайлар	кызлар		
0 – 3 яшь	39	21	18	5	-
3 – 5 яшь	25	16	9	12	-
5 – 7 яшь	40	22	18	17	12
7 – 10 яшь	72	42	30	41	44
10 – 14 яшь	160	102	58	105	116
14 – 18 яшь	257	167	90	103	132
Барысы	**593**	**370**	**223**	**283**	**304**

Ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар турында белешмәләр банкын анализлау шуны күрсәтә: агымдагы елда банкта исәптә тору балалар саны артса да, инвалид балалар саны кимегән – 320дән 283кә калган, ягъни 37 кешегә кимегән (2016 елда – 56,4%, 2017 елда – 47,7%), сәламәтлек мөмкинлеге чикле булган балалар саны 358дән 304кә калган, ягъни 54кә кимегән (2016елда – 63,1% , 2017 елда – 51,2%).

Узган ел белән чагыштырганда шулай ук 5 яшьтән 10 яшькә кадәрге балалар саны артты, 87дән 112гә җитте (25 кешегә, ягъни 28,7%ка арткан), ә бу яшьтәге инвалид балалар саны кимегән, 320дән 283кә калган (37 кешегә, ягъни 11,5%ка кимрәк). Безнеңчә, сәламәтлеге ягыннан җитди проблемалары булмаса, мондый балаларны гаилә тәрбиясенә бирергә кирәк.

2017 ел азагына опека һәм попечительлек органнарында уллыкка алучылар, бала алучы ата-аналар кандидатларына әзерлек узган һәм опека һәм попечительлек органнарында уңай бәя алган 528 гаилә исәптә тора, шулардан 371 гаилә региональ банк белешмәләренә кертелгән, бу бала алырга теләүчеләр санының 70,3% тәшкил итә.

Региональ банк белешмәләренә кертелгән кандидатлар арасында 160 гаилә (43%) елдан артык исәптә тора. Кандидатлар контингентын анализлаудан күренгәнчә, 2017 елда бала ала алмаганнарның күпчелеге I яисә II төркем инвалид балаларны алырга тырышучылар һәм 42,5%ы 7 яшькә кадәрге балаларны алырга телиләр.


Опека һәм попечительлек органнарының, алмаш ата-аналарга кандидатлар эзләп табу һәм ятим балаларны тәрбиягә алган гаиләләргә булышлык күрсәтү хезмәтләренең уңай һәм мөһим эш нәтиҗәләре **икенчел ятимлекне анализлаудан күренә** – баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында карарлар юкка чыгарылды.

2017 елда баланы гаилә тәрбияенә тапшыру турында карарларны юкка чыгару 12 очракка (48%ка) артты һәм барысы 37 очрак булды.

2017 елда баланы гаилгә тапшыру 19 очракка (76%ка) артты һәм барысы 44 очрак булды.

106 нче диаграмма

2011 – 2017 елларда үзләренә карата аларны гаиләгә тапшыру турында карарлар юкка чыгарылган балалар саны



Шундый 44 карарның гамәли көче 30 очракта уллыкка алучылар, опекуннар һәм тәрбиягә бала алучылар инициативасы буенча туктатылды, шул исәптән: Казан шәһәрендә – 7 очрак, Түбән Кама, Әлмәт муниципаль районнарында – 4әр очрак, Алабуга һәм Балык Бистәсе муниципаль районнарында – 3әр очрак, Аксубай һәм Бөгелмә муниципаль районнарында – 2шәр очрак, Алексеевск, Югары Ослан, Чүпрәле, Зеленодольск мунципаль районнарында һәм Чаллы шәһәрендә – 1әр очрак.

Шул ук вакытта, 44 карарның 14е бала алган ата-аналарның үз вазыйфаларын тиешенчә башкармауга бәйле кабул ителде (Нурлат районында – 7 очрак, Аксубай районында – 2 очрак, Кукмара, Менделеевск, Минзәлә, Түбән Кама, Спас районнарында – 1әр очрак).

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилның гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча тикшерү уздыруга бәйле гаиләгә алынган балалрның хоуклары һәм законлы

мәнфәгатьләре җитди бозылу очраклары Нурлат, Спас, Әтнә муниципаль районнарында күзәтелде.

Тикшерүләр уздыру барышында балигъ булмаганнарның яшәү шартлары бозылу, бюелем алу өчен опекуннар тарафыннан тиешле шартлар булдырылмау, балаларның тиешенчә каралмау, аларга тиешле ял, савыктыру чаралары күрелмәү очраклары һ.б.лар ачыкланды.

Балалар хокуклары бозылуның сәбәпләреннән берсе – районнарда тәрбиягә алынган балаларның хокуклары ничек үтәлүен опека һәм попечительлек органнары тарафыннан тиешенчә тикшереп тормау. Моңа бәйле рәвештә, муниципаль районнар башлыкларына, шулай ук Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең тиешле бәяләмәләре җибәрелде.

Шуның белән бергә, тикшерү барышында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан опека һәм попечительлек органнарына карата контрольнең булмавына бәйле системалы характердагы хокук бозулар да ачыкланды. Шуннан чыгып, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры адресына тиешле бәяләмә җибәрелде.

Әлеге тикшерү нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Прокуроры И.С. Нәфыйковка республиканың опека һәм попечительлек органнарына планнан тыш тикшерү оештыру турында мөрәҗәгать итте.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы районнардагы һәм шәһәрләрләрдәге опека һәм попечительлек органнарының ата-аналарны алыштыручы опекуннарның үз вазыйфаларын тиешенчә үтәүләренә котрольне көчәйтергә тиеш, дип саныйбыз.

Икенче яктан, үзләренә карата гаиләгә бала бирү турындагы карар гражданнарның үз инициативалары белән юкка чыгарылган һәр икенче гаиләнең (30дан 15е) элек махус әзерлек узуын исәпкә алсак, ата-аналарны алмаштыручыларга кандидатлар әзерләү буенча опека һәм попечительлек органнары эшчәнлегенең сыйфатын тикшерү мәсьәләсе актуаль булып кала.

Шулай итеп, гаиләгә бала тапшыру турындагы карарны юкка чыгару фактларын һәм балаларны ятимнәр өчен дәүләт учреждениеләренә кире кайтаруны минимальләштерү максатында Татарстан РеспубликасыМәгариф һәм фән министрлыгына 2016 елга билгеләнгән түбәндәге тәкъдимнәр бүген дә актуаль дип саныйбыз:

опека һәм попечительлек органнарының ата-ана булу өчен кандидатлар әзерләүдә нәтиҗәле һәм профессиональ эшли торган система булдыру һәм ятим баланы тәрбиягә алган гаиләне күзәтеп тору эшчәнлеген камилләштерү буенча чаралар күрергә;

бала алучы ата-аналарның, опекуннарның (попечительләрнең), гаилә әгъзаларының психологик-педагогик компетенцияләрен күтәрү буенча системалы эшоештыру мәсьәләсен карарга;

ата-ана булу өчен кандидатларның әзерлегенә һәм сәләтенә мәҗбүри психологик бәя бирү өлешендә гамәлдәге федераль законнарга үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне карау инициативасы белән чыгарга.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк, опека һәм попечительлек органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күпчелек очракта балалар хокукларын яклау буенча белгечләр составының сан һәм сыйфат составына бәйле булуы ачыклана.

2014 елда балигъ Булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча Хөкүмәт комиссиясе тарафыннан Россия Федерациясе субъектларына опека һәм попечительлек органнарында бала хокукларын яклау буенча белгеч штатын шәһәрдә иң күбе 1,8

мең балага һәм авыл җирлегендә 1,3 мең балага 1 берәмлек исәбеннән тулыландырырга күрсәтмә бирелгән иде (утырыш беркетмәсе, 18.12.2014 ел, № 6).

Әмма бүген Татарстан Республикасында 814 меңнән артык балага опека һәм попечительлек органнарында балигъ булмаганнар мәнфәгатьләрен кайгырту вазыйфалары 136 белгечкә йөкләнгән, республикада бала хокукларын яклау буенча бер белгечкә йөкләнеш 6 меңгә якын бала туры килә.

Безнеңчә, бүген опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыруда төп проблемалар түбәндәгеләр:

– кадрлар белән тәэмин ителешнең җитәрлек булмавы;

– белгечләрнең профессионализм дәрәҗәсе түбән булу (136 белгечнең 31е бу вазыйфада бер елдан кимрәк эшли, 2017 елда 10 муниципаль районда опека һәм попечительлек органнарында белгечләр составы тулысынча диярлек алышынды);

опека һәм попечительлек органнарының матди-техник тәэмин ителеше тиешле дәрәҗәдә булмау, шул исәптән, транспорт белән;

муниципальара һәм ведомствоара хезмәттәшлек тәртибе буенча, шул исәптән балаларның законлы вәкилләре тарафыннан аларның хокуклары һәм мәнфәгатьләренең үтәлешенә контроль буенча бердәм норматив база булмау;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ягыннан кирәкле методикярдәмкүрсәтү системасы һәм контроль булмау, балаларның хокукларын яклау буенча белгечләрнең квалификациясен күтәрмәү.

Моннан тыш, опека һәм попечительлек органнарына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан уздырылган тикшерүләр барышында җирле үзидарә органнарында бала хокукларын яклау буенча дәүләт вәкаләтләрен башкаручы 22 белгечнең дәүләт граждан хезмәткәрләре булмавы ачыкланды, бу законнар таләпләрен бозу дигәнне аңлата.

Шуңа бәйле рәвештә, түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк дип саныйбыз:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә тарафыннан гамәлгә ашырылуга контрольне һәрьяклап көчәйтергә;

муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыкларына «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә үтәүне тәэмин итәргә, шул исәптән балалар хокукларын яклау буенча белгечләрне муниципаль хезмәткәрләр итеп билгеләүне тәэмин итеп.

3.4.4. Баланың гаиләгә хокукын гамәлгә ашыру проблемалары һәм, гаиләдә каршылыклар булганда, гаилә эчендәге бәйләнешләр

Баланың гаилә бәйләнешләренә шәхси һәм мөлкәткә бәйле хокуклары бозылуның төп сәбәбе ата-аналарның аерылышуы аркасында каршылыклы очракларның килеп чыгуында күренә. «Каршылыклар белән аерылышу», балалар мәнфәгатьләре күзлегеннән чыгып караганда, бик мөһим мәсьәләләрне хәл иткәндә түбәндәге бәхәсле хәлләр тууга сәбәп була:

баланың яшәү урынын билгеләү;

балаларны ата-ананың икесе тарафыннан да тәэмин итеп тору тәртибен (алимент йөкләмәләрен) билгеләү;


баладан аерым яшәүче ата яки ананың бала белән аралашу тәртибен билгеләү;

баланың башка туганнары белән аралашу тәртибен билгеләү.

Аерылышуларның саны күп булу борчу уята: продуктив яшьтәге өйләнешкән яшьләрнең яртысы диярлек аерылыша. 2017 елда Татарстан Республикасы ЗАГ С органнары тарафыннан 26 983 язылышу теркәлгән, бу 2016 ел белән чагыштырганда, 1 205 (4,7%) язылышуга артыграк. Аерылышу белән тәмамланган никахларсаны саны, элеккечә, югары булып кала һәм 2017 елда мондыйлар 13 586 булды (2016 елда – 13 450). Бу 1000 өйләнешкән парның 503е аерылган дигән сүз.

107 нче диаграмма

2009–2017 елларда Татарстан Республикасында теркәлгән язылышулар һәм аерылышулар динамикасы




Аерылышу – һәр гаилә өчен җитди трагедия. Балалар өчен ата-аналарның аерылышуы чын-чынлап бәлага әверелә. Мондый балалар алар өчен табигый булмаган, психик яктан зыян китерә торган шартларга юлыккан балалар төркемен тәшкил итәләр. Мондый шартлар аларның психик-эмоциональ торышларына, тәртибенә һәм бөтен алдагы тормышына тискәре йогынты ясавы белән куркыныч.

2017 елда аерылышу вәзгыятен ата-аналары бергә 10 709 бала кичерде, бу 2016 елга караганда 1 198кә күбрәк, (2016 елда – 9 511 бала). Мондый балаларга үз вакытында психологик ярдәм күрсәтү һәм тормышларына үзгәрешләр кертү таләп ителә. Кызганычка каршы, ата-аналар балаларына нинди көчле психик зарар китүләрен, кагыйдә буларак, тиешенчә аңлап бетермиләр һәм профессионал психологлар ярдәмен сорап мөрәҗәгать итүне кирәксенмиләр.

2017 елда балаларның гаиләгә һәм гаилә эчендәге бәйләнешләргә булган мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләрен үз эченә алган 434 мөрәҗәгатьтә 149 кеше (34,3%) баланың яшәү урынын һәм аралашу тәртибен билгеләү буенча барлыкка килә торган гаилә эчендәге каршылыклы хәлләрне җайга салуда ярдәм күрсәтүләрен сорап язган.

108 нче диаграмма

2012–2017 елларда балаларның гаиләгә һәм гаилә эчендәге бәйләнешләргә булган мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләре буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре динамикасы



Соңгы вакытта Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә ***аерылышканнан соң баланың яшәү урынын билгеләү*** мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьләр саны артты. Бу мәсьәләне үзләре хәл итә алмагач, аны суд аша хәл итәргә мәҗбүр булалар.

Еш кына аерылышулар ир белән хатын арасындагы бәхәсләргә һәм бер-берсен күралмауга бәйле була. Нәтиҗәдә, олылар, балаларның хокукларын бозып, кагыйдә буларак, үз мәнфәгатьләрендә балаларны «кайгырталар». Аерым яшәүче атасы яки анасы һәм башка туганнары белән аралашу тәртибен билгеләү мәсьәләсе буенча судка бирелгән дәгъвалар һәрвакытта диярлек ата-ананың берсе тарафыннан гаилә законнары нормаларының да, шулай ук үз баласының законнарда гарантияләнгән хокукларының һәм мәнфәгатьләренең бозылуын да аңлата. Татарстан Республикасы Югары суды мәгълүматларына караганда, 2017 елда гомуми юрисдикция судларында әлеге категория буенча 303 балигъ булмаган балага карата эш каралган.

Мисал. *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гр.К. мөрәҗәгать итте, ул ире Е. белән аерылышканнан соң, баласының яшәү урынын билгеләү турында суд карарын үтәүгә ярдәм итүне һәм, баланы атасыннан алып, үзенә кайтаруны үтенә. 2017 елның 16 мартында аның элеккеге ире, баласын балалар бакчасыннан алып, билгесез юнәлештә алып китә. Гр.Е. баланы мөстәкыйль рәвештә эзләп карый, әмма нәтиҗәсе булмый, телефоннан шалтыратуларга гр. Е. җавап бирми, бернинди хәбәрләр җибәрми.*

Суд приставлары хезмәте тарафыннан гр. Е.не эзләү игълан ителә, тикшерү комитеты тарафыннан гр.Е.гә карата Россия Федерациясе ҖКның 330 ст. («Башбаштаклану») нигезендә җинаять эше кузгатыла.

Эзләү чаралары процессында гр.Е.нең үз гаиләсе һәм улы Д. белән Санкт-Петербург шәһәрендә яшәве ачыкланды. Әмма бала нык яшерелгән була, полиция хезмәткәрләренең тырышылыгы уңышка китерми.

Гр.М.нең ышанычнамә буенча эш итүче туганнары Санкт-Петербург шәһәренә киләләр, мөстәкыйль рәвештә эзләп табып, баланы 10 айдан соң әнисенә кайтарып бирәләр.

Балигъ булмаган балаларның гаиләдә яшәү һәм тәрбияләнү хокукы ***аларның аерым яши торган ата-анасы һәм якын туганнары белән аралашу хокукына*** турыдан-туры бәйле. Хәзер Россия Федерациясе законнары баланы аерым яшәүче ата-анасы тарафыннан тәрбияләү өчен мөмкин кадәр күбрәк уңайлыклартудыра. Шул ук вакытта бу хокукны гамәлгә ашыру өчен җаваплылык, иң элек, ата-аналарның үзләренә йөкләнә.

Кызганычка каршы, ата-ананың берсе тарафыннан гаилә законнары нормалары да, шулай ук үз баласының хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре дә бозылган очраклар шактый. Шуңа бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Гаилә кодексының 66 статьясын-

дагы 1 пункты нигезендә баладан аерым яшәүче ата-ана бала белән аралашырга, аны тәрбияләүдә һәм баланың белем алуы мәсьәләләрен хәл итүдә катнашырга хокуклы. Бала белән бергә яши торган ата-ана баланың алар белән бергә яшәми торган ата-анасы белән аралашуына каршы килергә тиеш түгел, тик мондый аралашуның баланың психик һәм физик сәламәтлегенә, аның әхлакый үсешенә зыян китермәве шарт. Бу шартларны, әлбәттә, балигъ булмаган балалары булган ата-аналар аерылышканда, суд ике якка да аңлатырга тиеш.

Судка бирелгән дәгъвалар да һәрвакытта диярлек ата-ананың берсе тарафыннан балаларның хокуклары сакланмавын күрсәтә. Татарстан Республикасы Югары суды мәгълүматларына караганда, 2017 елда гомуми юрисдикция судларында 457 балигъ булмаган балага кагылышлы әлеге категориягә кергән 373 эш каралган. Әмма баланың ата-аналары белән суд тәртибендә билгеләнгән аралашу тәртибе тормышта еш кына үтәлми.

Мисал. *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гр.Ш. үзенең кызы белән аралашуның суд тәртибендә билгеләнгән тәртибе үтәлүен тәэмин итүдә ярдәм сорап мөрәҗәгать итте. Элеккеге хатыны, аның үтенеченә һәм кызының теләгенә дә карамастан, аларның аралашуына тоткарлык тудыра.*

Суд тарафыннан ике ел элек билгеләнгән тәртип үтәлми. Ике ел эчендә ул үз кызын кунакка бары бер мәрәтә генә ала алган. Кызын каникулларга алып китәргә килергә ниятләве турында алдан хәбәр җибәргәннән соң (чөнки гр. муниципаль районда яши), элеккеге хатыны кызын башка шәһәргә җибәрә. .

Мәсьәләне тыныч юл белән хәл итәргә тырышып караганда, элеккеге хатыны һәм аның туганнары агрессия күрсәтәләр, тавыш чыгаралар, кызга атасы белән очрашуга рөхсәт бирмиләр.

Яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органнары, полиция, суд приставлары хезмәте хезмәткәрләре бернинди дә нәтиҗәле чаралар күрмиләр, хатын үзенә карата чаралар күрелмәгәнлектән файдалана.

Югарыда күрсәтелгән мисаллар ата-аналарның аерым яшәүче атасы яисә анасы белән баланың аралашу хокукын чикләү кебек явыз гамәлләр башкаруларын күрсәтә.

Гамәлдәге законнарда Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясындагы 2 һәм 3 пунктлары нигезендә баланы ата-аналары белән һәм якын туганнары белән аралашудан мәхрүм иткән өчен каралган административ җаваплылыкка тарту буенча өстәмә чаралар карала, ул әлеге норманың гамәлдә булуы шулай ук балаларны, аларның ирегенә каршы килеп, тору урынын махсус яшерү, балаларның яшәү урыннарын билгеләү турында суд карарын үтәмәү очракларына, шул исәптән суд карары закон көченә кергәнче балаларның яшәү урынынын билгеләү турындагы карарга һәм башка очракларга кагыла. Баларның тәрбиягә һәм белем алуга, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга хокукларын ата-аналары тарафыннан суд карары закон көченә кергәнче гамәлгә ашрыу тәртибен бозган өчен яисә аны үтәүгә тоткарлык тудырган өчен ике мең сумнан биш мең сумга кадәр административ штраф салына яки биш тәүлеккә кадәр административ арест салына.

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.2 статьясы нигезендә югарыда күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга вәкаләтле органнар балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район (шәһәр), районнардагы шәһәрләр (баланың яшәү урыны буенча) комиссияләре була.

2017 елда балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе белешмәләре буенча, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы буенча 15 190 ата-ана (законлы вәкилләр)

җаваплылыкка тартылган, шулардан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясындагы 2 өлеше нигезендә – 14 кеше (Казан шәһәре, Совет районы – 1 кеше, Бу районы – 1 кеше, Алабуга районы – 2 кеше, Зәй районы – 2 кеше, Түбән Кама районы – 6 кеше, Нурлат районы – 2 кеше). Калган районнарда баланың ата-ана һәм башка якын туганнар белән аралашу хокукын бозган ата-аналарга карата әлеге административ җәза чарасы кулланылмаган. Безнеңчә, балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр тарафыннан баланың ата-ана һәм башка якын туганнар белән аралашу хокукын бозган ата-аналарга карата административ ресурсны активрак кулланырга кирәк.

Моннан тыш, суд карарын үтәмәгәндә, гаепле ата-анага карата граждан процессуаль законнарда каралган чаралар кулланыла. Суд карары явыз ниятләр белән үтәлмәгәндә, баланың аерым яшәүче ата-анасы таләбе белән суд, баланың фикерен исәпкә алып һәм бала мәнфәгатьләреннән чыгып, аңа баланы тапшыру турында карар чыгарырга мөмкин (Россия Федерациясе Гаилә кодексының 66 ст., 3 өлеше). Шул ук вакытта әлеге норма, суд тәжрибәсеннән күренгәнчә, бөтенләй диярлек кулланылмый һәм ата-ана моның өчен, кагыйдә буларак, берничек тә җавап тотмый.

Бу тематика буенча 2017 елда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәсеннән чыгып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

Татарстан Республикасы Югары судына, гомуми юрисдикциядәге район (шәһәр) судларына балалар турындагы мәсьәләләрне караганда:

ата-аналарның (ата-ананың берсенең) таләбе буенча һәм опека һәм попечительлек органнарының мәҗбүри катнашында алдан үткәрелә торган суд утырышында балалар турында бәхәсләрне карап тикшергәндә суд карары үзенең законлы көченә кергәнчегә кадәрге чорга балаларның яшәү урыннарын һәм (яки) ата-ана хокукларын гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү практикасын (Россия Федерациясе Граждан кодексының 152 статьясында һәм Россия Федерациясе Гаилә кодексының 65 статьясындагы 3 пунктында каралган) киңәйтүне тәкъдим итәргә. Балаларның мәнфәгатьләрен яклауның мондый чарасы, ул 2011 елда кертелде, гаиләнең кризислы, каршылыклы хәлдәге очракларында балалар юлыккан хәлне тотрыкландыруны һәм җайга салуны максат итеп куя, чөнки яшәү урынын һәм аралашу тәртибен билгеләү буенча суд процесслары озак вакытларга сузылырга мөмкин;

баланың яшәү урырынын билгеләү һәм (яисә) аның ата-анасы һәм башка якын туганнары белән аралашу хокукын бозган ата-аналарга карата чыгарылган суд карарарын үтәмәгән өчен Россия Федерациясе Гаилә кодексының 66 статьясындагы 3 өлешен кулланырга;

балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләренә се Россия Федерациясендә Административ хокук бозулар Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясындагы 2 пункты нигезендә баланы ата-аналары белән һәм якын туганнары белән аралашудан мәхрүм иткән өчен каралган административ җаваплылыкка тарту практикасын киңәйтергә һәм активлаштырырга кирәк дигән мәсьәләне карарга;


судларга һәм опека һәм попечительлек органнарына аерылышкан очракта бала тәрбияләү буенча бәхәсле мәсьәләләргә бәйле эшләрне караганда, республика психологик хезмәтләрен җәлеп итеп, медиатив технологияләр практикасыннан актив файдалануны тәкъдим итәргә.

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә ***чит ил гражданнары белән аерылышканда*** яисә аерым яшәгәндә балаларның яшәү урыннарын билгеләү һәм ата-ана хокукларын, бурычларын үтәү тәртибе бозылу турындагы бәхәсле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатьләр артты.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы ЗАГС идарәсе белешмәләре буенча, республикада чит ил гражданнары белән өйләнешүне теркәү турындагы актларның саны арта баруы күзәтелә. 2017 елда Татарстан Республикасында чит ил гражданнары белән өйләнешү 2016 ел дәрәҗәсендә диярлек калган, әйтергә кирәк, 1338 өйләнешү очрагы теркәлгән (2016 елда – 1 350 булган).

109 нче диаграмма

2011 – 2017 елларда чит ил гражданнары белән өйләнешүләр саны



Электәге кебек үк, хәзер дә Россия кызлары белән Гарәбстан һәм Европа илләре ирләре арасындагы өйләнешүләр кбрәк өзел. Әлеге вәзгыятьтәге бәхәсләр күпчелек очракта чит дәүләтләрдә барлыкка килә. Кызганычка каршы, мондый вариантта россиялеләрнең мәнфәгатьләрен яклау дәрәҗәсе күпкә түбән. Бәхәс килеп чыккан очракта, хокукый җайга салуның катлаулылыгы төрле ил гражданнары булган ир белән хатынны һәм балаларны кыен хәлгә куя. Бу бигрәк тә чит илдә яшәүгә рөхсәте яисә гражданлык статусы булмаган хатын-кызлар өчен кискен проблемага әйләнә.

2017 елда баланың яшәү урынын билгеләү һәм балаларны Россия Федерациясенә кайтару буенча юридик консультация һәм бәхәсле мәсьәләне хәл итүдә ярдәм сорап, Төркия, Греции, Ирак, Германии, Швейцария, Италия, Украина гражданнары белән өйләнешкән гражданнар яисә аларның якын туганнары мөрәҗәгать итте.

Чит ил гражданы белән никахтан туган балаларны тәрбияләү хокукы тирәсендәге барлык диярлек бәхәсләр ике дәүләтнең – Россиянең һәм икенче дәүләтнең (Россия Федерациясе гражданы иренең йә хатынының иленеке) Гаилә законнарының төрле булуына бәйле. Һәр конкрет очракта да бу четерекле мәсьәләдә кайсы илнең хокукы кулланырга тиеш дигән проблема барлыкка килә.

Төрле дәүләтләрнең гражданнары – ир белән хатын аерылышу (аерым яшәү) вәзгыятендә балигъ булмаган балаларны опекалауга карата мәсьәләләрне хокукый җайга салу шактый катлаулы һәм ул үз эченә халыкара законнар нормаларын һәм төрле илләрнең милли хокукларын үз эченә ала. Әмма һәр конкрет очракта илнең милли законнары хокукый нормаларының һәм халыкара хокук нормаларының нисбәте индивидуаль карала. Бәхәсләр килеп чыкканда хокукый җайга салуның катлаулылыгы ир белән хатынны да, аларның уртак балаларын да авыр хәлгә куя.

Шуны әйтергә кирәк, өйләнешүчеләрнең берсе чит ил гражданы булган яшьләргә шул илләрнең гаилә мөнәсәбәтләрен хокукый җайга салу үзенчәлекләрен аңлатуны, консультация ярдәме күрсәтүне максатка ярашлы дип саныйбыз. Бу эшләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы ЗАГС идарәсе ярдәмендә оештырырга мөмкин.

3.5. Баланың белем алу өлкәсендә хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү

20 гасырда кешелекнең иң югары казанышларыннан берсе – баланың һәркем файдалана алырлык, мәҗбүри, түләүсез һәм тигез мөмкинлекләр белән әлеге хокукка әкренләп ирешү принциплары нигезендә белем алуга хокукы.

3.5.1. Мәктәпкәчә белем

2018 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү системасында 2 019 мәгариф оешмасы эшли, аларда 220 388 бала тәрбияләнә, шул исәптән:

1 788 муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмасы (аларда 212 187 бала);

23 дәүләтнеке булмаган мәгариф оешмасы (аларда 2 562 бала).

Татарстан Республикасында соңгы елларда республиканың иң яшь халкын һәркем файдалана алырлык мәктәпкәчә белем бирү белән тәэмин итү өчен күп эшләр башкарыла. 2011 елдан башлап республикада мәктәпкәчә өстәмә урыннар булдыру буенча президент программасы гамәлгә ашырыла, ул мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә чиратны бетерү һәм балалар бакчаларында урыннарга кытлык проблемасын хәл итү өчен кертелде. 2012 елдан алып 2017 елга кадәрге чорда гына да республикада балалар бакчаларында 47 яңа урын булдырылды, 203 яңа балалар бакчасы төзелде. 2017 елда гына да әлеге программаны гамәлгә ашыру кысаларында 1 240 урынлы 7 яңа мәктәпкәчә белем бирү оешмалары төзелде. Моннан тыш, 2013 елдан алып 2017 елга кадәрге чорда 3409,48 млн. сумга 266 балалар бакчасы төзекләндерелде, шуларның 110сы – 2017 елда (2017 елда капиталь ремонтлауның гомуми күләме 1 624,87 млн.сумны тәшкил итте).


Мәктәпкәчә белем бирүнең традицион рәвешләре белән беррәттән вариатив рәвешләре дә үсә. Республикада гаилә балалар бакчалары челтәре (мәктәпкәчә гаилә төркемнәре) эшләп килә, гомуми белем бирү мәктәпләрендә мәктәпкәчә төркемнәр ачыла. 2017 елда 14 гаилә балалар бакчасында, 386 мәктәпкәчә төркемнәрдә һәм мәктәпкәчә тәрбияләүнең башка рәвешләрендә, гомумән алганда, 5639 бала мәктәпкәчә белем алган.

Моның белән бергә, төрле чаралар күрелүгә карамастан, ***мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннарга кытлык проблемасы*** сакланып кала.

Туучылар саны арта бару сәбәпле республика балалар бакчаларына гомуми чират ел саен зурая бара һәм 2018 ел башына анда 34946 кеше исәпләнде. 2016 ел белән чагыштырганда, артым 1% (266 кеше) тәшкил итә.

110 нчы диаграмма


2017 елда мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында чиратлылык (кеше)



Яңа мәктәпкәчә урыннар булдырылуга карамастан, 2012 елдан алып республикада балаларны мәктәпкәчә белем бирү белән тәэмин итүнең артуы күзәтелә. 2017 елда әлеге күрсәткеч 68,8%ны тәшкил итте һәм 2016 елга караганда бу 0,9%ка артык.

111 нче диаграмма

2013-2017 елларда мәктәпкәчә белем бирү колачы (%)



Республиканың 13 муниципаль берәмлегендә (шәһәр округында) мәктәпкәчә белем бирү дәрәҗәсе белән тәэмин ителеш республика буенча уртача күрсәткечтән югарырак, алар арасында Азнакай (76,8%), Әлмәт (70,1%), Бөгелмә (76,1%), Югары Ослан (76,9%), Алабуга (81,4%), Зеленодольск (72,5%), Лениногорск (74,6%), Түбән Кама (79,9%), Саба (84,3%), Чистай (69,8%), Зәй (68,9%), Менделеевск (69,4%) муниципаль районнары, шулай ук Чаллы шәһәре (71,4%) бар.

Республиканың 32 муниципаль берәмлегендә мәктәпкәчә белем бирү дәрәҗәсе белән тәэмин ителеш республика буенча уртача күрсәткечтән түбәнрәк, шулардан иң түбәне Аксубай (47,5%), Әлки (51%), Балык Бистәсе (48,7%), Тукай (44,2%) муниципаль районнарында.

Россия Федерациясе Президентының «Мәгариф һәм фән өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 599 номерлы Указында мәктәпкәчә белем бирүдән файдалануны тәэмин итүдә өстенлек ***өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балаларга*** бирелде.


Күрелгән чаралар ярдәмендә чч яшьтән җиде яшькә кадәрге балаларны мәктәпкәчә белем белән өстенлекле тәэмин итү мәсьәләсе хәл ителде. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча, балалар бакчаларына урнашуга ихтыяҗы булган һәм электрон чиратта торучы 3 яше тулган балаларны урыннар белән тәэмин итү республикада 99% тәшкил итте, бу Балалар мәнфәгатендә гамәлләрнең республика стратегиясенең пландагы индикатив күрсәткечләреннән 1% ка азрак (2017 ел план күрсәткече 100% иде).

2012 – 2015 елларда тууның югары күрсәткечләрен исәпкә алып, 3 яшьтән өлкәнрәк балаларның чиратлылыгы 2016 ел белән чагыштырганда 43%ка артты һәм 4856 кешене тәшкил итте (2016 елда – 3388 кеше).

Өч яшьтән өлкәнрәк 4 856 баладан 3751 бала (77,2%) Казан шәһәрендә, 318 бала (6,6%) Чаллы шәһәрендә балалар бакчаларында урын көтә.

112 нче диаграмма

2017 елда Татарстан Республикасы районнары буенча 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларның балалар бакчаларына чираты (кеше)




Республиканың калган егерме муниципаль районнарында 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балалар өчен чират – 15 кешедән азрак.

1,5 яшьтән алып 3 яшькә кадәрге балалары булган гаиләләр өчен балалар бакчаларында урыннарның җитмәве аеруча актуаль проблема булып тора. Мәктәпкәчә мәгариф системасында ясел төркемнәре җитмәү мәсьәләсенең киеренке булуын 2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә балалар бакчасына урын алу мәсьәләсе белән 122 мөрәҗәгать алыну (2016 елда – 63), шуның 68%ы (81 мөрәҗәгать) гражданнарның 1 3 яшькә кадәрге балаларын бакчага урнаштыру өчен юллама алуда булышлык күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүләре раслый. Тикшерүләр барышында, шул исәптән күчмә рәвештә, «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләренә (балалар бакчаларына) гаризалар алу, исәпкә кую һәм балаларны урнаштыру» муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентын «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы электрон базасында балалар бакчаларын комплектлаганда чират өлешендә хокук бозу очраклары табылмады.

2017 ел ахырына мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына урын көтүче 1,5 яшьтән алып 1,5 яшькә кадәрге балалар 28 743 кешене тәшкил итте (чиратта торучыларның гомуми санының 82%). 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге балаларны балалар бакчаларына урнаштыру буенча иң зур чират (1000 кешедән артык) Казан шәһәрендә (15010 бала), Чаллы шәһәрендә (6412 бала), Әлмәт (2077 бала), Түбән Кама (1114 бала), Зеленодольск (1015 бала) муниципаль районнарында сакланып кала. 28 муниципаль районда бу төркем балалар чираты 100 кешедән кимрәк, ике районда чират гомумән юк.

113 нче диаграмма

2017 елда Татарстан Республикасы районнары буенча 1,5 яшьтән алып 3 яшькәчә балалар бакчаларына чират (кеше)



Шулай итеп, балалар бакчаларында өстәмә урыннар булдыру буенча Татарстан Республикасында шактый чара күрелсә дә, якын киләчәктә балалар туу арта барачак дип фаразланганга күрә, 1,5 яшьтән алып 3 яшькәчә һәм 3 яшьтән 7 яшькәчә балаларны мәктәпкәчә белем бирү хокукы белән тәэмин итү мәсьәләсе актуаль булып кала.

Мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә четерекле мәсьәләләрнең тагын берсе – балаларның балалар бакчаларында ***булу шартларының куркынычсызлыгын тәэмин итү***. 2017 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан үткәрелгән, шул исәптән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау кысаларында үткәрелгән тикшерүләр барышында мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына урнаштыру, аларда карап тору һәм эшләү режимын оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләренең бозылуы ачыкланды.

2017 елда Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (алга таба – Идарә) тарафыннан республиканың мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында 1 056 тикшерү уздырылды.

Республиканың барлык муниципаль районнарында һәм Казан шәһәрендә мәктәпкәчә белем оешмаларында тәрбияләү һәм уку шартларына таләпләрне үтәү өлешендә төп хәл ителмәгән мәсьәләләр бар әле, алар түбәндәгеләр:

һава-җылылык режимына таләпләрнең үтәлмәве: балалар була торган урыннарда көнкүреш термометрлары булмау; җылыту приборларында чикләү җайланмалары булмау;

дәресләр челтәрен һәм көн тәртибен билгеләгәндә түбәндәге таләпләр үтәлмәү: физкультура дәресләренең вакыт дәвамлылыгы тиешле вакыттан кыскарак, йокы вакыты тиешле вакыттан кыскарак, көн дәвамында максималь уку йөкләнеше тиешледән артыграк, аны дөрес бүлмәү;

җиһазны маркировкалау таләпләренең үтәлмәве: балаларны буйларын исәпкә алмыйча утырту, өстәлләр урындыклар белән бер комплекттан булмау, җиһазларның искергән булуы, өсләре кыршылган, читләре кителгән җиһазлар булу;

ясалма яктылыкның норматив таләпләргә туры килмәве (түбән яктылык); янган, шаулап торучы лампалар булу, аларны вакытында алыштырмау, логопед кабинет-

ларында өстәмә яктылык булмау; йокы урыннарында кроватьларның тыгыз торуы; үзәкләштерелгән субетерелгәндә раковиналарга җылы су тоташтыру каралмау; өс һәм аяк киемнәре киптерү өчен урыннар булмау һәм башка җитешсезлекләр.

Белем бирү учреждениеләрендә тукланууны оештыру һәм аның сыйфаты турындагы мәсьәлә Идарә эшчәнлегендә кискен мәсьәләләрнең берсе булып кала. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тукланууны оештыру өлешендә хәл ителмәгән төп мәсьәләләр түбәндәгеләр:

санитар таләпләргә туры килми торган матдио-техник база булу, җайланмаларның җитәрлек булмавы һәм искергән булуы, ризык әзерли торган бүлмәләрдә кул юуу өчен раковиналарның җитәрлек булмавы, технологик җайланмалар өстендә һава чистарту системаларының булмавы һ.б.лар;

ашханә һәм кухня савыт-сабаларын юуу режимаы үтәлмәү: юуу һәм дезинфекцияләү чараларында инструкцияләр булмау, юуу һәм дезинфекцияләү чараларын чамалап салу өчен үлчәүле савытлар булмау, су һәм юуу чарасының пропорцияләре үтәлмәү;

ризык әзерләү блогы хезмәткәрләре тарафыннан шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәү өчен шартлар булмау: ризык әзерләү блокларында кул юуу өчен раковиналар янында һәрберсенә аерым яисә бер мәртәбә кулланыла торган сөлгеләр йә тастымаллар булмау;

тукланууны оештыру буенча журналлар алып бару (тутыру) таләпләрен үтәмәү: аларны вакытында тутырмау, тиешле рәвештә алып бармау;

азык-төлек продуктларын саклау кагыйдәләрен үтәмәү: продуктларны савытларсыз идәндә саклау, товар күршелеге кагыйдәләрен үтәмәү;

башка җитешсезлекләр: инвентарьны һәм савыт-сабаны маркировкалау таләпләрен үтәмәү, тәүлеклек пробаларны сайлап алу һәм саклау кагыйдәләрен үтәмәү, продуктларга йөртү документациясе булмау, расланмаган меню буенча эшләү, расланган меню нигезендә әчетелгән сөт продуктларын даими бирмәү, эмале корылган аш-су савытлары куллану, савыт-сабаның җитәрлек булмавы.

Биналарның һәм аерым аш-су әзерләү урыннарының канәгатьләнерлек булмавы, санитария-дезинфекция режимын бозу 41 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы эшчәнлеген Идарә тарафыннан туктатып тору өчен нигез булды, болар: Казан, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә, Питрәч, Бөгелмә, Балык Бистәсе, Азнакай, Арча, Әлмәт муниципаль районнарында.

114 нче диаграмма

2017 елда суд карары белән эшчәнлекләре туктатып торылган балалар бакчалары саны



2016 елда мәктәпкәчә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил игътибарына тагын бер четерекле мәсьәлә алынган иде. Бу – ***мәктәпкәчә гаилә төркемнәренең эшчәнлеге***.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләренә караганда, 2016 елда республикада гаилә балалар бакчаларының саны шактый кимегән: 2015 елда 45 булса, 2016 елда – 25, 2017 елда 14кә калган.

Республикада мәктәпкәчә гаилә төркемнәре, бер яктан, балалар бакчаларында урыннар кытлыгы мәсьәләсен хәл итүдә ярдәм булырга тиешле мәктәпкәчә белем бирүнең вариатив рәвешләре буларак, икенче яктан, күпбалалы гаиләләргә дәүләт ярдәме чарасы буларак, 3 яшькә кадәрге һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны мәктәпкәчә белем белән тәэмин итү максатында төзелә башлаганнар иде.

Моннан тыш, мәктәпкәчә гаилә төркемнәрен үстерү күпбалалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең нәтиҗәле чарасы буларак һәм күпбалалы тәрбияче аналарны эш белән тәэмин итүнең үзенчәлекле төре буларак каралырга тиеш. Мәктәпкәчә белем бирүне оештыруның вариатив рәвеше буларак мәктәпкәчә гаилә төркемнәренә ярдәм итәргә кирәк, ә аларның эшчәнлеген федераль законнар таләпләренә туры китереп, тәртипкә салу чараларын күрергә һәм аның буенча карарлар кабул итәргә кирәк, дип саныйбыз.

Әлеге позиция Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең «2016 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм бала хокукларының аның һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында»гы докладында да күрсәтелгән иде, ул Татарстан Республикасы Дәүләт Советына чыгарылды һәм Татарстан Республикасы җитәкчелегенә җиткерелде.

Татарстан Республикасында гаилә балалар бакчаларын (мәктәпкәчә гаилә төркемнәрен) оештыру мәсьәләсе Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координация комитетында да (алга таба – Координация комитеты) каралды, ул Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында 2017 елның 15 февралендә узды. Координация комитеты утырышында аның әгъзалары тарафыннан республикада гаилә балалар бакчаларын саклап калуда һәм үстерүдә ярдәм итәргә кирәк дигән фикер әйтелде. Координация комитеты эшенең йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең искәрмәләрен һәм Татарстан Республикасы Прокуратурасы бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә гаилә төркемнәрен оештыру турында»гы карары эшләнеп бетте.

Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү оешмалары базасында мәктәпкәчә гаилә төркемнәрен булдыру мәсьәләсенең актуальлеген исәпкә алып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил әлеге теманы Казан шәһәр Думасының Законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре комиссиясе утырышында карау инициативасы белән чыкты, ул 2017 елның июлендә булды. Әлеге проблеманы депутаталар хуплады. Бүгенге көндә Казанда мәктәпкәчә гаилә төркемнәрен саклап калу мәсьәләсен хәл итү буенча уңай тенденция барлыкка килде.

Мәктәпкәчә гаилә төркемнәрен эшләтү мәсьәләсе Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контролендә тора.

3.5.2. Гомуми белем бирү

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча Татарстан Республикасында 2017/2018 нче уку елында 1 413 гомуми белем бирү оешмасы бар, шул исәптән:

Республикада 1 398 дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү мәктәпләре һәм интернат мәктәпләр бар (401 168 кеше), шулардан 240ында (17,2%) югары дәрәҗәдә белем бирү программалары гамәлгә ашырыла (177 055 кеше);

дәүләткә карамаган 15 мәктәп бар (1 964 кеше).

29 нчы таблица

Сеть общеобразовательных организаций Республики Татарстан в 2017 году

Белем бирү оешмаларының төрләре	Мәктәпләр саны, бер.	Аларда укучы балаларсаны, кеше
Дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү мәктәпләре һәм интернат мәктәпләр	**1 398**	**401 168**
башлангыч мәктәпләр	105	5 160
төп мәктәпләр	360	17 994
урта мәктәпләр	864	367 900
Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен гомуми белем бирү оешмалары	52	7 694
шифаханә тибындагы интернат мәктәпләр	2	240
башка министрлыкларга караган мәктәпләр	2	157
кичке мәктәпләр	12	1 964
девиант холыклы балалар өчен махсус мәктәп	1	59
Дәүләткә карамаган мәктәпләр	**15**	**1 964**

Дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү мәктәпләре һәм интернат мәктәпләр арасыннан:

105 – башлангыч мәктәп (5 160 бала);

360 – урта мәктәпләр (67 900 бала);

52 – сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен махсус (коррекция) мәктәпләре һәм интернат мәктәпләр (7 694 бала);

1 – девиант холыклы балалар өчен махсус мәктәп (59 бала);

12 – кичке мәктәпләр (1 964 бала);


2 – шифаханә тибындагы интернат мәктәпләр (240 бала);

2 – башка министрлыкларга караган мәктәпләр (157 бала).

Статистика хисабы белешмәләре буенча, 2017/2018 нче уку елында демографик үсеш аркасында дәүләт (муниципаль) көндезге гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның саны 2017 елда 2,6%ка артты, укучылар саны 399 204кә җитте.

115 нче диаграмма


Татарстан Республикасының көндезге дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмаларында укучылар санының үзгәрү динамикасы (кеше)



Мәгариф учреждениеләре челтәрен оптимальләштерү барышы һәм халык миграция-се фонында республикада авыл мәктәпләренең кимүе дәвам итә. 2017 елда аларның саны 9га кимеп, 878 гә калды, ә шәһәр мәктәпләренең саны 535 булды.

116 нчы диаграмма


Татарстан Республикасында шәһәр һәм авыл мәктәпләре нисбәте



Шул рәвешле, авыл мәктәпләрендә укучылар саны кимү, ә шәһәр мәктәпләрендә укучыларның саны арту тенденциясе тагын да ныгыды. Быелгы уку елында укучыларның гомуми санының 80,6% ын шәһәр укучылары тәшкил итә.

117 нче диаграмма


2016/2017 уку елында шәһәрләрдәге һәм авыллардагы гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны (кеше)



Гомуми белем бирү оешмалары челтәренең үсеше төп мәктәпләрнең саны арту һәм башлангыч һәм урта мәктәпләрнең саны кимү белән тасвирлана.

118 нче диаграмма

2013 – 2017 елларда Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмалары челтәре



2017/2018 уку елында гомуми белем бирү мәктәпләре структурасында башлангыч мәктәпләр өлеше 7,5% (105 мәктәп) тәшкил итә, анда барлык укучыларның 1,3%ы (5 160 кеше) исәпләнә. Башлангыч мәктәпләрнең гомуми санныннан 88,6%ы (93 мәктәп) авыл җирлегенә туры килә. Шул ук вакытта ***башлангыч мәктәпләрнең*** беркадәр артуы күзәтелә. 2017 елда башлангыч авыл мәктәбе 2гә арткан (2016 елда 91 иде).

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең докладында авыл башлангыч мәктәпләренең кимүе күрсәтелгән иде. Шуннан чыгып, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына һәм муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыкларына башлангыч белемне балаларның яшәү урыны буенча алуын тәэмин итүне оештыру тәкъдим ителгән иде.

Барлык дәүләт (муниципаль) мәктәпләрнең гомуми санныннан төп мәктәпләр 25,8% (360 мәктәп) тәшкил итә, анда барлык укучыларның 4,5%ы (17 994 кеше) белем ала. Күбесенчә болар авыл мәктәпләре (360тан 341е).

Урта мәктәпләр өлеше 61,8% (864 мәктәп) тәшкил итә, шуның 50%ы (431 мәктәп) авыл мәктәпләренә туры килә. Республиканың урта мәктәпләрендә барлык укучыларның гомуми санныннан 91,7%ы (367 900 кеше) укый, шуның шәһәр җирлегендәге укучыларның гомуми санныннан 95,1% (308 902 кеше) – шәһәр мәктәпләрендә, авыл җирлегендәге укучыларның гомуми санныннан 75,3% (58 99 кеше) авыл мәктәпләрендә укый.

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан гомуми белем алуны гамәлгә ашыру өлкәсендә түбәндәге проблемалы мәсьәләләр ачыкланды.

Беренчедән, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе белгечләре тарафыннан тикшерүләру здырганда, һәрвакыттагыча, гомуми белем бирү оешмаларында укыту-тәрбияләү процессын оештыру шартларына таләпләрнең үтәлмәү очраклары ачыкланды.

Бу вәзгыятькә җентекле анализ әлеге докладның «Балаларның сәламәтлеккә хокукларын тәэмин итүнең аерым проблемалы мәсьәләләре» дигән 3.3.3. бүлегендә бирелде.

Икенчедән, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне ***мәктәпләрдә белем бирү*** **процессында** ***катнашучылар арасындагы каршылыклы вәзгыятьләр мәсьәләләре*** буенча ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) кергән мөрәҗәгатьләр аеруча борчый. 2017 елда 105 мөрәҗәгать керде, бу балаларның белемгә хокукларын яклау темасы буенча кергән барлык мөрәҗәгатьләрнең 21%ын тәшкил итә. Соңгы елларда мондый вәзгыять сакланып кына калмыйча, кискенләшә бара.

2017 елда гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча үткәрелгән тикшерү йомгакларыннан күренгәнчә, белем бирү процессын тиешенчә оештырмау, тәрбияләүнең педагогик булмаган алымнарын куллану, балигъ булмаган баланы сәламәтлегенә зыян салырлык психик халәткә китерү кебек хокук бозулар түбәндәге 19 белем бирү оешмасында ачыкланды:

«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен Е.Г.Ласточкина ис. Казан интернат мәктәбе» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесендә (7 мөрәҗәгать);

Казан шәһәре Яңа Савин районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү буенча 179 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесендә (4 мөрәҗәгать);

«Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин ис. Бөгелмә кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесендә (2 мөрәҗәгать);

Казан шәһәре Идел буе районының «78 нче «Фарватер» лицее» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә (2 мөрәҗәгать);

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балалар өчен «75 нче Чаллы мәктәбе» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесендә;

Казан шәһәре Киров районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү буенча 135 нче урта гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү буенча 33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Казан шәһәре Совет районының «48 нче гимназиясе – Белем үзәге» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Казан шәһәре Яңа Савин районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү буенча 146 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном мәгариф учреждениесендә;

Казан шәһәре Яңа Савин районының «Россия Герое А.В. Козин ис. 7 нче гимназиясе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Чаллы шәһәренең «25 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Чаллы шәһәренең «26 нчы гимназия» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Алабуга муниципаль районының «Россия Федерациясе Герое А.Н.Епанешников ис. 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Түбән Кама шәһәренең «28 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Түбән Кама шәһәренең «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү буенча Н.М. Максимов ис. 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Баулы шәһәренең «4 нче гимназия» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Буа муниципаль районының «Р.З.Сәгъдиев ис.урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Кукмара муниципаль районының «4 нче Кукмара урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Зәй муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү буенча 7 нче Зәй урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2016 елгы докладында балалар катнашында барлыкка килә торган конфликтлы вәзгыятьләрне киметү буенча чаралар күрү тәкъдим ителгән иде. Бала үзенең белем алуга һәм тәрбияләнүгә хокукларын гамәлгә ашыра торган урында – мәктәпләрдә – балалар психикасына зыян китерә торган вәзгыятьләр тудырылмаска тиеш. Моннан тыш, мондый вәзгыятьләр агрессив гамәлләр кылуга, шулай ук балаларда барлыкка килә торган девиант яисә башка деструктив чагылышларга сәбәп булырга мөмкин. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль закон нигезендә конфликтлы вәзгыятьләр булдырмау, ә алар барлыкка килгән очракта – алардан профессиональлек күрсәтеп чыгу – мәктәп администрациясенең бурычы. Шуңа күрә һәр конфликтлы очракны Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил мәктәпләрдә җитәкчеләрнең үз һөнәри һәм функциональ вазыйфаларын тиешенчә үтәмәүдә күрә. Шуңа бәйле рәвештә, мөрәҗәгатьләрне карау йомгаклары буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белем бирү оешмаларының директорларына һәм аларны гамәлгә куючыларга, балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуны күрсәтеп, түбәндәгеләргә 24 бәяләмә җибәрә:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына (7 бәяләмә),

Казан шәһәре муниципаль районнары (шәһәр округлары) җитәкчәләре адресына (8 бәяләмә);

Чаллы шәһәре (2 бәяләмә);

Түбән Кама муниципаль районы (2 бәяләмә);

Буа муниципаль районы;


Баулы муниципаль районы;

Алабуга муниципаль районы;
Кукмара муниципаль районы;
Зәй муниципаль районы.

Мәгариф өлкәсендә конфликтларны профилактикалау мәсьәләләре бүген дә актуаль булганга күрә, мәктәпләрдә квалификацияле психологик ярдәм хезмәтләрен оештыру аерым әһәмияткә ия. Кызганычка каршы, хәзерге вакытта республикадагы 1 413 учреждениенең 384ендә генә (27,2%) психолог– педагоглар эшли.

119 нчы диаграмма

2011-2017 елларда гомуми белем бирү оешмаларында психологик ярдәмнең торышы



Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2016 елдагы докладында бәян ителгән күрсәтмәләр үтәлешенә анализдан күренгәнчә, күпчелек тәкъдимнәр мәктәпләрдә конфликтларны профилактикалау эшләрен оештырганда исәпкә алынмаган. Бары тик психологик хезмәтләр һәм мәгариф сстемасы үзәкләре белгечләре өчен балалар белән алга таба профилактик эшләр оештыру буенча стресска каршы тору тренинглары һәм белем бирү процессында катнашучылар арасында конфликтлы вәзгыятьләрне профилактикалау буенча практик юнәлешле семинарлар үткәрелгән, аларда 500ләп педагогик хезмәткәр катнашкан.

Шуңа бәйле рәвештә, республика мәктәпләрендә психиканы җәрәхәтли торган конфликтлар барлыкка килүне профилактикалау максатларында, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына профилактик характердагы системалы карарлар кабул итүне кабат тәкъдим итәргә кирәк дип саныйбыз, шул исәптән:

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының рейтингын булдыру һәм аны уздыру тәртибе турындагы Үрнәк нигезләмәдән фәннәр буенча БДИның уртача балларына бәйле критерийларны төшереп калдыру мәсьәләсен карарга;

белем бирү оешмаларының, белем бирү өлкәсендә муниципаль оешмаларның эшчәнлеген бәяләү критерийларына белем бирү оешмалары эшчәнлегенә карата ата-аналарның дәлилле шикаятьләре, шул исәптән прокуратура, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, башка контроль-күзәтчелек органнары адресына җибәрелгән шикаятьләр булуга бәйле күрсәткечне кертергә;

республика муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белән берлектә:

муниципаль берәмлекләрдә (шәһәр округларында) һәм белем бирү оешмаларында психолог-педагог хезмәтләре эшен дәвам итәргә;

белем бирү оешмалары каршында белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасындагы бәхәсләрне җайга салу комиссияләрен төзүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын башкарырга;

педагоглар һәм балалар арасында низаглар булдырмау буенча эшне дәвам итәргә.

Өченчедән, белем бирү оешмаларына балаларны илтеп җиткерүне оештыру мәсьәләләре дә актуаль булып кала. Мәсәлән, 2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең игътибарын Актаныш, Зеленодольск муниципаль районнарында, Чаллы һәм Казан шәһәрләрендә укучыларны белем бирү оешмаларына илтеп җиткерүне оештыру мәсьәләләре дә җәлеп итте.

2016 елдан башлап Актаныш муниципаль районының Иске Бикчәнтәй авылы кешеләренең күмәк мөрәҗәгате Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым контролендә тора.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең мәгълүматы буенча, авылда башлангыч мәктәп юк, балаларны башка авылга илтү оештырылмаган, чөнки иминлек таләпләренә җавап бирә торган юллар юк. Балалар 2 км төзек булмаган юлны җәяү узалар, бигрәк тә язны-көзен юллар ерып чыкмаслык була, аннары автобуска утырып мәктәпкә кадәр баралар: «Әтәс гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү оешмасына мәктәп автобусы бара торган төзек булмаган «Актаныш – Поисево – Бикчәнтәй» автоюлының озынлыгы 2 123 метр тәшкил итә, шуннан 1 430 метр «Главтатдортранс» ДКУ балансында тора, 1579 метр – муниципаль баланста.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил җирле үзидарә органнары тарафыннан балигъ булмаганнарның хокуклары бозылуын да карый.

Россия Федерациясе Конституциясенең 43 статьясы һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 56 статьясы нигезендә дәүләт һәм муниципаль белем бирү учреждениеләрендә һәркем файдалана алырлык, гомуми белем алу гарантиясе игълан ителә.

«Мәгариф турында» Федераль законның 9 статьясы нигезендә муниципаль берәмлекләрдә һәркем өчен гомум белем бирүне оештыру муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелә.

Әлеге Законның 40 статьясы нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларында укучыларны транспорт белән тәэмин итү (ягъни укучыларны белем бирү оешмаларына түләүсез илтү һәм алып кайтуны оештыру) тиешле оешмаларны гамәлгә куючылар тарафыннан башкарыла.

Россия Федерациясе баш дәүләт санитар табибының 2010 елның 29 декабрендәге 189 номерлы карары белән расланган «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә уку шартларына һәм аны оештыруга санитария-эпидемиология таләпләре» СанПиН 2.4.2.2821-10 һәм «Төзелеш климатологиясе» СНиП 23-01-99 нормалары нигезендә шәһәр гомуми белем бирү оешмаларына җәяүле юл башлангыч сыйныф укучылары өчен – 0,5 км.-дан артык булмаска тиеш, авыл гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен – 2,0 км.-дан артык түгел, төп гомуми һәм урта гомуми белем алучылар өчен – 4,0 километрдан артык түгел.

Күрсәтелгән ераклыктан артыграк булгада, авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен гомуми белем бирү оешмасына кадәр транспортта алып бару һәм аннан алып кайту оештырылырга тиеш. Бер як юлга вакыт 30 минуттан артмаска тиеш. Балалар аларны йөртү өчен билгеләнгән махсус транспортта йөртелә. укучылар җыела торган тукталышка җәяүле ара 500 метрдан артык булмаска тиеш. Авыл районнарына тукталышка кадәр җәяүле радиусны 1 км.-га кадәр арттыру рөхсәт ителә.

Транспорт хезмәте күрсәтелә торган иң чик ераклыктан артыграк арада тора торган укучылар өчен, шулай ук табигать шартлары аркасында транспорттан файдаланып булмый торган чорда 2.4.2.2821-10 СанПиНның 2.6. пункты нигезендә гомуми белем бирү оешмасы каршында интернат булдыруны күздә тоту тәкъдим ителә.

Укучыларны транспортта йөртүне оештырганда гамәлгә куючылар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларын-

нан нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 елның 3 августындагы 400 номерлы нигезләмәгә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәп автобусы маршрутын ачу турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 3 августындагы 615 номерлы карары белән расланган Мәктәп автобусы маршрутын ачу турындагы нигезләмәгә таянып эш итәргә тиешләр.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан балигъ булмаган балаларның белем алуга хокуклары бозылу турында Актаныш муниципаль районы башлыгы исеменә бәяләмә җибәрелгән иде. Әмма үокук бозулар бетерелмәде. Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Прокуроры адресына Актаныш муниципаль районында балигъ булмаганнарның белем алуга хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлешенә тикшерү уздыру һәм процессуаль карар кабул итү турында мөрәҗәгать җибәрде.

Уздырылган чаралар нәтиҗәсендә юлларның бер өлеше вак таш белән ябылган, юлның калган өлешен 2018 елда ремонтлау планлаштырыла, шуның өчен 10 млн.сум акча бирү турында карар кабул ителгән.

Зеленодольск муниципаль районында «Советлар Союзы Герое Н.Соболев ис. 2 нче Васильево урта мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесендә укучыларны һәм Казан шәһәренең «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балалар өчен 76 нчы мәктәп» шәһәр бюджет белем бирү учреждениеләрендә укучыларын китерү-кайтаруны оештыру мәсьәләләрен хәл итү өчен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан белем бирү оешмаларын гамәлгә куючылар адресына мөрәҗәгатьләр юлланды, соңыннан аларны карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Президентына югарыда күрсәтелгән мәктәпләргә мәктәп автобуслары бирү турында мөрәҗәгать җибәрелде.

Дүртенчедән, контроль-күзәтчелек эшчәнлеге кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ел саен балаларны гомуми белем бирү оешмаларына алудан баш тартуга карата ата-аналардан кергән шикаятьләрне карый.

2017 елда ***1 сыйныфка балаларны алудан түбәндәгеләрнең баш тартуына шикаятьләр керде:***

Казан шәһәре Идел буе районының «19 нчы гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү оешмасына (2 шикаять);

Әлмәт шәһәренең «24 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү оешмасына;

Чаллы шәһәренең «76 нчы гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү оешмасына.

Мөрәҗәгатьләрне карау барышында «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 67 статьясын һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номрлы боерыгы белән расланган Гражданнарны башлангыч, төп гомуми, урта гомуми белем алу программалары буенча укуга кабул итү тәртибен (алга таба – Кабул итү тәртибе) түбәндәгечә бозулар ачыкланды:

гаризаларны кабул итү кенәгәсендә кайбер ата-аналарның гаризаларын теркәүнең булмавы;

беркетелмәгән территориядә яшәүче балаларны гомуми белем бирү оешмасының беренче сыйныфына кабул итү гаризаларын алу агымдагы елның 1 июленә кадәр үк башланган;

яшәү урыны буенча яисә беркетелгән территориядә тору урыны буенча теркәлү турында белешмә булган документны алудан баш тарту.

Мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча өч очракта мәсьәләне уңай хәл итеп булды, шул исәптән бер очракта – суд аша. Бер очрата (мәктәпкә беркетелгән микрорайон-

нан читтә яшәүче баланы мәктәпкә урнаштыру буенча ата-аналар мөрәҗәгате буенча) мөрәҗәгать итүчегә аңлатма бирелде.

Гражданнардан биш мөрәҗәгать Казанда (3 мөрәҗәгать) һәм Алабуга муниципаль районында (2 мөрәҗәгать) 9 нчы сыйныфны тәмамлаучыларны ***10 нчы сыйныфка алу*** мәсьәләсе буенча керде.

Дүрт очракта яшүсмерләрнең хокукларын бозу фактлары расланды:

Алабуга муниципаль районының «4 нче гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе;

Казан шәһәренең Яңа Савин районының «Россия Герое А.В.Козин ис. 7 нче гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе;

Казан шәһәре Вахитов районының «131 нче лицее» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе.

Шуңа бәйле рәвештә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан тиешле чаралар күрелде. Мәсьәлә балигъ булмаганнар файдасына уңай хәл ителде.

Балаларын 10 нчы сыйныфка алудан баш тартуга карата гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлаудан күренгәнчә, мәгариф оешмалары сайтларындазаконнар таләпләренең бозылуы күзәтелә. Белем бирү ешмасына укучыларны кабул итү кагыйдәләрен регламентлаштыра торган локаль норматив актлар күчермәләрен урнаштыру һәм яңартуның үз вакытында башкарылмавы, йә кабул итү кагыйдәләрендә балаларның укырга керү регламенты турында мәгълүматның ачык бирелмәве, белем алучыларны индивидуаль «сайлап алу критерийлары» булмавы ачыкланды.

Белем бирү оешмаларының локаль норматив актларында билгеләнгән укучыларны индивидуаль сайлап алу критерийлары гамәлгә куючылар белән килештерелмәгән.

Балаларны профильле сыйныфларга кабул иткәндә индивидуаль сайлап алуның «ачыклык» өлешендә төгәл критерийлары һәм балаларны 10 сыйныфка алу процедураларының объективлыгы булмау коррупциячел фактор булып санала.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү барышында «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законы таләпләре нигезендә мәгариф оешмалары сайтларына гамәлгә ашырыла торган уку-укыту программалары турында, һәр уку-укыту программасы буенча кабул итү (күчерү) өчен вакантлы урыннар саны турында мәҗбүри мәгълүматны, оешмага белем алучылар кабул итү кагыйдәләрен регламентлаштыра торган локаль норматив актлар күчермәләрен урнаштыру һәм яңартуның үз вакытында башкарылмавы, йә кабул итү кагыйдәләрендә белем алучыларның укырга керү регламенты турында мәгълүматның ачык бирелмәве, белем алучыларны индивидуаль сайлап алу критерие булмавы, шул сәбәпләр аркасында ата-аналарның белем алучыларны 10 нчы сыйныфка кабул итү кагыйдәләре белән танышу мөмкинлекләре булмавы ачыкланды.

Шул ук вакытта, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 5 пункты нигезендә аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү буенча төп гомуми һәм урта гомуми дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны алганда йә күчергәндә индивидуаль сайлап алуны оештыру Россия Федерациясе субъекты законнарында каралган очракларда һәм тәртиптә башкарыла.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Министерства образования и науки Республики Татарстан от 27 февраля 2015 года № 1156/15 «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны алганда йә күчергәндә индивидуаль сайлап алуны оештыру тәртибен раслау турында»гы боерыгы

белән Татарстан Республикасының аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү буенча төп гомуми һәм урта гомуми дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны алганда йә күчергәндә яисә профильле белем алу өчен индивидуаль сайлап алуны оештыру тәртибе (алга таба – Тәртип) расланды.

Тәртип нигезендә аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү буенча төп гомуми һәм урта гомуми дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны алганда йә күчергәндә яисә профильле белем алу өчен индивидуаль сайлап алуны оештыру, тирәнтен өйрәнелә торган тиешле фәннәр яисә уку юнәлешендәге фәннәр буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен узуны исәпкә алып, өлгереш нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла. Укучыларны индивидуаль сайлап алу критерийлары, гамәлгә куючы белән килештереп, гимназиянең локаль норматив актлары белән билгеләнә.

Мисал: *Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә Алабуга шәһәренең «4 нче гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесендә балалары укучы ата-аналардан балигъ булмаганнарның хокуклары бозылу турында мөрәҗәгатьләр керде. Мөрәҗәгать итүчеләрнең мәгълүматында аларның балаларын 9 сыйныфтан 10 нчы сыйныфка күчерүдән баш тарту турында хәбәр ителә.*

Алабуга шәһәренең «4 нче гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесендә профильле белем алу турында гимназия сайтында ***(https://edu.tatar.ru/elabuga/gym4/page1616389.ht*** *урнаштырылган нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) анализлау анда законнар таләпләренә туры килмәү очраклары булуын күрсәтте.*

Нигезләмәнең «Профильле сыйныфларга укучыларны кабул итү, аннан чыгару, аны тәмамлап чыгу тәртибе» дигән III бүлекнең 3.4– 3.7 пунктлары нигезендә аерым фәннәрне профильле өйрәнү юнәлшендә урта гомуми белем алу өчен гимназиягә индивидуаль сайлап алу конкурс вәзгыяте барлыкка килгән очракта (профильле сыйныфларда укырга теләүчеләр саны билгеләнгән урыннар саныннан артып китәкн очракта) оештырыла.

Урта гомуми белем дәрәҗәсенә профильле сыйныфларга кабул иткәндә укучы сайланган тиешле профильгә туры килә торган фән/фәннәр буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе узарга тиеш. Әгәр 9 нчы сыйныф укучысы профильле фән буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен узмаса, рустеле һәм математика буенча нәтиҗәләре һәм укучының өлгереш портфолиосы исәпкә алына.

Гимназия ата-аналар (законлы вәкилләре) һәм укучылар белән мәгълүмати эш уздыра, шулай ук үзенең рәсми сайтында агымдагы елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча профильле сыйныфларга индивидуаль сайлап алу тәртибен урнаштыра.

Шул ук вакытта, «Укучыларның өлгереш портфолиосын» бәяләү критерийлары билгеләнмәгә (Нигезләмәнең 3.6 пункты).

Профильле сыйныфларга индивидуаль сайлап алу критерийлары Нигезләмәдә күрсәтелмәгән.

Гимназия сайтында урнаштырылган документларны анализлаудан күренгәнчә, гимназиябуенча Нигезләмәнең 3.7 пункты сылтама ясый торган «Профильле сыйныфларга индивидуаль сайлап алу тәртибе» дигән локаль акт та юк.

Шулай итеп, профильле сыйныфларга индивидуаль сайлап алу критерийлары гимназиядә юк, бу, балаларны 10 нчы сыйныфка (профильле сыйныфларга) алганда, «ачыклык» һәм объективлык процедурасы булмавын күрсәтә.

Профильле сыйныфларга индивидуаль сайлап алу турында мәгълүмат та гимназиянең сайтында урнаштырылмаган (Нигезләмәнең 3.9 пункты).

Балигъ булмаган П. һәм Н.ны 4 нче гимназиянең 10 нчы сыйныфына кабул итүдән югарыда күрсәтелгән нигездә баш тарту законлы түгел, балаларның хокукы бозылган, шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Алабуга муниципаль районы башлыгына ачыкланган хокук бозуларны бетерү буенча бәяләмә җибәрелде. ***Бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча мәктәп җитәкчесе тарафыннан ата-аналарга балаларын 10 сыйныфка алу турында гариза язарга тәкъдим ителде.***

Мисал: *Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә Казан шәһәре Яңа Савин районының «Россия Герое А.В.Козин ис. 7 нче гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесендә (алга таба – 7 нче гимназия) баласы укый торган гр.А.дан баласының хокуклары бозылу турында мөрәҗәгать керде. Мөрәҗәгать итүченең мәгълүматында аның кызын 9 сыйныфтан 10 нчы сыйныфка күчерүдән баш тарту турында хәбәр ителә. 7 нче гимназия хезмәткәрләре балигъ булмаган балага, ата-аналарына хәбәр итмичә, шәхси эшен тоттыралар һәм аның 7 нче гимназиядән чыгарылуы турында әйтәләр.*

7 нче гимназиянең сайтында урнаштырылган локаль актларны өйрәнү йомгаклары буенча түбәндәгеләр билгеләнде.

Казан шәһәре Яңа Савин районының «Россия Герое А.В.Козин ис. 7 нче гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең сайтта ***(https://edu.tatar.ru/nsav/page2297.htm/page1422290.htm)*** *урнаштырылган профильле сыйныфлар турындагы нигезләмәсен анализлау анда законнар таләпләренә туры килмәү очраклары булуын күрсәтте.*

7 нче гимназиянең «Профильле сыйныфларга укучыларны кабул итү тәртибенең» II бүлегендәге 2.3 пункты нигезендә профильле сыйныфларга кабул иткәндә түбәндәгеләр исәпкә алынмый:

«рейтинг бәяләнеше»,

укучының тиешле профильле фәннәр буенча олимпиадаларда. конкурсларда катнашуның югары нәтиҗәләре турында мәгълүмат булган «портфолио»сы

даими өлгереш;

укучының аттестат баллары;

гимназия укытучыларының һәм психологларының тәкъдимнәре.

Шулай ук «рейтинг бәяләнеше», «даими өлгереш» критерийлары юк; гимназия укытучыларының һәм психологларының тәкъдимнәре формлашуын барлыкка китерә торган критерийлар билгеләнмәгән.

Балигъ булмаган А.ны. 7 нче гимназиянең 10 нчы сыйныфына кабул итүдән югарыда күрсәтелгән нигездә баш тарту законлы түгел, баланың хокукы бозылган, шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан ачыкланган хокук бозуларны бетерү буенча тиешле бәяләмә җибәрелде. ***Бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча мәктәп җитәкчесе тарафыннан ата-аналарга баланы 10 сыйныфка алу турында гариза язарга тәкъдим ителде.***

Татарстан Республикасының белем бирү оешмаларында калга таба югарыда күрсәтелгән балигъ булмаганнарның белем алуга хокуклары бозылуга юл куймау максатларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары белән берлектә оешмага белем алучылар кабул итү кагыйдәләрен регламентлаштыра торган локаль актларны аларның законнарга туры килү-килмәвен тикшерергә, туры килмәү ачыкланган очракта, аларга тиешле үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә; профильле сыйныфларга индивидуаль сайлап алу тәртибен, критерийларын эшләргә һәм аларны гомуми белем бирү оешмаларын гамәлгә куючылар белән килештерергә.

Мөрәҗәгатьләрне карау йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының мәгариф бүлекләренә (идарәләренә) «Гомуми белем алу өчен муниципаль белем бирү оешмаларына кабул иткәндә хокук бозуларны булдырмау турында» хат җибәрелде, ә аннары «10-11 сыйныфларга кабул итүне оештыру турында» 2017 елның 2 ноябрендәге чыг.-2223/17 номерлы күрсәтмә җибәрде.

Бу документларда муниципаль районнар һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләренә муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем программалары буенча һәркем файдалана алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру кергәнлегенә аңлатма бирелә.

Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының мәгариф бүлекләренә (идарәләренә) түбәндәгеләр тәкъдим ителде:

гомуми белем бирү оешмаларының укучыларны профильле сыйныфларга кабул итү турында локаль актларын законнар таләпләренә туры китерү эшен оештырырга;

10 нчы сыйныфларны җитәрлек санда булдыруны күздә тотарга, профильле юнәлештәгеләрне генә түгел, ә универсаль (профильле булмаган) белем бирүне гамәлгә ашыручы сыйныфларны да;

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарны башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем программалары буенча белем алуга кабул итү тәртибенең 4 пунктны таләпләрен исәпкә алып, соңыннан универсаль сыйныфлар оештырыла торган белем бирү оешмалары исемлекләрен булдырырга;


универсаль (профильле булмаган) белем бирүне гамәлгә ашыручы 10 нчы сыйныфларны комплектлау мәсьәләсен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан контрольгә алырга.

Бишенчедән, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең даими игътибарында – белем бирү оешмаларында ***укымый торган (дәресләргә йөрми торган)*** 7 – 18 яшьтәге балалар һәм яшүсмерләр проблемасы.

Республикада «Белем бирү оешмаларында укымый торган (дәресләргә йөрми торган) 7 – 18 яшьтәге балалар һәм яшүсмерләр саны турында белешмәләр» 1-НД статистика хисабы күрсәткечләре буенча республикада белем оешмаларында төрле сәбәпләр буенча укымый торган балалар саны елдан-ел кими бара. Узган ел белән чагыштырганда бу сан 19 кешегә (3,2%ка) кимегән һәм хәзер андыйлар 579 кеше исәпләнә.

120 нче диаграмма


2013 – 2017 елларда мәктәпкә йөрмәүче мәктәп яшендәге балалар саны



Әлеге статистик хисапны анализлаудан күренгәнчә, 532 баладан 295е – 14 – 17 яшьтәге яшүсмерләр, 237 бала – 132 яшькә кадәргеләр, 47 бала – 18 яшьтәгеләр.

121 нче диаграмма

2017/2018 уку елында мәктәпкә йөрмәүче мәктәп яшендәге балалар саны



579 баладан бары тик 442се генә (76,3%) сәламәтлеге начар булу сәбәпле укымый, шул исәптән 250 баланың сәламәтлек мөмкинлекләре чикле.

Калган 137 баладан:

1 бала бөтенләй укымый;

90 балигъ булмаган бала эшкә урнашу аркасында укудан киткән;

3 бала укудан чыгарылган;

43 балигъ булмаган бала башка сәбәпләр аркасында укымый.

Шул 137 баладан 23е, мәҗбүри төп гомуми белем алмыйча, мәктәптән төшеп кала, шул исәптән:

1 баланың башлангыч гомуми белеме дә булмый;

22 баланың төп гомуми белеме юк.

91 бала, урта гомуми белем алмыйча, мәктәптән төшеп кала.

Ә бит Россия Федерациясе Конституциясе һәр гражданга төп гоуми белем алуны мәҗбүри итеп йөкли, ә аларның ата-аналарына яисә аларны алыштыручы затларга – балаларына шул белемне алуны тәэмин итү бурычын (43 статьяның 4 өлеше).

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 66 статьясындагы 5 пункты нигезендә башлангыч гомуми белем, төп гомуми белем, урта гомуми белем белемнең мәҗбүри баскычлары булып тора. Урта гомуми белемнең мәҗбүри булу таләбе белем алучының 18 яшенә җиткәнче үз көчен саклый.

Федераль законның 63 статьясы нигезендә муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары гомуми белем алуга хокуклары булган һәм тиешле муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче балаларның һәм балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) билгеләнгән белем алу рәвешләренең исәбен алып бара.

Балигъ булмаганнарның белем алуга хокукларын яклау максатларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк дип саный:

муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына гомуми белем алуга хокуклары булган һәм тиешле муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче балаларның исәбен алып баруны тәэминитәргә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

нинди ведомствога каравына бәйсез рәвештә, барлык типтагы һәм төрдәге мәгариф оешмаларына дәресләргә җитди сәбәпләрсез озак вакыт дәвамында (системалы рәвештә) йөрми торган балигъ булмаганнарны ачыклау һәм исәпкә кую буенча методик тәкъдимнәр эшләргә (кабат);

җирле үзидарә органнары белән берлектә, балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә балигъ булмаганнар тарафыннан федераль законнарның мәҗбүри гомуми белем алу өлешендәге таләпләрен бозуга китерүче сәбәпләрен детальләп анализларга;

балигъ булмаганнарның дәресләргә җитди сәбәпләрсез озак вакыт дәвамында йөрмәүләренә сәбәп булган шартларны ачыклауга, аларны алдан профилактикалауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән чаралар системасын, шул исәптән индивидуаль профилактикалау чараларын да кертеп, гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;


балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә һәм муниципаль комиссияләргә, нинди ведомствога каравына бәйсез рәвештә, барлык типтагы һәм төрдәге мәгариф оешмаларына дәресләргә җитди сәбәпләрсез озак вакыт дәвамында (системалы рәвештә) йөрми торган балигъ булмаганнарны ачыклау һәм исәпкә кую буенча эшнең оештырылуы өлешендә мәгариф оешмаларында, мәгарифкә идарә итү органнарында тикшерүләр оештырырга.

Алтынчыдан, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 9, 11 сыйныфларда укучы балалары дәүләт йомгаклау ***аттестациясенә кертелмәүгә*** бәйле ата-аналардан алынган мөрәҗәгатьләрне карады.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматы буенча, 2016-2017 уку елында 260 балигъ булмаган бала аттестациягә кертелмәгән: 249 укучы – 9 сыйныфтагылар – дәүләт йомгаклау аттестациясенә (ГИАга) кертелмәгән, 11 укучы 11 сыйныфныкылар – БДИга кертелмәгән.

122 нче диаграмма

2014– 2017 елларда дәүләт йомгаклау аттестациясенә кертелмәгән укучылар саны



Кагыйдә буларак, мәктәпләр администрациясе укучыларны аларның арадаш аттестация нәтиҗәләре начар булу аркасында дәүләт йомгаклау аттестациясенә кертми, алар мәктәпләрдә һәр елны апрель – май айларында уза. Формаль яктан караганда, аларны кертмәү нигезле дә, һәм хокукый яктан сораулар тумаска тиеш.

Шулай да, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә ата-аналардан кергән шикаятьләрне анализлау белем бирү оешмаларының администрацияләре һәм педагоглар коллективлары эшчәнлегенә җитди дәгъвалар тудырды. Шунысы ачык, имтиханга кертелмәгән укучыларның укуда артта калулары имтихан алдыннан кинәт булган хәл генә түгел. Бу, кагыйдә буларак, укучыларның берничә елларга сузылган системалы рәвештә начар уку нәтиҗәсе. Белем бирү оешмаларының администрацияләре балаларның начар укуларына, балаларга һәм аларның ата-аналарына законнарда каралган төрле чаралар (район мәгариф идарәләренең һәм балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең ресурсларын җәлеп итүгә кадәр) кулланып, вакытында игътибар итәргә тиеш иделәр. Ә шуның урынына укучыларда «өчлеләр тезелеп китә».

Мисал: *Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы мәктәбенең 11 сыйныф укучысы К.ның әнисе К.дан мөрәҗәгать керде, анда аның кызын БДИга кертмәүләре турында язылган иде.*

Мөрәҗәгать итүченең мәгълүматына караганда, сыйныф җитәкчесе аңа кызының «Математика»дан өлгереше начар булуы һәм җитди проблемлар барлыгы турында вакытында әйтмәгән. Шикаятьне тикшерү барышында шунысы ачыклана, 2016-2017 уку елының беренче һәм икенче яртыеллык йомгаклары буенча да, еллык йомгаклар буенча К.ның математикадан билгесе «3»ле булган. Ә 2017 елның 23 маенда балигъ булмаган баланың әнисенә кызының арадаш аттестацядә алган билгеләре нәтиҗәләре буенча аны аттестациягә кертмәүләре турында хәбәр итәләр.

Шул ук вакытта агымдагы елның 31 маенда К.ны математика буенча БДИ бирергә кертәләр, ә «Җәмгыять белеме» буенча имтиханга кертмиләр. Шуның нәтиҗәсендә К.ның сәламәтлегенә зыян килә, аның психикасы бозыла.

Барлыкка килгән вәзгыятьне комплексы бәяләү максатларында 2017 елның 8 июнендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында Координация комитетының утырышы була, анда Татарстан Республикасы прокуроры урынбасары О.А.Дәминов катнашты.

К.ны БДИга кертмәү турындагы мәсьәләне караганда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Координация комитеты утырышында катнашучы башкаларга К.ның әти-әнисенә аларның кызларының «Математика» фәне буенча өлгереше начар булуы турында вакытында мәгълүмат бирелүне раслый торган документлар, шулай ук вакытында профилактик чаралар һәм әлеге кызның укуындагы проблемаларны хәл итү буенча башкарылган чаралар турында документлар һәм мәгълүмат бирелмәгән.

Мәктәп администрациясенең, район белем бирү идарәсенең битарафлыгы аркасында балигъ булмаган баланың хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозыла,шуңа бәйле рәвештә район башлыгы исеменә ттиешле бәяләмә җибәрелә. Бәяләмәне карау йомгаклары буенча К.ны БДИга кертү варианты табылды, ә ул аны уңышлы узып чыкты.

Мәктәпләр җитәкчелегенең шундый битарафлык күрсәтүе, безнеңчә, мәктәп эшчәнлегенең юнәлеше, югары рейтинг күрсәткечләре артыннан «чабып», дәүләт йомгаклау аттестациясенең удышлы нәтиҗәләренә юнәлгән булуы белән аңлатыла. Мәктәп директорларына бүген түбән баллар аркасында мәктәп рейтингын куркыныч астына куюга караганда, «көчсез» укучыларны ГИАга кадәр җиткермәү отышлырак.

Әмма шуны да онытмаска кирәк, яшүсмер ГИАга кертелмәгән һәр очракта аның өчен тирән психологик вәзгыять барлыкка килә. Моннан тыш, мондый вәзгыять болай да хәлләре бик үк әйбәт булмаган балигъ булмаганны алга таба белем алуда, эшкә урнашуда тагын да кыенрак хәлдә калдыра һәм бу аның киләчәк язмышына тискәре тәэсир итәргә мөмкин.

Шул ук вакытта, укучыны ГИАга кертмәүнең һәр очрагы – мәктәп эшенә тискәре бәя бирү белән аңлатыла.

Шуңа бәйле рәвештә, укучыларның системалы рәвештә укуларында өлгерүләрен профилактикалау һәм балаларның белем алуга хокукларын тәүмин итү максатларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга кирәк дип саный:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

гомуми белем бирү оешмаларының рейтингына «Дәүләт йомгаклау аттестациясенә кертелмәгән укучылар өлеше» күрсәткечен кертергә;

муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белән берлектә, укучыларны дәүләт йомгаклау аттестациясенә кертмәү очракларын киметү буенча чаралар күрергә;

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика һәм муниципаль комиссияләргә үз утырышларында даими рәвештә укучыларны дәүләт йомгаклау аттестациясенә кертмәүгә китерә торган вәзгыять мониторингы мәсьәләләрен карарга, алар буенча карарлар кабул итәргә һәм балигъ булмаганнарның хокукларын яклау буенча чаралар күрергә.

Җиденчедән, 2017 елда тагын бер мәсьәлә – ***гаиләдә белем алучы балаларны укытуны оештыру*** да Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең игътибарыннан читтә калмады.

Ел дәвамында, балаларының (оныкларының) белем бирү оешмаларына йөрмичә, белем алмыйча калуларына борчылып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә ата-аналардан (әби-бабайлардан) мөрәҗәгатьләр керде.

Мисал: *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә гр. С.дан Казан шәһәрендә әтисе Л. белән бергә яшәүче оныгы Б.нең гаиләдәге тормыш киеренкелеге турында мөрәҗәгать керде.*

Бу мөрәҗәгатьне тикшерү максатында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белем бирү оешмасына һәм Б.нең яшәү шартларына тикшерү оештырды.

Тикшерү чаралары барышында һәм Б.нең яшәү урынын тикшергәннән соң (Идел буе районы), аның Казан шәһәре Совет районының «125нче гимназиясе»ндә 1 сыйныфтан 7 нче сыйныфка кадәр укыган булуы ачыкланды. 2006 елның мартында кызның әтисе Л.ның баласын мәктәптән өй шартларында белем алуга күчерү турында Совет районы белем бирү оешмасына бирелгән гаризасы нигезендә Б. мәктәптән җибәрелә. 2016 елның мартыннан Б. өй шартларында укый, 7 сыйныф өчен арадаш аттестацияне Казан шәһәре Совет районының «125 нче гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесендә уза.

2016/2017 уку елында һәм 2017/2018 уку елында Б. мәктәптә укымый, аның атасы тарафыннан да кызын укыту оештырылмый.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе ягыннана да Б.га карата исәпкә куюга юнәлдерелгән чаралар күрелми һәм укырга тиешле, әмма мәктәптә укымый торган баланы ачыклау өчен берни дә эшләнми. Шуңа бәйле рәвештә, баланың хокуклары бозылу һәм аларны бетерү буенча чаралар күрү турында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан бәяләмә җибәрелә.

Мисал: *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә балигъ булмаган Б.ның атасы аның балигъ булмаган кызы белән булган хәлдә ярдәм итүне үтенеп мөрәҗәгать итте. Аның кызы агымдагы елның 6 октябреннән кыен яшүсмерләр өчен «Герда» хосусый коррекция үзәгендә (алга таба — үзәк) тора. Балигъ булмаган Б.ның атасына, ягъни баланың законлы вәкиленә, оешманың администрациясе баланың урнашкан урынының кайда булуы турында мәгълүмат бирүдән баш тарта һәм кызы белән күрешергә мөмкинлек бирми.*

Мәсьәләне оператив тикшерү нәтиҗәсеннән күренгәнчә, әлеге үзәктә озак вакыт 40ка якын балигъ булмаган бала яши, алар гаиләдә белем алалар һәм 2016/2017 уку елында арадаш аттестация узу өчен Казан шәһәренең «156 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУенә беркетелгән.

Шул ук вакытта, мәктәп биргән документларны анализлаудан күренгәнчә, 2017/2018 уку елында мәктәпкә 35 балигъ булмаган бала беркетелгән, шунда ук 6 бала арадаш аттестация нәтиҗәләре буенча икенче елга калдырылган. Законнар таләпләре нигезендә гаиләдә белем алучы укучылар, билгеләнгән срокта академик бурычларын бетермәсәләр, белем бирү оешмасында укырга тиеш булалар.

Тикшерү барышында ачыкланган күпсанлы хокук бозуларны исәпкә алып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Казан шәһәре Прокуроры исеменә үзәк эшчәнлеген тикшерү һәм прокурор тарафыннан чаралар күрү өчен мөрәҗәгать җибәрә, нәтиҗәдә, прокуратура үзәк эшчәнлеген туктату турында судка дәгъва җибәрә.

Россия Федерациясе Конституциясе (43 статьяның 4 өлеше), Россия Федерациясе Гаилә кодексы (63 статья), «Россия Федерациясендә белем бирү турында» Федераль закон (66 статьяның 5 өлеше) нормалары нигезендә башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем укуның мәҗбүри дәрәҗәләре дип санала. Балаларга гомуми белем бирүне тәэмин итү законнар белән ата-аналарга яисә аларны алмаштыручы затларга йөкләнә.

Федераль законда, шәхеснең ихтыяҗларын һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып, белем алуның төрле рәвешләре карала.

Гомуми белем укыту эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда, шулай ук аннан тыш урыннарда алынырга мөмкин. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда уку көндез йөреп, көндез-читтән торып яисә читтән торып башкарылырга мөмкин. Белем бирүне гамәлгә ашыручы оешмалардан тыш, белем алу һәм укыту гаиләдә белем алу һәм үзлегеннән белем алу рәвешендә рәвешендә каралган.

Гомуми белем алу рәвеше һәм төп конкрет гомуми белем программасы буенча уку рәвеше балигъ булмаган укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан

билгеләнә. Балигъ булмаган укучының ата-аналары (законлы вәкилләре) гомуми белем алу рәвешен һәм уку рәвешен сайлаганда баланың фикере дә исәпкә алына. Ата-аналар (законлы вәкилләр), балалары өчен гаиләдә белем алу рәвешен сайлаганда, белем бирү оешмасында балаларын укытудан баш тарталар һәм гаиләдә белем алуны тәэмин итү буенча үзләренә җаваплылык – баланың белем, күнекмәләр алуы, тәҗрибә туплавы, сәләтләрен үстерү, алган белемнәрен гомер буена тормышта кулланырга өйрәтү буенча үз эшчәнлекләрен максатчан оештыру җаваплылыган алалар.

Гаиләдә белем алу рәвешендә укучы балаларга арадаш һәм дәүләт йомгаклау аттестациясе узу турында закон таләпләре кагыла. Алар тиешле белем бирү программасы буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда аттестацияне экстерн рәвештә (алдан) уза алалар. Моның өчен арадаш һәм дәүләт йомгаклау аттестациясе узу шундый оешмага экстерн рәвештә алынырга тиешләр. Башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу программалары буенча укучы һәм билгеләнгән срокта академик бурычларын бетермәгән балалар белем бирү оешмасында укуларын дәвам итәләр.

Балаларның гомуми белм алуга хокукларын гамәлгә ашыруны дәүләт тарафыннан гарантияләүне тәэмин итү максатларында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына закон белән һәр дәрәҗәдә гомуми белем алуга хокукы булган һәм тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче балаларны, шулай ук балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнгән белем алу һәм уку рәвешләрен исәпкә алу вазыйфалары йөкләнә. Балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан гаиләдә укыту рәвеше сайланганда, алар моның турында үзләре яши торган муниципаль районның яисә шәһәр округының җирле үзидарә органына хәбәр итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча, 2017/2018 уку елында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу программалары буенча гаиләдә укыту рәвешендә 606 кеше белем ала, бу узган елга караганда 19%ка күбрәк (2016/2017 уку елында – 510), шул исәптән:


башлангыч гомуми белем программалары буенча – 383кеше,

төп гомуми белем программалары буенча – 218 кеше,

урта гомуми белем программалары буенча – 5 кеше.

123 нче диаграмма

2017/2018 уку елында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем программалары буенча гаиләдә белем алу рәвешендә укучылар саны



Гаиләдә белем алучы 606 кешедән 2017 елның 6 октябренә 547 кеше (90,3%) арадаш аттестация һәм дәүләт йомгаклау аттестациясе узу өчен түбәндәге гомуми белем бирү оешмаларына беркетелгән:

444 кеше – Татарстан Республикасында урнашкан оешмаларга;

103 кеше – Россия Федерациясенең башка субъектларында урнашакан оешмаларга.

Шул ук вакытта, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил таләбе буенча Санкт-Петербургта Мәгариф идарәсенең Белем бирү комитеты рәисе урынбасары һәм Санкт-Петербург шәһәренең «ЦОДИВ» хосусый мәктәбе» директоры тарафыннан бирелгән мәгълүмат буенча, 2017/2018 уку елында бу мәктәптә генә дә Татарстан Республикасыннан 413 бала гаиләдә уку рәвешендә белем алган, шулардан 4 баланың академик бурычы була һәм алар арадаш аттестация оештыру һәм уздыру шартнамәсен озайтмыйлар.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 2016/2017 уку елында гаиләдә укучы һәм һәм арадаш аттестацияне узмаган, шулай ук белем бирү оешмасында укуларын дәвам итүче балалар саны турында мәгълүмат бирелмәде, бу балаларын гаиләдә белем алуга күчергән ата-аналарның үз өсләренә алган бурычларын ничек үтәүләрен бәяләргә мөмкинлек бирми.

Әлеге фактлар республиканың муниципаль районнары һәм шәһәр оукруглары җирле үзидарә органнары тарафыннан бу категория балаларны исәпкә алу җайга салынмаганлыгын күрсәтә. Тармак министрлыгында да гоумиләштерелгән мәгълүмат юк. Мондый хәл балаларны өйдә укытудагы вәзгыятьне тулысы белән объектив бәяләргә мөмкинлек бирми, һәм бу балаларның гомуми белм алуга хокукларын җитди бозуга китерергә мөмкин.

Моннан тыш, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил кайбер муниципаль органнарның өйдә белем бирүне оештыру мәсьәләләрен җайга сала торган җирле актларын өйрәнде, шул исәптән Казан шәһәре Мәгариф идарәсенең «Казан шәһәре территориясендә өйдә уку, үзлегеннән уку рәвешендә гомуми белем алу турында» 2013 елның 28 ноябрендәге 771 номерлы боерыгы да тикшерүгә алынды. Уздырылган анализлаудан күренгәнчә, бу документларда өйдә укытуга күчерелгән балаларны исәпкә алуның төгәл тәртибе каралмаган.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәгеләрне эшләргә кирәк дип саный:

өйдә уку, үзлегеннән уку рәвешендә гомуми белем алучы балигъ булмаганнарны исәпкә алуның үрнәк тәртибен эшләргә һәм расларга;

муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белән берлектә, балаларның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыруда дәүләт гарантияләрен тәэмин итү буенча катгый чаралар комплексын эшләргә;

шул исәптән һәр дәрәҗәдә гомуми белем алуга хокукы булган һәм тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче һәм 2016/2017 уку елында өйдә укучы һәм арадаш аттестацияне узмаган һәм белем бирү оешмасында укуларын дәвам итүче балалар санын, шулай ук балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнгән белем алу һәм уку рәвешләрен исәпкә алуны җайга сала торган җирле актлар эшләргә (балалар органнарның һәм белем бирү учреждениеләренең игътибарыннан төшеп калмасын һәм законнар таләпләре бозылмасын өчен);

белем алырга тиешле, шул исәптән өйдә укучы балаларны исәпкә алу өчен эчке муниципальара хезмәттәшлекнең ведомствоара тәртибен билгеләү буенча эшләрне оештыру регламентын эшләргә;


балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика һәм муниципаль комиссияләргә үз утырышларында балаларның өйдә уку рәвешендә белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру вәзгыяте мониторингы мәсьәләсен карарга, балигъ булмаганнарның белем алуга хокукларын яклау буенча тиешле карарлар кабул итәргә һәм чаралар күрергә.

3.5.3. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балаларга белем бирү

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча, республикада ***сәламәтлек мөмкинлекләре чикле*** балаларның (алга таба – СМЧ) гомуми саны ел саен арта һәм 2017 елда аларның саны 22 304 кеше булды, ягъни республиканың гомуми балалар санының 2,7% тәшкил итә.

124 нче диаграмма


2013 -2017 елларда сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар саны (кеше)



2017/2018 уку елында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларның саны 18 951 кеше булды. Алар арасында мәктәпкәчә яшьтәге балалар – 4 305 кеше, мәктәп яшендәге балалар – 14 646 кеше. Узган ел белән чагыштырганда аларның саны 6%ка, ягъни 822 балага артыграк.

125 нче диаграмма


2017/2018 уку елында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган укучылар саны (кеше)



Белем бирүгә идарә итү органнарында исәптә торучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле ***мәктәпкәчә яшьтәге*** 4 305 баланың күпчелеген сөйләмнәре бозылган (36,2%) һәм терәк-хәрәкәт системасы сәламәт булмаган (22,9%) балалар тәшкил итә. Узган ел белән чагыштырганда, күрү сәләте бозылган (5,3%ка күбрәк), сөйләме бозылган (6% ка күбрәк) һәм ДЦП булган (7,5% ка күбрәк) балаларның саны һәм акылга зәгыйфь балалар саны арту (12,8%ка күбрәк) күзәтелә.

126 нчы диаграмма

2015 – 2017 елларда авыру төрләре буенча сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны



2017/2018 уку елында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган мәктәпкәчә яшьтәге балалар белем бирүгә идарә итү органнарында исәптә торучы балаларның гомуми санының 86,7% тәшкил итте (2016 елда – 84%). Авыру төрләре буенча сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны 127 нче диаграммада күрсәтелде.

127 нче диаграмма

2017 елда авыру төрләре буенча сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү




Аерым шартларда белем алуга мохтаҗ мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирүгә ясалган анализдан күренгәнчә, соңгы елларда балалар бакчаларына йөрүче сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның артуы күзәтелә. Мәсәлән, быелгы 2017/2018 уку елын-

да махсуслаштырылган мәктәпкәчә учреждениеләргә яки төркемнәргә йөрүче балалар саны 6%ка арткан (2016 елда 1972 бала булса, 2017 елда 2089 бала булды).

128 нче диаграмма

2013 – 2017 елларда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган (СМЧ) балаларның мәктәпкәчә белем белән тәэмин ителеше (кеше)



Шулай итеп, бүген республикада сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балалар тәрбияләнә алган учреждениеләр челтәре булдырылган. Шулар арасында 15 махсуслаштырылган балалар бакчасы, 468 мәктәпкәчә мәгариф оешмасында 968 махсус төркем эшләп килә. Шулай да, булдырылган челтәр Татарстан гаиләләренең ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерә дип әйтеп булмый. 2017 елда сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән 574 бала мәктәпкәчә белем алалмады. Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга яшәү урыны буенча балалар бакчасына юллама бирүдән баш тартуның төп сәбәбе – дефектолог белгечләрнең булмавында. Бүген республика мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында дефектология буенча белеме булган 88 педагог һәм 906 логопед эшли.

Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән ***мәктәп яшендәге*** балаларның белемгә хокукын гамәлгә ашыру өлешенә караган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгълүматларына ясалган анализдан күренгәнчә, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле 14 205 баладан 98,2% бала (2016 елда – 93,5%) мәктәптә белем ала. 2013 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә республика стратегиясен гамәлгә ашыруның индикатив күрсәткеченең 2017 елга чик күрсәткече 99% тәшкил итә.

Бүгенге көндә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен мәгариф киңлеге үз эченә түбәндәгеләрне ала:

сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен 52 гомуми белем бирү учреждениесе, аларда ишетү, күрү сәләте, сөйләме, терәк-хәрәкәт аппараты һәм интеллекты бозылган 7 245 бала укый;

инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыручы 158 гомуми белем бирү оешмасы (яисә гомуми мәктәпләр), алар сәламәтлек мөмкинлекләре чикле укучыларга башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф системасын һәм акылга зәгыйфь (интеллектлары бозылган) белем алучыларга белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф системасын кертүне тәэмин итүче нигези гомуми белем бирү оешмалары булып саналалар, аларда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле 1534 бала укый;

12 муниципаль район һәм Казан шәһәр округы (Аксубай, Әлмәт, Апас, Буа, Биектау, Түбән Кама, Нурлат, Балык Бистәсе, Сарман, Тәтеш, Теләче, Чирмешән муниципаль районнары) мәктәпләрендә гомуми белем бирү оешмалары базасында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле – ишетү сәләте, сөйләме, акыл үсеше һәм психик үсеше бозылган балалар өчен 89 сыйныф, аларга 532 бала йөри;

озак вакыт дәваланыга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы 2 учреждение, аларга 240 кеше йөри.

2017/2018 уку елында «Ресурслы сыйныф» пилот моделен гамәлгә кертү буларак, гомуми белем бирү мәктәпләре эшли башлады, болар: Әлмәт шәһәренең «21 нче УБМ», Казан шәһәре Мәскәү районының «65 нче УБМ», Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «168 нче ГБМ», Казан шәһәре Идел буе районының «97 нче УБМ», Казан шәһәре Совет районының «156 нчы УБМ, Казан шәһәре Вахитов районының «1 нче УБМ», Чаллы шәһәренең «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү буенча 3 нче УБМ».

Яңа уку елында әлеге 7 мәктәптә аутизм белән авыручы 31 бала башлангыч гомуми белем бирүнең төп гомуми белем программасын үзләштерә.

Уку барышында җитәкләп йөрүгә мохтаҗ булган балалар өчен махсус (коррекцияле) белем бирүне тәэмин итүдә әлеге этапта республиканың гамәлдәге коррекцияле белем системасын саклап калуы аерым әһәмияткә ия. Бүгенге көндә эшли торган махсус (коррекцияле) учреждениеләр базасында инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыручы мәктәпләргә методик ярдәм күрсәтү өчен укыту-методика ресурс үзәкләре төзелә.

Шулай итеп, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалары булган гаиләгә баланың уку маршрутын сайлап алу мөмкинлеге бар:

коррекцияле мәгариф оешмасын (республикада алар 52) сайлау;

гадәти мәктәпне, әмма коррекция юнәлешендәге программа буенча укытыла торган сыйныфны (республикада 89 шундый сыйныф бар);


инклюзив (үзлегеннән) белем алуны гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү мәктәпләрендә укуны (республикада инклюзив белем 158 мәгариф оешмасында бирелә);

«Ресурслы сыйныф» базасында республиканың 7 гомуми белем бирү оешмасында белем бирү.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган мәктәп яшендәге балаларга авырулар төрләре буенча белем бирү 129 нчы диаграммада күрсәтелә.

129 нчы диаграмма

2017 елда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле (СМЧ) булган мәктәп яшендәге балаларга авыру төрләре буенча белем бирү (кеше)



Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча, былелгы уку елында психологик-медик-педагогик комиссиянең тиешле рекомендацияләре

бирелгән 7 245 (49,5%) бала махсус (коррекцияле) мәгариф оешмаларында укый; 7 401 (50,5%) бала гомуми мәктәптә белем ала. Соңгы елларда ишетү, күрү сәләте, сөйләме бозылган мәктәпкәчә барлык балалар беренче мәртәбә мәктәп белеме алуга җәлеп ителде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 28 сентябрендәге 716 номерлы карары белән расланган 2015 – 2030 елларга Татарстан Республикасында объектлар һәм хезмәт күрсәтүләрдән инвалидларның файдалана алу күрсәткечләрен арттыру буенча чаралар планын («юл картасын») үтәү мониторингыннан күренгәнчә, 2017 елда «Гомуми белем бирү оешмаларында төп инвалид балалар, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар санының гомуми белем бирүнең җайлаштырылган программалары буенча белем алучы инвалид балалар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өлеше» 51,9% тәшкил итә. Чынбарлыктагы күрсәткеч пландагыдан 1,4% ка кимрәк.

130 нчы диаграмма


2013 – 2017 елларда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле (СМЧ) балаларның мәктәп белеме белән тәэмин ителеше



2012 елдан республикада ел саен гомуми белем бирү оешмаларында уңай мохит булдыру буенча тиешле чаралар күрелә. «Уңайлы мохит» программасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә узган чорда 321 гомуми белем бирү оешмасы инвалидларның һәм үсешләрендә тайпылышлар булмаган затларның бергә укуын тәэмин итү өчен җайлаштырылды, алар гомуми белем бирү мәктәпләренең гомуми санының 22,7% тәшкил итә (2015 – 2030 елларга Татарстан Республикасында объектлар һәм хезмәт күрсәтүләрдән инвалидларның файдалана алу күрсәткечләрен арттыру буенча чаралар планының («юл картасы»ның) 2017 елда индикатив күрсәткеченең иң чик зурлыгы 22,3% тәшкил итә).

131 нче диаграмма

Уңай мохит булдырылган гомуми белем бирү мәктәпләре саны



2017 ел йомгаклары буенча, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру вәзгыятен анализлау түбәндәге проблемалы мәсьәләләрне хәлитәргә мөмкинлек бирде.


Беренчедән, соңгы елларда кирәкле уңай мохит элементлары белән җиһазландырылган гомуми белем бирү оешмаларының саны артуга да карамастан, ***өй шартларында укучы*** балалар саны ел саен артып тора. Асылда исә, соңгы биш елда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны өйдә укудан көндез йөреп укуга күчерү тенденциясе күзәтелми.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның күпчелеге элеккечә үк өйдә индивидуаль программалар буенча укыйлар, республикада инклюзив белем бирүне үстерү буенча чаралар күрелүгә дә карамастан, бер бала да өйдә укудан көздез йөреп укуга күчмәде.

Шул ук вакытта, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча, 2017 – 2018 уку елында өйдә укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны кимүгә барганы күзәтелә башлады. Мәктәп белемен алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган 4 646 баладан 1 088 кеше (бу категориядәге балаларның гомуми санынан 7,4%), мәктәп коллективыннан тыш, читтән торып укый. 2016/2017 уку елында өй шартларында 1 370 кеше (9%) укыган.

132 нче диаграмма

2011 – 2017 елларда өй шартларында укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны (кеше)



Икенчедән, шуны да билгеләп үтәргә кирәк, республикада инклюзив белем бирүне гамәлгә кертү буенча, шул исәптән инвалид балалар өчен «гомуми» мәктәптән файдалануны тәэмин итү буенча да, чаралар күрелүгә дә карамастан, барлык төрдәге махсус (коррекцияле) гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны кимеми, ә киресенчә, арта бара (2013 елда – 5 929 кеше, 2014 елда – 6 016 кеше, 2015 елда – 6 297 кеше, 2016 елда – 6 631 кеше, 2017 елда – 7 245 кеше). Аерым алганда, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча, махсус (коррекцияле) мәктәпләрдә укучылар саны түбәндәгечә артты:

ишетү сәләте бозылганнар – 2013 елда – 373 булса, 2017 елда – 472 булды;

күрү сәләте бозылганнар – 2013 елда – 520 булса, 2017 елда – 608 булды;

сөйләме бозылганнар – 2013 елда – 139 булса, 2017 елда – 330 булды;


таяну-хәрәкәтләнү аппараты бозылганнар – 2013 елда – 383 булса, 2017 елда – 466 булды;

акылга зәгыйфьләр – 2013 елда – 4514 булса, 2017 елда – 5 470 булды.

Яшәү урыны буенча гомуми мәктәпләрдә белем бирү буенча коррекциячел юнәлештәге хезмәт күрсәтүләрдән акылга зәгыйфь балаларның һәм ишетү сәләте бозылган балаларның файдалана алмавы аеруча проблемалы мәсьәлә булып кала.

133 нче диаграмма

2017 елда авыру төрләре буенча сәламәтлек мөмкинлекләре чикле мәктәп яшендәге балаларны укытуның тәэмин ителеше (кеше)



Әлеге вәзгыять шуны күрсәтә, бер яктан, коррекцияле белем бирелүгә мохтаҗ һәм махсус шартлар үтәлүне таләп иткән ата-аналарның, элеккечә, балаларының традицион коррекцион белем алуны хуплауларын расласа, икенче яктан, балаларның яшәү урыны буенча мәктәпләрдә сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен инклюзив белем бирү буенча күрелә торган чараларның җитәрлек булмавын аңлата.

Шул ук вакытта, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау гомуми мәктәпләрдә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балигъ булмаган балаларның хокуклары бозылу фактлары булуны раслый.

Мисал: *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә балигъ булмаган И.нең атасы кызының сыйфатсыз белем алу хокукларын яклау мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итте.*

Мөрәҗәгать итүче белән шәхсән очрашып сөйләшүдән шул аңлашылды: балигъ булмаган И. 2016/2017 уку елында Казан шәһәре Яңа Савин районының «25 нче төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУнең (алга таба – 25 нче мәктәп) 1 нче сыйныфында укыган. Әмма 2017 елның сентябрендә 25 нче мәктәп директоры Ю.М.Егорова И.гә 2017 елның 1 сентябреннән аның мәктәптән чыгарылуы турында хәбәр итә, янәсе ул «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен 76 нчы мәктәп» ДБМУендә (алга таба – 76 нчы мәктәп) укырга тиеш. Моннан соң И.не әтисе кызын 25 нче мәктәптән җибәреп, 76 нчы мәктәпкә күчерә турындагы гаризалар белән бу мәктәпләрнең җитәкчеләренә мөрәҗәгать итмәгән. 25 нче мәктәп җитәкчесе «Укучыларны җәйге чорга мәктәптән җибәрү турында» 2017 елның 1 сентябрендәге 99 номерлы боерыгыннан өземтә бирә, шуның нигезендә бала 2017 елның 1 сентябрендә мәктәптән җибәрелә, әлеге боерык 2017 елның 17 маендагы 10812 номерлы ПМПК беркетмәсе нигезендә чыгарылган була.

Ә бит законнар нигезендә 15 яшькә җитмәгән укучылар белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма инициативасы белән мәгариф оешмасыннан җибәрелә алмый.

Моннан тыш, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы боерыгы белән расланган «Гражданнарны башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем алу программасы буенча укырга кабул итү тәртибе» нигезендә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программасы буенча укырга бары тик аларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) ризалыгы белән һәм психологик-медик-педагогик комиссия күрсәтмәләре нигезендә генә кабул ителәләр.

Шулай итеп, мәктәп администрациясе гамәлләре белем бирү оешмасыннан укучыларны чыгару тәртибен бозуга һәм балигъ булмаган И.нең белем алуга хокукларын бозуга китергән

булуы ачыкланды. Шуңа бәйле рәвештә, Казан шәһәре Яңа Савин районының «25 нче төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ директоры Ю.М. Егорова исеменә хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылган булуы турында бәяләмә җибәрелде.

Бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча И.нең гомуми мәктәптә белем алу хокукы торгызылды һәм ул җайлаштырылган белем бирү программасы буенча элек укыган мәктәбендә укый башлады.

Өченчедән, Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча республика эксперт төркеме эшчәнлеге кысаларында 2017 елның августында коррекцияле белем бирү оешмалары эшчәнлегенә тикшерү уздырганда (Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның 2017 елның 4 августындагы № 43654 йөкләмәсе буенча) Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты белгечләре тарафыннан «Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф учреждениеләрендә төп гомуми белем программалары буенча мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирү» дәүләт хезмәте күрсәтү стандартының балаларны башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем программасы буенча ***укырга кабул итү тәртибе бозылган булуы*** ачыкланды.

Мәсәлән, «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен Лаеш интернат-мәктәбе» ДБМУендә тәрбияләнүчеләрнең эшләрен анализлау 12 кешенең белем бирү оешмасына кабул ителүе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 17 апрелендәге 2006 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф учреждениеләрендә төп гомуми белем программалары буенча мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирү» дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын бозып башкарылган булуын ачыкларга мөмкинлек бирде:

30 нчы таблица

Укучының Ф.И. Ат.ис.	Интернат-мәктәптә укый башлаган дата	Интернат-мәктәпкә кабул итү турындагы боерыкның номеры, датасы	Психологик-медик-педагогик комиссиянең беркетмәсеннән өземтә датасы
З.	01.09.2011	№222 10.09.2011	14.05.2013
Х.	01.09.2010	№ 216 01.09.2010	28.02.2013
К.	01.09.2010	№216 01.09.2010	16.08.2012
К.	30.11.2016	№ 271 29.11.2016	11.05.2017
П.	01.09.2011	№222 10.09.2011	16.08.2012
Н.	30.09.2015	№264 30.09.2015	13.12.2017

Шул ук вакытта, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы боерыгы белән расланган «Гражданнарны башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем алу программасы буенча укырга кабул итү тәртибе» нигезендә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программасы буенча укырга бары тик аларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) ризалыгы белән һәм психологик-медик-педагогик комиссия күрсәтмәләре нигезендә генә кабул ителәләр.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 17 апрелендәге 260 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф учреждениеләрендә төп гомуми белем программалары буенча мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирү» дәүләт хезмәте күрсәтү стандартының «Дәүләт хезмәт күрсәтүен алу өчен кирәкле документларның төгәл исемлеге» дигән III бүлеге нигезендә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен дәүләт

бюджет махсус (коррекцияле) белем бирү учреждениеләренә (алга таба – СМЧ балалар өчен учреждениеләр) укырга кергәндә психологик-медик-педагогик комиссиясенең консультациясе бирелә.

Дүртенчедән, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен гомуми белем бирү оешмалары чараларын тикшерү кысаларында шулай ук ***укучыларның җәрәхәт алу сәбәпләрен тикшерү эшчәнлекләрендә кимчелекләр дә ачыкланды.*** Интернат-мәктәптә укучы балигъ булмаган балаларга медицина ярдәмен күрсәтү мәсьәләсен өйрәнгәндә балаларның гаиләдә дә, шулай ук мәктәптә дә җәрәхәтләр алган түбәндәге очраклары ачыкланды:

Казан шәһәренең «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен 1 нче Казан интернат-мәктәбе» ДБМУендә (алга таба – интернат-мәктәп):

Укучыларның медицина ярдәме күрсәтү буенча мөрәҗәгатьләрен теркәү кенәгәсендә интернат-мәктәп укучыларының җәрәхәтләр алуы турында язмалар күп. Шулай булса да, алган җәрәхәтләр буенча тикшерү уздыру эшләре оештырылмаган.

Мәс., 2016 елның 29 сентябрендә меджурналда мондый язма бар: «Д.Э., уң терсәгенең каты авыртуы турында мөрәҗәгать итте, травмпунктка җибәрелде»;

2016 елның 8 декабрендә – «Ч.А., уң күз асты канаган», җәрәхәтнең сәбәбе ачыкланмаган, моның буенча тикшерү уздырылмаган;

2017 елның 2 февралендә – «Г.Д., ике кулында да гематома», сәбәбе ачыкланмаган, моның буенча тикшерү уздырылмаган;

2017 елның 12 мартында – «Д.Н., уң кулының терсәгендә каты авырту, бармакларына кан йөгергән»;

2017 елның 13 апрелендә – «С.Р., сул кулының бармаклары авыртуга зарлана, трампунктка җибәрелгән, аннан әнисе алган».

Шәфкать туташы Н.С. Капран аңлатуынча, әлеге журнал директор үтенече белән яңадан язылган, балаларның җәрәхәтләре теркәлгән иске журнал юкка чыгарылган, комиссия әгъзаларына тапшырылмады. Интернат-мәктәп директоры С.Б.Портнова белән әңгәмә вакытында журналның яңадан тутырылу факты расланды;

«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен Актүбә интернат-мәктәбе» ДБМУендә:

Интернат-мәктәптә укучы балигъ булмаган балаларга медицина ярдәмен күрсәтү мәсьәләсен өйрәнгәндә балаларның гаиләдә дә, шулай ук мәктәптә дә җәрәхәтләр алган түбәндәге очраклары ачыкланды:

Мәс., балаларны карау кенәгәсендә мондый язмалар бар:

«13 мартта Х.А. – сул як ботында алда да, артта да күгәргән урыннар бар. Аркасында вак күгәреклəр, кызыл сызыклар? Бала әйтүенчә, өйдә апасы кыйнаган».

Бу вәзгыятьне шәфкать туташы һәм мәктәп администрациясе аңлатып киттеләр, янәсе баланың ата-анасы белән сөйләшү булган, бала әйткән сүзләр расланмаган, әлеге хәл Профилактикалау советында каралган, әмма баланы кыйнау факты балигъ булмаганнарның эшләре буенча инспекторга җиткерелмәгән, әлеге вәзгыять Профилактикалау советында анализланмаган, бу факт буенча тикшерү оештырылмаган.

2017 елның 21 ноябрендә медицина журналында Т.А.нең сул ягының авыртуына зарлануы теркәләгән. Бала аңлатуынча, аңа Коркин Б. суккан. Администрация сүзләренә караганда, бу факт буенча ата-аналар чакырылган, әлеге очрак Профилактикалау советында каралган, балигъ булмаганнар эшләре буенча инспекторга хәбәр ителмәгән. Әмма Профилактикалау советы беркетмәләрен анализлау әлеге очракның Профилактикалау советында каралмаган булуын күрсәтә.

«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен Әлмәт интернат-мәктәбе» ДБМУендә:

укучыларның җәрәхәтләрен теркәү кенәгәсендә 2017 елның 17 гыйнварында Ф.Т.нең физкультура дәресендә бите һәм уң күзе җәрәхәтләнгән, дигән язма бар. Әлеге бәхетсезлек очрагын анализлау өчен документлар бирелмәде.

Әлмәт муниципаль районының «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен Рус Акташы интернат-мәктәбе» ДБМУендә:

Укучыларның медицина ярдәме күрсәтү буенча мөрәҗәгатьләрен теркәү кенәгәсендә интернат-мәктәп укучыларының җәрәхәтләр алуы турында язмалар күп. Шулай булса да, алган җәрәхәтләр буенча тикшерү уздыру эшләре оештырылмаган:

9.02.2017 ел – меджурналда мондый язмалар бар:
«Ш.Д., уң кулы яраланган»;
«Ш.Д., йомшак тиересе зарарланган (күгәрекләр), мазь сөртелде»;
10.02.2017 ел: «Ш.Д., 6 сыйныф, күгәрекләр», мазь сөртелде»;
20.02.2017 ел – «уң күз астында яра».
Бу баланың күпсанлы җәрәхәтләренең сәбәпләре ачыкланмаган.

Шулай итеп, балаларның җәрәхәтләнү очракларында белем бирү оешмалары администрацияләренең битарафлыгы ачыкланды. Ә бит һәр шундый күренеш артында балаларга карата җитди җинаять кылу очраклары яшеренеп калырга мөмкин.

Ачыкланган хокук бозулар йомгаклары буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балаларның хокуклары бозылу, аларны бетерү чараларын күрү турында бәяләмәләр җибәрде.

Бишенчедән, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ***таләбе буенча муниципаль районнар башлыклары тарафыннан җибәрелгән*** мәгълүмат– -аналитик материалларны анализлау, балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрдә муниципаль мәгариф бүлекләре (идарәләре) җитәкчеләрен тыңлау шуны күрсәтә, җирле үзидарә органнары, муниципаль мәгариф органнары тарафыннан сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балаларны төгәл исәпкә алу мәсьәләсе хәл ителмәгән. Мондый шартларда әлеге категориядәге балаларны контрольдә тоту һәм балаларның үсеш үзенчәлекләренә туры килә торган белем белән тәэмин итү буенча эшнең алар тарафыннан тиешле дәрәҗәдә оештырылуын һәм башкарылуын төгәл күзаллап булмый. Бу мәсьәлә бүген дә актуаль булып кала.

Моңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, муниципаль берәмлекләр башлыкларына, муниципаль мәгарифкә идарә органнарына әлеге категориядәге балалар буенча дөрес мәгълүмат булу мәсьәләсен һәм, шуннан чыгып, әлеге балаларга белем бирү мәсьәләсен махсус контрольгә алырга кирәк, дип саныйм.

Алтынчыдан, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә гражданнарданкергән мөрәҗәгатьләрне анализлаудан күренгәнчә, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар укый торган гомуми белем бирү оешмаларында тьюторларга ихтыяҗ зур. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы күрсәткечләре буенча, инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыручы ***мәктәпләрдә*** тьюторлар юк, республиканың база мәктәпләре штат расписаниесенә бары тик җитәкләп йөртүче кече тәрбияче берәмлеге генә кертелгән.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга башлангыч гомуми белем бирү Федераль дәүләт мәгариф стандарты буенча һәм Акылга зәгыйфь (интеллектлары бозылган) балаларга башлангыч гомуми белем бирү Федераль дәүләт мәгариф стандарты буенча белем бирү процессын төзү укучыларның индивидуаль яшь зурлыкларын, психофизик үзенчәлекләрен исәпкә алуга юнәлдерелгән, аерым алганда, индивидуаль уку планнарын

эшләү күздә тотыла. Җайлаштырылган белем бирү программаларын һәм индивидуаль уку планнарын гамәлгә ашыру тьютор ярдәмендә алып барыла.

Тьютор эше персональ белем бирү стратегиясенә корыла һәм гамәлгә ашырыла, моңа җайлаштырылган уку программасын, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле баланың шәхси үзенчәлекләре исәпкә алына торган индивидуаль үсеш программасын гамәлгә ашыру да, социаль инфраструктура булдыру да керә. Тьюторның бурычы белем бирүне оештырудан (дәрес өчен дидактик материаллар әзерләү, укытучының дәресләрен кабатлау, класстан чыгып китәргә кирәк булганда, баланы җитәкләпалып чыгуны оештыра) һәм тәрбия эшләрен оештырудан (тәнәфесләрдә сыйныфташлары белән аралашуны, баланың үзенчәлекләрен һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алып, аны социаль проектларга катнаштыруны оештыра) гыйбарәт. Инклюзив белем бирүдә тьютор, югарыда әйтелгәннәрдән тыш, ул сәламәтлек мөмкинлекләре чикле баланың белем бирү оешмасына һәм мәгариф учреждениесенең социаль мохитенә уңышлы кереп китүен оештыручы белгеч тә. Укытучылар, белгечләр һәм ата-аналар белән актив хезмәттәшлек итеп, тьютор баланың уңышлы укуы һәм социаль адаптациясе өчен уңай мохит тудыра ала.

Тьютора вазыйфасы гомуми, югары һәм өстәмә һөнәри белем бирүче хезмәткәрләрнең вазыйфаларына рәсми беркетелгән (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 5 май, 2008 ел, № 216-н һәм 217-н боерыклары, алар РФ Юстиция министрлыгында 22 май, 2008 елда № 11731 һәм № 11725 белән теркәлгәннәр). Тьютора вазыйфасы Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәсенең «Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификаци характеристикалары» бүлегенә кертелгән (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 26.08.2010 № 761н боерыгы, РФ Юстиция министрлыгында 2010 елның 6 октябрендә № 18638 белән теркәлгән). Шулай итеп, күрсәтелгән штат берәмлеге кертелергә һәм бюджеттан түләнергә мөмкин.

Җиденчедән, алдарак билгеләп үтелгәнчә, «Акылга зәгыйфь балалар өчен Дәрбиш балалар йорты» дәүләт автоном социаль тәэминат учреждениесен тикшерү барышында биш баланың опека һәм попечительлек органнары инициативасы белән аларны хокуктан файдалануга сәләтсез дип тану өлешендә хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең бозылуы ачыкланды.

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы белән «Балага тугач ук дәүләт тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясе, гомумтанылган принциплар, халыкара хокук нормалары, Россия Федерациясе халыкара шартнамәләре, әлеге Федераль закон, Россия Федерациясе Гаилә кодексы һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә бирелә һәм гарантияләнә торган кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре» беркетелә.

Россия Федерациясе катнаша торган Бала хокуклары турында БМО Конвенциясе белән балаларга карата барлык гамәлләрдә, аларны дәүләт яисә хосусый учреждениеләр башкарымы, судлар яисә закон чыгару органнарымы, шуларга бәйсез рәвештә, иң беренче чиратта, баланың мәнфәгатьләрен иң яхшы яктан тәэмин итү игълан ителгән. Катнашучы дәүләтләр, баланың иминлеге өчен кирәкле шундый яклауны һәм кайгыртуны, аның ата-аналарының, опекуннарының яисә закон нигезендә аның өчен җаваплы башка затларның хокукларын һәм бурычларын исәпкә алып, тәэмин итәргә тиеш булалар һәм шул максатта тиешле барлык кануный һәм административ чараларны күрәләр (Бала хокуклары турында БМО Конвенциясе, 3 статья).

Балигъ булмаган баланы хокуктан файдалануга сәләтсез дип тану, беренче чиратта, аны һөнәри белем йә нинди дә булса эшче белгечлеге алу, алга таба җәмгыятькә яраклашу, эшкә урнашу мөмкинлегеннән мәхрүм итә. Андый яшүсмернең киләчәк тормышы психоневрологик интернат диварлары белән чикләнә.

Шуңа бәйлерәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, учреждение администрациясе белән берлектә, балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызу буенча суд тәрибендә чаралар күрелде.

Билгеләнгән прблемалы мәсьәләләрне истә тотып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбндәгеләрне эшләргә кирәк дип саный:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

төп гомуми белем программалары буенча өйдә, дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмаларында укытуны оештыруга контрольне көчәйтергә;

дәүләт белем бирү оешмаларында балаларның җәрәхәтләнүен анализлау һәм ачыклау, балаларга карата рәхимсезлек күрсәтүочракларын ачыклау максатында, «Балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалауның төп системалары турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, медицина персоналы, учреждение администрациясе эшчәнлегенең алгоритмын эшләргә; ул алгоритмны барлык мәгариф оешмаларына җибәрергә;

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмалары җитәкчеләренең сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен белем бирү оешмаларында укучы балигъ булмаганнарны хокуктан файдалануга сәләтсез дип тану буенча судка мөрәҗәгать итү фактларын бетерергә һәм, аларның авыру үзенчәлекләрен тикшереп, һөнәри белем алуларын тәэмин итәргә;

балаларны башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү програмаалары буенча укыту өчен сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен гомуми белем бирү оешмаларына законнарда билгеләнгән тәртиптә алуны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» белән берлектә:

инклюзив белем бирү кысаларында сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты һәм акылга зәгыйфь (интеллектлары бозылган) белем алучыларга белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле укучыларның һәм акылга зәгыйфь (интеллектлары бозылган) укучыларның белем алуын оештыруны тәэмин итүгә, шул исәптән гомуми белем бирү оешмаларында тьюторларның штат берәмлекләрен кертү өчен финанс чыгымнары нормативларын расларга;

сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру өчен гомуми белем бирү оешмаларында тьюторларның штат берәмлекләрен кертүне финанслауны тәэмин итәргә;

җирле үзидарә органнары белән берлектә:

сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның системалы белем алуларын һәм һәр баланың белем алу маршрутын төзү максатында аларның барысын да исәпкә алып баруны тәэмин итәргә;

инклюзив белем алуны гамәлгә ашыру буенча нигези мәгариф оешмаларының челтәрен булдыру эшен дәвам итәргә;

коррекцияле белем алуга мохтаҗ балалар өчен махсус шартлар тудыру һәм ата-аналарның балаларының гомуми мәктәпләрдә укып белем алулары теләгән канәгатьләндерү максатында, балаларның яшәү урыннары буенча мәктәпләрдә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балалар өчен инклюзив белем бирүне үстерү буенча эшне дәвам итәргә, инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыру өчен инфраструктура шартларын булдырырга;

гомуми белем бирү оешмаларында, сыйныфларда конфликтлы вәзгыятьләрне киметү максатында сыйныф җитәкчеләренә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениесенең сыйныф җитәкчесе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 3 мартындагы боерыгы нигезләмәләрен исәпкә алып, системалы рәвештә укучыларның ата-аналары белән аңлату эшләре алып барырга.

3.6. Социаль тәэмин ителешкә хокукны гамәлгә ашыру

Баланың социаль тәэмин ителешкә хокукларын гамәлгә ашыру иң әһәмиятлеләрнең берсе, чөнки ул аеруча ярдәмгә мохтаҗ балалар төркемнәренең – инвалид балаларның, ятим балаларның, аз керемле гаиләләрдән булган балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау механизмнарын билгели.

2017 елда инвалид балаларны федераль законнар нигезендә ***техник тернәкләндерү чаралары һәм аларны карау чаралары*** белән тәэмин итү Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең игътибар үзгендә булды.

Инвалид балаларны техник тернәкләндерү чаралары һәм аларны карау чаралары белән тәэмин итү «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 10 статьясы нигезендә башкарыла. Дәүләт инвалид балаларга федераль бюджет акчаларын исәбеннән үткәрелә торган тернәкләндерү чаралары, тернәкләндерүнең техник чаралары һәм хезмәтләр күрсәтү буенча федераль исемлеккә кертелгән тернәкләндерү чаралары үткәрүне, техник чаралар белән тәэмин итүне һәм хезмәтләр күрсәтүне гарантияли. Бу хокукны гамәлгә ашыру Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 7 апрелендәге 240 номерлы карары белән расланган Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән һәм ветераннар арасыннан булган гражданнарның аерым категорияләрен протезлар (теш протезларыннан кала), протез-ортопедия әйберләре белән тәэмин итү кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) белән җайга салына. Мондый чараларның составы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 30 декабрендәге 2347-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Инвалидка бирелә торган тернәкләндерү чаралары, тернәкләндерүнең техник чаралары һәм күрсәтелә торган хезмәтләр исемлегендә (алга таба – Федераль исемлек) регламентлаштырылган.

Инвалид балаларны техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү инвалидны реабилитацияләү яисә абилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә гамәлгә ашырыла, ул медико-социаль экспертизаның дәүләт учреждениеләре тарафыннан эшләнә һәм аны тиешле хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук барлык оешу һәм милек рәвешләрендәге оешмалар тарафыннан үтәү мәҗбүри.

2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә гражданнардан, шул исәптән инвалид балалар ата-аналарының «Подари чудо» республика иҗтимагый хәйрия оешмасыннан да, инвалид балаларны техник тернәкләндерү чаралары белән, шул исәптән

протез-ортопедия әйберләре һәм инвалидны карау әйберләре белән тәэмин итүнең тиешенчә булмавы турында 27 мөрәҗәгать керде.

Мөрәҗәгатьләрне карау барышында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәге хокук бозуларны ачыклады:

инвалид баланың индивидуаль реабилитацияләү (абилитацияләү) программасында каралган техник чара белән тәэмин ителмәве (вакытында тәэмин ителмәве);

инвалид баланы индивидуаль реабилитацияләү (абилитацияләү) программасына туры килми торган, эшкә яраксыз техник чара белән тәэмин итү.

Ата-аналары Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән балаларга кагылышлы югарыда күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итү һәм оператив чаралар күрү максатларында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы белән Россия Федерациясе Социаль иминият фондының (алга таба – СИФ) Татарстан Республикасы төбәк бүлекчәсе – Дәүләт учрежденисе белән берлектә ел әйләнәсендә уртак утырышлар үткәрелде. Бу киңәшмәләр йомгаклары нәтиҗәсендә 19 мөрәҗәгать буенча мәсьәләләр тулысынча диярлек хәл ителде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итүчеләрнең һәрбер шикаятендә инвалид балалар хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу бәян ителүен истә тотып, балигъ булмаганнарның тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин ителеше өлкәсендә хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуы турында Татарстан Республикасы буенча Социаль иминият фонды (СИФ) идарәчесе исеменә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан бәяләмәләр җибәрелде, аларда балигъ булмаганнарның индивидуаль тернәкләндерү программаларында каралган рекомендацияләргә туры килә торган техник тернәкләндерү чараларын һәм инвалидны карау өчен кулланыла торган чараларны тулы күләмдә алу хокукын гамәлгә ашыруны оештыруга юнәлдерелгән чаралар күрү тәкъдим ителә.

«Инвалидларны техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү өчен күрсәтмәләр һәм каршылыклар исемлеген раслау турында» Россия Федерациясе Хезмәт министрлыгының 2014 елның 9 декабрендәге 998н номерлы боерыгы инвалид баланың хәлен җиңеләйтү яисә проблемасын тулысынча хәл итү (карала торган өлештә) мөмкинлеген бирә, әлеге боерык нигезендә, индивидуаль тернәкләндерү программасына кресло-коляскага ихтыяҗ булуын теркәгәндә медик-социаль экспертиза белгечләре характеристиканы төгәлрәк язарга тиеш: кресло-коляска аркасының төре (алып куела торган, биеклеккә һәм горизонталь, авышлыгы көйләнә торган, төшереп куела торган), утыргычының төре (алып куела торган, биеклеккә һәм горизонталь, авышлыгы көйли торган, коксит белән авыру бала өчен, җыелып куела торган, пружиналы), терсәк кую урынының төре (бер урынга ныгытылган, төшерә торган, әйләнә торган, алып куеп була торган, биеклеге көйләнә торган), аяк кую җайланмасы (алып куела торган, әйләнә торган, биеклеге көйләнә торган, авышлыгы көйләнә торган, аяк өчен җайлаштырыла торган терәге булган, аяк өчен җайлаштырыла торган терәге алып куела торган), җайланмалары (креслоның аркасын киңәйткеч, баш кую урыны, баш кую өчен ян-якта терәкләре, гәүдә өчен ян-якта терәкләре, утыргычында мендәр, аркасында мендәр, билгә валик, аяк арасында бушлык калдыру өчен валик, чәлтерләрне кую өчен махсус урын, чәлтерләрне кую өчен киңлеге көйләнә торган махсус урын, аяклар өчен тоткычлар, арттан тоткычлар, саклагыч билбау, көйләнгән өстәл); утыргычның киңлеге, тирәнлеге, биеклеге, аркасының биеклеге, терсәк кую урынының биеклеге һәм билгеләнеше (балалар өчен, өлкәннәр өчен); идарә итү төре (тәгәрмәчләр кыршавы ярдәмендә кулдан, рычаглы, электроидарә, актив төр). 2017 елда инвалид балаларны югарыда күрсәтелгән боерыкта бәян ителгән

киңәйтелгән функциональ характеристикалы кресло-коляска белән тәэмин итү проблемасы кискен булып кала.

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Баш медик-социаль экспертиза бюросы» ФКУ белгечләрен җәлеп итеп уздырылган ведомствоара эш йомгаклары нигезендә 2017 елда билгеләнгән тәртиптә, баланың индивидуаль параметрларын истә тотып, киңәйтелгән функциональ характеристикалы кресло-коляскалар сатып алынды, тагын 8 мөрәҗәгать буенча мәсьәлә тулысынча хәл ителде.

Шула итеп, техник тернәкләндерү чаралары белән, шул исәптән протез-ортопед әйберләре һәм чаралы белән тиешенчә тәэмин ителмәү турында гражданнардан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән 27 шикаятьтән 26 очракта (96%) мәсьәлә уңай хәл ителде.

Татарстан Республикасы буенча Социаль иминият фонды (СИФ) мәгълүматы буенча, инвалид балаларны техник тернәкләндерү чарасы белән тәэмин итү дәрәҗәсе 2017 елда 116,2% тәшкил итте: техник тернәкләндерү чараларына мохтаҗ инвалид балаларның гомуми саны 5 206 кеше исәпләнсә дә, үз хокукларын гамәлгә ашырган инвалид балалар саны 5 811 кеше булды. (2017 елда узган ел тәэмин ителмичә калган затлар да тәэмин ителде)

31 нче таблица

2017 елда техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин ителгән инвалид балалар саны

	Техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин ителүгә мохтаҗ балалар саны (2018 елның 1 гыйнварына)	Техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин ителгән балалар саны (2018 елның 1 гыйнварына)
Барысы,	5 206	5 811
Шулардан:		
протез-ортопед әйберләре белән	2 098	3 027
авыруны карау әйберләре-чаралары	358	1 851
башка техник терләндерү чаралары белән (кресло-коляскалар һ.б.)	2 750	933

Шуны да билгеләп китәргә кирәк, 2017 елгы вәзгыять, 2016 ел белән чагыштырганда, күпкә уңышлырак (2016 елда елда мондый тәэминат 45,3% кына иде, 2015 елда – 72%), балаларны протез-ортопед әйберләре, аларны карау чаралары белән тәэмин итү дә беркадәр яхшырды. Шул ук вакытта, инвалид бала, кагыйдә буларак, берүк вакытта берничә төрле техник тернәкләндерү чаралары белән (кресло-коляска, суставлар өчен бандажлар, йомшак һәм ярымкаты фиксациядәге корсетлар һ.б.), тәэмин ителергә тиешлекне исәпкә алсак, гомумән алганда, кызганычка каршы, бу вәзгыять яхшы якка үзгәрде дип әйтеп булмый әле. 2017 елда техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин ителү хокукын гамәлгәашыра алмаган инвалид балалар саны шактый күп калды әле.

Шул ук вакытта, инвалид баланың законлы вәкилләренә мөстәкыйль рәвештә индивидуаль тернәкләндерү программасы нигезендә техник тернәкләндерү чаралары һәм протез-ортопедия әйберләре сатып алырга һәм чыгымнарны кире кайтару өчен гариза белән Татарстан Республикасы буенча Социаль иминият фондына мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Мөстәкыйль сатып алынган техник тернәкләндерү чаралары өчен компенсация түләү Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Инвалид тарафыннан мөстәкыйль сатып алынган техник тернәкләндерү чаралары һәм (яисә) күрсәтелгән хезмәт өчен компенсация түләү тәртибен, аның күләмен билгеләү тәртибен һәм күрсәтелгән компенсация турында гражданнарга хәбәр итү тәртибен дә кертеп, раслау турында» 2011 елның 31 гыйнварындагы 57н номерлы боерыгы таләпләре нигезендә башкарыла. Компенсация күләме, алда телгә алынган боерык нигезләмәләренә таянып, техник тернәкләндерү чараларын сатып-алуларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча билгеләнә, бу хакта мәгълүмат http//:www.zakupki.gov.ru, шулай ук http://fss16.ru рәсми сайтында урнаштырыла.

2017 елда техник тернәкләндерү чараларын алудан 621 кеше баш тартты, шулардан:

551 кеше (89%) – теләгән характеристикаларга туры килмәү аркасында, әмма реабилитация яисә абилитация буенча индивидуаль программада каралган характеристикалар түгел,

65 кеше – реабилитация яисә абилитация буенча индивидуаль программада каралган рекомендацияләргә туры килмәү аркасында,

5 кеше – техник яктан төзк булмау сәбәпле.

Техник тернәкләндерү чараларын үзләре сатып алган өчен компенсация түләүләрен алырга хокуклы һәм аны алган балалар саны (2018 елның 1 гыйнварына) 5 816 кешене тәшкил итте, бу 2016 елга караганда 3,5 мәртәбә күбрәк (2016 елда – 944 кеше). Вәкилләре әлеге компенсацияне алган балалар саны 5 566 кеше булды (гомуми саннан 96%), шул исәптән протез-ортопед әйберләре өчен – 2 672 кеше, карау чаралары – 53 кеше, башка техник тернәкләндерү чаралары өчен (кресло-коляскалар һ.б.лар) – 2 841 кеше.

Әлбәттә, инвалид балаларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итүнең югарыда бәян ителгән торышы Россия Федерациясе чыгым йөкләмәләрен җитәрлек дәрәҗәдә финансламауга һәм «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэминитү өчен дәүләт тарафыннан товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә сатып алуларны башкарганда барлыкка килә торган аерым төр кыенлыкларга бәйле, чөнки тәэмин итү электрон рәвештә ачылган аукционнар (конкурслар) нәтиҗәләре буенча шул аукционнарда (конкурсларда) җиңүчеләр белән төзелә торган дәүләт контрактлары кысаларында башкарыла.

Инвалид балаларны тернәкләндерүнең тагын бер актуаль мәсьәләсе – аларны ***шифаханә-курортта дәвалануга юллама белән тәэмин итү***.

Инвалид балаларны шифаханә-курортта дәвалауны тәэмин итү «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә күрсәтелә торган социаль хезмәтләр җыелмасы кысаларында гамәлгә ашырыла һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2004 елның 29 декабрендәге 328 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарның аерым категорияләренә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Шифаханә-курорт дәвалавы өчен юлламалар бирү буенча тапшырылган федераль вәкаләтләрне гамәлгә ашыру 2017 елда Татарстан Республикасы буенча Социаль иминият фонды (СИФ) тарафыннан чыгым нормалары, дәүләт сатып-алулары турындагы законнар нигезендә, бу максатка бүлеп бирелгән акчалар кысаларында гамәлгә ашырылды. Финанслау социаль хезмәт күрсәтүләр җыелмасының бәясеннән чыгып гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «2017 елда шифаханә-курортта дәвалану, дәвалау урынына бару һәм аннан кайту өчен шәһәрара транспортта йөрү, шулай ук тимер юл транспортында барып-кайту буенча социаль хезмәт күрсәтүләр рәвешендәге дәүләт социаль ярдәмен алучы бер гражданга айлык финанс чыгымнары нор-

мативлары турында» 2016 елның 30 ноябрендәге 696н номерлы боерыгы нигезендә 2017 елда шифаханә-курорт дәвалавы кертелгән социаль хезмәт күрсәтүләр җыелмасының бәясе айга 124,9 сум иде (2015 елда – айга 110,83 сум, 2016 елда – айга 118,59 сум). Шул ук вакытта Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 30.11.2016 елның 695н номерлы боерыгы нигезендә 2017 елда инвалид балаларның шифаханә-курорт учреждениеләрендә бер көн дәвалануы 1 170,7 сум (2015 елда – 1 028,9 сум, 2016 елда – 1109,4 сум) күләмендә билгеләнде. Ә юлламаның реаль бәясе күпкә артыграк. Мондый вәзгыять инвалид балаларны шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тулысынча финансларга мөмкинлек бирми.

Татарстан Республикасы буенча Социаль иминият фонды белешмәләре буенча, 2017 елның башына шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗ инвалид балаларның гомуми саны 3 514 кеше булса, бу юнәлештәге хокукларын гамәлгә ашырган балалар 875 кешене генә тәшкил итте. 2017 елның ахырына шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин ителмәгән инвалид балаларның саны 3 515 кеше булды. Шулай да, бу саннар 2016 елга караганда 101 кешегә (2,7 %ка) кимрәк.

32 нче таблица

2013 – 2017 елларда инвалид балаларның шифаханә-курортта дәвалану белән тәэмин ителеше

Инвалид балаларның шифаханә-курортта дәвалану белән тәэмин ителеше	***2013 ел***	***2014 ел***	***2015 ел***	***2016 ел***	***2017 ел***
Шифаханә-курортта дәвалануга мохтаҗ инвалид балалар саны (ел башына)	2 495	3 112	2 187	3 843	3 514
Шифаханә-курортта дәвалануга бирелгән юлламалар саны,	1 190	1 558	2 002	1 534	875
шул исәптән озата баручы затлар өчен	595	779	1 001	766	437
Шифаханә-курортта дәвалануга юллама бирелмәгән балалар саны (ел ахырына ихтыяҗ	897	2 106	4 090	3 616	3 515

Шулай итеп, инвалид балаларны шифаханә-курорт оешмаларына юлламалар белән ел саен тәэмин итү проблемасы кискен булып кала.

Шулай ук шифаханә-курорт шартларында сыйфатлы дәвалану проблемасы да актуальлеген югалтмый. Кызганычка каршы, финанслау җитәрлек дәрәҗәдә булмауга бәйле рәвештә, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэминитү өчен дәүләт тарафыннан товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә таянып үткәрелә торган конкурс процедураларында иң аз бәя принцибы нигез итеп алына һәм илнең әйдәп баручы шифаханә-курорт учреждениеләренә юлламалар белән тәэмин итү мөмкинлеген бирми.

Аз керемле гаиләләрдән булган балаларга социаль ярдәм күрсәтү һәм аларның мәнфәгатьләрен яклау юнәлешендәге эшләрнең тагын берсе – республиканың гомуми белем бирү мәктәпләрендә кучыларны ташламалы тукландыру.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъектларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укучыларны мәктәптә тукландыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан җирле

бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укучылар өчен билгеләнгән очраклларда һәм тәртиптә җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 4 өлешен, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 14 пунктын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 26 сентябрендәге 682 номерлы карары белән тр бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укучыларны тукландыруны тәэмин итү очраклары һәм тәртибе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) расланды.

Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы бюджет ассигнованиеләре исәбеннән тукландыру түбәндәгеләр өчен гамәлгә ашырыла:

ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга,

җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча укытуны гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында, шулай ук озак вакыт дәваланыга мохтаҗ булган укучылар өчен белем бирү оешмаларында укучыларга,

«кадет мәктәбе» дип атала торган махсус гомуми белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләргә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларын финанслау нормативлары турында» 2017елның 8 августындагы 566 номерлы карары белән гомуми белем бирү оешмалары карашындагы интернатларда яшәүче укучыларның тукланууын тәэмин итү нормалары «кадет мәктәбе» дип атала торган махсус гомуми белем бирү оешмаларында тәрбияләнүче, әмма интернетта яшәми торган укучыларга да кагыла дип билгеләнә.

Шулай итеп, 2017 елда дәүләт кадет мәктәп-интернатларында укучы, әмма интернатта яшәми торган укучылар һәм интернатлары булмаган дәүләт кадет мәктәпләрендә укучылар түләүсез туклану белән тәэмин ителмәгән.

Шул ук вакытта, интернатлары булмаган дәүләт кадет мәктәпләрендә укучыларны түләүсез туклану белән тәэмин итүне оештыру мәсьәләсе хәл ителмәгән килеш кала.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына әлеге вәзгыятьне төзәтүгә юнәлдерелгән чаралар күрергә кирәк дип саный.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән гражданнарның аерым категорияләре өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары билгеләргә, шулай ук аз керемле гаиләләрдән булган укучы балалар өчен муниципаль белем бирү оешмаларында түләүсез тукланууны тәэмин итәргә хокуклы.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча, 2017/2018 уку елында аз керемле гаиләләрдән булган укучы балалар саны 28%ка артты һәм ул 30 043 кеше тәшкил итә. 2016/2017 уку елында бу категориядәге 23 483 укучы түләүсез туклану белән тәэмин ителгән.

Республиканың муниципаль белем бирү оешмаларында тукланууны оештыру мәсьәләләрен, гражданнар мөрәҗәгатьләрен өйрәнү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, кайбер муниципалитетларда моңа кадәр дә, хәзер дә аз керемле гаиләләргә социаль ярдәм чаралары күрсәтелми.

Шуңа бәйле рәвештә, җирле үзидарә органнарына, аз керемле гаиләләрдән булган укучыларны 100% түләүсез тукландыру белән тәэмин итүне күздә тотып, норматив хокукый актларына тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

3.7. Баланың торак һәм башка мөлкәти хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү

Физик яктан, акыл ягыннан, рухи, әхлакый яктан һәм социаль үсеш өчен һәр баланың лаеклы тормышка хокукы тәэмин ителергә тиеш.

3.7.1. Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын тәэмин итү

Ярдәмгә аеручы мохтаҗ балалар категорияләре – ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның торак хокукларын гамәлгә ашыруны тиешенчә тәэмин итү аеруча кайгыртылуга мохтаҗ балалар өчен тигез мөмкинлекләр булдыру өлкәсендә мөһим дәүләт бурычы булып тора.

Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нормалары нигезендә тораккa мохтаҗ дип танылган ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны һәм ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны (алга таба – ятим балалар) Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондыннан уңайлы торак урыннарны махсуслаштырылган торак урыннарга наем шартнамәләре буенча бирү рәвешендә бер мәртәбә дәүләт ярдәме күрсәтелә.

2017 елда әлеге чыгым вәкаләтен гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак урыннары белән тәэмин итү» ярдәмче программасы кысаларында гамәлгә ашырылды.

33 нче таблица

2008 – 2017 елларда ятим балаларны торак урыннар тәэмин итү

Ел	ТР бюджеты акчалары күләме (мең сумнарда)	РФ бюджеты акчалары күләме (мең сумнарда)	Акчаларның гомуми күләме (мең сумнарда)	Торак урыннары алган ятим балалар саны (кеше)
2008	89 000,0	11 563,3	100 563,3	112
2009	50 000,0	11 170,1	61 170,1	70
2010	50 000,0	10 697,9	60 697,9	72
2011	106 600,0	51 795,2	158 395,2	182
2012	112 996,0	50 529,3	163 525,3	179
2013	173 942,2	72 086,4	246 028,6	265
2014	233 730,0	83 410,0	317 140,0	309
2015	269 811,0	86 610,4	356 421,4	331
2016	288 697,8	50 485,0	339 182,8	311
2017	302 840,0	43 880,0	346 720,0	305
Итого	**1 677 617,0**	**472 224,6**	**2 149 844,6**	**2 136**

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: 2011 елдан башлап ятим балаларны торак белән тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны финанслауның Татарстан Республикасы бюджетына акчалары өлешендәге күләме ел саен арта бара.


Кызганычка каршы, ятим балаларга торак төзүне федераль финанслау күләме соңгы вакытта елдан-ел арта барып, 2016 елдан кими башлады һәм 2017 елда 43 880,0 сум тәшкил итте.

2017 елда ятим балалар өчен торак төзүгә бүлеп бирелгән финанс күләме 346 750 мең сум тәшкил итте, шуннан 302 840,0 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, 43 880,0 мең сумы – федераль бюджет акчалары исәбеннән булды. Күрсәтелгән акчалар чикләрендә 2017 елда 305 бала торак белән тәэмин ителде, шуларның 18 яшьтән 23 яшькә кадәргеләре – 252 кеше һәм 23 яшьтән өлкәнрәкләр – 52 кеше.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләреннән күренгәнчә, 2017 елга махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары алучы ятим балалар реестрына 1 243 кеше кертелгән, шулардан бары тик 305 кеше генә үзләренең торак хокукларын тормышка ашырган. Шулай итеп, узган елда реестрда торучы, ягъни 2016 елда махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары белән тәэмин ителү хокукына ия барлык затларның бары тик 24,5% ы гына үз хокукларын гамәлгә ашыра алганнар. Шулай итеп, ел саен ятим балалар өчен торак төзелешенә региональ финанслау күләмен арттыру буенча чаралар күрелсә дә, ятим балаларның закон белән гарантияләнгән торак белән тәэмин ителүгә хокукын финанслау дәрәҗәсе, элеккечә үк, җитәрлек түгел. Торак тәэминаты буенча бурычларның ел саен арта баруы ятим балаларның торак көтү чорын озайта бара. 2017 ел йомгаклары буенча, ул 5 ел тәшкил итте. Өстәвенә, торак бирү буенча исәптә торучы ятим балаларның гомуми саны шулай ук ел саен арта бара: 2017 ел башына аларның саны 3 012 кеше булса, ел ахырына 2 290 кеше булды.

134 нче диаграмма

2017 ел ахырына торак урыны алу өчен исәптә торучы ятим балаларның гомуми саны (яшьләре буенча)



2018 елда Татарстан Республикасында ятим балаларны торак белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән акчаларның гомуми күләме 355,3 млн. сум тәшкил иттә, бу сумма торак алуга хокуклары 2017 елда гамәлгә ашырылырга тиешле 1 240 ятим баладан бары тик 297 баланы гына торак белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирә, ягъни 23,9% ятим бала торак белән тэмин ителәчәк.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә республиканың ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслауны арттыру мәсьәләсен хәл итәргә кирәк, дип уйлыйбыз.

Ятим балаларны вакытлыча яшәү урыны белән тәэмин итү мәсьәләсе бүген дә актуаль булып кала. «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннар белән тәэмин итү һәм «Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 9 өлеше нигезендә, махсуслаштырылган торак фондында ятим балалар өчен буш торак урыннар булмаса, вәкаләтле орган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннпры бирү тәртибе турында» 2007 елның 20 сентябрендәге 475 номерлы карары белән билгеләнгән шартларда һәм тәртиптә ятим балаларның уңайлыклар булган торак урыннарда вакытлыча яшәвен тәэмин итә.

Шул ук вакытта, әлеге маневр торак фонды оешмау аркасында һәм дәүләт мәгариф оешмаларының барысы да тулай тораклар белән әэмин ителмәгәнгә күрә ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны вакытлыча торак белән тэмин итү мәсьәләсе ачык кала. Мондый шартларда әлеге категориягә караган балалар өчен вакытлыча торак буларак республиканың халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәкләреннән, балаларны гаиләгә урнаштыруда ярдәм күрсәтү үзәкләреннән һәм балалар йортлары каршындагы социаль кунакханәләрдән файдаланып булыр иде.

Ятим балаларның торак хокукларын гамәлгә ашыруның 2017 елдагы иң актуаль проблемаларыннан берсе – ***аларның яшәү урыны буенча торак алуы*** булды. Гомуми кагыйдә буенча, 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы таләпләре нигезендә ятим балалар торак белән яшәү урыннары буенча тәэмин ителергә тиеш. Ятим балаларга торак урыны бирелгән вакытта махсуслаштырылган торак фондыннан тиешле торак урыны чикләрендә яшәү урыны буенча торак урыны булмаган очракта, күрсәтелгән затларга аларның теләге буенча Татарстан Республикасы чикләрендә башка торак пунктта махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыны бирелә. Шуны билгеләп үтәргә кирәк: 2017 елда республиканың Чаллы, Әлмәт, Зеленодольск һәм Бөгелмә кебек эре шәһәрләрендә ятим балаларга махсуслаштырылган торак фондыннан бер торак урын да бирелмәгән, Казан шәһәрендә 3 фатир бирелгән.

2017 елда, фатирлардан тыш, ятим балаларга республиканың Актаныш, Алексеевск, Югары Ослан, Кайбыч, Яңа Чишмә, Чирмешән муниципаль районнарында 11 индивидуаль торак йорт бирелгән.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәгълүматы буенча, 2017 елда Әлмәт, Балтач, Бөгелмә, Зеленодольск, Минзәлә, Саба муниципаль районнарында, шулай ук Чаллы шәһәрендә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен махсуслаштырылган торак фондыннан торак бирелмәгән.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ятим балаларны торак белән тәэмин итү һәм алар белән эшләү буенча вәкаләтле органы буларак, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә, ятим балалар арасыннан булган затларны яшәү һәм эшләү урыны буенча торак белән тәэмин итү тәжрибәсен ятим балаларның мәнфәгатьләрен дә, дәүләт мәнфәгатьләрен дә канәгатьләндерә торган тәжрибә буларак дәвам итү буенча чаралар күрергә кирәк, дип уйлыйбыз.

Ятим балаларның торак хокукларын гамәлгә ашыру буенча проблемалы мәсьәләләргә ***23 яшькә җиткән ятим балалар арасыннан булган затларны,*** ягъни «өлкәнрәк» затларны ***торак белән тәэмин итүне*** гамәлгә ашыруны кертергә кирәк.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны 23 яше тулганнан соң торак урын белән тәэмин ителүчеләр исемлегенә кертүдән баш тарту турында карарлар кабул итү гадәткә керде. 2013 елның 1 гыйнварыннан ятим балалар арасыннан «өлкәнрәк» затлар үзләренә торак урын бирүне сорап судка дәгъва белдереп мөрәҗәгать итәләр. Татарстан Республикасында әлеге категориядәге гражданнарны яклап, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертүдән баш тарту турындагы карарны законсыз дип тану турында һәм гражданнарны күрсәтелгән исемлеккә кертүне йөкләү хакында гариза белән район прокурорлары да мөрәҗәгать итәләр. 2013 елның 1 гыйнварыннан бирле килгән суд практикасында судлар Россия Федерациясе Конституция судының 2009 елның 5 мартындагы № 376-О-П билгеләмәсендә күрсәтелгән хокукый позициягә таяналар, аның нигезендә ятим балаларның торакка объектив ихтыяҗы әһәмияткә ия.

2017 ел йомгаклары буенча республика судлары тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын ятим балалар арасыннан булган затларны торак алу исемлегенә кертүне йөкләү турындагы дәгъвалар буенча 50ләп карар кабул ителде, шушы категориядәге эшләрне карау нәтиҗәләре буенча 5 дәгъва канәгатьләндерелде. Моннан тыш, ятим балалар арасыннан булган 6 затка торак урын суд карарлары буенча бирелде.

Ятим балаларның торак хокукларын гамәлгә ашыруда ятим балаларга файдалану яисә милек хокукында карый торган торак урыннарда ***торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен бурычлар булу*** актуаль мәсьәлә булып кала. Әлеге мәсьәләне карау һәм өйрәнү барышында Татарстан Республикасы Дәүләт Советында төзелгән эшче төркем (аңа Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дә керде) ятим балалар андыйлар өчен учреждениеләрдә, төзәтү учреждениеләрендә, опекуннар (попечительләр) гаиләләрендә, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә булган чорда ятим балалар милкендәге торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен яллаучылар яисә яллаучыларның гаилә әгъзаларының социаль наем шартнамәләре буенча түләмәүләренә бәйле күпсанлы проблемалар барлыгын ачыклады.

Торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча бурычлар еш кына ятим бала беркетелгән торак урында беркем дә яшәмәгән очракта, шулай ук мондый торак урыннарда яшәүчеләр (мәсәлән, ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән затлар, ятим баланың күп очракта әхлаксыз тормыш рәвешен алып баручы гаилә әгъзалары) түләү буенча бурычларын үтәмәгән очракта барлыкка килә.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында ятим балаларның бурыч күләмнәрен исәпләүнең төгәл механизмнары эшләнде һәм торак-коммуналь хезмәтләргә ятим балалар бурычларының кимүе буенча ай саен мониторинг оештырылды. Ятим балаларның торак-коммуналь хезмәтләргә торак урыны өчен бурычының Татарстан Республикасы буенча гомуми суммасы 2017 елның 1 гыйнварына 20 798 832,67 сум тәшкил итсә, 2018 елның 1 гыйнварына 11 439 081,64 сум калды.

Әлеге мәсьәлә опека һәм попечительлек органнарының даими контролендә булырга тиеш. Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, опека һәм попечительлекнең төбәк органы буларак, республика районнарының һәм шәһәрләренең опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген җайга салырга тәкъдим итәбез.

3.7.2. Күпбалалы гаиләләрнең торак хокукларын тәэмин итү

Балаларның һәрьяклап үсүе һәм тәрбияләнүе өчен кирәкле уңай мохит тудыруда дәүләт ярдәменә аеруча мохтаж гаиләләргә күпбалалы гаиләләр дә керә.

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Президентының «Күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшырту буенча өстәмә чаралар турында» 2001 елның 17 мартындагы ПУ-216 номерлы Указы нигезендә ата-анасы белән торучы, үз гаиләсен кормаган биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү аларга ***торак урын сатып алу өчен*** Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән ***субсидияләр бирү*** юлы белән башкарыла. Торак урын сатып алу өчен субсидияләр алу хокукы сертификат белән таныклана, сертификатлар бирү һәм алардан файдалану «Торак шартларын яхшыртуга мохтаж күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаж күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү һәм алардан файдалану тәртибендә гамәлгә ашырыла.

2017 елда торак шартларын яхшыртуга мохтаж күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 93-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 143 784,5 мең сум акча каралган иде. Бүлеп бирелгән акчалар чикләрендә узган елда 50 сертификат бирелде.

34 нче таблица


2013–2017 елларда биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне торак сертификаты хисабына торак белән тәэмин итү

Ел	Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбендә торучы гаиләләрнең гомуми саны	Татарстан Республикасы бюджеты акчалары күләме (мең сумнарда)	Торак сертификатын алуга җыелма исемлектәге гаиләләр саны	Балаларның үз гаиләләре булу сәбәпле сертификат алу хокукын югалткан гаиләләр саны	Сертификат алган гаиләләр саны
2013	4 626	116 191,4	822	8	44
2014	4 675	122 001,0	824	2	37
2015	4 219	128 101,0	801	3	45
2016	3 921	137 068,2	793	3	42
2017	2 959	143 784,5	723	19	50

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2017 елда 2 959 күпбалалы гаилә торак шартларын яхшырту буенча исәптә торды, шулардан биш һәм аннан да күбрәк баласы булган 723 күпбалалы гаилә Торак сертификатын алуга җыелма исемлектә торды.

135 нче диаграмма

2013 – 2017 елларда торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләр саны



«2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2016 елның 30 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә биш һәм аннан да күбрәк баласы булган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә 2018 елга 149 535,9 мең сум акча каралган, 2019 һәм 2020 елларга тиешенчә 155 517,3 мең сум һәм 161 738,0 мең сум планлаштырылган.

Югарыда китерелгән күрсәткечләргә ясалган анализ бүлеп бирелгән финанслау күләменең торак сертификатлары белән бер елга Җыелма исемлектә торучы күп дигәндә 6,9% гаиләне тәэмин итәргә мөмкинлек бирүен күрсәтте, әлеге күрсәткеч 2016 ел белән чагыштырганда (5,3%) 30,2% ка югарырак. Мондый шартларда торак сертификаты алуны көтүнең уртача чоры 9 – 10 ел тәшкил итәчәк.

Һичшиксез, мондый озак вакыт эчендә биш һәм аннан да күбрәк баласы булган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләр исемлектәге статусларын һәм, шуңа бәйле рәвештә, торак сертификаты алу хокукларын да югалталар. 2017 елда 19 гаилә, балалары үз гаиләләрен кору сәбәпле, торак сертификатын алу хокукын югалтты. Мондый вәзгыять күпбалалы гаиләләргә лаеклы тормыш шартлары тәэмин итүгә, аларны социаль яклауга, ахыр чиктә, кешенең уңай мохиткә һәм ирекле үсешенә хокукларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән дәүләт чараларының мәгънәсен киметә.

Шул ук вакытта, торак сертификатын көткән чорда балалар үсеп җитеп, үз гаиләләрен коралар. Дәүләт, үз чиратында, күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча үз өстенә алган бурычларын үти алмыйча кала. Күпбалалы гаиләнең сертификат алу чираты җиткәч, аларны исемлектән төшереп калдыралар. Шулай итеп, биш һәм аннан күбрәк балалы гаиләләргә каралган дәүләт ярдәменең мәгънәсе югала.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үзенең «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карарына яңа үзгәрешләр кертү мәсьәләсен карарга тәкъдим итәбез, алар Җыелма исемлектә торучы күпбалалы гаиләләргә, ата-аналар һәм үз гаиләләрен кормаган гаилә әгъзалары (балалар) исәбеннән чыгып, торак сертификатын алу хокукын гамәлгә ашыру мөмкинлеген бирергә тиеш.

Күпбалалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең, шул исәптән торак шартларын яхшырту өчен каралган дәүләт ярдәменең, тагын бер чарасы – ***түләүсез җир кишәрлекләре бирү.***

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2017 елның декабренә җир кишәрлекләрен түләүсез алучылар исемлегенә кертү турында 44 721 карар кабул ителде. Гомуми өлешле милеккә бирелгән 28 684 җир кишәрлеге, тулаем алганда, республикада исемлекләргә кертү турында кабул ителгән карарлар санының 64,1% тәшкил итә.

35 нче таблица

2017 елда түләүсез җир кишәрлекләре алган күпбалалы гаиләләр саны

(районнар һәм шәһәрләр чикләрендә)

Т/с №	Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) исеме	Җир кишәрлекләре алу өчен исәптә торучы күпбалалы гаиләләр саны	Җир кишәрлеге алу хокукы гамәлгә ашырылган күпбалалы гаиләләр саны	Җир кишәрлеге алу хокукы гамәлгә ашырылмаган күпбалалы гаиләләр саны
1	Казан шәһәре	10 565	3 069	7 496
2	Чаллы шәһәре	6 248	2 599	3 649
3	Әгерҗе	469	405	64
4	Азнакай	736	695	41
5	Аксубай	277	270	7
6	Актаныш	380	375	5
7	Алексеевск	433	385	48
8	Әлки	163	146	17
9	Әлмәт	2 973	1 712	1 261
10	Апас	214	196	18
11	Арча	1 104	929	175
12	Әтнә	168	154	14
13	Баулы	376	308	68
14	Балтач	592	532	60
15	Бөгелмә	818	509	309
16	Буа	536	465	71
17	Югары Ослан	294	282	12
18	Биектау	584	491	93
19	Чүпрәле	281	269	12
20	Алабуга	1 254	988	266
21	Зәй	682	650	32
22	Зеленодольск	1 620	1 212	408
23	Кайбыч	244	243	1
24	Кама Тамагы	199	191	8
25	Кукмара	1 139	935	204
26	Лаеш	643	593	50
27	Лениногорск	801	584	217
28	Мамадыш	607	603	4
29	Менделеевск	295	293	2
30	Минзәлә	592	559	33

31	Мөслим	430	378	52
32	Түбән Кама	2 708	1 773	935
33	Яңа Чишмә	211	210	1
34	Нурлат	849	699	150
35	Питрәч	586	486	100
36	Балык Бистәсе	296	282	14
37	Саба	732	687	45
38	Сарман	699	698	1
39	Спас	284	284	0
40	Тәтеш	230	227	3
41	Тукай	699	681	18
42	Теләче	291	291	0
43	Чирмешән	123	122	1
44	Чистай	1 045	990	55
45	Ютазы	251	234	17
Барысы		**44 721**	**28 684**	**16 037**

Югарыда китерелгән күрсәткечләргә ясалган анализ республикада буш җир кишәрлекләре җитмәү проблемасының сакланып калуы турында нәтиҗә чыгарырга нигез бирә. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белешмәләреннән күренгәнчә, бу проблема элеккечә үк Казан шәһәрендә (7 496 кишәрлек җитми), Чаллы шәһәрендә (3 649 кишәрлек), Әлмәт шәһәрендә (1 261 кишәрлек), Түбән Кама шәһәрендә (935 кишәрлек) кискен тора.

Җир кишәрлекләре бирелүгә исәптә торучы күпбалалы гаиләләрнең 14%ка артуы да игътибарны җәлеп итә. Мәс., 2015 ел белән чагыштырганда, җир кишәрлекләре бирелүгә исәптә торучы күпбалалы гаиләләр саны 2016 елда 5 594 гаиләгә артты, 2016 ел белән чагыштырганда, 2017елда 5 483 гаиләгә артты һәм ул 44 721 гаилә булды (2015 елда – 33 644 гаилә, 2016 елда – 39 238 гаилә). Әлеге хокукны гамәлгә ашырмаган гаиләләрнең саны шулай ук 2017 елда 3 866 гаиләгә артты (2015 елда – 9 484 гаилә, 2016 елда – 12171 гаилә, 2017 елда – 16 037 гаилә).

Шулай итеп, күпбалалы гаиләләрне җир кишәрлекләре белән тәэмин итү мәсьәләсендәге иң мөһим проблемалар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

буш җир кишәрлекләре җитмәү, торак пунктларның чикләрен киңәйтү өчен кирәкле шартлар булмау (магистраль торбаүткәргечләрнең сакланулы зоналарда булуы, газүткәргеч юллары булу, элект линияләре, терлек зиратлары); өстәмә җир кишәрлекләре эзләү һәм ызанлау процедурасын уздыру; болар хәлләрне тагында катлауландыра;

күпбалалы гаиләләрнең исәбе арту (2017 елда 5 483 гаиләгә артты);

күпбалалы гаиләләрнең бирелгән җир кишәрлекләреннән баш тартуы (җир кишәрлекләре урнашкан урыннар ямьсез булганга, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктура булмаганга күрә);

әзерләнгән җир кишәрлекләрен инженерлык коммуникацияләре белән тәэмин итү буенча эшләрне финанслау өчен җирле бюджет акчаларының җитәрлек булмавы яисә бөтенләй булмавы.

3.7.3. Инвалид балалары булган гаиләләрнең торак хокукларын үтәү

Торак шартларын яхшырту проблемасы – инвалид балалары булган гаиләләрнең, мөгаен, иң кискен проблемаларыннан берседер.

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль Законның 17 статьясы нигезендә Россия Федерациясе законнарында һәм Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган тәртиптә исәпкә куелалар һәм торак белән тәэмин ителәләр. 2005 елның 1 гыйнварына кадәр исәпкә куелган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ инвалидларны һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү федераль бюджет акчалары исәбеннән Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасында әлеге тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган һәм югарыда күрсәтелгән гражданнарга Федераль компенсацияләр фондыннан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак сатып алуга субсидияләр бирүне күздә тота.

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белешмәләре буенча, 2017 елда Федераль бюджет акчалары исәбеннән торак шартларын яхшыртуга субсидияләр алучыларның (инвалидларның) җыелма исемлегенә инвалид балалары булган 422 гаилә кертелгән. 2017 елда шушы категориядәге 5 гаилә субсидия алу хокукын гамәлгә ашара алды.

Моның белән бергә, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына еллык субвенцияләр күләме инвалид балалары булган гаиләләрнең иң күбе 2%ына гына торак сатып алуга субсидияләр бирергә мөмкинлек бирә, бу исә югарыда күрсәтелгән категорияләргә Россия Федерациясе законнары белән гарантияләнгән дәүләт ярдәмен нәтиҗәле тәэмин итә алмауда объектив сәбәп булып тора. 2013 елдан башлап бүгенгә кадәрге чорда аларның гомуми саны 26 булды.

36 нчы таблица

2013 – 2017 елларда инвалид балалары булган гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуга бирелгән субсидияләр

Еллар	Россия Федерациясе бюджетыннан субвенцияләрнең гомуми күләме* (мең сумнарда)	Субсидияләр алган инвалид балалы гаиләләр саны (гаилә)
2013	122 202,21	1
2014	108 451,2	4
2015	115 317,0	6
2016	110 367,9	10
2017	114 596,0	5
Барысы	570934,31	26

*Инвалидларга, инвалид балалары булган гаиләләргә һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарына торак шартларын яхшыртуга субвенцияләр күләме.

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ инвалид балалары булган гаиләләр, әгәр алар 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан булсалар, торак урыннар белән Россия Федерациясе законнары нигезендә, ягъни социаль наем йә социаль файдаланудагы торак фонды торак урынына найм шартнамәсе буенча торак алуның һәркем өчен уртак булган тәртибе буенча тәэмин ителәләр.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (алга таба – 63-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасында инвалид балалары булган гаиләләрнең 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан аерым категорияләре өчен торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирү каралган. Шулай итеп, Законның 8.2 статьясы нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 16 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган исемлектә күрсәтелгән һәм гражданнарның бер фатирда бергә яшәвенә каршы килә торган авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалар тәрбияләнә торган гаиләләр әлеге социаль ярдәм чарасын алуга хокуклы.

63-ТРЗ номерлы Законның 8.2 статьясын үтәү максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Инвалидларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясен (бер мәртәбә акчалата түләү) бирү турында» 2016 елның 18 апрелендәге 236 номерлы карар кабул итте, аның белән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер мәртәбә акчалата түләү) күләмен билгеләү тәртибе һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер мәртәбә акчалата түләү) бирү тәртибе расланды. Хроник авыруларның авыр төрләреннән интегүче инвалидларга торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер мәртәбә акчалата түләү) бирү буенча чаралар үткәрергә вәкаләтле орган итеп Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы билгеләнде.

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер мәртәбә акчалата түләү) бирү тәртибенең II бүлеге нигезендә күрсәтелгән категориядәге гражданнарга торак сатып алуга субсидияләр бирү 2005 елның 1 гыйнварыннан соң социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының исемлекләре нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан төзелгән субсидия алучы гражданнарның җыелма исемлеге буенча чират тәртибендә башкарыла.

Әмма шуны да билгеләп үтәргә кирәк, Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2017 елның 28 декабренә республика муниципаль районнары башкарма комитетларыннан социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар буларак исәпкә куелган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 16 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган исемлектә күрсәтелгән һәм гражданнарның бер фатирда бергә яшәвенә каршы килә торган авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалар тәрбияләнә торган гаиләләр турында мәгълүмат кермәгән.

2017 елда суд карарлары нигезендә югарыда күрсәтелгән категориягә караган 3 гаиләгә гомуми суммасы 3 265,3 мең сум күләмендә субсидия түләнгән.

«2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2017 елның 30 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 63-ТРЗ номерлы Законның 8.2 статьясында билгеләнгән аерым категориядәге гражданнарны торак белән тәэмин итүгә 2018 елга 50 000 мең сум бүлеп акча бүлеп бирелгән. 2019 һәм 2020 елларга да шундый ук сумма каралган.

3.7.4. Балигъ булмаганнарның башка мөлкәти хокукларын яклау


Баланың тормыш дәрәҗәсен бәяләүнең билгеле бер критерие – аны карап тоту буенча ата-ана вазыйфаларын тиешенчә башкару.

Кызганычка каршы, 2017 елда ата-аналарның балигъ булмаган балаларына алимент түләү йөкләмәләрен үтәмәү мәсьәләсе буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә мөрәҗәгатьләрнең саны шулай ук күп булды.

Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе биргән белешмәләрдән күренгәнчә, 2017 елда балигъ булмаган балаларына алимент түләтү турындагы суд карарларының үтәлмәвенә бәйле рәвештә 16 803 суд эше кузгатылды. Гомумән алганда, республика суд приставларының территориаль бүлекләрендә ел дәвамында 37 395 үтәтү эше буенча мәҗбүри үтәтү эшләре алып барылган. Шулардан 5 712 үтәтү эше аларның таләпләре үтәлүгә бәйле төгәлләнде, 10 263 үтәтү эше буенча бурычлыларның эш хакыннан алиментлар тотып калына.

136 нчы диаграмма

2013 – 2017 елларда балигъ булмаган балаларны тәэмин итүгә мәҗбүри рәвештә алиментлар түләтү буенча суд карарларын үтәүнең торышы



Балаларны тәэмин итү өчен алиментлар түләтү турындагы суд карарлары үтәлмәвенең төп сәбәпләреннән берсе, барыннан да элек, аларның ата-аналар тарафыннан үтәлмәвенә бәйле. Күп кенә «алиментчылар» балаларын тәэмин итүгә акча түләп тору гына түгел, хәтта яшәү һәм эшләү урыннарын да яшерәләр. Алимент йөкләмәләре буенча эзләү игълан ителгән бурычлылар саны 2017 елда 2 193 кешене тәшкил итте.

137 нче диаграмма

2013 – 2017 елларда алимент йөкләмәләре буенча эзләү игълан ителгән бурычлылар саны (кеше)




Үтәтү эше турындагы законнарны бозган өчен 2017 елда 2 834 кеше административ җаваплылыкка тартылган, бу тәмамланмаган үтәтү эшләренең гомуми санының 13,3% тәшкил итә.

2017 елда Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тикшерүчеләре 981 җинаять эше ачкан, шулардан 616 эш буенча – гаепләү хөкеме, 5 эш буенча җинаять эшен туктату турында суд карарлары чыгарылган.

138 нче диаграмма

2013 – 2017 елларда алиментлар түләтү буенча җинаять эшләре ачу




Балаларны тәэмин итү өчен алиментлар түләтү турында суд карарларын үтәмәүнең тагын бер сәбәбе бүгенге көндә алиментлар буенча зур бурычлар булуга мөмкинлек бирә торган үтәтү эшләре турындагы законнарның камил булмавы белән аңлатыла.

Алиментлар түләтү турында төгәлләнмичә калган үтәтү эшләре санының кимү динамикасын тәэмин итү Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе суд приставлары тарафыннан бурычлыларның хезмәт хакыннан акча тотып калу, мөлкәтләрен ачыклау һәм аларны сатып түләттерү, Россия Федерациясе чикләреннән читкә чыгуга чикләү билгеләү, бурычлының махсус хокуктан файдалануын чикләү, административ һәм җинаять юрисдикциясе вәкаләтләреннән файдалану рәвешендә бурычлыларга йогынты ясау чараларын кулланулары ярдәм итте.

Ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның мөлкәти хокуклары бозылу, аерым алганда, ата-аналардан алиментлар алуга кагылышлы өлешендә, еш кына опекуннар, попечительләр яисә тиешле дәүләт учреждениеләренең үзләренең турыдан-туры бурычларын тиешенчә үтәмәү (бөтенләй үтәмәү) нәтиҗәсе дип әйтергә кирәк.

139 нчы диаграмма

2013 – 2017 елларда ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның алимент алуга хокукларын үтәүне тәэмин итүнең торышы



Югарыда китерелгән белешмәләрне анализлаудан күренгәнчә, 2017 елда ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга алиментлар түләтү турындагы 1 444 үтәтү эшенең таләпләре үтәлүгә бәйле рәвештә 390 эше генә, ягъни 27% төгәлләнде (2016 елда – 264, ягъни 22,3%, 2015 елда – 172, ягъни 10,3%, 2014 елда – 271, ягъни 15,8%, 2013 елда – 206, ягъни 12 %), әлеге күрсәткеч узган елгы белән чагыштырганда югарырак. Әлеге мәгълүмат шуны күрсәтә, алимент буенча бурычлыларның бары тик дүрттән бер өлеше генә балигъ булмаган балаларын тәэмин итеп тору буенча үз йөкләмәләрен үти. Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, опека һәм попечительлек органнарына ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның законлы вәкилләре эшчәнлеген контрольдә тоту, ата-аналардан алимент алу хокукларын яклау һәм тәэмин итү буенча эшне көчәйтү (активлаштыру) зарурлыгы турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итү максатка ярашлы булыр дип саныйм.

ЙОМГАКЛАУ

2017 елның сентябрендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов тарафыннан аның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык Юлламасында 2018 елга Татарстан Республикасы эчке сәясәтенең мөһим юнәлешләреннән берсе буларак гаиләнең икътисадый үсешен һәм социаль-мәдәни хәлен яхшырту билгеләнде. Республика Президенты мәгариф системасының өстенлекле һәм аеруча катлаулы мәсьәләсе буларак тәрбиягә аерым игътибар бирде: «Белем һәм тәрбиянең аерылгысыз булуын игълан итәргә генә түгел, ә аны чынлап торып тәэмин итәргә кирәк. Бу эш чаралар һәм акцияләр уздыру белән генә чикләнергә тиеш түгел. Һәр укытучы һәм һәр җитәкче тәрбияче булырга тиеш. Ышанычка һәм үзара хөрмәт итешүгә, Татарстан яшүсмеренең аңында традицион рухи кыйммәтләрнең төшенчәләрен, сәламәт яшәү рәвешенә һәм иҗади эшчәнлеккә омтылышны һәрьяклап аңлатып-төшендереп формалаштыруга корылган тәрбия – бу зур һәм көчле илдә шәхес һәм граждан булып җитешүнең нигезе. Һичшиксез, тәрбиядә гаилә төп рольне уйный. Нәкъ менә гаилә аша буыннан-буынга традицияләр күчә, үз Ватанына мәхәббәт һәм ихтирам уятыла». Р.Н.Миңнеханов: «Яшьләр мәктәптә укыганда ук республикада үзенең киләчәген күрергә, аны үстерүдә, тормыш һәм эш өчен лаеклы шартлар булдыруда безнең кызыксынуны тоярга тиеш» дип, махсус билгеләп үтте.

2017 елда яшь татарстанлыларның һәм балалары булган гаиләләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга корылган, нигезенә бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тулысынча тәэмин итү принцибы салынган максатчан дәүләт сәясәте дәвам итте. Әлеге сәясәтне гамәлгә ашыру өчен дәүләт структуралары, җирле үзидарә органнары, дәүләткә карамаган оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары, балалар белән һәм алар мәнфәгатьләрендә эшли торган барлык белгечләр, ата-аналар һәм җәмәгатьчелек тырышлыгы бергә тупланды.

Бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылуның аерым очраклары булуга карамастан, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 2017 елда Татарстан Республикасында балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлешен тәэмин итүне канәгатьләнерлек дип бәяли. Бала хокукларын гамәлгә ашыруның әлеге докладта күрсәтелгән аерым мәсьәләләре буенча, аларның үтәлешен тәэмин итү өчен, чаралар күрү таләп ителә.

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясында каралган Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен дәүләт тарафыннан яклау гарантияләрен тәэмин итү, әлеге хокукларны һәм мәнфәгатьләрне Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан барлык оештыру-хокукый рәвешендәге һәм милек рәвешендәге оешмалар һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан тануны һәм үтәүне тәэмин итү максатын гамәлгә ашырып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына әлеге еллык докладны балалар мәнфәгатьләрендә региональ сәясәтне гамәлгә ашыруны мөстәкыйль бәяләү һәм тикшерү механизмы итеп кабул итәргә тәкъдим итә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, кызыксынучы ведомстволарның һәм оешмаларның вазыйфаи затларыннан 2017 елда Татарстан Республикасында балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча еллык докладта бирелгән

төп тәкъдимнәрне һәм рекомендацияләрне үтәү буенча мөстәкыйль һәм ихтыярый тәкъдимнәр һәм гамәлләр көтеп кала.

2017 ел Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы Указы белән расланган Балалар мәнфәгатьләрендәге гамәлләрнең илкүләм стратегиясе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендәге гамәлләрнең республика стратегиясе турында» 2013 елның 1 февралендәге 90 номерлы карары белән расланган 2013-2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендәге гамәлләрнең республика стратегиясе гамәлгә ашырыла торган соңгы ел булды. Бу стратегияләрнең төп максатлары һәм бурычлары үтәлде. Бүген республикада балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен билгели торган чираттагы программачыл документны эшләү мөһим санала, ул Татарстан Республикасында Балалык унъеллыгының башлангычы булып танылырга тиеш.

Татарстан Республикасында
Бала хокуклары буенча
вәкаләтле вәкил Г.Л. Удачина

2018 ел, март